# казан утлары

10

ОКТЯБРЬ - 1973

Эрот Зарипов


# ТУГАН АВЫЛЫМ

**циклыннан линогравюралар**



Өй арасында.

**Яшь рәссам Эрот Зарипов туган як күренешләрен, авылдашларының портретларын яратып яза. Журналыбызның 10—11 саннарында без аның «Туган авылым» дигән циклыннан берничә линогравюрасын урнаштырабыз.**



Авылдашым.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

10

ОКТЯБРЬ
1973

## Бу санда

Ә. БАЯНОВ. Һәйкәл. Драматик повесть . . . . . 3
Ш. МАННУР. Агымсуларга карап. Повесть . . . 21
Н. АРСЛАНОВ. Әйтәсем килә. Шигырьләр . . . 71
Ю. ӘМИНЕВ. Сәләх бабай мәхәббәте. Хикәя . . . 81
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Кыска шигырьләр . . . . . . . 91
Г. ЛАТЫЙП. Безнең яклар. Шигырьләр . . . . . 96
Р. МИҢНУЛЛИН. Әллүки. Шигырьләр . . . . . . 102

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

А. МИНҺАҖЕВА. Мин гашыйк сиңа, Казан. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 104

Т. ЮЛДЫБАЕВА. Болытларга башым салып. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 107

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 109
Г. КАШШАФ. Диләрә ханым . . . . . . . . . 111

РИЗА ИШМОРАТКА 70 ЯШЬ

Һ. МӘХМҮДОВ. Заман белән бергә . . . . . . . 128
Р. ИШМОРАТ. Сараш авылында . . . . . . . . 134

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Матурлыкка бай ул безнең заман. 148
Р. БАТУЛЛИН. Гүзәл сәнгать белән очрашу . . . 161

ХАЛЫК ИҖАТЫ

М. МӘҺДИЕВ. Әйдә барыйк, кызлар карыйк . . . 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

И. КАДЫЙРОВ. Халык моңнарына һәйкәл . . . . 176
В. НУРУЛЛИН. Барыбыз өчен дә кирәкле китап . 179
Н. ГАМБӘРОВ. Тәлгәшләрдә сусыл җимешләр . . . 181

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. ГАЛИЕВ. Хәерле юл. Шигырьләр . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 190

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

---

Производствога бирелде 4/VII-1973 ел. Басарга кул куелды 27/VIII-1973 ел. ПФ 07125. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83246 экз. Заказ Я-353. Бәясе 50 тиен.

---

ТАССР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19. 1973 ел.

Әхсән Баянов

# һӘЙКӘЛ

ДРАМАТИК ПОВЕСТЬ

Сахраларга чыксам,
Елгаларда, диңгез өсләрендә чайкалсам,
Кемне булса яратсам я яратмасам,
Сагынсам я нәфрәтләнсәм,
Үләннәрнең, агачларның чыңлап кыяк һәм яфрак чыгаруларын күрсәм я ишетсәм,—
Бер-берсенә үрелә-үрелә үсеп,—
Тирәмдә күптән таныш көйләр бөтереләләр.
Моңлы көйләр, тынгысыз көйләр, дәгъвалы тавышлар.
Уйлар, хатирәләр, хыяллар.
Аларны мин шушы көнгә чаклы туктата һәм җиңә алмадым.
Хәзер беләм:
Мәңге инде җиңәлмам.
Көннәр арты көннәр...
Әкрен-әкрен, тавышлар, чыңнар — силуэт һәм сыннарга әвереләләр дә —
Күрәм, каршымда
Ят бер сәер дөнья ачыла.
Тереләр дә, үлгәннәр дә, исәнләшеп, миңа кул сузалар.
Юк, ят тормыш түгел икән, кайчандыр үзем туган өйгә кергәндәй, алга узам.
Бөтен нәрсә таныш бу җирдә.
Кырык ел күрешмәгән әтием белән исәнләшәм.
Елмая да каядыр югала.
Әниемә эндәшәм.
Хәзер дә исәнгәме, ул сөйләшә.
Аларның танышлары, замандашлары телгә килә.
Инде күрәм,
Вакыт дигән илаһи кодрәтне җиңә-җиңә, торатаишлар, миңа буйсынып, мин теләгәнчә атлап китә.
Могҗиза!
Кара, мин кешеләрнең төсләрен, исемнәрен, хәтта яшьләрен үзгәртә алам!
Вакыт чикләрен рәхәтләнеп узып йөрер өчен аларныкын гына түгел, үземнең дә исемем-яшемне үзгәртеп куям.
Хакимгә әйләнәм.

Тик беркемнең җанына, кылган эшенә кагылмыйм:
Һәркем монда бөтен нәрсәне үзенчә тоя.
Кемдер курай уйный...
Шундый моңлы!
Күз алдымда — дөнья.
Бу дөньяга мин көйләр, тавышларның сүзгә әверелә
торган чикләре буйлап килдем — Агыйделдән Базы елгасына
кергән шикелле.
Күз алдымда — гомерем буе тынмый яңгыраган рапсодия...

## ӘТКӘМ, КИҢӘШ БИР...

*Яшел таулары, урманнары, болыннары, вак-вак күлләре, тегермәннәре, тирән ярлары белән бергә гасырлар буйлап ага Базы елгасы.*

*Аны бер генә кабат күрсәң дә гомер буе сагынырга мөмкин.*

*Мин аны инде ничә кабат сагынып кайтканмындыр — саны юк моның.*

*Ләкин бу юлы башка хисләр, бөтенләй башка уйлар белән килдем — киңәшергә килдем, сөйләшергә.*

Шушы суда калган аның гомере,
Мәңгелеккә кушылып су белән,
Үлемсезлек тапкан минем атам.
Яз җиттеме, упкын төбеннән
Ул чыгарга тырышып тиберчена
Әйләнә дә язгы суларга;
Агызып китә буа, күперләрне...
Ә җәй җитсә, үкенеп шуңарга,
Кала тып-тын.
Әткәм!
Кайттым тагын,
Су телендә, әйдә, эндәш бер.
Кирәк сүзең, акылың — киңәш бир!

*Чишмә чылтыравы, акчарлаклар, чөлдиләр тавышы ишетелә. Баласын җуйгандай, тәкәрлек моңая.*

Бу тавышлар синең сүзләр бугай,
Хәл сорыйсың, беләм, син, әткәм.
Кабат кичерүләр авыр миңа,
Ә шулай да сөйләп күрсәтәм,
Тыңла минем ниләр күргәнне.
...Бер авылдаш безнең: зур галим —
Исеме аның, даны ил гизә.
Киңәшләре белән юл аралап,
Алып керде фәнгә мине дә.
Син беләсең аны, ул — Юламан.
Мин аңарда кунак.
Бакчасында ялгыз уйланам.
Кинәт күрәм күктән иңгән сыман,
Нәкъ фәрештә сыман бер чибәр
Пәйда булды. Ул Лениза.
Һични вәгъдә итмәсә дә сүзләр,
Серләр ачар кебек бу күзләр.
Янып тора кырыс чибәрлек,
Сүз әйталмый телем тибрәнеп.

Л е н и з а. Фирудин, шатлан, яхшы хәбәр алып килдем.

М и н. Карлыгач үзенең канатларында язны алып килгән кебекме?

Л е н и з а. Ихтимал.

М и н. Зинһар утырыгыз.

Л е н и з а. Карлыгачлар килә май аенда.

М и н. Яз белән бергә, алар яшеннәр, күк күкрәүләре дә алып килә.

Л е н и з а. Бәлки мин дә шулай... Сак булыгыз.

М и н. Ни булса шул, әйтегез, нинди хәбәр?

Л е н и з а. Сез үз авылыгыз хакында китап язасыз икән.

М и н. Әйе. Кем өчендер бу да яңалыктыр. Ә сез аны каян беләсез?

Л е н и з а. Күктән аваз килде. Шул аваздан сихерләнеп, үзем шәһәр кешесе булсам да, авылга гашыйк булдым, сезнең авылга.

М и н. Ә кешеләренә?

Л е н и з а. Кешеләренә дә.

М и н. Мин шул авыл кешесе.

Л е н и з а. Минем өчен андагы бөтен нәрсә изге.

М и н. Тагын әйтәм, мин шул авылныкы.

Л е н и з а. Һәр шаяртуның начинкасы — дөреслек.

М и н. Мин чын сүз әйтергә дә биш куллап әзермен.

Л е н и з а. Алайса, әйтегез әле: сез яза торган геройларны минем һәйкәл теленә күчерәсем килсә, сез моңа ничек карар идегез?

М и н. Шулаймыни! Миңа ничек! Әйбәт, мин шат.

Л е н и з а. Аннары нәрсә әйтер идегез?

М и н. Аннары... Аннары сезнең күңелне безнең авылның нәрсә белән мавыктырганын белергә теләр идем.

Л е н и з а. Сезнең авыл моңарчы бер әкияттә дә кабатланмаган, поэмаларда җырланмаган яңа романтика почмагы сыман тоела миңа. Аның кызыклы тарихы, геройлары бар. Гомумән, ачылмаган бер дөнья. Ә без, сезнең белән, Робинзон шикелле...

М и н. Ләкин анда безне кыргыйлар көтми.

Л е н и з а. Ә ачышлар көтә.

М и н. Ачышлар, җиңүләр, ихтимал — җиңелүләр.

Л е н и з а. Юк, юк, только җиңелү түгел.

Күк йөзендә яшен белән,
Көрәшләрдә ал кан белән
Язарбыз геройлар исемен —
Ерак еллар укылыр.
Герой, геройлар!
Сезнең сүз, сезнең васыятьне
Мәңге-мәңге
Җырга тиңләп җир тыңлар.
Даныгызны яфрак сөйләр,
Исемегезне язар җилләр,
Хәреф тезәр дулкыннар —
Ерак еллар укырлар.
Геройлар, геройлар!
Сезнең сүз, сезнең васыятьне
Мәңге-мәңге
Җырга тиңләп җир тыңлар.

Ах, геройлар, геройлар! Сезнең заманга барып кайтасы иде. Шаулы заман, изге заман, бөек заман.

М и н. Заман шаулы булган, тик гел геройлардан гына торма-

ган. Хәзер герой булып йөргәннәрнең дә кайберләренең кабыкларын чак кына кырсаң, аннан бөтенләй бүтән адәм килеп чыга.

**Лениза.** Минем алай кырып, ваклап, кисәкләп карыйсым килми. Бөтен заман — бөек бер һәйкәл. Изге нәрсәне тикшермиләр, аңа ышаналар гына.

**Мин.** Ныклап тикшерә башласаң, ходай юкка чыга.

**Лениза.** Сез нәрсәдәндер шикләнәсез.

**Мин.** Әйтегез әле, сезгә безнең авыл хәлләре турында кем сөйләде?

**Лениза.** Шул заман геройларының берсе. Ул шундый шәп истәлекләр сөйли!

*Сүзебезне Юламан кереп бүлдерде.*

**Юламан.** Комачауламадыммы?

**Лениза.** Юк, юк! Киресенчә, бик кирәк чакта кердегез.

**Юламан.** Әллә сез эш хакында ук сөйләшә башладыгыз инде?

**Лениза.** Түзми күңел.

**Юламан.** Бераз гына сабыр итик. *(Өстәлгә җиләк-җимешләр куя.)* Барысы да үзебезнең бакчадан. Рәхим итегез. Менә виноград. Татарстан җирендә виноград! Кызык бит?

**Лениза.** Кызык! Матур символ: тормышта да, табигатьтә дә, фәндә дә — үзгәртүче... көрәшче. Җиңү бәхете — өстәлдә. Кая без татып карыйк әле. *(Виноград каба һәм йөзе сытыла.)* Һым... Әйтмәс идем мин... Әйбәт, ярый. Яңалык башта ук татлы булмаска мөмкин. Главное — үскән бит әле. Беренче тапкыр, беренче!

**Юламан.** Дөрес. Мин үземчә үстереп күрсәттем, хәзер аны камилләштерү — сезнең бурыч, яшьләр бурычы. Рәхим ит, Фирудин.

**Мин.** Ә мин куактан өзеп караган идем инде. Рәхмәт.

**Юламан.** Фирудинның кәефе бик шәптән түгел, дияр идем мин.

**Лениза.** Минемчә, сезнең икәүдән-икәү генә сөйләшеп җавап табасы сорауларыгыз бар. Рөхсәт итсәгез, мин розалар тирәсеннән әйләним әле.

**Мин.** Туплар шавын тыңлауга караганда, розалар исен сулау күңеллерәк. Шулай.

**Лениза.** Эшләрегез артиллериягә үк барып җитмәс дип ышанам. *(Китә.)*

Уңайсыз тынлык.

**Юламан** *(креслога җайлап утырган).* Мин сезне шатландыра алам, Фирудин.

**Мин.** Безнең авыл темасын әйтәсездер инде. Президиумда карап, планга керткәнсездер.

**Юламан.** Әйе, үзем тәкъдим иттем. Кызыклы тема: авылда революция.

**Мин.** Мин аны башладым да инде.

**Юламан.** Алай ашыгырга ярамый. Катлаулы һәм, әйтергә кирәк, шактый буталчык вакыйгалар. Аларга бер генә кеше тикшереп төпле бәя бирә алмаячак.

**Мин.** Ул темага сезнең катнашуыгыз уңайсыз булыр шикелле. Үзегезгә үзегез бәя бирү килеп чыга бит.

**Юламан.** Без синең белән авылдашлар, материал икебезнеке дә. Өстәвенә, без күптәнге соавторлар. Минемчә, гаҗәпләнерлек хәл тумас.

**Мин.** Әйе, безнең фамилияләр күп китапларда бергә тора. Менә

болар да. *(Өстәлдәге китапларны кулга алам.)* Сезнең фамилия алдан йөри.

Юламан. Моңарчы гел үзегез үтенә идегез.

Мин. Хәзер оят. Сезнең атаклы фамилиягә ияреп, җиңелрәк яшәү юлын эзләгәнмен.

Юламан. Бу юлы мин үзем генә алынмакчы идем дә.

Мин. Үзегез генә? Мин тәкъдим иткән темагамы?

Юламан. Гражданнар сугышы — безнең чор. Миңа күбрәк аңлашыла. Ләкин сине дә рәнҗетәсе килми. Шулай дөресрәк тә булыр. Кемдер әйткән, сәнгать — ул мин, фән — ул без.

Мин. Минем андагы вакыйгаларга бәя бирүем икенчерәк.

Юламан. Фәндә бәхәссез булмый, тора-бара килешсәк, бик шәп булыр.

Мин. Ә килешә алмасак?

Юламан. Дөреслек өчен фәндә кайбер хисләрне корбан итәргә дә туры килә. Шунысын онытмасагыз, калганы хәл ителер.

Мин. Нинди хис? Атага тугрылык хисеме?

Юламан. Син алгы планга үз әтиеңне чыгармакчы буласың. Куелачак монументның да шундый булуын телисең. Ленизага да үз әтиеңне ясарга тәкъдим иткәнсеңдер. Шулай бит?

Мин. Һәйкәл куярлык кеше түгелме минем атам?

Юламан. Куярлык. Ләкин үзе генә түгел иде ул, күбәү идек без.

Мин. Юламан агай, мин бит бөтен нәрсәне беләм, ишетәсезме, ул чакта булган бөтен хәлләрне.

Юламан. Кеше сүзе буенча. Ә мин үзем шулар эчендә кайнаган кеше. Хәзер онытылып беткәч, кем нәрсә сөйләмәс! Аннары, үз атаң. Юк, син объектив була алмаячаксың. Темага миннән башка тотынырга киңәш бирмәс идем. Бу сүзне директор буларак әйтүем.

Мин. Сезнең бу темага кагылырга хакыгыз юк. Чөнки минем атамны...

Юламан. Мин аңа тырнак белән дә чиертмәдем. Минем бөтен гаеп — аны яклый алмауда. Анысы да бала чак гаебе. Моны син гафу да иттең, ялгышмасам.

Мин. Сез миңа авыр чакта институтка керергә булыштыгыз, аспирантурага тәкъдим иттегез. Кайчандыр булган хәл өчен хәзер үч алу кыргыйлык булыр иде. Ләкин сез дөреслекне бутап калдырырга, атама һәм кайбер бүтән кешеләргә хыянәт итәргә әтәрмәкче буласыз икән, гафу итегез...

Юламан. Син мине гафу иттең!

Мин. Ләкин бит әти бар. Ул гафу итәргә тиеш. Үзе!

Юламан. Балалык юләрлеген ул чал чәчле кешедән түләтер иде дисеңме?

Мин. Әйтә алмыйм, үзеннән сорагыз.

Юламан. Үлгән кешедән. Ничек итеп?

Мин. Белмим. Ләкин сорагыз, шунсыз ярамый.

Юламан. Моның өчен аны терелтергә кирәк.

Мин. Ул терeләчәк.

Юламан. Лениза шуңа алынамы? Ул бөтенләй киресенчә уйлый иде бит?

Мин. Аңлагач килешер. Аңламаса, бүтәннәр табылыр. Ничек булса да, теләсә нинди хәлдә дә сез кайтуга минем атам авыл түрендә басып торыр. Атам сүзен бары тик шунда гына ишетерсез.

Юламан. Син — коточкыч сәер кеше!

Мин. Чөнки сезнең ул чактагы эшегез коточкыч. Сез анда — авылда инде онытканнар дип уйлыйсызмы? Үзегез хакында минем белән бергә китап язып, анда шулай бүтән кешегә әйләнеп кайтмак-

чы буласызмы? Ялгышуыгызны хәтта сез үзегез дә сизеп торасыз. Югыйсә, киткәннән бирле, утыз елдан бирле бер генә кабат булса да кайтып карар идегез. Куркасыз, дөрес әшлисез.

Ю л а м а н. Моңарчы мин үзем кайтырга теләмәдем.

М и н. Инде белгән, күргән кешеләр үлеп бетте, сүз әйтмәсләр дисезме? Барыгыз, кайтып карагыз.

Ю л а м а н. Күпме тырышлыкларым, ярдәмнәрем өчен ничек итеп әйтте ул рәхмәтне! Менә ничек!

М и н. Юк, сезне ачуландырмыйм дип, үз атама үзем хыянәт итә алмыйм. Аны талаган кебек итеп, күрәләтә, тереләтә, үземне талата алмыйм — сезнең өчен хәзер китап яза алмыйм, гафу итәсез.

Ю л а м а н. Синеңчә, мин — разбойник, кеше талаучы, кеше хезмәтен үзләштерүче. Кара, нинди шәп сүзләр!

М и н. Сез хаклы. Ләкин бүгеннән соң алай булмаячак.

Ю л а м а н *(озак тынлыктан соң)*. Минем сезгә билгеләнгән вакытым бетте.

М и н. Ярый, мин китәм.

*Безнең сүзне Лениза тыңлап торган, ахрысы — нәкъ кирәк урында каршыма килеп басты.*

Л е н и з а. Юк, китмисез. Болай ярамый, сез килешергә тиеш: дөреслек хакына, эш хакына. Изге эш хакына.

Ю л а м а н. Аның өчен изге нәрсә юк. Ул бер генә нәрсәне белә: аңа ничек булса да үз атасын герой итеп шаулатырга кирәк.

М и н. Әйе, безнең бәхәс катгый. Сүз аталарыбызга бәя бирү турында бара. Кемнәрне без герой дип кабул итсәк, шуларча яшәргә дә тиеш булабыз.

Л е н и з а. Берни аңламыйм.

М и н. Чын художник моны аңларга тиеш.

Ю л а м а н. Ул гына башлы, ул гына белә. Нинди молодец, каян табылган! Ләкин боларны исбат итәргә туры киләчәк, исбат итәргә!

М и н. Әйе, сүз сезнең кем булуыгыз хакында да бара, Юламан абый, урталыкта яшәүчеләр, яраклашучылар хакында. Андыйларга нинди көч, кайсы як җиңсә дә барыбер. Тир һәм кан түкмичә генә, качып ятып, соңыннан җиңгән якка кушылып, әзер капиталь һәм мораль байлыклар эләктерергә, дан яуларга тырышучылар элек тә булган, хәзер дә бар.

Л е н и з а. Юламан абый шундый кешеме? Юк, ул чын кеше, чын герой. Мин сезгә ышанмыйм, это ужасно! Мөмкин түгел, мөмкин түгел! Мин менә шул чал чәчләргә ышанам.

М и н. Әгәр чал чәчләр алдаса?

Л е н и з а. Алдаса? О, дөньяда аннан да коточкыч җинаять буламыни! Юк, мин аңа ышанам, мөмкин түгел, мөмкин түгел!

М и н. Алайса, мин сезне үзебезнең авылга кунакка чакырам.

Ю л а м а н. Шушы сүзләрдән соң икебезнең бер институтта калуыбыз ихтимал дип уйлыйсыңмы?

М и н. Кемнәрдер белән килешү өчен дөреслекне, тарихны үзгәртим дисәң, шул чорга кайтып яңадан яшәргә кирәк. Бүген кемнәрдер үзләрен герой итеп тасвирларга һәм шул кыяфәттә тарихка теркәлергә маташалар икән, моннан берни дә чыкмаячак. Аларга һәйкәл куймаячаклар — беркайчан һәм мәңге!

*Шул сүзләрне әйттем дә киттем. Озакламый институт белән дә хушлашырга туры килде. Анысын сөйләп тормыйм — үзе бер тарих. Ләкин эштән тукталмадым. Хәзер башта бер генә уй: исбат итәргә. Әле исбат ителмәгәнмени? Кемнәрдер өчен шулай. Шулай... Язганнарымны тикшерү, ялгыш булса дөресләү өчен тагын авылыма, туган ягыма кайтып төштем — менә шушында.*

Әтием! Моңарчы Юламан Ардашировны бары минем белән генә көрәшә дип йөргән идем, юк, алай түгел, ул миннән бигрәк синең белән көрәшә икән. Ни өчен? Ник? Ә мин нишләргә тиеш? Әтием? Мин синнән шуны сорарга кайттым.

Авылдан авылга күчеп йөргән хәбәр чын түгел, ахрысы... Ниндидер вакытта шушы дәрья төбеннән минем әтием кычкыра диләр... Ничәмә-ничә еллар инде! Әллә чын, әллә легенда... Ләкин мин моңа ышанам. Легендага ышанам. Синнән сүз көтәм.

*Елга буйлап, урман буйлап атлыйм... Күңелдә әллә нинди уйлар тирбәлә.*

Ак каеннар минем уйны сөйләп,
Минем моңны көйләп утыра.
Ак каеннар сөйли бүгенгене,
Узган еллар талган йокыга.
Саз буйларын буйлап төш елгага,
Карт тегермән анда тын тора.
Кәвесләргә күптән тулмый сулар,
Күңелләргә бары моң тула.
Сулар шавын тутырып кочагыма,
Битләремне куям җилләргә.
Бер елыйсы килә, бер җырлыйсы
Әткәм-әнкәм сөйгән көйләргә.
Әй, заманнар, кушылыгыз бергә.
Кемнәр үлгән, кайтсын өенә.
Иркәләнеп әткәм-яшьтәшемә,
Асылыныйм аның иңенә.
Вакыт та тар кешегә, киңлекләр дә —
Чикләрен тик акыл, уй вата.
Ара түгел, чорлар гизсәң икән
Галәм дигән киңлек буйлата.
Заманнарга нигә кирәк чикләр,
Йөрсәң икән чикләр бүлмичә.
Теләкләргә сүзсез җавап булып,
Узганнардан бугай җил исә...

*Алтыпочмаклы бүрәнә өй. Түргә узам — өйдә беркем дә юк. Борынгы сәгать йөрешен тыңлап, уйга калам. Сәгать кичке җидене суга...*

*Караңгы төшә...*
*Кемдер асылмалы лампага ут кабыза.*
*Өйдә — үткән заман.*

Сылубикә. Арсланның тагын кайтмавы микән инде? Озак сәфәрләрдә йөреп күзне күгәрткәне җитмәгән, кайткач та кулга тими башлады.

Мәгъдәния. Ир кеше өйгә кайтмый башласа, хатын гаепле буладыр...

Сылубикә. Мин гаепле. Шулай диген. Авызыңны ачыбрак әйт.

Мәгъдәния. Синең урында булсам, мин дә тынычсызланыр идем. Уен эш түгел: хатынын күрәсе килеп ир кеше тәүлек буе бер тапкыр кайтмасын да...

Сылубикә. Син минем ирем хакында авыз чайкама. Ичмасам, сүз чәйнәгәнче, чүбек чәйнә: ал конҗәлә, җеп җегерлә.

Мәгъдәния. Ялчың итмәкче буласыңмы? Хәзер революция!

Сылубикә. Рибалитсә эшсез утырырга кушамы? Кеннәр бу шушылай бөкшәеп, үзеңне-үзең кочаклап утырырга кушамы?

Мәгъдәния. Кочаклар кеше булмагач, нишлим инде. Си ирең була торып та бит әнә...

Сылубикә. Тимә минем иремә! Тимә! Шәһәр ялкавы!

Мәгъдәния. Кайтмый бит ирең. Тәки кайтмый.

Сылубикә. Синең аркада... Сине күрәсе килми. Шуңа күр дә кайтмый.

Мәгъдәния. Күрәсе килмәсә, Уфа тикле җирдән Минзәл өязенә хәтле алып кайтмаган булыр иде.

Сылубикә. Уфа тикле җирдән! Кала читендә, кышкы сал кында уштан язып, үләргә яткан җиреңнән коткарып калган би ул сине. Үз толыбына син юньсезне төреп алып кайткан.

Мәгъдәния. Начар кеше булсам, ямьсез булсам, әйләнеп та карамаган булыр иде.

Сылубикә. «Матур, ямьсез...». Ул сине кызганып, җәлләп үлмәсен дип... Йомшак күңелле шул минем Арсланым, йомшак.

Мәгъдәния. Шулай шул.

Сылубикә. Сине буржуйларың әнә кем кызы дип тормаганнар, үзеңне хәлдән тайдырганчы, үләр чиккә җиткәнче җырлаткан-биеткәннәр дә шәһәр читенә ыргытканнар.

Мәгъдәния. Мин алардан үзем качтым, кызыллар ягына. Чыгып кына җиталмадым, авыруым басты.

Сылубикә. Арслан коткармаса...

Мәгъдәния. Коткармаса да ярыйсы икән, дөньясыннан котылыр идем.

Сылубикә. Ит яхшылык, көт явызлык.

Мәгъдәния. Буржуйлардан котылдым, хәзер коммунист ялчысы.

Сылубикә. Мескен, бигрәк каты эшлисең шул!

Мәгъдәния. Эшләсәм, эшләтер идегез, оялмас идегез, революция дип тә тормас идегез.

Сылубикә. Ике бидрә су гына да алып кайталмыйча, дүмгәккә абынып егылган башы белән, сөйләнә бит. Телне ходай биргән — бытбылдык!

Мәгъдәния. Бытбылдык түгел, сайрар кош, илләр гизәсе кош, читлектә ябылып ятам.

Сылубикә. Дүрт ягың кыйбла: бар оч, олак!

Мәгъдәния. Син кемне куасың? Ни хакың бар?

Сылубикә. Үз өемнән куарга нишләп хакым булмасын?

Мәгъдәния. Син нәрсә, өй салдыңмы?

Сылубикә. Ирем салды, үз ирем.

Мәгъдәния. Үз ирем, имеш. Синекеме, минекеме — билгеле түгел әле!

Сылубикә. Ничек? Нәрсә дисең?

Мәгъдәния. Ирең ник кайтмый, алайса?

Сылубикә. Синең анда эшең булмасын.

Мәгъдәния. Булсын! Ул синеке генә түгел, хәзер революция — барысы да уртак! Уртак!

Сылубикә. Җир бит!

Мәгъдәния. Ул мине ярата, сине түгел. Күзләреннән, бөтен торышыннан сизәм.

Сылубикә. Себерке! Сине кем яратсын!

Мәгъдәния. Ирләр шундыйларны ярата, өй тавыкларын түгел.

Сылубикә. Бар чыгып кит, нигеземне пычратма. *(Ишекне киереп ача.)* Бу сиңа фәхешханә түгел, шанситкалар кирәкми, бар, эзең калмасын.

М ә г ъ д ә н и я. Чыкмыйм.

С ы л у б и к ә. Чык! Үзең дә хәсис, сүзең дә. Пычратма дөньямны. Бар! Себерке! Бар, шанситка.

М ә г ъ д ә н и я. Синең үзең түгел. Ирецнеке. Бәлки әле мин монда калырмын, хозяйка булып. Бәлки әле сине куып чыгарырбыз Арслан белән икәү!

С ы л у б и к ә. Өемдә җылан җылыткач ни аны! Бар, олак, теләсәң кая! *(Чәчләреннән эләктереп ала, ишеккә таба тарта.)*

М ә г ъ д ә н и я. Үтерәләр! Коткарыгыз! Караул! Үтерәләр!

*Караңгыдан күтәрелеп мин аларга якынлашам, туктатырга тырышам. Ә алар ишетмиләр, бар дип тә белмиләр.*

М и н. Сезгә ни булды, ник сугышасыз? *(Хатыннар эндәшми.)* Сезгә ни җитми? Нәрсә бүлешәсез? *(Хатыннар һәйкәл төсле хәрәкәтсез кала.)* Сез мине ишетмисез! Сез шул гасыр башында, ә мин — уртасында. Арада озак еллар, шуңа ишетмисез. Мин сезгә ярдәм итә алмыйм, киңәш тә бирә алмыйм, тик кызганам гына. Мескеннәр! Кайда минем әтием! Юк, ул юк. *(Тагын тынып калам.)*

*Сылубикә белән Мәгъдәния яңадан тарткалаша башлауга атам кайтып керә.*

А р с л а н. Бу ни дигән сүз? Монысы нишләвегез?

С ы л у б и к ә. Әнә, шанситкаңнан сора!

А р с л а н. Сылубикә!

С ы л у б и к ә. Симерде, ир кирәк була башлады, сине үзенеке итмәкче, мине куып чыгармакчы.

М ә г ъ д ә н и я. Кирәк булса куарбыз да, шулай бит, Арслан?

С ы л у б и к ә. Шулай булмыйни? Шул гына калды. Әшәке!

М ә г ъ д ә н и я. Сиңа гына димәгән, мин дә синең кебек үк хокуклы, революция тигезләде.

С ы л у б и к ә. Бар, бар, буржуйларың янына.

М ә г ъ д ә н и я. Миңа коммунист та ярый.

А р с л а н *(каты җикереп)*. Җиттеме сезгә, юкмы?

*Тынып калалар. Сылубикә сәкегә табак белән аш китереп куя. Мәгъдәния кечкенә тәлинкә белән уҗау китерә.*

С ы л у б и к ә *(Мәгъдәниядән уҗауны тартып алып)*. Үз ризыгыңны куярсың, үз күкрәк көчең катнашкан ризыкны.

А р с л а н. Сылубикә.

*Арслан ашаганда хатыннар икесе-ике яктан аңа карап торалар.*

С ы л у б и к ә. Тагын салыйммы?

А р с л а н. Җитеп торыр.

С ы л у б и к ә. Итеннән авыз ит... Юлга да пешердем. Ипи дә суынгандыр.

А р с л а н. Капчыкка салырсың. Мин кайтканчы.

С ы л у б и к ә. Тагын чыгып китәсеңмени инде? Бөтенләй кулдан ычкындың син.

А р с л а н. Ярый, соңыннан. *(Пауза.)* Мәгъдәния, киен!

С ы л у б и к ә. Бу ни дигән эш тагын?

М ә г ъ д ә н и я. Китәбезме бу өйдән? Икәүме? Кая?

А р с л а н *(Мәгъдәниягә)*. Синең өчен өй белештем: шунда торырсың.

М ә г ъ д ә н и я. Кем белән?

Арслан. Берүзеңә бер әй.
Мәгъдәния. Берүземә бер әй? Мин анда нишлим берүзем?
Арслан. Үзең теләгәнчә яшә, иркенләп.
Мәгъдәния. Миңа монда җылырак.
Сылубикә. Кунак кызы. Өйрәнеп җитте. Бар, үз өеңне үзең җылыт. Утынын үзең кис, үзең як.
Мәгъдәния. Минем утын кисәсем килми.
Арслан. Сиңа бүтәнчә бу өйдә калырга ярамый, начар сүзләр йөри башлады.
Мәгъдәния. Нинди сүз син куркырлык?
Арслан. Революция ясап йөргән кеше, үзе ялчы тота, диләр.
Сылубикә. Шәп ялчы!
Мәгъдәния. Үзеңне бел!
Арслан. Киен! Үзем илтеп куям. Ну!

*Мәгъдәния теләр-теләмәс киенә. Сүзсез генә чыгып китәләр. Сылубикә, бусагага килеп, Мәгъдәния басып узган җирләрне себерә.*

Сылубикә. Я аллам, өемә бүтән аяк бастырма пычрак бәндәләрне, рәнҗетмә бусагамны! *(Өй артында кемнәрнеңдер сөйләшкәнен ишетеп.)* Болары кемнәр икән инде тагы?

Өйгә Заһит керә.

Заһит. Товарищ Арслан өйдәме?
Сылубикә. Арслан сиңа ниткән товарищ булсын. Синең иш булырлык нинди малың, нинди туарың булсын?
Заһит. Ул да коммунист, мин дә.
Сылубикә. Шул кадәр әйттем, адәм актыгы кеше белән бер партиядә булма дип. Гарьләнеп үләрсең.
Заһит. Мин адәм актыгы? Мин кемнән ким? Кемнән?
Сылубикә. Шундый да шарлатан, шундый да ялганчы, шундый да хөрәсән...
Заһит. Абыстай! Керпе дә керпе, син дә керпе бит.
Сылубикә. Товарына күрә бәясе, үпкәләмә.
Заһит. Син үзеңне кем дип беләсең? Сез дә әллә кем түгел, ике атыбыз дип масайма, берсе егылып үлсә, берәү генә кала.
Сылубикә. Ә синең үләсе дә юк. Савар сыерың гына да үзеңнеке түгел бит — Юламан энең калдырып киткән сыер. Шуңа күрә дә энеләрең кубызына биеп яшисең.
Заһит. Атым юк урамда, кайгым юк буранда. Пырлитар. Безнең заман хәзер! Безнеке! Пырлитарлар җиңә!
Сылубикә. Бөтен пырлитар синең кебек булса, алла сакласын инде. Минем Арсланым әйтә: пырлитарлар, ди, ил-көннең, ди, иң алдынгы төркеме, ди, акыллы этрәде, ди.
Заһит. Дөрес әйтә. Арслан күбрәк белә шул, укыган кеше. Синең кебек тавык баш түгел.
Сылубикә. Мулла буласы кеше иде дә бит. Куярга шул хәтле кыстадылар, ризалашмады. Үзем үгетләдем, сүземне колагына да элмәде.
Заһит. Мелкий буржуаз син, абыстай. Мир җыелышына куеп аерттырам мин сине, коммунист белән торырга хакың юк.
Сылубикә. Бә-бә-бә! Синең белән сөйләшеп торган мин җүләр.

З а һ и т. Мин дә бик сагынып йөрмим. Эш төшкәнгә күрә кердем. Кайда Арслан?

С ы л у б и к ә. Эшсез йөрмәс, эше бардыр.

З а һ и т. Мин дә тәк йөрмим.

Нидер сөйләнә-сөйләнә, Ю л а м а н белән Г о б ә й керә.

Ю л а м а н. Әссәләмагейләкүм.

Г о б ә й. Исән-саулармысыз.

С ы л у б и к ә. Бик исән, бик саубыз. Бәй, Юламан энем, син түгелме соң бу?

Ю л а м а н. Мин шул, Сылубикә җиңгәчәй, мин.

С ы л у б и к ә. Кайчан кайттың, рәхмәт төшкере, күпкәме дигәндәй.

Ю л а м а н. Бераз торылыр әле, шактый озак торылыр.

С ы л у б и к ә. Сезнең кебек кала мәдрәсәсе бетергән галим кешегә салада ямь дә, тәм дә юктыр ул. Картәтәгез юлыннан китеп, мулла булсагыз инде. Хәзрәтебез күптән түгел вафат булды, керчәле шуның урынына. Арсланга шул кадәр әйттем, еландай телләремне чыгарып ялындым — юк, сүземне колагына да элмәде. Мулласыз яшибез.

Ю л а м а н. Юк әле, җиңгәчәй, мин беркем дә булмыйм әле — дөнья тынычлангач карарбыз.

З а һ и т. Мулла белән этне сатып аласы юк, җиңгәчәй, табылыр, кайгырма.

С ы л у б и к ә. Мин инде болай, сүздән генә. Әйдәгез, утырып торыгыз.

Г о б ә й. Арслан абый кайда соң?

С ы л у б и к ә. Хәзер кайта абыегыз, көтә төшегез.

Г о б ә й. Бик үк ерак китмәгән, алайса?

С ы л у б и к ә. Теге себеркене олактырырга.

Ю л а м а н. Шансонетканымы? Кая?

С ы л у б и к ә. Теге кемнәр өенә... Берүзен бер өйгә.

Ю л а м а н. Дөрес эшли Арслан абый, бик дөрес.

Г о б ә й. Кайда, җиңгәчәй, бер йомры белән бер кисәк суган бир инде, алайса.

С ы л у б и к ә. Ниткән суган ди ул. Хәзер чәй китерәм, самаварым куелган *(өй алдына чыга).*

Г о б ә й. Арсланны әйтәм, риза булырмы икән?

Ю л а м а н. Һич тә әйтә алмыйм.

З а һ и т. Күнмәсә, бүтән җай табарбыз.

Ю л а м а н. Ничек?

З а һ и т. Уйлагыз, сез бит грамотный кешеләр.

Г о б ә й. Шансонетка аша дисеңме?

З а һ и т. Ярамый дисезме?

Ю л а м а н. Башта үзе белән сөйләшергә кирәк. Риза булмаса, әлбәттә, карарбыз.

С ы л у б и к ә. Арслан үзе дә кайтып килә. Бергә-бергә күңелле булыр.

Г о б ә й. Менә, ичмасам, җиңги. Ә дигәнче самаварын да китереп утыртты.

З а һ и т. Безнең җиңгинең теле ачы булса да, сые тәмле инде аның.

Ю л а м а н. У! Арслан абый! Әйдүк, түргә уз, үз өеңә кергән төсле кер, тартынмыйча.

А р с л а н. Юламан! Кайчан кайттың?

Ю л а м а н. Кичә генә, Арслан абый.

С ы л у б и к ә. Мактап кына йөриләр икән, чәй алдыннан килеп керделәр.
А р с л а н. Ярый, әйбәт.
Г о б ә й. Безнең чәй алдыбыз да бар иде бит, Арслан абый, рөхсәт итсәң.
А р с л а н. Рөхсәт дип, нинди рөхсәт кирәк аңа, урланган әйбер түгел, үз көчебез.

Урамда җыр ишетелә:

Ак үрдәккә, күк үрдәккә
Җимнәр салдым дүмгәккә.
Эчем җана, тышым җана,
Әл дә капмый күлмәккә.

С ы л у б и к ә. Гомәр эчеп алгандыр.
Ю л а м а н. Әмма да, егетләр, хәзер шундый заман ки, һич тә җырлап йөрисе килми.
А р с л а н. Җырлап кына йөрерлек булмаса да, заман әйбәткә бара.
З а һ и т. Кайда, Гобәй, чыгар инде тизрәк.
Г о б ә й. Чыгарасы юк аны, ул монда гына *(куен кесәсеннән аракы чыгарып, йомрыга коя).* Беренче йомры — хуҗага.
З а һ и т. Әллә син агу салгансың... башта үзең эч.
А р с л а н. Куй әле пүчтәк сүзне. *(Аракыны ала.)* Без киткәч имин яшәгез. *(Эчә.)* Шәп. Кайтуыңны әйтәм. Сиңа эш табып бирергә кирәк бит инде. Кая чамалыйсың?
Ю л а м а н. Әйтеп булмый шул әле. Алыш җен туе шикелле: әле берсе өскә чыга, әле икенчесе. Дөньяның кая барып чыгасын һич белерлек түгел, һич тәртип юк.
А р с л а н. Тәртип дип, ни. Менә шуны урнаштырырга кирәк тә инде.
Ю л а м а н. Кем урнаштырсын аны?
А р с л а н. Кем дип. Менә син, мин, без.
Ю л а м а н. Ярый, син монда урнаштырдың, ди. Ә башка җирләрдә? Мин бит губернадан. Мин ул биеклектән күбрәк күрдем бугай.
А р с л а н. Алайса, турысын гына әйт: син безгә ярдәм итәргә кайттыңмы, киреге сукаларгамы? Болай гына йөрергә тиеш түгел, син бит губисполком кешесе.
Ю л а м а н. Әйе, соңгы вакытта мин анда депутат булдым.
А р с л а н. Кайсы партиядән?
Ю л а м а н *(ишетмәгәнгә салышып).* Хәзер калада Колчак. Исполком таркалды.
А р с л а н. Таркалмады, күчте. Ә син качтың.
Ю л а м а н. Нинди сүз ул качтың? Мин просто киттем — вакытлыча крестьян булып яшәргә. Синең кебек үк.
А р с л а н. Мине монда өяз исполкомы тәкъдим итте, халык сайлады. Дезертир булып кайтмадым.
Ю л а м а н. Нәрсә, Арслан агай, син мине дезертир димәкче буласыңмы?
А р с л а н. Карарбыз, тикшерербез.
Г о б ә й. Сүз кыекка китте, туганнар. Без бит, Арслан агай, монда сине туган итеп килдек, совет башлыгы булганың өчен түгел. *(Аракы сала.)* Монысы, Юламан, сиңа.
Ю л а м а н *(аракыны эчәр алдыннан).* Без бик җитди хәлләр хакында сөйләшә башладык. *(Сылубикәгә карый.)*
А р с л а н. Безнең монда сүз бар иде, Сылубикә.

Сылубикә. Тагын берәр патша төшерәсезме? Ярый, төшерегез. *(Чыга.)*

Заһит. Аллага шөкер, патшалар бетте.

Юламан. Мин яхшы ният белән, синең иртәгә чыгасы юлыңның хәтәр икәнен исеңә төшермәкче идем.

Арслан. Анысын үзем дә беләм, юл авыр. Ничә мең сум акча сакларга кирәк. Ничә мең сум акчага ашлык сатып алырга кирәк — алданмаска. Ул ашлыкны илтеп үзебезнекеләргә исән-аман тапшырырга кирәк. Юлда бандитлар да юк түгел.

Юламан. Менә шул шул. Ә синең эшме соң бу, саилчы кебек икмәк җыеп йөрү совет председателе эшеме? Кем куша, нәрсә мәҗбүр итә?

Арслан. Кем? *(Йөрәген күрсәтә.)* Менә бу, вөҗдан. Шул куша.

Юламан. Нәрсә ди?

Арслан. Ул миңа әйтә: Совет дәүләтен дошманнар бокрасы буып тора — Уфа, Себер ягында Колчак чыелдый, Тула ягыннан Деникин улавы ишетелә, Петроградка таба Юденич үрмәли. Ә тылда, шуыша-шуыша, ачлык, ялангачлык, тиф дигән, тагын да яманрак өрәкләр аларга кул чаба. *(Кулын тагын йөрәгенә куеп.)* Үзенең бөтен көчен җыеп, Ленин сүзләре белән, дөньяның бүгенге иң ачы сүзләрен кычкыра, Совет дәүләтен саклап калыгыз, социалистик Ватан куркыныч астында, ди. Менә ул миңа нәрсә, ди. Ә син ул тавышны ишетмисеңмени?

Юламан. Ә мин әйтәм, ашлык ташу, олау артыннан юргалау синең бурыч түгел, аның үз кешеләре булырга тиеш дим. Бу эшнең үз оешмасы — Көнчыгыш фронтның махсус продкомиссиясе бар, дим.

Арслан. Алайса, мәгълүм булсын, бездәге продкомиссарны бандитлар үтерде. Аның урынына бүтән кешеләр куеп карадык, алары да һәлак булды.

Гобәй. Хәзер башында мие булган кеше шул юлга чыгамыни инде?

Арслан. Заһит белән без, мисез кешеләр.

Заһит. Әйе шул, өч тапкыр өч караван ашлык илттек инде, өчесендә дә исән калдык, аллага шөкер.

Юламан. Дүренче кабат та исән калырбыз дип ышанасызмы?

Арслан. Анысын әйтә алмыйбыз, әмма Совет дәүләтенең исән калачагына шигебез юк.

Юламан. Валлаһи, бу бөтенләй ычкынган икән. Табигатьнең үзен саклау законыннан да колак каккан.

Гобәй. Анысы ниткән закон тагы?

Юламан. Сүз өчен, фикер өчен үлемгә бармаска куша бу закон. Ике Алып сугышып, берсен-берсе һәлак итә икән, итә бирсен, дөнья синңа кала, син акыллырак бул, ди бу закон.

Арслан. Акыллы! Өченче юл тапкан. Ә Ленин әйтә, өченче юл юк, ди. Димәк, син дошман ягында.

Юламан. Мин буржуймы сиңа? Мә, ат, алайса.

Арслан. Сыйнфый дошманнар беткәч, сезгә дә җитәр чират.

Юламан. Гобәй, ишеттеңме, ул безгә яный.

Заһит. Сезнең эш хәтәргә китте. Мин сыпыртыйм әле моннан.

Юламан. Үзең кара, Заһит.

Заһит. Әллә ниләр сөйләшәсез. Аңлап та булмый сезне. Үзегез карагыз инде. *(Китә.)*

Гобәй. Син безгә юкка күсәк күтәрәсең, Арслан агай, без синең файдага әйтәбез. Үзеңне дә, кулыңдагы байлыкны да әрәм итмәү нияте белән.

Юламан. Без моны туганлык бурычыбыз дип санадык.

А р с л а н. Мин сезнең бу изге ниятегезне дә сизенәм, әлбәттә.
Ю л а м а н. Шәп. Алайса, тизрәк килешүебез ихтимал.
Г о б ә й. Я, ничек карыйсың?
А р с л а н. Минем кулдагы байлык — дәүләтнеке.
Г о б ә й. Ашлыкны башта сез бит акча түләмичә генә җыйдыгыз. Шуны илтеп тапшыргач кына хөкүмәт акча бирде ләбаса.
Ю л а м а н. Ул акчаларны сез, ашлык алган кешеләргә түләргә тиеш тапсагыз да, алай эшләмичә, яңадан ашлык сатып алып, яңадан илткәнсез.
А р с л а н. Халык һәм ячейка ризалыгы белән.
Ю л а м а н. Дөрес. Совет дәүләтен ныгыту өчен. Анысы шулай.
Г о б ә й. Менә бит, җайсыз килеп чыкты бит әле, ячейка сине үлемгә җибәрә.
Ю л а м а н. Син, Гобәйдулла, арттырып җибәрмә, ячейкага тел тидермә.
А р с л а н. Әйдәгез, турысын әйтеп бирегез: тел төбегездә ни ята?
Ю л а м а н. Аңлыйсың бит инде!
Г о б ә й. Без өч кенә кеше... Минемчә, артык ваклап җибәрергә ярамас.
Ю л а м а н. Заһитны өлешсез калдыру килешмәс.
А р с л а н. Артык баеп китсәгез, помещиклар байлыгын конфисковать иткән кебек сезнекен дә бит...
Г о б ә й. Күпме икәнен кем белә? Кычкырып йөрергә дигәнмени.
Ю л а м а н. Сатулашма инде, Арслан агай, ярар инде.
Г о б ә й. Гомерлек бәхетеңнән баш тартмакчы буласыңмы әллә!
А р с л а н. Гомерлек бәхетемнән? Юк, баш тартмыйм.
Ю л а м а н. Ризамы син?
Г о б ә й. Әйткән идем аны, Арслан үз кеше, аңлар дип.
А р с л а н. Мин аңладым сезне.
Ю л а м а н. Молодец!
Г о б ә й. Рәхмәт, Арслан, яшә! Әйдәгез, бүлешәбез. Кайда акчалар?
А р с л а н. Мин шуны аңладым: сез — казнокрадлар!
Ю л а м а н. Нәрсә?
Г о б ә й. Арслан, шаяртма. Шаяра торган эш түгел.
А р с л а н. Казна караклары! Чыгып сызыгыз хәзер моннан, яхшы чакта. Югыйсә...
Г о б ә й. Нәрсә, югыйсә?
А р с л а н. Рәтен табарбыз.
Ю л а м а н. Янама, Арслан агай, янау егетлек түгел.
А р с л а н. Янамыйм, кисәтәм.
Г о б ә й. Кисәтмә дә!

Ишек ачыла. Аннан Г о м ә р керә.

Г о м ә р. Кара син боларны, ә! Күршеләреннән качып, эчеп утыралар! *(Әйдәгеләр аңа сүз кушмагач.)* Сез курыкмагыз, минем үземнеке дә әле, менә! *(Кесәсеннән эчелеп бетмәгән аракы чыгара.)* Сезнең белән утырасы килеп кенә керүем. Авылда сездән дә рәтле кеше юк бит инде безнең. Яратам мин сезне, чукынмышлар. Яле, Арслан, эчеп җибәр әле минем исәнлеккә. *(Аракыны салып бирә.)*
А р с л а н. Бик вакытлы кердең, Гомәр, рәхмәт. *(Эчә.)*
Ю л а м а н *(урыныннан кузгалып)*. Я, туганнар, сүз беттеме безнең?
А р с л а н. Бетте.

Г о б ә й. Килештекме?
А р с л а н. Килешмәдек.
Ю л а м а н. Арслан, соңыннан безгә үпкәләмә, кара.
Г о б ә й. Терсәгеңне тешли алмассың.
Г о м ә р. Куегыз әле хатыннар кебек әрепләшүегезне. Җыен дус очрашканда матур итеп утырыйк. *(Аракы салып Юламанга бирә.)* Әйдә, авылдаш, минем исәнлеккә.
Ю л а м а н. Яшә, Гомәр. *(Эчә.)*
Г о м ә р. Яшәячәкбез, алла бирсә. *(Җырлый.)*

Ак үрдәккә, күк үрдәккә...

Ю л а м а н. Синең һаман бер җыр, Гомәр.
Г о м ә р. Мин теләсә кем җырын җырламыйм, Гомәр диләр мине, үз җырым бар минем. Арсланның да үз җыры. Җәле, Арслан.
Ю л а м а н. Чынлап та, Арслан. Шәп җырлыйсың бит син.
Г о б ә й. Әйдә, Арслан.
А р с л а н *(уел көенә).*

Әрәмәгә керсәм, уләң сирәк,
Сахраларга чыксам, җир җиләк.
Эчемдә генә минем утлар яна,
Ник җилкенә икән бу йөрәк.

Г о б ә й. Арсланның нәкъ үзе турында бу җыр.
Г о м ә р. Мишәйт итмә, туган.
А р с л а н.

Арслан да киек һич кайгырмас,
Каршысында биек тау булса.
Егет тә кеше һич кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса.

Г о б ә й. Башны сакларга кирәк сиңа, Арслан, сакларга.
Г о м ә р. Я, Гобәй дус, син дә күрсәт һөнәреңне.
Г о б ә й. Мин җырлый белмим шул.
Г о м ә р. Син, Юламан?
Ю л а м а н. Җырлаганым юк, үзең беләсең.
Г о м ә р. Әйтәм бит, үзегезнең җырыгыз юк сезнең. Теләсә кемнекен җырлап йөрисез.
А р с л а н. Безнең җырлар аерыла башлады әле, Гомәр, дөрес әйтәсең.
Г о б ә й. Үзең гаепле.
Ю л а м а н. Безнең бөтенебезгә бер уртак җыр бик кирәк, югыйсә. *(Ишек кагалар.)* Кем бар анда?
Г о м ә р. Минем җырны җырлагыз әле, адәм буласыгыз килсә.
А р с л а н *(ишеккә таба атлый).* Кемдер бар, мин ишек ачыйм инде. *(Чыга.)*
Г о м ә р *(җырлый).*

Ак үрдәккә, күк үрдәккә
Җимнәр салдым дүмгәккә.
Эчем яна, тышым яна...

Г о б ә й *(ишектән кергән Заһитны күреп).* Моның да эш уңмады, ахрысы.
З а һ и т. Нигкән уңмай ди ул. Бик уңды минем эш. Сәфәр чыгарга бөтенесе әзер минем — арбалар дегетле, атлар тышаулы.
Ю л а м а н. Алайса, ярты йомры аракы сиңа да әрәм түгел. Бирчәле салып, Гобәй.



Әхсән Баянов ◆ Ленин

Г о б ә й *(аракы салып).* Я, ничек?

З а һ и т *(Юламан белән Гобәй янына килеп, ярым пышылдый).* Мәгъдәния риза!

Г о б ә й. Аның шулай буласы көн кебек ачык иде.

Г о м ә р. Нәрсә, Заһит, Мәгъдәнияне хатынлыкка алмакчы буласыңмы?

Г о б ә й. Әйе, начар кыз түгел бит?

Г о м ә р. Начар түгел, бөтен дөньядагы барлык ирләр өчен яхшы кыз. Әйдә, Заһит! Булдыргансың...

Ак үрдәккә, кук үрдәккә...

Ю л а м а н. Ташлыйсыңмы шул үрдәгеңне, юкмы?

Г о м ә р *(кереп килүче Арсланга).* Карале, син кем, Арслан, Заһит хатын ала бит, син ялчыңнан колак кагасың икән.

А р с л а н. Нинди ялчы?

Ю л а м а н. Я, яшермә инде, монда чит кеше юк — туганнарың, дусларың.

Г о б ә й. Бөтен авыл белә инде бу хакта.

З а һ и т. Бүгеннән башлап Мәгъдәния бу өйдә тормый. Арслан — маладис, хатасын төзәтте.

Г о м ә р. Менә шул хатынны Заһит үзенә караткан, риза ди.

А р с л а н. Риза? Мәгъдәнияме?

Г о б ә й. Нәрсә, Арслан, кәефең киттеме?

Ю л а м а н. Кешегә җитми, ә! *(Көлә.)*

Г о м ә р. Бәйләнмәгез әле рәтле кешегә. Арслан — безнең кебек җилкуар түгел ул.

*Ишек кагалар. Арслан чыга. Күренеш алышына — өй тирәсендә Мәгъдәния. Арслан аның янына килә.*

А р с л а н. Ни булды? Ник килдең?

М ә г ъ д ә н и я. Ул өйдә берүзем йоклый алмыйм, шундый караңгы, шундый куркыныч, бөтен авылга кычкырасы килә. Кычкыруын да кычкырып карадым: беркем ишетмәде, беркем килмәде.

А р с л а н. Килде ич, Заһит килде!

М ә г ъ д ә н и я. Син нәрсә, көнләшәсеңме?

А р с л а н. Ни сөйлисең син, Мәгъдәния?!

М ә г ъ д ә н и я. Әйдә, монда беркем юк, үзебездән үзебез курыкмыйк: мин сизенәм: син аз гына булса да мине яратасың бит.

А р с л а н. Мәгъдәния!

М ә г ъ д ә н и я. Бүгенге көнгә чаклы мин дә куркып йөрдем, мондый уйны күңелгә кертмәскә тырыштым.

А р с л а н. Безнең арада нинди уй булырга мөмкин?!

М ә г ъ д ә н и я. Башта мин дә үземне шуңа ышандырырга тырыштым. Хәзер ялгызлыкка түзә алмыйм.

А р с л а н. Син ялгыз булмаячаксың, сиңа кеше табылачак, менә дигән егетләр...

М ә г ъ д ә н и я. Миңа бернинди егет кирәкми.

А р с л а н. Тик Заһит түгел.

М ә г ъ д ә н и я *(куркып).* Заһит? Син нәрсә беләсең?

А р с л а н. Беләм, син аңа кияүгә чыгарга ризалык биргәнсең.

М ә г ъ д ә н и я *(җиңел сулап).* Ә! Юк, ризалык дип белгәннәр. Үзең уйлап кара, шул ни акыллы, ни җүләрне ничек ярата алыйм.

А р с л а н. Бүтәннәре булыр, сабыр ит.

М ә г ъ д ә н и я. Миңа алар кирәкми.

А р с л а н. Ә кем кирәк?

М ә г ъ д ә н и я. Син!

Арслан *(бераз аптырап торгач).* Мин сине акыллырак дип уйлаган идем, Мәгъдәния.

Мәгъдәния. Син куч минем өйгә.

Арслан *(тавышын әкренәйтеп).* Син... мине кем дип беләсең? Кем дип беләсең син мине?

Мәгъдәния. Син — Арслан, Сылубикә ире. Син мине үз хатыныңа караганда артыграк яратасың. Сизми дип йөрмә.

Арслан. Ә мин сизмим.

Мәгъдәния. Сизәсең, үзеңнән яшерергә генә тырышасың. Ә хатын-кыз анысын да сизә. Мин дә, Сылубикә дә... Юкка көнли дисеңме аны? Мине өйдән кучерүегез дә шуның аркасында түгелме? Мин барысын аңлыйм. Җүләргә исәпләмәгез.

Арслан. Нинди хатын син! Шайтан токымыннандыр... Беренче тапкыр күрәм мондый хатынны...

Мәгъдәния. Күчәсеңме минем өйгә?

Арслан. Юк, күчмим.

Мәгъдәния. Син күчәргә тиеш, без кавышырга тиеш. Мәхәббәт җиңәргә тиеш барлык җайсыз гадәтләрне.

Арслан. Безнең арада мәхәббәт булмаячак.

Мәгъдәния. Ул бар инде, син аны җиңә алмаячак. Безгә аңлашырга кирәк, барыбер.

Арслан. Андый аңлашу синең өчен һәлакәт булыр иде.

Мәгъдәния. Янып торган учакка төнен килеп кунган күбәләк сыман, мин шуңа да риза, безнең кавышу шундый булса да мин риза. Янарга! Риза! *(Тынлык.)* Ә син куркасың! Куркасың!

Арслан. Куркам һәм кызганам.

Мәгъдәния *(елап).* Алайса, син мине кайдан алып кайттың, шунда илтеп куй.

Арслан. Монысын да эшли алмыйм. Күрәләтә һәлакәткә илтә алмыйм.

Мәгъдәния. Мин бит монда да, болай да яши алмыйм. Ичмасам, синең алда үлмәм...

Арслан. Син үлмәскә тиеш.

Мәгъдәния. Мине хәзер бер генә нәрсә коткара ала — синең мәхәббәтең!

Арслан. Мәхәббәтне мин вәгъдә итә алмыйм.

Мәгъдәния. Чынлапмы!

Арслан. Чынлап.

Мәгъдәния. Шәфкатьсез! Үтерүче! Син мине үтерәчәксең! Һәлак итәчәксең! Теләсәң кая куй мине, теләсәң кая, мә, үтер, хәзер үк!

Арслан. Нинди гаҗәп кешеләр була икән!

Мәгъдәния. Алып кит мине, илтеп куй! Яңадан! Теләсәң кая! *(Үкси.)*

Арслан *(тынлык).* Ярый, тынычлан, алып китәрмен!

Мәгъдәния. Син бик нык үкенәчәксең әле, Арслан.

Арслан. Китәргә дә теләмисең! Ни эшләмәкче буласың?

Мәгъдәния *(озак сүзсез торганнан соң).* Үкенерсең, мин булмам.

Арслан. Ә хәзер бар, өеңә. Таң аткач килерсең.

Мәгъдәния. Хуш! *(Китә.)*

Арслан тәмәке төрә, күтәрмәгә утырып тарта башлый. Өйдән Юламан, Гобәй, Заһит, Гомәр чыгалар. Шактый кызмачалар.

Юламан. Ярый, Арслан, ачуланма инде.

Заһит. Арслан ачулана торган кеше түгел!

Гобәй. Ну син, Арслан, бик нык ялгышасың!

Юламан. Бәлки әле яңадан уйларсың.
Арслан. Минә монысын көтмәгез.
Гомәр. Ташлагыз әле сүз көрәштерүне. Сүзегезнең атасы-анасы юк.
Арслан. Иртәгә — юлга.
Гомәр. Үзегезгә эш табып, хәсрәт тудырып йөрисез дә инде. Менә минем кебек яшәргә кирәк.
Гобәй. Сиңа — диңгез тубыктан.
Гомәр. Әйе шул. Диңгездә дә батмый торган кеше мин.

Ак үрдәккә, күк үрдәккә...

Заһит. Без синең белән сознательный кешеләр. Шулай бит, Арслан?
Гомәр. Синме сознательный? Тфу!
Юламан. Хуш, Арслан, ялгышма.
Гобәй. Үкенерлек булмасын.
Заһит. Иртән үзем уятырмын.
Арслан. Соңга калма.

*Кунаклар киткәч, атам тагын тәмәке төреп кабыза, тагы утыра, тагы тора. Мин аның янына киләм...*

Арслан. Сарык исе килгәч, бүреләр нишләргә белми сикерешкән кебек... Алтын исе борыннарны кытыклыймы? Түзә алмагач, мине таларга җыенасызмы? *(Кесәсеннән пистолет чыгарып карый.)* Мин әзер, зинһар!

*Әтәч тавышлары ишетелә. Еракта җыр килә.*

Ак үрдәккә, күк үрдәккә
Җимнәр салдым думгәккә.
Эчем яна, тышым яна,
Әл дә капмый күлмәккә.

Арслан. Аңа беркем дә янамый. Нишләп мин аның төсле була алмыйм икән? Аныңча яши алмыйм... Юк, мин барыбер үземчә бәхетле. *(Өйдә сәгать уникене суга.)*
Ә мин тыңлыйм вакыт авазын. Әти, ишетәсеңме, сәгать суга? Бу — синең язмыш... Син ишет аны, сакла үзеңне, сакла!

*Атам тораташ булып торды да чак кына тагын кузгалды — кулын күкрәгенә куйды.*

Мин моны шулай аңладым: язмыш кешенең үзендә, язмыш — йөрәктә. Йөрәктән аерылып булмый. Син миңа да шундый йөрәк калдырып киткәнсең, әткәм... Ә син тап юлын, тап. Исән кал! Син шул кадәр кирәк безгә, шул кадәр!
Юк, әткәм, син мине ишетмәдең, тәмәке төпчеген ташладың да үз заманыңа кереп киттең...

*Дәвамы бар.*

Шәйхи Маннур

# АГЫМСУЛАРГА КАРАП

ПОВЕСТЬ



Яңгырлар туктап, аяк асты кипшергәч, безнең янга авыл кешеләре килә башлады. Алар ат-арба җигеп, азык-төлек, курмы төяп, шахта сугу эшенә килә, сәкенең бер ягы тулып узды хәзер. Шахта стволын [1] төшү яңадан башланып китте, алар өч сминә булып шунда эшли. Ишегалдындагы безнең учак янында тагын бер зур учак яна башлады. Анда Фрося исемле кыз, таганга ике чиләк асып, аш пешерә. Ул юантык симез гәүдәле, салынкы түшле, боек күңелле һәм шактый әкрен кыймылдаучан бер кыз иде. Усаллыгы да юк, хәтта юаш холыклы, кемдер тарафыннан җәберләнгән сыман мескен кыяфәтле һәм эчендә нин-дидер сагышы бар төсле күренә ул. Шулай күңеле үсмәгәнгә үзенең шактый ук ыктыматсыз йөргүен дә сизми иде бугай.

Үзе шундый гына күренсә дә, бу боек кызның авызыннан җыр өзел-ми. Учак ягамы, бәрәңге әрчиме, ит юамы, бөтен эшен гел җырлап эшли, күңел түре гел җыр белән, моң белән тулгандыр шикелле — авыл көенә туктаусыз агылып кына тора. Без көн саен аның белән бер-гәләп аш пешерәбез. Көн саен мин аны рәхәтләнеп тыңлыйм, хәтта рус көйләренең тәменә, моңына да төшенә башладым шикелле хәзер. Та-вышы да әйбәт кенә, йомшак кына чыга аның. Башкалар төсле әче тавыш белән чәрелдәп кычкырмый ул. Кайчакта, җырлый торгач, мы-шык-мышык кына балавыз сыгып та алгалый үзе. Белмим, миннән тартынамы, озакка сузмый, тагын җырга керешә. Күпме җырласа да, көн саен кабатланмыйча калмый торган ике җыры бар аның:

---

Дәвамы. Башы 8, 9 саннарда.

[1] Стволын — коесын.

«С неба звездочка упала
На сарайчик сеновой,
Вся любовь наша пропала
И платочек носовой...»

Бу жырга мин тора-бара бөтенләй гашыйк булдым. Печән сарае түбәсенә күктән атылган йолдыз да, шул йолдыздай кинәт югалган мәхәббәт тә, шул мәхәббәт белән бергә югалган (бүләк) кулъяулыгы да шундый матур булып тоела, әз генә сагышлы да, әз генә елмаюлы да булып яңгырый иде...

Ә минә икенче жырының соңгы яртысы гына хәтердә сакланган, баштагы сүзләре нигәдер онытылган. Фрося бу жырның ахырын бик моңаеп кына жырлаганда минем үлеп көләсе килә. Ник дисәң, болай дип жырлый ул.

«...Кабы я не тосковала,
Не худая бы была...»

Гәүдәсенә карыйм да кычкырып көлүдән көчкә тыелып калам. «И бичаракаем, нишләп ябык буласың ди, ике кыз юанлыгы бар ич син!» дим эчемнән генә. Көн саен ишеткәч, күңел тик тормый, мин аны үзебезчәгә әйләндереп кабатлый башладым:

«Сагынмасам-саргаймасам,
Болай ябыкмас идем...»

Шулай да без аның белән көннәрдән бер көнне сөйләшеп киттек.

— Как тебя зовут,— дип соравыннан башланды. Мин авыз тутырып: «Шайхулислам» дигән идем, ул аны әйтә алмыйча аптырады да:

— А, ладно, будешь — Шурка! — диде. Каршы килмәдем, шуннан соң Шуркага әйләнеп киттем.

Әз-мәз сөйләшә торгач, аның чыннан да хәсрәтле кыз икәне беленде. Аңлый алган хәтлесенчә, болай булган: ике ел элек, уракка төшәр алдыннан гына, үзенең яратып йөргән Гришкасына кияүгә чыккан бу. Ай да торып өлгермәгәннәр, сугыш башланган. Гришканы беренче наборда ук алып киткәннәр. Ә моннан ике ай элек кенә похоронный килгән. Шуннан бирле Фрося кара кайгыда яши икән.

— Свет не мил...— ди ул. Аталарына иярәп монда килүе дә шул авыр хәсрәтен кая куярга белмәүдән, имеш...

Билгеле, мин ул чакта сугышның шундый үзәк өзгеч якларын, үз өебездән китүче булмагач, яхшылап аңлый алмый идем әле. «Минем дә әни үлде» дип, Фросяны үземчә юатырга тырыштым, кызганыч булып китте, көлүне дә ташладым, күңел аңа таба тартылды...

Озакламый минем яңа танышлар да булды.

Бер көнне, төштән соң булса кирәк, баскыч төбендә чабата ясап утыра идем, каршыдагы бураның ишек тишегендә өч кызчык пәйда булды. Киселмәгән аркылы бүрәнәгә түшләре белән ятып, минем нишләгәнне карап тора башладылар, аннары нидер пышылдашып, чырык-чырык көлгән булдылар. Ниткән чыпчыклар соң бу? Берәр нәрсә эшләп пыркытасы иде үзләрен, йөрмәсеннәр иде монда ачу китереп.

— Чево ты делаешь, малайка? — дип сорады берсе.

— Я не малайка! — дидем мин төксе генә. Белмим, нилектәндер, үлеп яратмыйм «малайка» диючеләрне. «Лайка», «полай-ка!» дип мыскыл итәләр шикелле.

Тынып калды болар, көлмәделәр. Байтак шулай торганнан соң:

— Алайса, исемеңне әйт,— диде олысы. «Әйтимме-юкмы?» дигәндәй дәшми тордым да:

— Шурка! — дидем тамак төбе белән генә.

Ул көнне безнең сүзләр ябышмады. Кызлар тагын ни әйтергә белмәгәндәй терәлеп тордылар-тордылар да урманга таба китеп бардылар. Иртәгесен төштән соң тагын күренде болар. Берни булмагандай ачык йөз белән эндәштеләр:

— Здорово, Шура!

Минем дә кичәге ачу мендәр астында калган иде бугай:

— Зрасти! — дип җавап бирдем. Аннары уртанчысы үз кулындагы ямь-яшел нарат ботагын миңа сузды. Нәрсәгә икәнен белмичә, алыралмас аптырап тора идем:

— А ты попробуй вот эту шишечку,— дип, ап-ак булып йомрыланган нарат күркәсенә күрсәтте. Мин аңлап бетермәдем: нарат күркәсен кем ашый? Тагын көлмәкче буласызмы дигәндәй, кырын күз белән ботакны кире кактым.

— Юк, син ашап кара, ашап кара! — дип, өчесе дә ялына башлады һәм үзләре дә берәр күркә өзеп каптылар. Шуннан мин дә бик сәерсенеп, җилкәне куырып кына, бер яшь күркәне өзеп каптым. Баллы икән! Әз генә сагыз тәме бар, шулай да ашамаслык түгел.

Ясый торган чабатаны өйгә кертеп ташладым да алар белән китеп бардым. Олысының исеме Наташа икән. Анысы ап-ак битле, сыек сары чәчле, гәүдәгә солы буедай гына миннән калкурак, яшькә дә шул чама булыр. Уртанчысы белән кечесе бөтенләй аңа охшамаган: карасу йөзле, малайларныкыча кырыкмыш чәчләре дә, каш-керфекләре дә карасоры, күзләре дә шундый ук бугай. Уртанчысы түгәрәк битле, бәләкәе озынча ябык чырайлы, үзе дә чыра гына. Күргән саен аптырап калырлык: өчесе өч ана баласы төсле алар. Уртанчысы Лида, төпчеге Люда исемле иде бугай, тик мин аларны гел бутап эндәшә идем. Шәһәрдә укыйлар икән, җәйге каникулга кайтканнар.

Үзебезнең тирәдәрәк кенә җәелеп үсә торган наратлар янына алып киллдем мин аларны. Берсенең биелгы ап-ак күркәсе бигрәк күп, бик тәмледер шикелле салынып торалар. Сикереп карыйбыз — ботакларга буй җитми. Шуннан мин табан астын, уч төбен тәкерекләдем дә, бик егетләнеп, наратка менә башладым. Беренче коры ботак төбен әләктерсәм, эш хутка китәсе китүен, тик ул шактый югары шул. Нарат кәүсәсен нихәтле шытырдатып кочаклап, тезләрне бик каты кысып өскә үрмәләргә тырышсам да, аска сыдырылып төшәм. Бер төштем, ике төштем. «Ла-а-дно, Шура, не на-адо»,— ди тегеләр. «Ладно» түгел шул, шәпләнеп тотынгач, менәлми калсаң, бетте башың аннары!

Өченче тапкырында, бик җан-фәрманга тырмаша торгач, бер кул белән тәки теге ботакка ябыштым бит! Шактый өскә күтәрелдем дә иң эре, иң симез күркәле ботакларны гына сындырып, тегеләргә ташлый башладым.

— Хватит, хватит, Шура! — диләр астан.

— Ашагыз, ашагыз теләгән хәтле! — дип кычкырам агач башыннан.— Киракса, бөтен наратын ботап бирәм!..

Төшүе кыен булмады. Дәрәҗә үскәнне сизеп, әз генә борынны да чөйдем бугай. Тик сагызга катып беткән күлмәк-ыштан өчен әти «арт сабак»ны бик суганлап-борычлап укыткач кына төште ул борын.

Икенче көнне мин ул кызларны каен әкәе белән сыйладым. Миңа аны ашарга Югары Тәкәнештә үк өйрәткәннәр иде. Каенның тулган кузактай эре булып, чук-чук асылынып торган ямь-яшел сусыл әкәен чәйнәп суырудан да татлы бернәрсә юктыр. Яз көне каен суы эчкән тәмнәр тула авызга. Кызларның исе китте, «ах, ах!» диделәр. Моңарчы шуны да белмәгәннәр икән!

Шулай аралаша торгач, без дуслашып киттек. Бу яшеллек дөньясындагы кош-кортларга, үлән төбенә сыенган кәлтәләргә, үрмәкүч, кырмыскаларга, ничәмә-ничә төстәге бөҗәкләргә исебез китеп йөрийөри туйгач, теге бәләкәй күл читендәге комлыкка килеп утырабыз.

Үзебезгә калса — сүзләребез һич бетә торган түгел. Мин урысча пупаларга һаман шомара барам. Бик күп җан ияләренең, үләннәрнең, агачларның урысча исемнәрен белеп алдым мин болардан. Ә бер көнне уртанчы кыз сорый миннән:

— А ты читать умеешь? — ди.

— Умею,— мин әйтәм,— три клас кончил!

— По-русски? — дип сорый бу.

Татарча икәнен әйткәч, урысча укый белмәвемә бик гаҗәпләнеп куйды. Шуннан бер чыбык алды да, ком өстенә ике кырын сызык сызды, шулар арасына тагын бер аркылы сызык төшерде.

— Нәрсә бу? — дип сорады.

— Каян белим? — дидем ис китми генә.

— Это «А», буква «А»,— диде бәләкәе.

Сизми дә калдым, алар өчәүләшеп хәреф күрсәтешле уйный башладылар. Берсе яза, икенчесе сорый, ә мин белмим, өченчесе әйтеп бирә, аның артыннан мин кабатлыйм. Кат-кат әйттереп күңелгә сеңдерәләр дә үземнән яздырып карыйлар. Кайбер хәрефләрне тиз генә отып та, язып та булмый. Шулай да бу уен миңа да бик кызык булып китте. Көн саен маташа торгач, бөтен хәрефләрне диярлек аңлый башладым, кайбер кыска сүзләрне яза алам. Болай булгач, минем хәзер әдрис язарга өйрәнәсе килеп куйды. Авылга хат салганда Атиг пучтасында өчесенә унбиш тиен биреп яздыра безнекеләр. Бер көнне болар баскыч төбенә килгәч, Себердән кайткан дәфтәрне актарып алып чыктым да:

— Әдрис язып бирегез, мин күчереп язып, үзем өйрәнермен,— дидем.

Наташа, баскыч төбенә утырып, кәгазь-карандашны кулына тотты да әйтеп торырга кушты.

— Казански губирна, Мамадышски уязь, Кабыккүперски волос, деревня Тулбай,— дип тезеп киттем мин.

Лида белән Люда, башларын аска иеп, көлемсерәп утырган булдылар, мин шулай батыр әйткәнгәдер дип уйладым. Ә Наташа бер дә йөзен үзгәртмичә язып чыкты. Ул тегеләре шикелле шыркылдык түгел шул, иха-хайга бик бирелми, уйчан кыз...

Мактадым мактавын да, ул язганны күчерә башлагач, бөтенләй аптырап калдым. Хәрефләрне берәм-берәм укмаштырып укып та карыйм, һич дөрес язмаган! «Казанская губерния» килеп чыга. Өязне — уезд дип язган. «Уезд-поезд» дигән шикелле. Кабык-куперская волость» дигән. Һәй, кызкай, әллә кайда шәһәр җирләрендә укып йөргән була тагы! Иртәгесен, үзен тегеләре алдында кызартмакчы булып, дәфтәрне суздым да:

— Дөрес язмагансың, панимаеш! — дидем.— Дөрес түгел әдрис белән хат йөрми бит!

Наташа рәхәтләнеп көлеп җибәрде, тегеләре дә катышты.

— Эх, Шурик,— диде ул аннары,— син бит үзең дөрес әйтмәдең, русча алай сөйләшмиләр!..

Минем шундук борын салынды, түбән карадым, эндәшмим.

— Кирәкми, үпкәләмә син,— диде ул кичәге төсле җитди йөз белән.— Давай без сине дөрес сөйләшергә өйрәтәбез, ризамы?

Риза булмыйммы соң? Урысчаны урыс малайларының үзләреннән дә уздырып беләсе килә минем. Теге борынгы мәзәктәге солдат белгән шикелле «ипилек-тозлык» кына түгел, су күк эчәсе! Әммәдәки, бу урысча тел хәтле читен тел бар микән дөньяда? Безнең телгә чүт кенә дә охшамаган. «Топтать» дигән сүзләре генә татарча. Ә бүтән сүзләренең бик күбесе авызга сыймый, боргалап әйтә башласаң, телең сынардай була!..

Сөйләшү телемне шомартучы да, хәреф танытучы да, адрес язарга өйрәтүче дә, җәй буе бергә уйнаган яхшы иптәшләр дә — алар булды.
И Наташа, Лида, Люда! Исәннәрме сез? Урман арасыннан килеп чыккан якын дусларым, рәхмәт сезгә!



## «Гөмберт» уены

Сәп-сәер хәл: каян белгән? Ничек тапкан?
Без бит кеше эзләп табарлык җирдә түгел идек!
Көннәрдән бер көнне безнең янга «бармаксыз Тажи» абзый килеп чыкты. Мин аны Ерак күмердә чакта ук күргән идем, ул анда без киткәнче килеп унбиш-егерме көн эшләгән дә иде инде, күптәннән бирле читтә йөри торган кеше. Аның чыннан да бер кулының имән бармагы юк. Хәер, яртысы юк, нәкъ урта буыннан өзелгән. Баракташлар ул бармак турында болай сөйлиләр иде: Тажи абзыйның солдатка каралачы елны шахтада крепельшек булып эшләгән чагы икән. Шулай каптилка яктысында креп агачы юнып ятканда, «Аллага тапшырдык, чүтри кәмин — дүрт таш, күрсә күрсен безнең баш!» дигән дә, имән бармагын шул агач өстенә салып, су күк үткен балтасы белән урталай чапкан да өзгән, имеш. Читкә сикергән ярты бармагының тырпылдап ятуын күрү белән бик кызганыч булып киткән дә, шунда ташланган бу, тиз генә урынына ябыштырып, бәйләп куймакчы булган, янәсе. Ә ярты бармак күз алдында юкка чыккан, әллә пәри урлаган тагы! Сукыр яктыда күпме карманса да тапмаган. «Пәри, бир, бир, биш баланы буармын» — дип такмаклап эзли-эзли, забойга ук кереп киткән. «Кая, бармакны күрмәдегезме?» дип сорый икән, ә кулыннан шыбырдап кан ага, имеш. Забойдагы авылдашы, ни әйтергә белми аптырап, аннан-моннан бәйләү белән канын баскан да, клит төбенә илтеп, өскә күтәрткән моны.
Тажи абзый җавабын да алдан ук уйлап куйган, имеш: «Креп башына кыстырырга чөй юнганда ялгыш чабып җибәрдем бармакны», дигән. Авылдашы да чын дөреслек белән гуаһлык биргән: «Бармагын эзләп забойга менде, ярый әле, мин канын басып, клиткә озаттым», дигән. Эштә яраланган-имгәнгән кешегә акча чыга икән. Тажи абзый бармак ярасы төзәлгәч расчет алган да, олы бер кесә акча төяп, туган авылы Түбән Тәкәнешкә кайтып киткән... Билгеле инде, солдатка ярамаган...
Белмим, болай сөйләүләре бәлки уйдырма гынадыр, бәлки чынлап та ялгыш чабып өзгәндер, әмма ничек кенә булмасын, шуннан соң ана төрле кушамат тактаннар. «Таз Тажи», «Бармаксыз Тажи», «Алтын тырнак», «Чүтри кәмин» — бар да аныкы. Ул, югыйсә, таз түгел, аның башында бик матур кара чәч, үстеребрәк җибәрсә — бөдрәләнеп тә китәсе. Маңгае киң, биек: бик акыллы кешенеке шикелле. Озынча йөзе, елтыравык кара күзләре дә сөйкемле генә көлемсерәп тора. Юк, төсбиткә чибәр кеше ул. Шахта бае белән патша түрәләрен кәкре каенга шулай оста терәтү хәйләсен тапканга күрә генә «Таз» дип атаганнардыр аны. Ә инде «Чүтри кәмин» һәм бүтән шундый әйтемнәре — аның авызыннан атлаган саен коелып кына тора.
Менә шул Тажи абзый безнең янда хәзер. Ишектән керә-кергәндүк:
— Чүтри кәмин — дүрт таш, ниләр күрми безнең баш дигәндәй, тәки эзләп таптым бит үзегезне! — диде ул.
Чәй эчтек, сәкедән урын да күрсәттек. Әтиләр озак сөйләшеп утырдылар. Хәснулла абыйның исән-сау эшләп ятуын әйтте. Төхфәт абый тагын чыгымчылап киткән икән. Мәүләне Омски базарында кыйнап

үтергәннәр, имеш. Адресны Хөснулла абыйдан алган икән. Әгәр анда эше рәтсез булса, монда ничек-ничек килергә икәнен өйрәтеп язган идек. Тажи абзыйга шул бик яхшы маяк булып чыккан. Тик аны эшкә кая урнаштыру турында гына аптырап утырдылар. Безнекеләр шурфына берьюлы дүрт кеше төшеп эшләрлек түгел — тар, эше дә булмас, акчасы да төшмәс, имеш. Шахта сугучы авыл кешеләре ат-тун белән үзләре өч артил булып, өч сменада эшли, Тажи абзыйны араларына сыйдырырлармы — билгесез. Иртәгесен әти белән икәүләп управляющигә киттеләр. Ул аны кучер итеп алмакчы булган. «Хакын рәнҗетмәм, кыш башына хәтле эшләп тор, ул вакытка шахта сугылып бетәчәк, теләсәң забойга, теләсәң крепленигә керерсең», дигән. Шуннан Тажи абзый кучер булып китте, тимерхут башында кукраеп, пар атта гына йөри башлады. Тора-бара безнең яннан күчеп үк китте ул. Управляюши аңа үз йортыннан бер бүлмә сымак куыш биргән. «Атларны карау да синең өстә, төнлә китеп, төнлә кайтып кергән чаклар да еш була, шушында гына тор, кул астында булырсың, тамагың да шушында узар», дигән, имеш. Шулай итеп, Тажи абзыйны әллә нидә бер күрә башладык без...

Шул көннәрдә Атигдагы белешебез Ларион дәдәй дә Петькасын ияртеп безнең янга килеп чыкты. Кодалар килгәндәй шатланып каршыладык, шул ук вакытта гаҗәпләнеп тә куйдык: Ларион дәдәй заводта эшли иде, нишләп монда килде икән?

— Нет сырья, завод закрыли,— диде ул.

«Сырья» дигән сүзне беренче ишетүем иде, аңламадым. Ниндидер чи әйбер күз алдыма килде: «Ул заводка нинди чи нәрсә кирәк икән?» дип уйладым. Петька төшендерде: чәнечкеле чыбык ясарга тимер беткән, имеш. Монысы да гаҗәп тоелды: соң без чыгарабыз ич, нигә шуннан ясамыйлар икән? Петька да әйтә алмады. Күп заманнар узгач кына белдем: башта руданы кайнатып чуен коярга, чуеннан тимер-корыч коярга, аннары гына чыбык ясарга була икән...

Ларион дәдәй балта эшенә керде. Рудникка якын-тирәдән ат-тун белән килүчеләр һаман күбәя барып, безнең «алачык»ка сыймый башлагач, үрдән түбән юл буена тагын бер алачык эмәлләргә керешкәннәр иде. Ул такта баракны тиз җитештерделәр һәм балтачыларның күбесе, Петька белән Ларион дәдәй үзе дә, шунда күчте. Аннары балта осталары безнең каршыдагы олы баракка тотындылар. Безнекеләр дә тик ятмый. Көн саен эштән кайткач чыгып, яңа баракның аргы башындагы бәләкәй тау астына мунча урыны казый башладылар. Бер хәтле бүрәнә кисеп, каезлап та куйдылар, алар шунда мунча җиткерергә уйлыйлар. Дөрес тә шул, хәзер авылга барып юынабыз да бит, ә көзге-кышкы суыкта мунча керер өчен ничек алты чакрымга йөрмәк кирәк?

Петька белән миңа да бер «кызык» эш табылды. Тау астындагы иске шурф кырыена өелгән руданы шул ук шурфның икенче кырыена носилка белән ташый башладык һәм шундый ук итеп өя дә барабыз. Бу миңа бик сәер тоелды: комнан аркан ишкән сыман. Ни өчен кирәк булуын да аңламадык. Малайлар тик ятмасын дип, этиләр сорады микән, әллә управляюшигә шулай кирәк булды микән? Моның өчен безгә акча түлиләрме — юкмы, анысын да белмибез.

Әй ташыйбыз эссе кояшлы көндә тирләп-пешеп, әй эшлибез, ә безне килеп караучы да юк, ничә сәгать эшләргә кушучы да юк — үз иркебездә. Шулай итеп, бу шурф янындагысын күчереп бетердек. Әтигә кайтып әйттем. «Ярар, улым, әйбәт булган, иртәгә бүтән җирдән ташырсыз»,— диде. Иртәгесен шуннан ерак кына түгел икенче шурфны ул үзе күрсәтте. Күрәсең, Блинов белән шулай сөйләшкәннәрдер инде. Тагын тотындык. Ә тора-бара бу эш безнең «кәҗәгә» тия башлады, сүлпәнәя төштек. Ара якын гына булса да, урталыкта утырып шактый ял итәбез.

Аяк очыбызда гына шурф авызы, аннан салкынча һава бәреп торган шикелле. Иелеп карыйбыз, төбе күренми, дөм-караңгы булып тора. Утыра торгач, Петька кулларын носилкадагы рудага, аннары шурф авызына сузып күрсәтте. Шунда ук аңлашылды бу. Мин дә кулны шунда таба сузып, ым кактым. Беренче олы руда кумкәсен җибәрдек. «Гөмбер-рт!» итеп, стеналарга бәрелә-сугыла, төшеп китте. Тагын җибәрдек, тагын шулай. Ах, шәп гөмберди икән бу! Куанабыз, көләбез — кызык булып чыкты бу эш.

Шулай шурф эченә тондыра торгач, носилкадагы руда бетте. Тагын алып килеп, тагын шулай тондырдык. Юл кыскарды, эш җиңеләйде безнең. Ничәдер көннән соң руданы яңа урынга күчереп бетердек. Ләкин ул анда элеккесенә караганда шактый әз урын алды...

Хәзер дә гаҗәпләнәм әле: бигрәк тинтәк буласың икән малай чакта, шуны уйларлык та баш булмаган! Кемнәрдер интегеп, манма тир түгеп дигәндәй, кул көче белән өскә чыгарган бит инде аны. Ә без — яңадан аска! Ярый әле, безнең «эшчелек» шуның белән бетте, бүтән күчерәсе булмады, юкса, тагын күпме руда «гөмбер-рт!» иткән булыр иде...

## Гөмбә, тырыс, черкиләр...

Вакыт күп хәзер. Әлеге өч кыз белән урман гизә торгач, җиләкләр дә пешеп өлгерде. Бер көнне ярты түбәтәй каен җиләге белән кара җиләк җыеп кайттым. Монысын мин белми идем, кызлар өйрәтте: «Черника, бик тәмле», диделәр. Чынлап та, авызга кабып, тел белән кыссаң — үзлегеннән эри дә бетә. Гыймран абзый бик һәвәс кеше булып чыкты:

— Урманда ятып, җиләк тә ашамагач! — ди дә эштән соң һәркөнне агачлыкка кереп китә. Мин инде аның артыннан калмыйм. Кай көннәрне Җыянша абый белән эти дә иярә. Табыннан иртә-кич җиләк өзелми хәзер. Шулай йөргәндә безгә атлаган саен бик күп гөмбә очрый башлады. Аптырарсың, безнең эти гөмбә танырга бик оста икән.

— Монысы каен гөмбәсе, монысы ак гөмбә, монысы таш гөмбә, монысы усак гөмбәсе, бу сарысы майлы гөмбә — табада кыздырып ашарга әйбәт, ә бу шәмәхә битлесен ашарга ярамый, чебен гөмбәсе — агулы,— дип тезеп китте ул. Аннары, уч төбедәй түгәрәк бер гөмбәне өзеп алды да: — Монысы инде нарат гөмбәсе. Бу — иң әгъләсе, нәчәлсуа кешесе аның өчен үлә дә китә,— диде.

Яңа гына мичтән чыккан вак төче күмәч төсле өсләре кызарып торган шушы матур гөмбәне җыеп өйгә алып кайттык. Бүтән савыт булмагач, бердәнбер пыяла банкыбызга тозлап, идән астына куйдык. Иртәгесен эти каен чырагачны буйдан-буйга калын итеп телде дә агач пычак төсле ике озын шыбын ясады, аларны мыча тоттырды, үзе балта белән пычкы алды — урманга кереп киттек. Тәнендә ботак җөе булмаган зифа бер каенны шома тузының югары ягыннан кисеп аудардык. Ямь-яшел каен зарлы гөҗелдәп җир өстенә төште. Безнең анда эш юк, эти шома тузның түбән ягын су күк үткен балтасы белән кистереп-каезлап чыкты да ике шыбын белән шыбыннарга тотындык. Кайры белән агач кәүсә арасына шул озын агач пычакны тыгып шөшкели һәм кочаклап боргалый торгач, тырыслыгыбыз агачыннан кубып, суырылып чыкты. Икенче бер юанрак каенның шома тузын балта борыны белән сызып кына салдырып алдык. Әтинең осталыгына шаккаттым: бик матур «дугалы» тишекләр белән «бүрек башлы» каптыргычлар ясады да тузны тырыслык өстенә беркетте, аннары өске кырыен кайнар суда пешекләп, тыш якка әйләндереп салды, төп кидерде, капкач ясады, сап куйды. Нәкъ

ШӘЙХИ МАННУР ◆ АГЫМСУЛАРГА КАРАП ◆

базарныкы төсле әйбәт бер тырыс килеп чыкты. Нарат гөмбәсен шунда тозлый башладык.

Эт чаба дип бет чаба дигәндәй, мин дә тырыс ясадым, бөтен җире килде: шомырт таяктан бөгеп, сабына хәтле үзем куйдым, тик су тотмый торган булып чыкты, төбен тыгызлап утырта белмәгәнмен. Шулай да мин ясаган дүртенче тырыс акмады, аның эченә өч чокыр су сыя иде! Тик бу эшнең күңелгә тия торган бер ямьсез ягы бар: егылган зифа каен, синең итәгеңә ябышырдай булып, елап кала төсле. Аның янынннан күзләреңне чытырдатып йомсаң гына узып китү мөмкин...

Вакыт ничек җитә торгандыр: аш та пешерәм, авылга барып сөт тә алып кайтам, җиләк-гөмбә дип тә чапкан булам, Лида-Людалар белән уйнарга да ара табыла, аннары да әллә нихәтле буш булам әле. Шуннан файдаланып, мондагы пермякләрчә кыек башлы мөгезсез чабата ясарга һәм юкә башмак үрергә өйрәндем. Үземә дә, әтигә дә үрдем, иртә-кич өйдә өстери башлады. Җыянша абый белән Гыймран абзый гына теләмәделәр. Шулай итеп, минем һөнәр һаман арта тора. Егет булып җиткәндә җитмешкә җиткерәчәк әле мин ул һөнәрне! Исән йөреп авылга кайтсам, шушы башмак белән шушы тырысны ясап та шаккатырам әле мин Тулбай малайларын!

Кешеләр тагын тарала башлады: печән җиткән, имеш, аның артына урак терәлеп килә, имеш. Петька белән Ларион дәдәй дә кайтып киттеләр, иртәгесен мин торуга Фрося дә юк иде инде. Икенче зур учак та сүнде, аның янындагы җыр да тынды. Сагыш баскан тол хатынның: «Кабы я не тосковала, не худая бы была» дигән моңлы-зарлы сүзләрен ишетеп булмый инде хәзер. Шау-шуга бер өйрәнеп киткәч, тынлык күңелсез була икән. Бәхеткә каршы, бу хәл озакка сузылмады: управляюши безнекеләрне дә печәнгә чакырган. Түрә кешенең сүзен ничек аяк астына салмак кирәк. Берәр көннән алар өч атка төялеп килделәр дә безне дә утыртып алып киттеләр.

Печәнлекләре өч-дүрт чакрымда гына икән. Шул ук урман арасы инде — киселгән, яндырылган, ярым әрчелгән җир. Бармаксыз абзый пар ат белән печән машинасында йөрде, әтиләр — чалгыда; Блинов агай белән гимназист малае да чапкан булдылар. Аның шундый егет малае белән Галина исемле җиткән кызы да бар икән, мин аларны беренче күрүем.

— Ай-яй, каты чабасыз, бер дә сезнең белән куышып булмый, маладцы! — дигән була управляюши. Ә безнекеләргә шул җитә кала — тагын да җиллерәк селтәнә башлыйлар. Беренче көнне без бала-чагага бөтенләй диярлек эш булмады, җиләк артыннан чаптык, кичке якта гына печән кабартырга куштылар. Ялан аяк барган идем, үлән камылы бармак араларын кисә, табан астын үтереп чәнчә башлады, тәпине гел куырып кына басарга туры килә.

Блинов агайның олы кызы бик зур казан асып, бөтен әртил өчен аш пешерә. Үзе болай шәһәрчә сыманрак киенгән булса да, никтер авыл марҗа кызларына күбрәк охшый төсле. Тулы-итләч гәүдәсен артык борчымаска теләгәндәй, салмак кына атлап йөрүе беләнме, киселмәгән табигый озын чәчләренең, гади каш-керфекләренең ясалмаган булуы беләнме, башындагы өчпочмаклап бәйләгән гади яулыгы, аягындагы гади кара ботинкасы беләнме, төскә-биткә шактый чибәр булса да, ярыйсы ук олы чырайлы күренә иде ул. Шуның өстенә ниндидер эчке боеклык та сизелә кебек иде. Шул олы чыраена карагандa яше аның егерме биштән дә ким булмас, гимназиядә дә укымый калган икән, аның Наташадан белдем. Ничектер, сүз иярә сүз чыгып, әйтә куйды:

— Галина укып бетерә алмады... Әти белән безне караучы булып калды ул...

— Ничек? — дип гаҗәпләндем мин.— Әниегез соң?..

— Әни?.. — диде кыз көрсенеп.— Әни юк шул безнең...

— Әллә үлдеме?..
— Юк, үлмәде...

Аның бу җавабы мине тагын да әллә нишләтеп җибәрде. Озак йөрдек урманда. Лида белән Людадан аерылып киткәнбез. Бүтән чакта артык чишелергә яратмаган Наташа, белмим, мин төпченгәнгәме, әллә үз эчендәгеи әз генә бушатырга теләпме, минем акыл җитмәслек нәрсәләр әйтеп ташлады:

— Әни дигән кешебез... бер приска хуҗасына ияреп китте... Люда бишектән дә төшмәгән иде әле... Әти белән егерме еллап торганнан соң... Инде биш ел тулып узды...

Һич аңламассың бу дөньяны, юк, башыма сыймый! Бу әдәм баласы эчендә нинди генә хәлләр юк? Биш бала ташлап! Егерме ел... Вәт син аны...

Ниндидер җылы сүз әйтәсе килде Наташага, юата торган сүз... Ә каян алырга соң андый сүзне?.. Агач телле авыл малае бит әле мин... Эзли торгач табылды: «Не горюй!..» дидем, кулыннан алдым... «Мин дә энисез бит...» дип әйтәсе дә килгән иде, кыюлык җитмәде. Шулай тотынышкан килеш печәнлек кырыена килеп чыктык.

Кушучтай эре яфраклы, киң күләгәле юан өрәңге төбенә бик олы җеп палас җәйгәннәр, аның өстенә табак-савыт, кашык-аяк, ипи-тоз таратып табын әзерләнгән. Таҗи абзый белән Галина, бакыр казанны ике колагыннан күтәреп, палас читенә китереп куйды. Галина тәлинкәләргә аш бүләргә тотынды, барысы да табын кырыеннан урын алды. Безнекеләр аргы почмакка чүмәшкән. Җыянша абый аяк бөкләп утыра, ә Гыймран абзый байларча гына кырын яткан, зимагур кешенең тезләр бөгелми башлаган, ахры. Бармаксыз абзый да аның янына килеп утырды, мин Җыянша абый тирәсенә кысылдым. Ашау башланды. Ә нилектәндер әти юк табында. Мин аптырап торганда гына управляющи сорый куйды:

— А где Фазлутдинич?

Җавап юк. Безнекеләр үзара пышылдашып алды: «Урыс суйган иттер», дип килмәгән, дуңгызныкыдыр дип курка икән.

Таҗи абзый шундук сикереп торды:

— Тана ите бит! Тенәген кич кенә үзем суйдым! — Һәм ул тиз генә безнең куышка йөгерде, әтине җилтерәтеп алып килде. Блинов агай бу хәлне аңламый да калды.

— Што опаздываешь, старина? — дип кенә куйды.

— Маленке дило было,— дигән булды ул көлемсерәп.

Аптырарсың бу әтигә. «Җүләр дисәң — акыллы сыман, акыллы дисәң — шыр тиле!» — ди ул үзе мондый чакта. Мин алай ук дип әйтергә куркам, шулай да кәмит яклары чыккалап куя аның.

Ашны Галя бик тәмле пешерә икән, ничә тәлинкә меңгерсәң дә туярлык түгел. Табынның ике башында ике зур җиз табак түбәсеннән ит, озынча таш савытта каз күкәедәй эре-эре майлы бәрәңге — сыпыр җаның теләгән хәтле! Печәнчеләргә ике шешә «котырган сыер сөте» дә куелган. Гыймран абзый белән Таҗи абзый анысын да кырын какмый; управляющиның үзе белән бергәләп күтәрделәр. Җыянша абый да тыптын гына, оялчан кунак кызыдай елмаеп кына, ярты стакан чамасы кәгеп куйды. Йотуы белән чыраен сытып, тизрәк шурпага, иткә тотынды. Мондый чакта безнең әти читкә карап утыра, табыннан торып ук китә торган гадәте дә бар...

Юк, бу Блинов агай (монда белдем: Константин Семеныч икән) ничектер простой кеше, әйбәт күңелле булса кирәк, бер дә түрәлеген күрсәтми. Шул дүрт татар белән эчкерсез чөкердәшеп, кыстап-сыйлап утырган була. Әллә печәнен чабышканга шулай итә микән? Хәер, аннан гына түгелдер инде, килгәннән бирле әтиләрнең бер дә ул кешедән зарланганы юк ич. Үзе шундый гадел әдәмдер бәлкем...

Аштан соң печәнчеләр берәр сәгать йоклап алдылар да тагын үз эшләренә тотындылар. Тагын урман эче чыңлатып чалгы янаган, печән машинасы челтерәгән тавыш белән яңгырый башлады. Без дә кояш иңгәнче печән әйләндереп йөргән булдык. Авылда печән кабартырга барган чаклар искә төште. «Шыятавы» дигән ерак болында бигрәк тә күңелле була иде. Болын кырыеннан дугай-дугай бормаланып Шыя суы ага, аның ярларындагы куп-куе вак таллык эченә кереп китсәң, баш-көлләй югаласың, этең дә эзләп таба торган түгел. Ә шул таллык арасында чалгычылардан качып калган баллы какы, балтырган көпшәсе, кара-шәмәхә кабыклы йөнтәс көпшә! Валлаһи, бер дә арттырмый гына әйткәндә дә балтырганы сабый бала беләге юанлыгы була торгандыр! Кайсын гына әрчеп ашасаң да, кетер-кетер чәйни башлауга авызда эри дә бетә, тач бал үзе — шикәрең бер якта торсын! Таллыктан килеп чыксаң, каршыңда уймакланып-уймакланып аккан инеш суының май күк җылы икәнен алдан ук сизеп торасың, тирән дә түгел, артык сай да түгел, тот та сикер, чум! Рәхәтлән бер!

Монда, югыйсә, мина бер дә начар түгел, тамагым да тук, өс тә ялангач дип әйтеп булмый, артык күңелсез дә түгел, яшь ананың «татлы» тавышы да юк — рәхәтнең рәхәте инде! Тик барыбер нидер житми... Нидер түгел, әнә шул тәгәрәп үскән мең чәчәкле болыннар газиз икән, онытылмый икән!.. «Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил» дигән җыруны бик үзәге өзелгән кеше чыгаргандыр, ахры. Дөрес чыгарган, бик дөрес әйткән...

Әкрен җилдә уйнаган куе яфраклы агач башларының бер ягын ут кабынгандай кызартып, кояш баеды. Бу йомшак ахак нурлар сүнүгә күңелдә күбәләктәй җиңел кайнашкан сагышлар да юылып төште, туган болыннар да кояш артында калган шикелле булды. Кичке җил бөтенләй тынып, сыңар кыяк та селкенми утырганда, усак яфракларының сүзләре бетмәгәндәй әле һаман шыбырдашкан булуы гаҗәпләндерә инде мине хәзер. Чынлап та, нишләп алай икән ул? Нинди сихри көч белән лепердәшеп, көмеш койган асларын күрше каеннарга күрсәтә-күрсәтә, нәрсә сөйләшкән була икән алар? Юк, белеп бетерә торган түгел бу дөньяны...

Җиләк суы сибелгәндәй алсу-зәңгәр шәүлә әкрен-әкрен сүнде, әле генә озын-озын булып җиргә сузылган күләгәләр, барысы бергә кушылып, тоташ кара пәрдәгә әйләнеп китте, кара-күксел күктә беренче йолдызлар күренде, йоклар вакыт җитте. Печәнлектә управляющинең агач өе булса да, бәләкәй, барыбыз да сыярлык түгел. Безнекеләр яфраклы агач ботакларыннан үзләренә шалаш корып, яшел үлән белән капладылар, әчкә дә калын итеп печән түшәлде, алдан ук кызыктырып тора: аска печән, өскә печән, ә салаш эчендә баш әйләнгеч хуш ис — йокла бишектәге нәнидәй мәмрәп кенә! Тажи абзый да, «Чүтри кәмин — дүрт таш, кайда йөрми мескен баш»ны такмаклый-такмаклый, безнең янга кереп, иң кырыйдагы урынга ятты.

Көн буе чалгы селтәгән кешеләрнең талчыгуы билгеле инде. Печән мендәргә башы тию белән Гыймран абзый гырлый да башлады, эти дә тигез, татлы гына мышнап, йокы күленә чума бара бугай. Җыянша абыйның да борыны сызгыра, иң кырыйдагы Тажи абзый гына ничектер. Мин үзем дә инде «нәвем базары»на китеп бара идем, каяндыр бер озынборын, «энеммм!» дип, нечкә генә тавышын сузып килде дә колак яфрагына кадалды. Үз колагыма үзем «шап!» итеп китереп суктым. Инде жанын җәһәннәмгә җибәрдем дип кенә торганда, тагын икәү-өчәве чәңгелди башлады, кулны караңгыда бутый-бутый, алар белән сугышырга керештем. Ул арада булмады, берсе каракларча сиздерми генә килеп, үткен сөңгесен күз кабагына ук батырды. Җан ачуым белән тагын «шап!» итеп сугуга күздән утлар чәчелде. Каян керә соң бу үләт тигерләре! Салаш авызы да каплаулы бит — Гыймран абзыйның иске

пинжәге асылынып тора. Качты йокы дигән ин татлыдан татлы нәрсәкәй. Керфекләргә шырпы тераткән диярсең.

Шулай интегеп ятканда тыштан ниндидер кыштырдау колакка чалынды, аяк тавышы сыман тоела, ат-фәлән микән соң ул... Колакларны торгыздым: һаман ишетелә, әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп йөри төсле. Шулай байтак вакыт узганнан соң кырыйдагы Таҗи абзый сак кына кузгалды да тышка чыгып китте. Озак та үтмәстән, теге кыштырдау каядыр ераклашкан сыман бөтенләй ишетелми башлады. Мин черкиләр белән сугышып һаман йоклый алмадым. Таҗи абзый шактый озак торып, сак кына кереп ятты. Белмим, аның чыгып йөргәнен сизмәделәрме,— эндәшүче булмады. Ул кергәч күп тә үтмәде, салашның кичтән күренми калган тишек-тошыгыннан таң яктысы эчкә сарка башлады. Әнә каян кергән икән ул каһәр черкиләр! Инде чәңгелдәмиләр дә хәзер, берәм-берәм сызалар бугай шул ярыклардан...

Мин уянганда куыш әллә кайчан буш иде инде. Теге кызлар белән без тагын печән кабартып, күбәләп, җыеп йөргән булдык. Без дә эшем кешесе бит! Куып эшләтүче булмагач, арган-талганың да сизелми икән, уйнаган шикелле генә йөрисең. Шулай да икенче-өченче төннәрне кайда ятканымны да белми йоклаганмын, озынборыннар да сизелмәгән. Аның сере бар икән: йокыга киткәнче тешләмәсәләр — берни түгел. Тик актык төнне тагын йокы бирмичә җелекне киптерделәр, тагын: «энеммм дә энемм!..» һәм тагын теге аяк кыштырдавы: тагын Таҗи абзый сак кына чыгып югалды һәм тагын таң беленгәндә генә кереп ятты. Нинди серле кыштырдау булгандыр бу, һич аңлый алмадым.

Дүрт көн эчендә бөтен пакос чабылып, җыелып бетте, әтиләр олы-олы кибән куйдылар. Печәннең болай яңгыр-фәләнгә эләкмичә, әйбәт тәгәлләнүенә Кастантин Симунич (әти шулай әйтә) бик сөенеп, тагын сый табыны әзерләде. Бу юлы инде Гыймран абзыйлар күбрәк тә төшереп куйдылар. Хәтта ул үзенең картая башлаган тавышы белән бер күңелле җыру да кыстырып җибәрде:

> Ночька темна, я боюся,
> Проводи меня, Маруся...
> Провожала до вокзала,
> У вокзала целовала!...
> И слезники проливала...

Кычкырып көлешә-көлешә бар да кул чәбәкләделәр. Вәт картлач, ничек сайрый, ә!.. Аннары управляюши, рәхмәт әйтеп, эчүчеләр белән чәкәшеп чыкты. Безнең янга килеп әтинең кулын кысты, «молодец, маленький Фархуллич» дип, миңа да кул биргән булды. Хикмәт кеше бу Блинов агай, һәркемнең юктан гына да күңелен таба белә.

Кояш баеганда гына атларга төялешеп, печәнлектән чыгып киттек. Наташа миңа үз яннарында урын калдырган. Урман эченә серле караңгылык тула бара. Юл тар җирләрдә агач яфраклары салкынча йомшак учлары белән безнең маңгай өсләреннән сыйпап кала. Миңа рәхәт. Ниндидер бик якын дуслар белән, җыйнаулашып, күрше авыл сабан туена барган шикелле рәхәт миңа. Наташага шуны әйтәсем килә... Хәер, кирәкми, ул бит сабан туен белми, аның матурлыгын да аңлата алмам мин... Менә, өйгә дә кайтып җиттек. Арбадан төшкәндә минем кул нишләптер аның кулына тиде... Алар үз өйләренә киттеләр...

## Таҗи абзыйның мәхәббәт тәүбәсе

Печәннән кайткач, көннәр әллә нинди күңелсез булып китте. Безнең бәләкәй иске алачык (шуны нигәдер барак дип атыйсы килми) һаман шып-шыр буш. Ишегалдына чыксаң да бер әдәм заты юк. Кайсыдыр

яктан килеп, ат белән Михайловка заводына руда ташучы өч кенә кеше бар, алар да түбәнге баракта торалар. Атна буена Люда, Лидаларның да күренгәне булмады. Аш пешерәм дә урманга керәм. Якында гына җир җиләге тулып ята, каен җиләге бетте инде, анын каруы, ике төрле карлыган белән бөрлегән пешеп килә, кура җиләгенә дә тәм керә башлады, чәй табыны җиләксез булмый хәзер.

Бер кичне чәй эчеп утырганда, һич уйламаган җирдән бармаксыз Таҗи абзый килеп керде. Керде дә:

— Качам! Качам мин моннан! — дип куйды ул. Кулындагы биштәр капчыгын идәнгә төшерде. Без ялт борылып аңа карадык. Төсе-бите алмашынган, килеш-килбәте дә бик сәер, әллә берәр чокыр төшереп алган инде, әллә болай шомланган — күз очларына ниндидер куркыну очкыны кунган шикелле. Сәлам дә биреп тормыйча, ярсынып дәвам итте:

— Чүтри кәмин — дүрт таш, бетте бугай җүләр баш! Ычкынмый булмый. Иртәгә палучка, шуны гына алам да сызам! Җиде төн уртасында юкка чыгам! Сизә генә күрмәсен!..

— Әйтерең бармы, кыек авызынны чалшайтып! — диде әти, нәкъ аныңча тавыш белән ярсынган булып.

Без, бер нәрсә аңламыйча, көлешеп куйдык. Гел чәйни торган «чүтри кәмин»нәре колакка да кермәде инде, ә бүтән сүзләренең кай ягыннан тотынырга да белмәслек буталчык иде.

— Менә күрерсез! — диде Таҗи абзый, әтигә карап.— Көлмә әле, Пәрхулла абзый... Тычканга үлем, мәчегә көлке дигәндәй...

— Айса, ник бәрәнге пешерәсең авызыңда? — дип ачуланды Гыймран абзый.— Ябалак шурпасын чамасызрак чөмердең мәллә? Сүзеңнең атасы-анасы юк!

— Какуй монда шурпа! Белмисез сез картла-ар! — дип сузды Таҗи абзый баш түбәсен кашыгандай итеп.— Чүтри кәмин — биш таш, барысы да куыш таш дигәндәй, каткан инде тиле баш! Хәлләр кәкәй минем.

— Нәрсә? Нәрсә? — диеште безнекеләр.— Ни булды ул хәтле егылып үләрлек?

Таҗи абзый тирәнтен сулап куйды да кызулыгын тыя төшкәндәйрәк итеп әйтте:

— Егылып та китәрсең шул... Марҗа кызының «кашыгы» төшкән миңа... Башың Себер китәр...

— Ха-а-ха-ха! — дип көлде Гыймран абзый гыжынкы тавышы белән.— Бик шәп! Кайсысы ул? Фроська мәллә?

— Көлмә, карт мәче! — диде Таҗи абзый, ачулы гына итеп.— Мин сезне олылар санап киңәшкә килгән, ә син авыз җырасың!.. Фруськә булса, чүтри кәмин, китәрием төкереп тә мин! Аннан хәтәррәге шул — Галә, управляюши кызы.

Барыбыз да шып булдык. Олыларның йөзе аптыраудан таштай катып калды. Мин дә гаҗәпләндем, аңлап бетермәсәм дә бик сәер тоелды. Галинага күп булса егерме биш яшьләр, ә Таҗи абзый кырыктан уза барган кеше, авылда семьясы бар, укымышы да юк... Белми микәнни соң?... Үзләрендәге хезмәтчегә гашыйк була торган бай кызлары турында укыганым бар, шундыйрак хәл була микәнни инде бу?..

— Әллә үзең андый-мондый әшәкелек эшләдеңме, җүнсез? — диде әти, кашларын җыерган килеш.

— Аллам сакласын, Пәрхулла абзый, минем андый гадәт җуклыгын үзең дә беләсең ич...

— Шулай да ничек килеп чыкты соң ул? — дип сорады Гыймран абзый да кырку гына итеп.

— Ничек дип... Белмим инде...— Таҗи абзый өстәлгә сыгыла төште.— Башта ун-унбиш көн әйбәт кенә эшләп йөрдем... Ашау — байдан, үлем — ходайдан дигәндәй, үзегез беләсез: чырай ачык, уен-көлке бер

капчык, тел житмәсә дә, сукалый бирәм шунда, кара коелып йөрисенмени инде? Булдыра да алмыйм мин аны... Галә белән һаман бер тирәдәрәк кайнашырга туры килә. Мин мал-туар астын карыйм, атларга курмы салам, дирбияны рәтлим, ишегалды себерәм — ялчының эше бетәмени. Ә Галә сыер сава, бозау имезә, тавык-чебеш туйдыра, кер элә, кер җыя... Булышкан да булам үзенә... Мәнә сиңа, телә-теләмә: гел бергә; юк дисәң дә сөйләшкәләп китәсең. Тора-бара гел елмаеп, нурлы йөзен балкытып йөри башлады бу. «Тажи абый (үзе сорап, шулай әйтергә өйрәнде), ты очен дубрый чаловик» дигән сүзләре дә ычкынгалап куя. Мин уен-көлкегә алам: «Син үзең дубрый кыз бит», дим. «Милый Таджи абый, утын кертеп бирче кухнәгә», дигән була. Миңа нәрсә, ваклыйм да кертәм, җаның күпме тели... Ә ул кружкасы белән салкын куас бирә, җә булмаса, савыты белән парлы сөт эчертеп чыгара. Шуннан, дәлше-бүлше: һаман сырпалана бу. Уйнап-көлеп кенә әйткәндәй итеп: «Мине яратасыңмы»,— ди. Да, да, дигән булам. Ә бер көнне әйтә: Тый красивый и милай чалавик, ди. «Я тибә лүблү» дигән сүз сезнеңчә ничек була, дип сорый. Әйткәннем, «Мин сине суям!» — дип кабатлады бу. Бот чабып көлдем дә җибәрдем. «Булыр, булыр, мәйтәм, суярсың!» «Ник көләсең, ник алай дисең?» дип үпкәләгән булды бу, мин бит чын күңелдән әйтәм: «Лүблү я тибә!» ди. Түшемә ук килеп сыенды бу. Мәнә сиңа чүтри кәмин — дүрт таш! Минем дә кисәк кенә баш әйләнеп китте, әллә нишләдем. Күңел үрле-кырлы сикерә, тыя торган түгел, күз аллары томанланды... Шуннан: «Бетсә, беткән тиле баш!» дидем дә, кочакла да үп мин моны! И үтен-түтен чиген дә чык та кач ат сараена! Печәнлекнең түренә ук менеп яттым. Нишләвем булды бу? — белмим! Коточкыч хәлдә калып, янам-пешәм, тетрим-калтырыйм, тирлим-туңам!..

Ә күңелдә ап-ак фәрештә белән чуп-чуар шайтан сугыша. «Оятсыз! — ди фәрештә әйтә,— өеңдә ике балаң бар, катының бар, ничек кайтып аларга күренерсең? Ил эчендә ни битең белән йөрерсең? — ди.— Чүлмәк маңгай-чүбек баш булмасаң, болай ук кыланмасың син»,— ди. Үтерә бит гел, җон урынына тетә!

«Төкер, Тажи дус! — дип көлә чуар шайтан. Чүтри кәмин — дүрт таш, чүбек түгел синең баш! — ди.— Бер үпкәннән кем беткән? — ди.— Чибәр бит ул,— ди.— Мысыр күгәрченедәй матур көлә бит,— ди,— сине бәк-бәк яратканын үзе үк әйтеп тора бит ул,— ди.— Нижәли шундый чибәр, шундый һәйбәт кызның сандугач сайравыдай матур сүзе колагыңны бер дә кытыкламый? — ди.— Юк, сап-саңгырау кеше дә ишетми калмас аны, йөрәге таш булса да йомшар! Йомшар гынамы? — Кайнар утка әйләнеп, үзе яна башлар! — ди.— Дөресен генә әйткәндә, яшереп маташмыйк, Тажи дускай, ди, синең үзеңә дә ошый бит ул!» — ди.

Үтерде дә салды. Икесе ике яктан тереләй туный! Юк, бу газапка түзәр әмәл калмады. Төн урталары үткәч, сәндерә түреннән шыпырт кына төшеп, эткә дә сиздермичә, үземнең алачыкка кердем. Ут кутәрми генә тәгәрим дип, өс-башны аннан-моннан салып, тапчаныма килсәм, кулым җылы нәмәстәгә тиеп китте, шундук аңлап алдым — ул ята! Иа алла! Инде нишләсе миңа хәзер? Ялан тәпи килеш яңа чыгып йөгерәсеме? Алай да — вай, болай да — вай!..

«Таджи абый, ни сердись! — ди бу, кайнар тавыш белән пышылдап.— Мин хәзер чыгып китәм»,— ди. Ә үзе җен-пәри кызыныкы күк уттай беләкләре белән муенга сарылды да өянке талдай иеп төшерде мине үз янына. Үлем исереклегендә калдым. Ә ул, тын алырга ирек тә бирмичә, әллә нинди оҗмах татлылыгы килгән кайнар иреннәре белән үбәргә тотынды, үпмәгән җиремне калдырмады. Исердем дә киттем. Өнме бу, төшме бу — белмим... Шуннан ары килеп, еларга керешә бу. Юк, кычкырып түгел, мендәргә капланып елый, ятим баладай сөмсерләре коелып елый. Нихәтле таш бәгырьле булсаң да, кызганмый түзә алмассың.

Беркаум шулай сулыгып елагач, яшь аралаш тотлыга-тотлыга пышылдый башлады. «Син инде мине эшәке кыз дип уйлый торгансыңдыр Таджи абый, ди, бозык катын дип... Шулаймы-түгелме икәнен үзең сынап белә аласың... ди. Шушы яшемә җитеп, гомеремдә беренче тапкыр ир-егет янында буй сузып ятуым, ди. Теләсәң нишләт — мин синеке, ди Син мине утка салдың, теләсәң — суга сал, теләсәң — мыскыл итеп ташла, теләсәң — алып кит, җир читенә хәтле китәргә дә риза! Син ач булсаң — ач, син тук булсаң — тук, барын да күтәрәм, тик син генә янымда бул, тик син генә ярат!» — дип җылый...

Ә мин, чүтри кәмин, мендәргә сибелеп төшкән көлтә чәчләренә кул тиереп бер сыйпарга да куркып ятам. Курыкмаслык та түгел, минем үз гомеремдә мондый хәлне күргәнем югые шул. Йөрмәдек түгел, йөрдек егет чакларда. Үземә күрә буй-сын да, төс-бит тә барые, өс тә шәрә түгел, тел дә тышауланмаган... Кызларын да күрдек, аулак өйләрдә куеннарына да кергәләдек, әммә дә ликин мондыйны белгән югые... Әллә нәстә бу!.. Башта мең төрле сорау — тай типкәндәй чыңлап тора, ә берсенә дә җавап табып булмый. Ятам чеп-чи усак кискәсе шикелле шунда — ут сулаган кыз янында...

Ай, рәхмәт төшкере,— әтәс кычкырып җибәрде шул чагында. Хуҗаның бәк шәп галан әтәсе бар. Карт бугай үзе, шпурлары кыршылып беткән, шулай да әкәмәт гайрәтле кылана... «Тетри җир-күк!» дигәндәй, яман да ачулы тавыш белән дөньяны кисеп салды бу. Кыз ут капкандай сикереп торды да шыпырт юк булды... Мин айный алмыйча ята бирәм... Таң шәүләсе тәрәзәдән сирпелә башлау белән атлар янына чыгып киттем. Тукмак башта туксан төрле уй, очын-кырыен таба торган түгел. Күп уйлый торгач, үземне авызлыклап-йөгәнләп дигәндәй, бәк каты кулга алып, атна буе күренмәскә тырышып йөрдем... Әз генә шәүләсе күзгә чалындымы, теге-бу бер йомыш тапкан булып, ишегалдыннан чыгып таям, кичтән үк, сиздерми генә, сарай башына үрмәлим. Җәйге төн — җылы төн, хуш исле печән — җан рәхәте...

Юк шул... уйлыйм гына шулай дип, качты ул миннән җан рәхәте дигән нәстә. Җан яна, дөрләп яна хәзер җан! Чи усак кискәсенә дә ут кабына икән! Ә күз алдында гел шуның асыл сурәте басып тора, моңлы сурәте... Як-якка әйләнәм, кырыкка кырлапам — барыбер шул боек шәүлә, шул сөйкемле шәүлә югалмый...

Ә инде озын йортның иң аргы почмагындагы бәләкәй генә тәрәзәле, шәкертнекедәй тар булган «хөҗрә»мә килеп керсәм, бөтен җире чистартылган, барлы-юклы күлмәк-ыштан, бүтән чүпрәк-чапрак юып үтүкләнгән, катып беткән колак күпчегенә ап-ак тыш киертелгән, иске киезле тапчан өстенә ап-ак җәймә җәелгән була. Бу ниткән хәл бу? Моны ничек аңнарга? Ул гына дисеңме әле, өстәл өстендә озынча куыш савыт,— агач тамырыннан сырлап-бизәкләп эшләнгән,— шуның эчендә ике генә сабак чәчәк. Ул көн саен алмашынып торса да, гел матур чәчәк була. Чәчәк... Чәчәк... Ул, бичаракай, күңеле белән мине бәк югары куя торгандыр инде. Чәчәк аңлый белә торган нечкә күңелле, әйбәт тәрбияле, абразауный шәһәр егете итеп күз алдына китерәдер...

Ә мин, чүтри кәмин, мин нәстә соң?..

Мин — гомер буе җир тырнаган, тирестә аунаган, шахты прискеләрендә бөкре чыгарган, ә хәзер үзенең атасында ялчы булып торучы каткан мужик! Түбән Тәкәнешнең Хисаметтин малае, житмәсә тагын — татар! «Татарин галалобый!» Ник ярата ул мине? Әйтегез әле, ник ярата?.. Син бит, Пәрхулла абзый, син дә Гыймран абзый, дөньяны күбрәк күргән, күбрәк яшәгән кеше, ниемә дип ярата ул мине? Әйтегез әле, зинһар, нәстә өчен?..

Гыймран абзый көлемсерәп куйды.

— Мин моны, парин, үзеннән барып сорамыйча әйтә алмыйм сиңа.

Моңарчы бик эсәрләнеп тыңлаган эти дә:

— Һи... корт чаккыры, болай бик акыллы, бик басынкы күренәдерие бит ул кыз,— дип аптырауда калды.— Унҗиде яшьлек җилкенчәк булса — бер хәлие, утырган-сазаган бала бит, югыйсә...

— Үзеннән сорыйлар аны! — диде Җыянша абый да җемнеп кенә.

Барыбызга да сәер дә, гыйбрәтле дә иде Таҗи абзыйның бу озын хикәясе.

— Сорады-ым,— диде ул башын чайкап.— Атна узганнан соң сәндерә түреннән төшми булдыра алмадым, йөрәк түзмәде. Үзем дә әллә нишләдем ич: үзем качкан булам, үземнең күрәсе килә шуны... Чибәр бит ул, күгәрченкәй! Эх, җегетләр, сез белмисез аның нинди сөйкемле җан икәнен! Андый бүтән юктыр бу дөньяда...

Әйе, түзмәдем, төшеп яттым. Күп тә узмады, килеп тә керде бу минем янга шыпырт кына. Әллә, минем төшәсен сизеп, чоланда качып торган тагы? Үзе бит ул бозык якка да каермый, вәсвәсә дә салмый сиңа, чын күңел белән кочаклап кына ята.

«Җаңгышасың ич, Галә, дим, мин сиңа бер тиенгә дә ярый торган кеше түгел, дим. Үзең дә күрәсең, ат абзарында ауный торган күчер генә ич мин, дим. Юри генә шаярасыңдыр син», дим. «Не говори так!» дип, учы белән авызымны каплый. Ә учы җофар мае белән югандай хуш ис, сөю исе аңкытып тора — әйтеп бирә торган түгел! Авызымны гел шулай каплап торса да, бер сүз әйтмәсием төсле. Юк шул, әйтмиче булмый. Кирәкми, ташлыйк бу эшне, дип үгетләргә тотынам. Ул аның саен түшемә кысыла бара, яндырырлык итеп суырып үбүләренә нишләргә белмим, чүтри кәмин — дүрт таш! Йөз дә беренче кат тагын сорыйм: «Ник яратасың соң син мине, дим, нинди сөйкемле сөяк табасың миндә?» дим. Уйга калгандай сүзсез ята да, пышылдап кына әйтә бу: «Белеп буламыни аны... ди, җиңел буламыни йөрәкне?..» ди. Вәт, сөйләш син аның белән! Тагын беркауым сүзсез ята да, тагын пышылдый әкрен генә: «Әйбәт кеше син, ди, матур кеше, ди. Синең җан түреңнән ниндәендер җылы, йомшак якты сибелеп тора, син аны үзең дә сизмисең...» ди.

Ипекиләремдер, ул дә кит, чүтри кәмин; сезгә үз-үзеңне мактап борчак сибү шикелле тоелыр, ә ул — шулай ди. Алай гынамы, тагын әллә нәстәләр сөйләп китте: «Мин шушы урман эчендә коргаксып калган бер кура гына бит, ди. Язгы чәчәктәй ачылып килгән чагымда, бишебезне ташлап, мама чыгып китте, ди. Папа бу хәлне бик авыр күтәрде, бер-ике ай эчендә чәчләре чалланып, саргаеп, картаеп калды, ди. Мин аны җәлләп, укуны ташладым, бар теләкләремә, унҗидедә хыяллана торган бөтен матур өметләремә кул селтәп, ата караучы, балалар караучы, йорт-җир караучы, сыер савучы булып калдым, ди. Ярый ла, бездә хәзер күңелле әле, ди. Ә көз җиткәч?.. Алар дүртесе дә укырга китә, папа да мин калам, ул бер бүлмәдә, мин икенчедә. Ул үз эше белән тегендә-монда чаба, көне уза, атнасы уза, ә мин?.. ди. Мин көздән алып язга хәтле япа-башым, ди. Акылдан язып үләрсең бу саңгырау урман эчендә!» ди...

Хәзер инде мин телсез ятам. Билләһи газим, бер уйласаң, гел авыр икән шул аның да хәле. Җаңгызлык сагышы яман да хәтәр бит ул, ходай күрсәтмәсен! Ничек итептер юатасы килә моны, ә кирәкле сүз, әйбәт сүз табылмый. Ничә әйтсәң дә шул инде: чүтри кәмин — дүрт таш, нәстә белә такыр баш?.. Ә ул, мин сиңайтим, дальше-бүльше тагын ялгап китте. Аның сүзләрен кабатлап утыру көлке дә күк, әйтми дә булмый, бигрәк сәер тезә бит: «Менә син килеп чыктың да якты чырай белән җылмая башладың, уен-көлке сүз белән миңа эндәшә башладың, и безнең бөтен ишегалдына җан кереп китте, бу карурман эче яктырып, җылынып киткәндәй булды. Аннары син, үзең дә сизмисең бугай анысын, бөтен кош-корт, мал-туар белән гел сөйләшеп йөрисең, ат солы-

сына ябырылган тавыкларга да, чыпчыкларга да ачуланып кычкыра белмисең, хәтта безнең явыз этнең дә колак артын кашып китәсең», ди. Тагын әлләниләр — тавык та чүпләп бетерерлек түгел. Менә сөйләш син катын-кыз белән! Мин кычкырып көләрдәй булып ятам. Ну, нишлим, мәйтәм, кимчелек як инде ул минем, гаеп итмә, дим. Шуннан ул көлә: «Бар кешенең дә шундый кимчелеге күбрәк булсачы!» ди. Берни аңламыйм, ничек күңелен суытырга белмим. Тел тибрәтеп әйткән сүзләрнең көче юк, үземне күпме әшәке итеп күрсәтсәм дә файдасыз. «Юк, аерыла алмыйм мин синнән!» дип, тагын муенга сарыла бу. «Син мине яратмыйсыңмыни?» — дип җанымны суыра...

Шуннан килеп, актыкны кузырны чыгарып салам: «Мин бит симияле кеше — катыным бар, ике балам бар!» дим. Бә-әк озак эндәшмичә ятты бу. Ләм-мим бер сүз. Дажыки муенга сарылган җылы беләге дә салпаеп төште. Бәгырен ачу уты көйдерәме, әчтән җылап, әчтән сызамы — караңгыда белеп булмый. Түлке нәстәдер уйлана, тирәнгә төшепме, бәк җыректан әйләндерепме уйлана — анысын шәмсез дә күреп була. Һаман телсез бу... Әмма болай да көйсез икән. Авыз төбендә генә татлы пышылдап яткан тутый кошың кисәк кенә шып тукталып калса да борчый икән... Белмим, күпмегә сузылырые бу хәл, ярый әле, шул чакта тагын теге карт галан дөньяга разбуй салды. Әйтерсең төнге каравылчы безнең куркыныч сизелә башладымы, кулындагы шакмаклы бәләген шакылдатырга тотына!..

Итәгенә ут капкандай, кузгалып юк булды Галә. Иркен бер тын алып куйдым, инде аңнагандыр эшнең барып чыкмаслыгын, бүтән тыгызламас, дип уйладым. Шуннан печәнгә китеп бардык. Актык чиләк суык суны да сипкәч, суынсын инде бу, гүпчи суынсын, дип гел читләшеп йөрдем. Сезнең куышка килеп кунуым да Гыймран абзыйны кочаклап ятасым килгәннән түгелие... Әммә дә ликин булмады, котылу дигән нәстә юк икән миңа. Дүрт төннең өчесендә чалаш янына килде бу. Зыр әйләнә таптана да таптана. Ни җаның белән түзеп ятасың? Сез, кәнишне, чүп тә сизмәдегез,— үлеп йоклыйсыз, ә мин: шыпан-шыпан гына аның янына...

Тажи абзыйның бу сүзен ишеткәч, минем күзләр дүрт булды: менә нинди кыштырдау булган икән ул! «Юк, мин сиздем!» дип кычкырып җибәрә яздым. Ярый әле, авызны уч белән каплап өлгердем, олылар сүзенә кысылырга кирәкме соң!

— Шуннан,— диде Гыймран абзый бик сәер кыйхылдап кына,— нишләдегез инде сез?..

— Шуннанмы? — дип җилкәсен куырды бармаксыз гашыйк.— Берни дә эшләмәдек. Алып китте ул мине пакусның аргы башына, утырдык бер чүмәлә төбенә и һәм... сүз дә сүз... «Син ул катыныңны яратып өйләндеңме?» — дип сорый бу. Нәстә дисең аңар — ялганнап буламыни?.. Мин бит, чыннап та, яратып өйләнгән кеше. Алгайның бер дигән кызын җыенның актыкны көнендә көпә-көндез тимерхутка салып чапкан егет заманында. Арттан куа да чыктылар, тоттылар пычагым!.. Әгәр дә мәгәр яратмасаммы соң? Интектерериемме мин моны? Ипекиләремдер дип әйтәм, чүтри кәмин — дүрт таш, бетсә беткән тиле баш! дип, җәһәннәмнең жиденче катына да төшеп китәрием мин моның белән! Тик бөтен бәлә дә шунда шул, җегетләр, катынны да яратам мин, балаларны әйткән дә юк инде, и шуның өстенә бу урман күгәрченен дә яратам...

Әйттем, үзенә дә шулай дидем. Тагын сүзсез калды бу. Чамасыз газап чиккәне күренеп тора мескеннең. Үзем дә көннән-көн ике ут арасында кала баруымны бик яхшы сизәм хәзер. Озак кына боегып, теге бер әкияттәге үги кыздай тез өсләренә башын салып, ут йотып утырды-утырды да тагын җилкәгә сарылды бу. «Милый мой Таджи абый, ди. Әйдә без качыйк моннан, ди, ике генә елга качыйк! Курыкма, син эшләрсең, мин эшләрмен — ач булмабыз, ди. Ике генә ел бергә

торырбыз! Безнең нәкъ сиңа охшаган бик матур малаебыз булыр, ди. Бүтән бер нәстә кирәкмәс миңа, синең төсең калса — шул җитә! — ди.— Аннары син балаларың, катының янына кайтып китәрсең, мин тотмам, ди. Ә малайны үзем тәрбияләп үстерем, укытып кеше итәрем»,— ди.

Мена нишләтеп көрчеккә китереп терәде ул мине! Өч төн буена шул хакта сөйләштек. Сөйләшү дигәне дә көлке генә: җүнле-рәтле бер сүз чыкмый миннән. Баш чөереп кырт киссәң дә — вай, өметләндереп мата-шу да — вай! Ә күңелдә тагын теге шайтан белән теге фәрештә сугыша: «Шәп бит бу! — ди берсе.— Яраткан кызың белән ике генә ел булса да торып калу — үзе бер гомер ич! — ди.— Аннары — дүрт ягың кыйбла! Үзе үк әйтеп тора — сине һичкем тотмаячак!» — ди...

«Ышанма азгын вәсвәсәгә! — ди икенчесе бармак янап.— Элмәккә бер эләксәң — ычкыну юк! Җиләк бөртегедәй ике балаңны гомерлеккә ятим итмәкче буласыңмы?.. Күзең уйнаклаган саен катын алырсың-мы?» — ди.

Шабаш. Аптырагански! Икесе дә шәфкатьсез, икесе белән дә көн-төн бәхәсләшәм. Икесен дә бәреп ыргытасы килә, икесен дә җинә алмыйм! Икесе дә хаклы шикелле... Ә Галинага һаман җавап таба алганым юк әле, һаман шушы нәләт көрчектән чыгып булмый. Шулай да бер уй көннән-көн баш була бара башка:

Качарга!

Качарга!..

Шулай дип уйладыммы — күзләрен мөлдерәтеп, ул күгәрченкәй килеп баса йөрәк өстемә: «Мине ташлапмы, Тажи абый?..» — ди.— Мин сиңа нинди начарлык эшләдем?..» — ди. Вәт чүтри кәмин — дүрт таш, әйләнде дә чуалды бит җүләр баш!.. Менә шундый хәл, егетләр. Кай-чандыр мин имән бармакны күрми чабып өзгәнием, ә хәзер, күрәләтә торып, йөрәкне урталай чабып өзәргә туры килә!.. Бүтән чара тапмыйм...

Шунда ул тынып, моңаеп калды. Безнекеләр аның бу кичерешләрен бик гаҗәпләнеп тыңлады. Минем малай баш өчен бигрәк тә аңлашыл-мый иде. Йөрәк чабу шикелле авыр микәнни соң ул эш? Алай булса, ул аны үзе дә үлеп ярата булып чыга түгелме соң? Белмим, белмим... Ә менә управляюши кызы, чынлап та, аны шул хәтле нык яраткандырмы, шундый-шундый сүзләр сөйләгәндерме, барына да ышанып бетәсе кил-ми иде, безнекеләрнең көлемсерәп утыруларыннан да шул аңлашылды, арттыра бу, дип уйладык. Әмма Тажи абзыйның качып китәчәгенә барыбыз да ышандык. Аның күз уртасында һаман әле сүнми янган иләс очкыннар шуңа тәвәккәлләвен ачык күрсәтәләр иде.

— Раччут алып китәргә булмыймыни соң? — диде эти, аптыраган төс белән.— Җайсыз килеп чыга бит: син югалу белән Кастантин Симуныч бездән сораячак. Ничек дип җавап бирербез икән?..

Бар да уйга калдылар.

— Ничек дисәгез дә риза мин,— диде Тажи абзый кул селкеп.— Артымнан эзләп йөрмәс әле, әйбер урлап китмим...

— Даже кызын да ташлап китәм, диген, кызын да! — дип кыйхылда-ды Гыймран абзый.— Э-э-эх-х! — дип сузды ул аннары.— Ник мин җирән алашага берсе дә гашыйк булмый икән!? Чуртыма да качма-сыем! Җүләр син, чүтри кәмин! Бәхеттән качамы кеше?..

## И бишмәтем, бишмәтем...

Печәннән кайтканнан соң, этиләр иске шурфтагы руданы алып бетереп, яңа шурф суга башлаганнар иде. Мин гел алар янында кайнашам хәзер: ашны леп кенә кайнарга куям да шунда йөгерәм, кызык бит — өстән аска таба бурап төшәләр! Бу шурфны искесенә караганда бермә-

бер киң дә, озын да итеп казыйлар. Аста дүрт кеше эшләгәндә дә иркен булачак. Таҗи абзыйны да үзләре янына чакырганнар иде, ә ул койрык чәнчеде...

Хәер, мин аны шул кичтән соң күрә дә алмадым. Ул тәки үз әйткәненчә эшләгән: получкасын кесәсенә салгач, җиде төн уртасында килеп бездәге капчыгын җилкәсенә аскан да — син күр дә мин күр! Ике-өч адым атласаң, урман авызы — йота да куя, вәссәләм! Ә минем нәвем базарында «сыбызгы саткан» чак булган...

Шуннан соң бер көнне шурф янына Блинов агай килеп чыкты. Гадәтенчә якты йөз белән исәнләшеп, яңа эшнең ничек барышы белән таныштып йөрде дә папирос чыгарып кабызды, Гыймран абзыйга да суздыут бирде. Аннары симез итеп бер суыргач, әйтә куйды:

— Што-то безнең Хисмуттиныч күренми әле, берәр йомыш белән авылга-фәләнгә китмәгәндер бит ул?

Әти авыз кыймылдатырга ашыкмады. Сизеп торам: аның өчен бик кыен иде бу. Ник дисәң, управляюши аңа «баш» сыманрак итеп карый — җаваплы кеше, янәсе. Гыймран абзый, моны күреп, тиз генә бер уйга килде булса кирәк: үзенең күп еллардан бирле шомарта килгән оста урысчасы белән сүзгә кереште.

— Беләсезме, Константин Семенович,— диде ул, булдыра алганча әдәпле генә итеп.— Таджи Хисмутдинович солидный крепельщик, үз эшен ярата торган кеше, шахталарда аны беләләр... Ә монда ул кучерконюх булып йөрүенә бер дә риза түгел иде... Ясно что, моңа берәүне дә гаепләмәде ул, киресенчә, сезне бик әйбәт кеше дип сөйли иде. Без дә кыстап карадык, анда ошамаса, давай бергә эшлик, дидек... Күрәсең, көтәсе килмәгәндер, риза булмады...

— Соң, әйтеп, расчет алып китсә ни булган? — диде Блинов, тавышын күтәрми генә.— Аның бит әле шактый гына акча аласы да калган...

— Җибәрмәс дип курыккандыр ул,— дигән булды әти дә.— Әйбәт кешедән сорап китүе дә читен, качсаң гына инде...— дип көлдерәдерие.

— Веселый был мужик,— диде управляюши көлемсерәп.— Аның белән юлда йөргәндә бер дә күңелсез булмый иде... Хәтта балалар да юксына, ә Галина арттырып та җибәрә: «Кем миңа утын ярып бирер хәзер? дип, пропадет его добрая головушка!..» дип, күзләрен дә юешләндергән була... Што поделаешь...— дип, китеп барды ул аннары. Ә мин Галяны күз алдыма китердем: ничек икән ул мескен? Шулай атасы алдында ук елый микәнни? Каргамый микән чүтри кәминне?..

Әлеге дус кызлар белән көн саен диярлек очрашсак та, мин бу хакта, әлбәттә, сораштыра алмадым. Хәер, алар белән урман сукмаклары буйлап гизә башлагач, андый житди нәрсәләр истән үк чыга, үз сүзебез, үз уеныбыз бетә торган булмый...

Агач яфракларына карт чырай кереп, өсләренә миң төсле тут төшә башлады. Әле кайчан гына без ашаган ап-ак нарат күркәләре, яшькелткара төскә кереп, сагыз белән капланды. Без суырган каен әкәйләре җилдә оча хәзер. Кура җиләге, карлыган-бөрлегәннәр дә әллә кайчан бетте, гөмбәләр дә яңгырда җебеп черде, ә куе яшел майлы буяу белән ялтыраткан төсле вак кына яфраклы нарат җиләге кызарып кына килә әле. Без шуны җыярга йөрибез. Мин аның пешкәнрәкләрен сайлап, ярты гына кружка булса да чәйгә алып кайтам. «Бик файдалы җиләк бу, зәңгеләдән әйбәт», дигән була әти.

Алар яңа шурфны сугып та бетерделәр инде. Төнәген беренче рәт динамит аттырып, яңа руданы өскә күтәрделәр. Авыл кешеләре дә, басу эшләрен бетереп, янадан жыелды, олы шахтада тагын эш кузгалып китте.

Бер төнне мине шунда ат куарга чакырдылар. Анда эшләүче Васька дигән малай сәкенең аргы башында чирләп ята. Болай караганда ансат

кына төсле ул эш. «Өй салуның ние бар — мүкләсе дә чутласы»! Аркан чорнала торган барабаннан олы чүмеч сабы төсле шома борыс сузылып төшә. Шуның башына утырасы да, дилбегә тотып, түгәрәк сукмак буенча ат куасы. Шахта авызындагы зур бадьяны шул аска төшерә, өскә чыгара. Сигналларны гына дөрес үтәргә кирәк. Тик менә шунда башлана икән инде хәлләр: атны әле тегеләй, әле болай бор, артка чигер, алга атлат, тагын туктат, тагын бор. Команда явып кына тора, бар хәрәкәтне дә тиз яса. Әйтерсең машина ул ат — кнопкасын гына басасы! Ә мин ат тотып үскән нәрсәме? Һич кенә дә кәмаленә китереп җиткерә алмыйм. Шуның өстенә, кеше аты бит әле ул: аның телен белүе дә мең бәлә! Үзем болай урысча гына кычкырган булсам да, ат хәйләкәр ул, минем Васька түгеллекне әллә каян белеп тора: җә кәҗәләнә башлый, җә койрыгын яман селтәп биткә чәпәмәкче була, җүнсез. Җитмәсә тагын: «Йоклама-а!» «Каян килгән бу җебегән!?» дип кычкыралар. Мин аның саен кабаланам, кабаланган саен каушыйм, каушаган саен буталам,— еласылар килә, утырган борыс башыннан төшеп качардай булам. Ә качарга йөрәк җитми — хурлык. Күзеңне дә ачырмыйлар инде аннары!

Иртәнге смена килгәнче җаннар чыккандай булды, үземне генә түгел, кешеләрне дә җәфалап бетердем. Көчкә өйгә кайтып кердем дә үз почмагыма аудым. Кая тәгәрәгәнне дә белми йоклаганмын. Шунысы сәер, кич белән әллә уйнап, әллә чынлап тагын чакырган булдылар мине. Кая ул бару! Аллам сакласын, җүләр!..

Ә Васька бик каты ята, күзен дә ача алмый... Нишлисең, туры килде тагы бер төн, аннары... тагы бер төн чыгарга. Инде гел егылам хәзер дип торганда, авылдан яңа малай китереп җиткерделәр, ә Васьканы шул ат белән өйгә озаттылар. Мин дә өч төнлек «шахта сугучы»лыктан котылдым...

Инде җәй бетте бугай, кырау төшә башлады, җилләр дә көзгә борылды шикелле — суык алып килә. Өй уртасындагы тимер мичтә кичләрен ут күренгәли хәзер, аның әйләнә-тирәсендә юеш аяк-чу киптерәләр, янып челтәрләнә башлаган торбасыннан әче төтен чыга, күзгә борынга кереп йөдәтә...

Бер көнне иртәнге якта мин аш пешереп яткан җиргә Наташа, Лида, Люда килеп чыкты. Аякларында ботинка, өсләрендә пальто, башларында бәйләгән бүрек. Мин дә оек-чабатадан хәзер. Хушлашырга килгән болар, иртәгә укырга китәләр икән, сентябрь башы җиткән, имеш.

Наташа куеныннан чыгарып миңа бер китап сузды. Лида каты тышлы дәфтәр бирде, Люда резин башлы матур бер карандаш бирде. Нишли болар? Гел күмделәр бит мине бүләк белән. «Зачем? Не надо!» дип кычкырган булам, ә сөенечтән үземнең авыз колакка җиткән!

— На память! — ди бәләкәе.— Укы, яз, өйрән! Безне дә онытма, рождествога кайткач, тагын килербез синең янга! — Чатылдата гына бу, әллә өйрәтеп килгәннәр тагы.

Рәхмәт-фәләне бәлки әйтелгәндер дә инде, ә менә бүләккә каршы нәрсә бүләк итәргә? Һич нием юк! Әллә ниткән томана бугай мин: шундый чакны күздә тотып бер әйбер саклый белмим. Җәй башында үзем ясаган бәләкәй тырысларның актыккысы белән өченче көн генә учак үрләтеп җибәрдем. Ә сакланган булса, менә шуны биргән булыр идем, ичмаса! Җитмәсә, әлекке шикелле урман да әйләнә алмадык, минем аш пешәргә шактый вакыт кирәк иде әле. Алар озакламый китеп бардылар. Иң элек төпчеге миңа кул сузды, аннары Лида-кырыкмыш, аннары Наташа. Алар сузгач, мин дә суздым, сәер тоелды бу: олыларча кул биреп хушлашкан булабыз...

Аштан соң этиләр ялга ятты, ә мин табак-савыт эшен бетердем дә әлеге китапны актарырга утырдым. Иң элек аның өч урыныннан өч чәчәк килеп чыкты. Кайсысы кемнеке икән? Әгәр яшь буенча салсалар, берен-

чесе Наташаныкы булырга тиеш. Бик нәзек ләпәскәләре алсу-тоныграк булып кипкән нәфис чәчәк, исемен һич белә торган түгел. Уртадагысы күз явын алырлык зәңгәр чәчәк. Нигәдер ул миңа иң матуры булып тоелды, әз генә хуш исе дә килеп тора шикелле. Лида шундый матур чәчәк кыстырды микәнни? Шул кырыкмыш? Ә иң соңгысы — шомырт чәчәге. Теге төпчек чәтертәннеке икәне әллә каян күренеп тора.

Китапның бите саен диярлек җәнлек-җанвар, кош-корт сурәте төшерелгән. Алары белән дә танышып чыккач, җәй көне комга язып өйрәнгән хәрефләр буенча сүзләр укмаштыра башладым. Кайбер урыннарына теш үтеп җитми, авызда әвәләп бетереп булмый торган күп хәрефле озын сүзләр еш килеп чыга, мәгънәләрен дә тиз генә аңлап булмый. Андый урыннарны сикертеп узам да яңа биттән тотынам. Шигырьләр дә шактый очрый. Минем әле урысча шигырьне күргәнем-белгәнем юк иде. Укып-укып карыйм, аксак-туксак килеп чыга, аңлавы да читен. Ә менә берсе җиңел сыман тоелды.

П-и-сь-м-е-ц-о о-т вы-н-у-к-а
П-о-л-у-ч-и-л Ф-е-д-о-т,
Вы-н-у-к е-г-о д-а-л-е-к-о
Вы -г-о-р-о-д-е ж-и-в-е-т,—

дип хәрефләп укып киттем. Монда миңа «внук» дигән сүз генә аңлашылмый иде. Гыйmран абзыйдан сорадым.

— Баласының малае,— диде,— оныкдип тә әйтәләр.

«Оньк-внук», кара, татарчага якын икән! Бу шигырьне күп кабатлый торгач, сүзләп укырга, төртелми сукаларга өйрәндем. Шулай итеп, ул гел күңелгә сеңде. Күрми белгән беренче урысча шигырем шушы булды.

Әйбәт китап калдырган бу кызлар, рәхмәт төшкерләре. Миңа хәзер эш табылды: әз генә бушадыммы, гел шуңа барып ябышам. Әтинең дә читтән-читтән генә күз ташлавын сизәм, минем урысчага ябышып яту бик ошый булса кирәк үзенә. Хат саласы булса, әдрисне дә минем кул астына китереп кыстыра ул хәзер. Кыстырмыйча соң! Аның малае әдрис яза белә бит! Урысча китап укый!..

Ә тышта инде туктаусыз яңгыр ява, кай көннәрне кар катыш була, әче җил сызгыра, чыксаң — битеңә китереп шул яңгырлы карны сылый. Безнең аш та өйдә пешә хәзер. Өсте плитәле киң тимер мич куйдылар, челтәрләнгән торбаларын да алыштырдылар, төтен чыгу да бетте, өй җылы, рәхәт. Минем мәктәп тә шушы өйдә, шул китап өстендә булыр инде быел. Юкса, кая барып укыйсың?..

Алай түгел икән шул... Безнекеләр Пирмегә чыгарга җыена башлады, өс-башларына кышкы кием алырга. Ни өчен шул хәтле еракка? Хәер, бу тирәдә каян тапсыннар. Атиг кибетендә күсе капкыннарыннан башка әйбер сатылмый ич хәзер... Ә инде көне-сәгате килеп җиткәч кенә әти болай диде:

— Әйдә, улым, җыен, син дә чыгарсың... Шуннан илгә озатырбыз...

«Шалт!» итеп баш түбәсенә чүлмәк төшкәндәй бу хәбәргә шаккатып, аларга карадым. Берсе дә минем шикелле гаҗәпләнми иде. Күрәсең, бу хакта алдан сөйләшкәннәрдер инде... Ә мин сөенергә дә, көенергә дә белмәдем. Ярар, җыенырга булгач җыенырга. Үземнең теге-бу нәмәрсәне югаргы шүрлектән алып, актара башладым, яздан бирле кулга тотмаган читек килеп чыкты. Әти аларның башын киңәйтебрәк тегеп бирде, киеп карадым — кысмый да, баш бармакларны авырттырмый да хәзер. Резин кәлүшне кидем — алар да төртми, бик шәп! Инде килеп, ул минем өскә бишмәтне кидерде. Авылдан киткәннән бирле көндез киеп, төнлә ябынып яткан бишмәт, өзлексез «ике сминә» куа торгач, шактый тузган булып чыкты.

Мине әйләндергәләп, карап-карап торды да әти:

— Элә-танагы калмаган икән шул моның, бигрәк тиз бетерәсең әйберне,— диде.

Бу сүзгә хәтер калып, борынны шыркылдатып алдым: кая инде тиз бетерү? Мин ул бишмәтнең кайчан тегелгәнен дә белмим хәзер! Шуны сизгәндәй әти бер юаткыч сүз өстәп куйды:

— Ярар, Пирмедә берәр нәрсә карамый булмас...

Монысы ярый, ичмаса. Дөрес әйтә, яңа бишмәт бик кирәк миңа. Яңа бишмәт! Чынлап та, читтә күпме йөреп, яңа бишмәт тә киеп кайтмасаң, әдәм күзенә ничек күренерсең аннары?..

Үзем белән алырдай ни нәрсәм бар — һәммәсен рәтләп төреп биштәр капчыгына тутырдым. Кич белән әти өстәге күлмәкнең инеч астына чүпрәк салып, эченә бер егерме бишлек, бер унлык кәгазь тегеп куйды. Йокларга яткач ул акчалар нәкъ уң як күкрәк өстендә генә шыштырдап йөдәттеләр.

Иртәгесен без вак-төяк әйберләрне складка илтеп бикләттек тә сәфәргә чыктык. Атигдагы Марфаттәйдән юл ризыгы алып, шуннан ук поездга да утырып киттек, килгәндәге шикелле җитмеш чакрым җәяүләп йөрисе булмады.

Пирмегә килеп төшкәндә коеп яңгыр ява иде. Вокзалдан ерак түгел бер Ибраһим дигән кешегә фатир кердек. Әтинең белгән кешесе икән: «Әйдүк, Пәрхулла абзый», дип каршылады. Күрәсең, ул монда элекке сәфәрләрендә дә кереп-чыгып йөргәләгәндер. Хуҗалар чәй белән сыйлагач, безнекеләр «талчук»ка киттеләр, шундый җир бар икән. Искеяңа кием-салымны, җаның теләгән бүтән кирәк әйберне кулдан сата торган базар, имеш. Алар кичке караңгы төшкәндә генә әйләнеп кайттылар, куллары буш — бер нәрсә тапмадык, диделәр.

Икенче көнне иртүк, тагын яңгыр астында, парахут белешергә төштек. Пристенгә керә торган биек агач күпердән барганда әти бер кешенең җиңенә кагылды да: «Әссәләмегаләйкем, Шәрифулла!» диде. Ул кеше әтине танып, сәламен алды, ике куллап күрешү, исән-саулык сорашу китте. Бу абзый Шәмәк кешесе булып чыкты, әтинең күз күргән егете, әле үндүртенче елны гына Катернислауда бергә эшләгән булганнар. Читтән кайтып барышы икән.

— Алайса, хикмәти хода, бик яхшы булып чыкты бит әле бу! — диде әти куанып.— Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, дигәндәй, менә бу малайны да үзең белән алып кайта күр инде син, Шәрифулла!

Ул абый миңа карап куйды, әз генә елмайды да шикелле.

— Ярар, Пәрхулла абзый,— диде,— олы кешенең сүзен аяк астына салып булмас инде...

Парахут иртәгә иртән китәсе икән. Әле пристенгә дә кермәгән, йөк бушата, йөк төйи, имеш. Билит тә кичсез сатылачак түгел ди. Әти аңа акча чыгарып бирде.

— Билитне үз яныңа бергә ал инде, Шәрифулла,— диде.

Фатирга әйләнеп кайттык, алар тагын базарга, кибетләргә дип чыгып киттеләр. Белмим, Гыймран абзый белән Җыянша абый үзләренә берәр әйбер тапкандырмы, кич кайтып кергәндә арка капчыкларында нидер бар иде шикелле, ә безнең әтинең капчыгы да, кулы да буш иде. «Һич ниямәрсә таба торган түгел, томалангыры», дип сукранды ул. Чәй эчкәч, бишмәтнең тискәре ягын әйләндереп, электр яктысына тотатота караштырды да:

— Җәле, киеп кара әле,— диде.

Кигәч, тагын ут каршына китерде дә, мине уңга-сулга бора-бора, бишмәтне тагын күздән кичерде, җиң очларын, терсәк асларын, чүгәләп итәк очларын карады, чабуларны түбәнгә тарткалап куйды. Үзе тавышсыз гына сызгыра иде — гел тегүче шикелле. Шуннан аягүрә басты да:

— Кара, моның бу ягы ярыйсы гына икән лабаса, ертык-тишеге

күренми,— дигән булды.— Итәк-җиң очларын әз генә рәтләп җибәрсәң, менә дигән булачак!

Аннары ул хуҗа хатыннан кара җеп белән бер кара почкак[1] сорап алды, ике җиң очына да тигез итеп ямау салып чыкты, читтән карагандә җиң авызларына кыршау киерткән шикелле булды, кыршылган төшләрдәге мамык күренми башлады. Итәк очыларының да мамык нык күренгән урыннарын әтмәләп чыкты. Яңадан кидерде, әйләндерә-бора караганнан соң:

— Үтә чыккан булды бу! — диде.— Кайткач, яңаны тектерерсез,— дип тә юатты...

Көрән бумаҗидан куелган бишмәт эчлеге хәзер тышлыкка әйләнде. Шулай итеп, мин «менә дигән», «үтә чыккан» бишмәтле малай булдым. Әтинең дә пошынуы бетте бугай, минем дә җан тынычланды. Кайткач яңаны тектерәсе бит!..

Иртәгесен һаман шул ук яңгыр иде. Суык яктан искән җил белән сибәли дә сибәли. Башка буш капчыкларны киеп, парахутка төшеп киттек. Пристендә Шәрифулла абыйны табып янына утырдык. Ул инде икебезгә дә билитне алып куйган, тиздән юлчылар төйи башласы парахут та кырыйдагы чуен «түмгәк»ләргә арканланган иде. Олылар анымоны сөйләшеп, күргән-белгәнгә сәләм әйтергә кушып утырдылар, ә минем кәеф әллә ничек шунда: ары-бире чапкынлыйсы да килми, парахутын да күргән, пристенен дә күргән — карыйсы әйбер юк. Әллә илгә кайтам, әллә бүтән җиргә китәм — анысы да барыбер. Башны салып утыра торгач, бишмәт чабуларына күз төште. Кара, бу бумаҗи эчлекне шакмаклап сырмаган, буйга гына сырган икән. «Болай булгач, ничава икән әле бу, әйләндергәнлеге бик беленмәс», дип уйладым. Ярлы яманыр да куаныр, дигәннәре шушыдыр инде ул...

Парахут, шактый озак сузып, беренче авазын яңгыратты. Пристендәге кешеләр ду кубып, ыгы-зыгы килә башлады. Без дә кузгалыштык, бәләкәй капчыкны әти җайлап аркага кигезде, дөньямны онытмаска, Шәрифулла абый сүзен тыңларга кушты. Ул абый да кутумкаларын киде, без аның белән парахутка керә торган трап янына килгәч, әтиләр кул биреп безнең белән хушлаштылар. «Шәмседоха җиңгәңә барып сәләм әйт,— диде Җыянша абый үземә генә.— Әйбер-фәлән җибәреп булмады инде, гаеп итмәсен»,— дип өстәде.

«Прхади, прхади!» дип арттан кычкыра башлагач, тагын бер кат саубуллашып, эчкә кереп киттек. Өченче класста икән безнең урын, өстәге сәндерәгә урнаштык. Җылырак булыр, диде Шәрифулла абый. Аннары мин парахут авызына яңадан килгән идем, әтиләр янына чыгып булмады,— олы-олы мичкә тәгәрәтәләр иде парахут эченә. Пристен читеннән карап торган әтиләргә кул гына болгарга туры килде. Алар да миңа кул болгап, бар кер, без китәбез инде, дигәнне аңлаттылар. Күп тә үтмәде, парахут бик моңлы итеп актык рәт кычкыртты да, парларын пошкыртып, кузгала башлады...

Бу парахутта ничә көн, нәрсә ашап-эчеп, ниләр сөйләшеп, ничек кайтканбыздыр — бер кызыгы да булмады. Хәтта килгәндәге шикелле усал кондуктор билит тикшереп тә йөрмәде. Хәер, бу юлы мин «куян» түгел шул инде, пулный билит белән кайтам! Читбиртидә дә түгел, трити класста! Тик шул үкенеч кенә калды: инде килгән чакта ук күңел бик кызыккан өске катка чыгып карамакчы булган идем, Шәрифулла абый җибәрмәде.

— Ярамый, энекәш, тотып алырлар,— диде.— Безнең ише чабаталыны йөртмиләр анда!..

Минем аякта, югыйсә, читек белән резинке! Ник алай диде икән ул?..

[1] Почкак — чүпрәк кисәге.

Караңгылы-яктылы бер иртәдә тагын шул ук Сукулкы пристенена килеп төштек. Без ярга чыкканда тагын шул Пирмедәге төсле чи янгыр сибәли иде. Фатир-фәләнгә төшеп тормадык бугай, яр буенда ук туры китереп, Шәрифулла абый ат яллады. Әйберләрне тимерхут артына бәйләп, минем капчыкны кузла астына тыктык, аннары юеш печәнне әйләндертәләп өстенә менеп утырдык, ат текә тау сыртындагы кыйгач юлдан үргә таба күтәрелә башлады. Яңгырдан тәмам чебердәгән булыр идек, ярый әле, ямшекнең запас кажаны булып чыкты. Икебезгә бер кажан бөркәнгәч, бөтенләй шәп булып китте.

Кайта-кайта көн кич булды. Мамадышка сугылмыйча, сулга борылып, олы юлга чыктык та бер бәләкәй авылда төн кундык. Утыз биш чакрымнан артык киленгәндер, атка да ял кирәк иде. Бетә торган яңгыр түгел икән, иртәгесен без юлга чыкканда тагын шундый ук көн иде. Икесенә бер чапан бөркәнгән остабикәләр шикелле кайта бирәбез икебез бер кажан астында. Шәрифулла абый, бер якка кыйшаеп, папирус көйрәтеп алгалый. Ямшек тә фарт кеше булып чыкты, аяк асты лыжырдык булуга карамастан, атын йоклатмый, әйбәт алып кайта. Акчишмә авылына килеп җиттек, бу тирәләрне мин әзрәк беләм инде, алга таба Алкин, Әҗмәк, Ишки авыллары булырга тиеш. Безнең якта бер сүз бар: башланган берәр эш тиз генә бетәрлек булмаса, «һи-и, Әҗмәк дәлүке әле», диләр. Каян килеп кергәндер. Чынлап та, ул керәшен авылы якын түгел икән, урманнар узып килә-килә күзләр күгәрде, урамын чыгып бетә алмыйча да тас булдык, әллә чакрымнан артыкка сузылган тагы.

Аның артыннан Ишки кул сузымында гына икән. Авыл уртасыннан уңга борылып Тауиленә төшә башладык. Аннан чыккач — Кабык-күпер. Болар икесе дә татарча исемле урыс авыллары. Нигә шулайдыр, һаман белә алганым юк шуны. Ә Кабык-күпердән Шәмәк өч кенә чакрым — үр генә менеп төшәсе. Ахырда ул араны да үтеп, караңгы төшкәндә Шәмәккә килеп кердек. Яңгыр булгангадыр инде, басу капкасы тирәсендә бала-чага күренмәде, прәнник чәчми генә узарга туры килде, ә Шәрифулла абыйның ике кесәсе тулы иде. Аларның өе шушы юл каршында гына икән, урамны аркылы кисеп, капка төпләренә килеп туктадык. Без арбадан төшүгә, өйдәгеләр дә чыгып җитте, капка ачылды, ишегалдына уздык. Мондый чакта билгеле инде: күрешү-куанышу, ыгы-зыгы башлана, мин дә күрешәм. «Тулбайның Пәрхулла абзый малае,— ди Шәрифулла абый,— читтән алып кайттым егетне...»

Әле бик искермәгән нечкә бүрәнәле җыйнак бер өйгә килеп кердек. Шул арада чәй дә кайнап өлгерде. Сәкегә бик матур кижеле ашъяулык җәйделәр, өйдәгеләр куйган сый янына Шәрифулла абый күпереп торган бөтен калач чыгарып куйды, прәнник-канфит, чәй-шикәр шикелле нәрсәләр белән табын тулды. Ямшекне дә, мине дә утыртып, үзләре дә зыр-әйләнә тезелеп чәй эчү башланды. Чит сые белән чәй эчү!

Ямшекне озаткач, миңа түр почмакта бик йомшак урын салып бирделәр, чыланган әйберләрне мич каршына элделәр. Күр инде бу кешеләрне, мин аларга кем соң?..

Иртәгесен сызгырып коймак пеште. Ай, кайчаннан бирле ашаган юк минем ул коймакны, кесәллек онынннан юка гына итеп, яндырмый-көйдерми генә пешергән авыл коймагын! Табынга утыру белән сыпырдым гына үзен тегe бер кияү шикелле. Өчәрне берьюлы дигәндәй кабам да йотам, кабам да йотам! Песмелсезрәк кылангыны үзем дә сиздем сизүен, тик тыелып булмады — коймагы бик тәмле иде шул.

Рәхмәтләрне күп итеп әйткәннән соң өс-башны киендем дә, мескен капчыкны аркага асып, бу яхшы кешеләр белән саубуллашып чыгып киттем. Урамнан кайтмас өчен «Бытый» Зариплар тыкрыгыннан төшеп, басма аркылы чыктым да тау астыннан атладым. Моннан ел ярым гына элек күпме тапкырлар узып йөргән чишмәләр янына җиткәч, эчәсем

килмәсә дә кызыгып, сагынып, бер генә кушуч су эчтем, рәхәт булыр китте. Чит җирләрдә мондый чишмәләрне бер генә тапкыр да очратмадым ич мин...

Шәмәктән чыгып киткәндә көн ачалак та йомалак булгач, яумас дип уйлаган идем. Менә тагын томалап алды, тагын инә күзедәй вак кынә яңгыр сибәли башлады. Тау итәгеннән борыла-сарыла бара торган тар гына сукмактан атлыйм. Болын саргайган, мал йөреп изеп бетергән. Әнә безнең зират та күренә инде, әни яткан зират... Чит җирләрдә йөреп, мин аның янына кайтам... Читтән кайтучылар берсе дә бу кәҗә сукмагыннан йөрми. Кая ул! Алар тимерхутка утырып, дуга башларына шөлдер тагып, тузан туздыра-туздыра юлдан юртып, «келлиң-келлиң» генә басу капкасын узганда прәнникләр чәчеп, ә кайберләре уч тутырып акча — гел бер тиенлекләр генә булсын, барыбер көмеш тәңкә булып күренә торган акча сибеп, авылга керәләр. Артларыннан бер көтү малай йөгереп бара!..

Ә мин?..

Мин, кеше очрамаса ярар иде, дип курка-курка гына, кәкре-бөкре урынтын сукмактан атлыйм. Тәпи-тәпи «келлиң-келлиң» читтән кайтам... Кая инде ул прәнник чәчү! Капчыгымда минем өйдәгеләрне әз-мәз сөендерердәй күчтәнәчем дә, ичмаса, яртышар клиндерем дә юк, буләк-салак булмавын әйтеп тә торасы түгел инде. Чынлап та, әллә ничек килеп чыкты бу. Әти Пирмедә капчыкка берәр нәрсә тыгып җибәргән булса, кайткан булыр иде инде ул, башына килмәгәндер, күрәсең...

Аллага шөкер, беркем дә очрамады, Җамалый тау башыннан авылга кереп, бакчалар аркылы гына үзебезнең каралты артына төштем, абзар капкасының биген кулны тыгып этәрдем дә ишегалдына уздым. Өйалды ишеген шып кына ачып, үзем үрмәләп үскән балчык баскычтан түбән төшәм... Мин өйгә килеп кергәндә, әни кеше йөзлек буенда җеп йомгаклап утыра иде.

— Бәлеш тагы, кайттың дамыни әле? — диде ул.

Түтәй кече якта тәрәшле ясый иде, урыныннан кузгалып каршыма килде.

— Нихәл, ылан,— дип кулларын күрешергә сузды. Бик моңлы булып күренде ул миңа. Ә түр башында уйнап утырган Шамил белән Лотфулла энекәшләрнең исләре дә китмәде. Хәер, мин киткәндә бишектә иде бит Лотфулла — танымагандыр да абыйсын...

Аяктагы читек белән резин кәлүш гел саз булганга идән пычранган, бозау бүрек җебегән, әйләндереп кигән бишмәт итәгеннән лыч-лыч тамчы тама иде.

Читтән кайттым!..

## Юныс байдан бай булам!

Туган авыл... Читтән караганда чокырда утырган Тулбай, «Тулы бай» дигән мәгънәдә булса, исеме бер дә җисеменә туры килми торган ярлы авыл, шулай да Туган авыл! Мин юктагы ел ярым эчендә бер дә үзгәрмәгән ул: шул ук «сәҗдә»гә киткән мескен өйләр, кыйшык-тишек дигәндәй абзар-кура, буйдан-буйга салам түбә. Җитмәсә, ул өйләрнең әйләнә-тирәсенә салам-тирестән «диңгез» салганнар хәзер, кышкы суыктан салам тун! Бу «киеме» тагын да боеграк күрсәтә ул өйләрне.

Чит җирләрдә «дөнья күреп» кайткач, туып үскән авыл бик тә жансыз, бик тә күңелсез күренде, шактый вакыт кыланә алмый йөдәп беттем. Кулга тотардай зурдак эш тә юк: утын ярам, абзардагы өч баш сарык белән кызыл тананың астын җыям, салам көлтәлим, өйдәгеләргә чабата ясыйм. «Карагайлы»да өйрәнгән җукә башмакны да үреп кидем аякка. Тик аны күреп шаккатучы гына булмады...

Көз ахырында өзлексез яңгырлар, ниһаять, туктап, җир туңды, су өсләре боз белән капланды. «Шәрә кыш» сымак бу көннәрдә без әни кеше белән урман кисәбез хәзер. Теләсә нинди эшкә батыр ул. Пычкы тартканда, буй утынны өемгә салганда манма тиргә батыра ул мине. Җиңелен түгел, авыр башын үзе күтәрә. Ә кайтканда буй сузып буш атлауны бер дә яратмый.

— Әйдәле,— ди,— бер-ике буй булса да жукагач алыйк, чабаталык булыр.— Һәм өчәр буй яшь җүкә агачы җиде чакрым юлны безнең җилкәләрдә кайта. Кеше эшенә чыкканда да рыядан гына селкенеп йөрми ул, имәндәй ирләр рәтендә торып, алты чабагыш белән көн буе дөп-дөп ындыр суга — эһ тә итми. Шуның белән утын китертә, курмы кайтарта. Ә кыштан алып яшел язга тикле безнең өй эченнән стан чыкмый икән хәзер. Кемгә кижеле ашъяулык, шакмаклы тастымал, кемгә аршин башлы чүпләм сөлге, кемгә өч көреле нечкә чыбылдыклык, кемгә капчык-тобыршалык, кемгә киндер, кемгә һәр төрле алача ыштанлык — алар һәммәсе дә безнең өй «фабригендә» эшләнеп чыга. Әни кеше боларны үзе генә сукмый, үз һөнәренә түтәйне дә өйрәтә. Ә ул инде уналты тутырып килә торган кыз, мондый һөнәр аңа бик кирәк булачак. Мин дә бер заманны «катынша»ланып киттем, стан арасына кереп сөлге чүпләме жыярга һәм үзем сугарга өйрәндем. Бу инде «эше юк — эш тапкан...» дигәндәй, бүтән файдалырак мавыгыр нәрсә булмаудан килеп чыккандыр. Чынлап та, мин ул кышны ничек уздырырга белми аптырап беттем. Мәдрәсәгә барган булган идем, анда гел шул искечә икән хәзер. Хәзрәт көненә бер генә тапкыр күренә, калган вакыт малайларның үз кулында: ни тели, шуны кылана. Ә мин инде андыйлардан бизгәнмен. Себердә өйрәнгән тәртип һәм өч сыйныф бетереп алган гыйлемлек бик зур икән минем. Монда миңа уку ягыннан тиң малай бөтенләй юк икән хәзер. Ә мулла абзый минем берүземне генә алга таба укытырга теләвен бик курсәтмәде. Бәлки булдыра да алмас иде, ул бит яңача укымаган. Шулай итеп, мин анда гел йөрми башладым.

Әни кешенең минем мәдрәсә ташлауга бер дә исе китмәде. Дөньяда уку-язусыз да менә дигән итеп яшәп булуына бик нык ышана иде ул. Ә язга таба миңа «бик әйбәт» эш табып бирде.

— Син акылсыз малай түгел,— дип, салпы якка салам кыстырудан башлап җибәрде сүзен.— Әрәм-шәрәм итүне яратмыйсың, укымышың да бар, чутны да яхшы беләсең,— син бай булыр өчен туган малай!..

Мин тавышсыз гына көлеп куйдым. Ана кеше алдында ихахайларга ярамый бит. Шуның өстенә мин аның кайсылай таба каерганын да аңлап бетермим әле.

— Бер дә көләсе түгел,— дип дәвам итте ул.— Шәмәктә безнең Җунис абый белән Миннехан абыйлардан бай кеше бармы? Юк! Бөтен Шәмәгендә юк! Алар нәстәдән башлаган? Каләмфер-бадьяннан башлаган. Менә сиңа да шулар кәсебенә тотынырга кирәк, шулардан да уздырып баерга кирәк!

Тагын бик күп сөйләде, бик күп кызыктырды ул, мин инде гел баеп беткәндәй тоя башладым үземне. «Ничек итсә итте, Мәкәрҗәгә китте» дигәндәй, ул мине үзебездән биш чакрымдагы Чәбиягә алып барды да Фазлулла байлар кибетеннән тугыз тәңкәлек вак тавар алып бирде. Бу акча мин кулмәк инечендә саклап кайткан утыз биш сумның бер өлеше иде. Кайчандыр үзем белән чүбек җыйган Мәхмүтнең кырык тартмалы бәләкәй иске сандыгы бар икән, шуны сорап алып, кырык төрле таварны әчена бик килештереп тезеп чыктым һәм киттем авыллар буйлап. Капка саен, тәрәзә саен тукталам да:

— Вак таварлар кирәк түгелме-е? — дип кычкырам. Өйгә чакырып кертсәләр, баулы сандыкны йөзлек буена куеп, ачып җибәрәм. Ниләр генә юк аның эчендә! Бөтен кызыктыргыч әйберләр капкачның эч ягына тезелгән: төрле-төрле ялтыравык төймәләрдән муенсалар, «гәрәбә» кул-

баулар, ефәк тасмалар, җем-җем килеп торган «балык тәңкәле» кәйтәннәр, чәчтәңкәлек киң кара тасмалар, «алтын-көмеш»тән койган йөзек, беләзек, балдаклар, түшкә кадый торган күбәләк-чикерткәләр; әллә ничә төстәге чигү җепләре, тамбур инәләре, бияләй инәләре, тегү инәләре, ак, кара, кызыл кәтүкләр; эреле-ваклы сәдәпләр, каптырмалар, «пыртлый»лар; ислемай, гөлсирин, дарчин мае, гатырша мае, чәч мае, «мәтликәп»; астагы тартмаларда кара борыч, кызлар ярата торган дарчин, каләмфер, бадыян, карчыклар өчен эмбер тамыры, татлы тамыр, тәмле сабыр, кәлгән тамыры, җиңгиләр өчен кызыл, яшел, «кугавай», зәңгәр буяулар, малайлар өчен әллә ничә төрле кармак. Кыскасы, кемнең җаны ни тели, шуның барысы да бар миндә! Хәер, алай ук түгел бугай. «Сандугач теле», «күгәрчен сөте», «фәрештә керфеге», «сөйдергеч даруы», «таракан дагасы», «җылан мөгезе» сорап, җелекне киптерә кайбер чәчрәп торган кызлар. Мин аларга җавап таба алмыйча, бурлаттай кызарып калам. Ә кайберләре, юма сүзләр белән сыйпаштырып, ислемай шешәсен алъяпкыч асларына озатырга маташалар. Ике генә түгел, сигез күз кирәк икән кырык тартмачы егеткә!

Шулай йөри торгач, тирә-як авылларны гизеп чыктым. Бара безнең сәүдәләр! Кайтам да бакыр бишлекләрне санарга тотынам. Хәер, алар күп түгел хәзер, патша сурәте сугылган ун, унбиш, егерме тиенлек кәгазь маркалар тулган була. Патшаның үзен чүпкә чыгарганнар дип ишетсәк тә, кәгазь акчалары чүпкә чыкмый әле. Җыелган чүбек-чабык, иске бияләй, җон оек шикелле нәрсәләрне Тәкәнешнең Миргазиз байга менгереп бушатам, кирәкле таварны да шуннан гына алам хәзер.

Инде март ахырының җылы көннәре башлангач, ерак сәфәргә чыктым. Бездән унике чакрымдагы Өскебаш авылында Майтүти бар иде бит, өй борынча дигәндәй эзләп-сорап, шуларга барып кердем. Малай гына булсам да, Майтүти үзе дә, җирән чәч, сакал-мыеклы, озын чандыр гәүдәле Юлтимер җизни дә, дүрт кенә бөртек кызлары да бик туганнарча каршыладылар. Майтүтине күргәч тә, сабыйларча мин аңа сыендым. Аның тавышы, сөйләшүләре, ягымлылыгы, бөтен кыланышхәрәкәтләре нәкъ әнинеке шикелле тоела иде. Мин аны бик нык сагынганмын икән, култык җылысында бөтенләй эреп калдым.

— И балакаем, гел үсеп беткәнең икән син хәзер, күзләр генә тия күрмәсен! — ди.

Беркая чыгармыйча, тәүлек буе кунак иттеләр. Килгәч тә куе сөтле чәй, туйганчы ашарлык ап-ак йомшак кесәллек күмәче, капламыш[1] төбәсеннән ак май. Унике чакрым юл килгән малай өчен моннан да тәмле бүтән нәрсә бар дөньяда! Ә кичен тукмачлы каз ашы, каз боты! Шуның янына ярка-ярка өреле бәрәңге. Иртәгесен тагын каз мае четердәп торган кайнар коймак. Казлары бик күп булгандыр, ахры, инде яз җиткән: ите дә, мае да һаман бар үзләрендә.

Бу хәтле зурлап кунак итүләренә ояла башладым. Кем соң мин? Юеш танау гына бит әле! Тормышлары да әллә ни түгел сыман. Ат, сыер тотсалар да, вак маллары артык күренми. Ике үсмер кызы белән минем чананы тартып бакча башындагы ындырларына печәнгә мендек. Олырак башлы кешенең бүрегедәй генә бер сомы кибәне тора, күп дигәндә имана ярым җирне каплар. Арыш кибәне юк... Сугылган салам өеме белән бәләкәй генә печән кибәне күренә тагы. Хәер, ир затыннан җизни берүзе бит, бу мескен дүрт кызга җир тәтеми. Димәк, алар да безнең шикелле бер имана белән көн күрә инде.

Шушы хәлдә җизнинең ат-сыер тотуы мине бик гаҗәпләндерде. «Ничек асрап чыгаралар икән? Ник безнең юк?» дигән сораулар аптырата мине. Әллә безнең этинең юри ат тотасы килмиме? Үзем читкә

[1] Сөян агачыннан кырып капкачлы итеп ясалган савыт.

киткәч, кем карар дип куркамы? Ә мин нәрсәгә? Шушы яшемә житеп, ат та карый алмас идем микәнни?..

Житмәсә, бәхетсез хәерчегә жил каршы дигәндәй, асрамага алып үстергән танабыз да мин монда чыгар алдыннан гына үлеп куйды бит әле безнең. Ул алты айлык «кыдыл бодау»ны арыякның Зәйнеттин абзый хатыны биргән иде, инде сыер булып килә һәм жәйгә бозаулавын көтә идек... Ә бер иртәне мал асты карарга чыксам, күзләрем акайды да калды: зур гәүдәле сыерыбыз абзарның урта бер жиренә чалкан килеп төшкән дә, аякларын өскә тырпайткан, мөгезләре тирескә батып кергән, башын кыйшайтып, телен аркылы тешләгән, йоннары кабарган. Ята бу мескенкәй бурадай булып...

Йөгереп кереп өйдәгеләргә әйттем, Мактый бабайны алып чыктым. Беребез дә берни белә алмадык. И кызганыч та булды соң!.. Мактый бабай ат жигеп керде, жыйнаулашып сыерны чанага салдык һәм басу түрендәге мал зиратына илтеп куйдык.

Шулай итеп, «авызга сөт тия, сөт!» дип торганда гына: «Ашыкма! Көт! Борыныңны сөрт!» диде бәхетсезлек. Әйе, көтәргә калды. Ә кайчанга тикле?.. Житмәсә, шул сөт дигәнен ник шул хәтле яратамдыр. Күрше Һадиулла, анасы сөт ашарга кушса, «аем нә!» дип, борынын жыерган була. Ә мин чүлмәге белән эчеп бетерер идем! Хәтта көн саен сөтле чәй генә эчсәм дә, бик риза булыр идем әле.

Күңелдә беркемгә дә әйтелмәскә тиешле бер уй туып килә. Эх, барып чыкса, шәп тә булыр иде соң?! Ә чынлап торып тотынсаң, ник барып чыкмас икән? Менә шушылай авылдан-авылга йөри-йөри кәсепләрең уң булып китсә, маяны тып-тын гына жыя киләсең дә көннәрдән бер көнне сатудан кайтышлый сыер житәкләп кайтып керәсең! Әшлекле үги әнинең күзләре маңгаена менә! Әй, түтәй сөенә, гөлкәем! Ә мин, үзебезнең тегермәнче Сапый кук, бөйрәккә таянып кына карап торам. Озак та узмый, беренче бозау, ак тояклы дүрт аягын тырпайтып, идәнгә баса. Безнең авыз-борын сөт-катыкка чума! Ә шул ел эчендә мин тагын мыштым гына акча жыеп, алмачуар бер колын алып кайтам. Әти читтән йөреп кайтканчы ат та бар, сыер да бар! Менә, сөйләшеп кара син хәзер Шәйхелисламм дигән олы малаең белән! Баюның башы шуннан башлана!.. Биш ел эчендә мин Шәмәк Юныстан да, Чәбия Фазулладан да, Тәкәнеш Миргазиздән дә баерак булып китәм!..

Кич буе уйлап яткан һәм төштә күргән шушы бәхетне өндә табарга ашкынып, иртәгесен әлеге бәләкәй сондык белән өй борынча йөрергә чыгып киттем. Йорт саен диярлек чакырып кертәләр, ни дә булса алмый чыгармыйлар. Чакрымга сузылган зур авыл икән бу, әллә күпме тыкрык урамнары да бар тагы. Бөтенесен йөреп чыкканчы өч көн узып китте, таварны да кырып алдылар. Алдагы көннәрдә якындагы Аксыбы һәм Казаклар авылына да йөреп килгәч, әйбер сондык төбендә генә калды. Төеп тутырылган өч капчык чүбек жыелды, акча пыртманитка сыймый башлады. Бер өйдә миңа, алган әйберләре өчен, уч төбе хәтле генә яңа кәгазь акча суздылар, егерме тәңкәлек — Керенски акчасы икән. Бик теләп алыштырып бирдем — пыртманит бүксәсе бушап калды...

Кичләрен Майтүтәйнең кече кызлары мине уйнарга алып чыга. Бик олы сымак кылансам да, малайлык бетмәгән икән әле: уйныйсы килә. Урамда яз, жылы, гөрләвекләр ага инде. Түбәләрдә күгәрченнәр, чыпчыклар үзләренчә бәйрәм итә. Баксана, хәтта сыерчыклар да килгән! Табан бөгүче байларның өй кыегындагы челтәрле оя башында өздереп сайрыйлар. Әллә каян ерактан узган кыр казы тавышлары ишетелгәндәй булып китә. Ник яратам икән шул кошларны бу хәтле! Алар ел саен мине моңайталар, куандыралар, әллә кайларга чакыралар...

Хафизә белән Таһирә мине су буена алып төшәләр. Инешләре безнекенә караганда бәләкәй генә икән, боз өстенә инде кызгылт-болган

чык су чыккан. Арыяк яр буенда гына, олырак печән чүмәләседәй, ике таучык күренә. Борынгы заманда Йөзмән бабай дигән кешеләре булган, имеш. Шул бабай каты сукадан кайтышлый каршыдагы текә тау башына утырган да чабаталары эченә тулган балчыкны яр буена кагып калдырган, ике чабатадан ике таучык булган, имеш. Мондый риваятьне әлек тә ишеткәнем бар иде, тик анда Алып бабай дип атыйлар, ә боларның үз бабалары бар икән. Йөзмән бабай миңа никтер якынрак тоела, безнең Тулбай басуында «Йөзмән күле» дигән урын бар, әллә шул бабай күле булды микән?..

Инде кары беткән түбә тыкрыкта минем шикелле үк кыбырсыклар «йөгереш туплы» уйный башладылар. Ятсынып торсам да, мине дә бөтереп алдылар. Бу уенда хәлдән тайганчы йөгерергә, авыз арганчы кәләргә туры килә. Иң кызыгы «санау» икән аның. Уенга керешкәнче, кем алдан туп чөяргә, кем йөгерергә тиешлекне әллә нинди ят сүзләр белән такмаклап, санап чыгаралар:

Атсый, батсый, шәмәмшүр,
Мәмшурәкәй, битәмбүр,
Мәмдухиди бирәнтис,
Кәжә паю дим тифлис!

Нинди сүзләр икән бу? Моңарчы мин белгән санауларның бик күбесе аңлашыла иде, ә монда аптырарсың. Ә үзе матур янгырый, отып аласы килә. Тукта, авылга кайткач малайларның күзен ут итим әле бу шәп санау белән!

Бишенче көнне чанага сандык белән өч капчык чүбекне салып бәйләдем дә кайтыр юлга чыктым. Бүтән авылларга кереп йөрерлек әйбер калмаган иде инде. Сандыгыңны ачып җибәрүгә туп-тулы малың булмагач, сиңа рәтләп күз дә салмыйлар, дәрәҗәң генә төшә. Ә берәрсе: «И, ылан, өч тиеннек әйбереӊ бар икән, ярты тиеннек песи төчкерегә бир әле!» — дип мыскыл итсә, нишләрсең?..

Инде бата башлаган җепшек кар өстеннән өч капчык чүбек төягән, сандык утырткан чананы тартып, биек үрләрне менгәндә бозау бүрек астыннан пар чыга, әйләндереп кигән теге бишмәт, толыптай җылы тоелып, арканы тирләтә.

Ниһаять, ун чакрым юл кичеп, Түбән Тәкәнешкә кайтып җиттем дә җелеккә тигән капчыкларны Миргазиз байның чүбек-чүпрәк таудай өелгән лапасына бушаттым. Аннары өй астындагы таш кибетеннән сандык тулганчы тавар алдым. Хәзер чана да җиңел, күңел дә көр. Җырлый-җырлый Тәкәнеш үренә килеп җиттем.

Тәкәнеш үре... Белмим, Тулбайның башка кешеләре ничектер, ә мин шушы үрдә тукталмый китә алмыйм. Алты яшемнән бирле шулай. Әни үлеп, чит авылда кышлаганнан соң, туган авылга беренче тапкыр Хөршит түтәй белән җитәкләшеп килгәндә, шушы урынга туктаган идек, шушындагы ямь-яшел чирәмле «димнәмир баганасы» төбенә утырып, зиратка карап елашкан идек. Бу юлы да шул багана төбенә килеп утырдым. Аның инде кояш җылыткан бер почмагы бөтенләй коры диярлек. Иң әлек зират, аннары уч төбендәгедәй булып Тулбай күренә. Бу юлы миндә моңаю да юк. Бу юлы күңелдә үзем дә аңламый торган яз шатлыгы һәм «сәүдәгәр» шатлыгы. Себерчә әйткәндә, шүткемени: кесә тулы акча, сандык тулы тавар! Пыртманитны чыгарып, барлык «мая»ны санап карыйм. Иң әлек Керенски егермелеге шыштырдап килеп чыга. Учка җәеп салу белән әллә ниткән ирәю хисе биреп куя. Кара, патша акчасы да сәмрәү кошлы иде, бу да сәмрәүле икән, тик моныкы икенче төрлерәк. Хәер, яңа патшаның яңа сәмрәве булырга тиештер инде ул. Калганнарын саныйм: маркалар, көмеш-бакырлар тагын алты тәңкәгә тула. Җәмгысы егерме алты сум саф акча. Шуның өстенә сандык тулы тавар! Туктале, бик зурга китә түгелме соң бу? Әле генә тугыз тәңкә

белән башлаган кеше бит мин. Инде бергә — биш була язган бугай. Эти күпме вакыт җир казып, минем күлмәк инеченә утыз биш тәңкә тегеп җибәргән иде, ә мин аны тулар-тулмас ике ай эчендә тапкан булып чыгам. Болай булгач, тана турында ныклабрак уйларга мөмкин ич хәзер. Тик кайсысын алдан: тананымы, Алмачуарнымы? Хәер, ир-егеткә башта ат кирәк. Бу егермелекне кайту белән эни кеше кулына тоттырыйм әле — ике күзе ут булсын! Һәм шунда ук Алмачуар турында сүз куертырга кирәк. Аның әле кулында эти җибәргән акча да бетмәгәндер, әллә үз саклыгы да бардыр, һәммәсен бергә кушкач, нижәли колынга җитмәс икән?

Исәп-хисапларны шушындый матур уйлар белән тәгәлләп, юлыма юнәлдем. Үрне төшеп зират турындагы иңкелгә житү белән аптырап калдым: калку басулардан төшкән гөрләвекләр монда яткан калын тигез кар эченә җыелып, олы бер «быламык күле» ясаган, юл катысы да ашалып беткән, кай урынга бассаң да, төшәсең дә китәсең. Моңарчы да бата-чума кайткан идем, ә монда инде күзне йомып ерырга туры килде. Кулга бер маяк таягын табып, оек-чабата белән тездән бата-бата, «быламык күлен» аркылы кичтем. Ярый әле, чана батмады да сандыктагы «мал» чыланмады. «Әт-тә-тә!» икән ул язгы кар суы — аякларыңны мең чәнечке куырып ала! Лычкылдаган аяк-чу, ката башлаган бишмәт итәкләре, җиңнәр, бияләйләр белән лыштыр-лыштыр йөгерә-йөгерә, шык-шык орынган тешләрне туктата алмыйча, начылый өйгә кайтып кердем.

Өйгә кайтып керсәм, сәкедә чәй табыны, ә түр башында эти утыра. Менә сиңа кирәк булса! Мин аның читтән ничек кайтып кергәнен тагы күрә алмый калдым. Кайчан булды икән: төнләме, көндезме? Минем шикелле мескен булып, тау асты сукмагыннанмы, әллә олы юлданмы? Прәнник чәчепме? Хәер, апысы булмас инде хәзер. Прәнник дип катырганнары арыш камыры диләр, авызга ала торган түгел, имеш.

Үзем лычкылдаган өс-башны, оек-чабаталарны чишенәм, үзем этинең болай көтмәгәндә кайтып керүен уйлыйм. Әле үктябрдә генә мине озатып җибәргән иде, април башында үзе кайтып килгән. Нишләп ашыкты икән, тагын эшләре уңмады микәнни?

Хөршит түтәй мич башыннан итек китереп бирде. Кыска гына кунычлы булса да, олтанлы киез итек бар бит әле минем. Кар суыннан ап-ак булып, тиреләре бөрешеп чыккан аякны майдай җылы итеккә тыккач, җаннар оҗмахка кергәндәй булды. Кул юып, сөенгән сымак елмаю белән табынга утырдым, ә күңелдә бөтенләй киресе. Барып чыкмады болай булгач, җилгә очты теге матур уйлар... Мин аны бирәр елсыз да көтми идем әле, ә шул бер ел эчендә бик шәп сату итеп, кайтуына колын алып, тана алып шаккатырмакчы идем үзен!..

Чәй эчкәндә чит хәлләрен сөйләшеп утырдык. Дөньялар болай үзгәреп киткәч, Гыймран абзый белән уйлашканнар да ил җиренә кайтасы иткәннәр икән, ә Җыянша абый, көзгә хәтле эшләмәкче булып, шунда калган. Мин киткәч анда әстрияк әсирләрен китереп тутырганнар, яңа баракта бергә торганнар, олы шахта да ачылган, шурфларны ташлап бар да шунда күчкәннәр.

— Әстрияклар бик әйбәт кеше икән,— ди эти.— Үзләре кече күңелле, якты чырайлы, үзләре бик гадел, шырпыңа да кагыла торган түгелләр, без алар белән бик тату яшәдек,— ди. Аннары бер бәләкәй кесә кенәгәсе чыгарып миңа суза. Ул аларның миңгә хәтле санауларын, үзара алмашырга кирәкле егерме-утыз җөмләләрен язып алган. Хәзер шуны гел үземә тапшырды: «Син дә өйрән, кирәк булыр», дигән сүзедер инде. Шулай да, бер уйласаң, маладис кеше безнең эти!

Инде килеп сүз минем хәлләргә күчә. Кәсеп кылыштан исәп-хисап бирәм. Пыртманиттан яңа егермелекне чыгарып, эни кеше дә күрсен өчен кулда озаграк уйнаткандай итеп, эти алдына салам. Аннары кал-

ган вак-төякләрне дә шунда бушатам. Моны күргәч, әни кешенең күзләре, чынлап та, бизәкле яңа кашык асты хәтле булып елтырый башлады. Әти дә, кулына егермелекне тотып, беравык елмаеп миңа карап торды. «Бакчи бу күн танауны, күпме акча китергән бит!» — дип уйлады бугай. Аның шул җылы күзләре үсендергәндер инде мине: тиледән сорама, үзе әйтер дигәндәй, әле шушы айларда гына эчкә оялап килә торган баю хыялларымны иреннәрне чапылдата-чапылдата сөйләп бирдем.

Түр башында аяк бөкләп утырган әти мыек астыннан гына көлемсерәп чәй эчә. Шуннан мин, башлаган сүзне бөтенләй чуалтып, гел икенче бер нәрсә турында әйттем дә куйдым:

— Әти, бу акчага бер тай алып җибәрсәк, ничек булыр икән?

— Тай? — диде ул, аңлап җитмәгәндәйрәк итеп.— Һемм... тайның бер тояклыгы булган инде, улым,— дип көлеп җибәрде аннары.— Калган өч тоягын гына табасы бар икән...

— И, безнең Шәйхелсам әлләниләр булдырыр әле ул! — дип, әни кеше дә минем салпы якка салам кыстырды. «Әнә безнең Юныс абыйлар...» дигән кыйссасын да өстәде. Аннары сөтле булабыз дип торганда гына сыерның егылып үлүе хакында бик кызганыч итеп сөйләп бирде. «Әллә башта сыер җүнәтәсе микән, бала-чагалы өйдә сөтсез бик читен», дигән зарын да әйтте. Әтинең кәефе яхшы иде.

— Була ул! — дигән булды.— Ат та алабыз, сыер да!

## Гаҗәп хәлләр булды бу җәйдә

Әтинең читтән кайтып төшүе бик яхшы булды әле.

Елдагыча шаулап килгән язгы ташулар, сабан туйлары узуга бөтен кеше чәчүгә чыкты. Без аны кемгә чәчтерер идек? Ә ул мин сондык сөйрәп йөргән арада моның да җаен табып куйган. Балта остасы Шакир абзыйның үз янында калган Ибраһиме дә, башка чыккан олы малае Сөләйман да сугышта иде, икесе дә пленгә эләккән. Йортта сиксәнгә җитеп бара торган карт белән карчык та киленнәре Шәмсенур җиңги генә. Атлары бар, ике имана җирләре бар, ә чәчәр кешеләре юк. Менә шул ат белән аларның ике иманасын, үзебезнең бер имананы чәчәргә килешкән ул. Мин аның янында тырмачы булып йөрим. Бу минем беренче тапкыр буразнага басуым. Атлары юаш икән: әйткәнне, чөңгергәнне, сызгырганны тыңламыйча, әллә кая сөйрәп китми. Шулай да әти минем арттан күзәтеп бара, җир башы почмакларыннан атны ничек борырга, чи калмасын өчен тырманы ничек тартыбрак салырга икәнен өйрәтә. Игенчелек гыйлеменең беренче сабакларын алам.

Безнең бу җирдәге эш беткәч, «Бүләк авызы» басуындагы Шакир абзыйлар җиренә күчәбез. Әти чәчеп барган тубалдан һич көтмәгәндә эре-эре кызгылт йомыркалар сибелә. Баксаң, Шәмсенур җиңги орлык эченә күкәй салып җибәргән икән. Менә бәхет! Мин аларны әти артыннан җыя бардым, җир башына утырып ашадык та янә тырмага тотындым. Шәмсенур җиңги соңыннан да гел шундый «майтамар» куллы булды. Кай басуга гына барсак та, әбәт төенчеге кыстырмый калмый, ә ул төенчектә дучмактыр, катламадыр, тәбикмәктер шикелле «коры-сары» белән бәләкәй генә бер тәпәндә катык та була, өстенә сары майлы каймак утырган куе катык!

Шәмсенур җиңги үзе «яшь килен» әле ул. Ибраһим абый никрут булып йөргән чакта ук бер-берен яратыша башлаганнар. Яратышсалар да кавышырга өлгермәстән, егеткә солдат хезмәтенә китәргә туры кил-

гән. Өч ел көткән аның кайтканын, ә кайткач инде, туй ясап бергә тора башлаганда гына сугыш чыга да, өч айлык килен тагын утырып кала. Менә хәзер тагын дүртенче елын көтә инде ул аны. Ә Ибраһим абый герман кулында, әле кайчан әйләнеп кайтыр бит?..

Без язгы чәчүне генә түгел, кара көзгә хәтле булган бөтен атлы эшләрне бергә башкардык. Бер көнне каты сукада мин үзем генә калдым. Әти беренче буразнаны салды да, каядыр барасы булыпмы, кайтып китте. Ул сукалаганда бик җиңел генә сыман күренгән иде бу эш. Үз башыңа төшкәч, кәҗә маеңны чыгара икән. Бу «көңгер сука» дигән агач машинаның ике сабыннан күтәреп, гел җайлап кына бару өчен әллә нихәтле көч кирәк иде. Каты урында сука өстенә бөтен гәүдәң белән басмасаң, төрән өстән генә җирне ертмачлап, буразнадан ук чыгып китә. Йомшак җирдә аска ук кереп кадала да ат тарта алмый башлый. Суканы да күтәрәсе бар, дилбегә дә тартасы бар. «Нә-сәнә, үләт тигере-е!» дип, әче тавыш белән атка да кычкырасы бар, аны туптуры гына атлатып, кәсне тип-тигез генә каплатып та барасы бар, җир башыннан борылганда төрән борынын бөтенләй өскә чыгарып, сикерт-ми-нитми генә тагын эзгә саласы да бар — җан тирләрем чыкты. Кояш күренгәндә башлаган дүрт саржинлы бу җирне бетергәнче төш ауды. Ә сыйфаты аның ничек булгандыр — ярый әле, әти килеп күрмәде. Юкса, укытыр иде ул миңа әлхәм сүрәсен, унөченче яшьтәге малай бит инде мин.

Әмма ничек кенә булмасын, ат янында миңа бик рәхәт. Юк, атланып юырту, сугарып кайтуда гына түгел кызыгы. Ат тирәсендә кайнашу — аңа башак бирү, печән салу, астын көрәү, җигү-тугару, чөелдерек тарту, дилбегәне үзең тотып басуга бару-кайту, йөк өстендә торып печән төяү, арбадагы әтигә көлтә бирү, бастырык бавы тартышу, төннәрен Бәкәш болынына сакларга чыгу — менә шулары кызык иде. Дөрес, бу кеше атын карау, кеше арбасына утырып йөрү, тик барыбер рәхәт! Шул җәйдә мин атның бик акыллы мал булуын аңладым. Үзе сөйләшә белмәсә дә, ул синең бөтен сүзләреңне төшенә, бөтен хәрәкәтеңне тиз сизеп ала. Хәтта шаяра да белә, хәтта синең җилкәңә башын куеп, дус иткәндәй була, моңайгандай итә...

Сабанны шулай әйбәт кенә чәчеп бетергәч, шифалы яңгырлар теләп, имин җәйләр, тук игеннәр көткәндә, «патшасы төшкәч, сугышы да бетсение» дип, ут эчендә йөрүче солдатның кайтып килүен өмет иткәндә, бөтенләй сәп-сәер кире хәлләр булгаларга тотынды. Иң әлек көннәр һаман чалт аяз торды, төннәрен ап-ак кырау төшеп, яңа чыккан бәрәңгеләрнең беренче яфракларын көйдерде. Аннары, шундый төннәрнең берендә, басу капкасы янындагы Мәннәп абзыйларның моржасыннан тубал хәтле ут күтәрелеп, зыр әйләнә-әйләнә очып барган җиреннән Кара чишмә болынына килеп төшкән дә, ут койрыклы, ялкын ялы кызыл арыслан кыяфәтенә кереп, Кабыккүпер авылы өстеннән бер сикерүдә Карабаш камышлыгына төшеп күздән югалган, имеш. Моны бөтен малай күргән, мин генә йоклап калганмын.

Шуннан күп тә узмады, авылда бер кеше пәйдә булды: җилкәсенә төшкән салам чәчле, шәһәрчә киемле, тезенә хәтле шнурлап менгергән сары батинкәле. Кулында озын саплы, тирән төпле агач чүмечкә охшаган бер нәмәкәе бар,— мандалин дигән уен коралы, имеш. Ул көн саен шуны тотып йөрде, бер генә тапкыр да уйнап күрсәткәне булмады, беркем белән бер авыз сүз сөйләшмәде. Ничек кинәт пәйда булган булса, шулай кинәт юкка да чыкты. Без тик шуны гына белдек: Дусай очындагы Сәйфи абзыйларның ниндидер туганы, имеш, ниндидер каладан «авыл күрергә» кайткан, имеш...

Ул югалуга бер атна уздымы-юкмы, болытлар куерып, яшеннәр чатырдап йөрде дә, бездә ямьйчә, кояш баешына китеп тә барды. Андагы ерак тау өсләрендә күренгән күксел урманнар артына шул кара

болытның куш имән юанлыгы бер тармагы сузылып төште. Без моны кичке уңайда Җамалый абзыйлар тау башыннан карап тордык. Алсу-кызыл күк читенә кап-кара багана сузылып төшүе серле дә, шомлы да булып күренә. Нинди шомлы тоелса да, малайлар курыкмый, нинди серле булса да, малайлар барын да белә: шул күксел урманнар артында тагын да иксез-чиксез урманнар җәелеп китә, имеш. Шул иксез-чиксез урманнарның иң карурманы уртасында әллә ниткән сихерле, әллә кемең дә төбенә төшеп җитә алмастай төпсез бер күл бар, имеш. Шул төпсез күл төбендә алты башлы аждаһа ята, имеш. Әнә ул куш имән юанлыгы кара болыт шул алты башлы аждаһаны суырып алырга төшкән, имеш. Бугазыннан буып, суырып ала да Каф тавы артына илтеп ташлый, имеш, ул аны! Озак көттек бу куәтле болытның шул явыз аждаһаны суырып алып менеп киткәнен. Тик мин күрә алмадым. Шамил энекәш килеп алды, өйдә ачуланалар, имеш...

Иртәгесен Гыйльметтин белән Һади сөйләп бирде: караңгы төшеп килгәндә кара болыт тегене тәки суырып алган да күтәрә башлаган. Алты башлы аждаһа, бер дә менәсе килмичә, як-якка болгана-тулгана тыпырчынып тартыша торгач, юан койрыгын өскә борып, кара болытның куш имән юанлыгы беләгенә китереп суккан да, болытны өзеп чыгарып, яңадан үз күленә төшеп чумган. Кисәк яшен яшенләгән, күк келтерәгән, җир селкенеп куйган, малайлар өйләренә йөгергәннәр...

Әйтәм бит, сәер әле бу җәй дип. Шуннан ике-өч көн соң бик каты давыл булып узды. Шул аждаһа күле ягындагы Нугаш урманын чалгы белән чапкан шикелле аркылы кисеп чыккан, диделәр. Безнең авылның да арыяк очына итәге белән генә сәлам биреп, Димеки абзыйның өй түбәсен тилкенләй[1] кубарды да алды да китте. Сыңар саламын да тапмадылар. Шундый өермәле җилләр, патша төшүгә өч ай тула дигәндә, безнең Тулбайлар күңелен дә җилкетә башлады бугай. Иң элек авыл теленә «хөррият» сүзе килеп керде, «патша төшкән» дигән хәбәр, былтыргы кар шикелле, искереп калды. «Хөррият чыккан» дигән яңа сүзне хәзер инде бик теләп кабатлыйлар. Мәгънәсе дә бик әйбәт икән аның: «Ни теләсәң — шул ирек!» дигән сүз икән. Гомер буе судан сүзсез, тигәнәктән тәбәнәк, дигәндәй яшәгән кешеләр дә көн буе урам таптаналар. Йөрәкләрен теге кызыл арыслан тырнагандай, җан тынгылары беткән, ахры... Бер көнне иртәнге якта эти белән өй артына рәшәткә тотып ята идек, Ситдыйк Шакире килеп туктады. Ул эти белән бер тирәле кеше. Беренче хатыннан булган ике олы кызы — бүген кияүгә бирерлек. Икенче хатыннан тагын дүрт малае бар — сигез кашыкка бер имана җир! Җитмәсә, ат тотып азапланган була әле ул. Чүлмәге бик кызган сыман күренә, сүзне туп-туры мөгезеннән эләктереп китте:

— Ничек уйлыйсың, Пәрхулла,— диде,— аман да шулай судагы балыктай су кабып ятабызмы, әллә җир чутыннан шартлатып сөйләшер вахыт җиттеме?

Бер кулына рәшәткә тактасы, икенчесенә чүкеч тоткан, ә ирен арасына кадак кыстырган эти, авызы бушагач та әле, тиз генә җавап бирә алмады. Нәрсә дип әйксен соң? Һай, ул җир дигәнең! Көн саен диярлек безнең өйдә шул хакта сүз чыкмыйча калмый. Әле тенәгеп генә дә үги әни белән шул җир буенча әрепләшеп утырганнар иде.

Ниһаять, ул әйтә куйды:

— Вакыты җиткән җитүен, бик җиткән, Шакирҗан агай-эне! Түлке бит ул җир дигән нәрсә — җирле кешенең йөрәгенә бик тирән тамыр җәеп үскән имән шикелле. Шуны ничек кубарырга? Бае, хәллесе, ат-тунлысы дигәндәй, бу унбиш ел эчендә сатып алып шактый җиргә тиенгән, тиресләгән, караган, гел үзенекенә әйләндереп бетергән, үз хәләл көчем дип саный ул аны. Алар өчен ник кирәк җир бүлешү? Инде

[1] Тилкенләй — тулысы белән.

килеп, картаепмы-чирләпме дөнья куйган кешеләрнең җире дә китәргә тиеш була бит әле. Шуның өстенә, бер карыш җире китми дә, артмый да торган кешеләр күпме? Алар өчен дә ник кирәк җир өләшү? Ә сугышта үлгән егетләрнең җирен ничек тартып алырга? Менә ни төрле кәкре-бөкре бит ул тамыр! Ничек кубарабыз шуны. Тотындың исә, йөрәге-ние белән йолкынып чыгарга тиеш була!

Шакир абзыйның да әзер җавабы барлыгы күренмәде. Җыен саен бу хакта сүз кузгатырга кирәк, дигән фикерне генә әйтте ул.

— Ярый ла, безнең як тавышы көчлерәк булса? — диде эти.

— Катырак кычкырырбыз, безнең ише бала баскан хәерчеләр әзмени?.. Ә Тришкин баярының җирен, мал-мөлкәтен нишләткәннәр, ишеттеңме? Берни булмаган! Җыламаган балага имчәк бирмиләр!

Белмим, алар нихәтле кычкырганнардыр, эти мина каравыл өе тирәсендә олылар арасына кысылып йөрмәскә куша иде. Әмма җирне безнең авылда тагын бер яз үтеп, икенче язда гына өләштеләр әле.

Ә бу җәйдә көтелмәгән сәер хәлләр һаман була торды. Көннәрдән бер көнне безнең урамнан зур бер төркем малайлар узды. Башларында Сәхәби абзый бара. Аның кулында озын бер таякка беркетелгән кызыл комач, комач өстендә ниндидер ак бизәкләр дә күренә. Бу ниткән хәл икән дип, капка төбендә шаккатып карап тордык та, Гыйльметтин белән без дә барып кушылдык. Ин элек теге бизәкләргә күз төште. Тар гына ак бәздән комач өстенә машинада каелган кәкре-бөкре хәрефләр иде ул. Бары ике сүз: «Яшәсен хөррият».

Йөз төрле сорау берьюлы туды башта: кем уйлап чыгарган моны? Сәхәби абзый үземе, әллә волостьтан кушканнармы? Комачын каян тапканнар? Сүзләрен кем уйлап чыгарган? Кем каеган? Ник малайлар гына йөри? Ник олылар юк икән? Хөррият ул без малайлар өчен генә түгелдер бит? Ә Сәхәби абзый, күптәнге солдат кеше, без беләбелгәннән бирле дисәтник булып, халыкка артык катылыгы да, артык йомшаклыгы да тимәгән, ниндидер беркатлырак, бала күңеллерәк кеше, комачны югары күтәреп, горур гына атлый бирә.

— Җырлагыз, җегетләр, җырлагыз! Һайт, дба! Һайт, дба! — ди ул.

Очраган саен мине мыскыл итеп, теңкәгә тия торган Зиннәт исемле малай бераздан соң гыжлавык тавышы белән, чынлап та егетләр сымак итеп, җырлап җибәрә:

Урам үтә, кирта сүтә
Йөгерә үрдәк күл курса.
Ике күзен сөртә-сөртә
Җылый мескен бер курсә.

Икенче кабатында малайлар да кушыла. Ә мин аптырап калам: ничек инде бу? Үзең хөррият комачы күтәреп урам гиз, үзең шушындый җыру җырла? Ә нәрсә җырларга соң? Белмим. Мондый җыру кирәкмәслеген сизәм, ә нинди кирәклеген белмим. Бүтәннәр дә белми аны. Андый җыру бардыр, югыйсә, безнең авылга гына килеп җитмәгәндер.

Уйланып бара торгач, башта нәрсәдер кыймылдый башлагандай булды. Кат-кат пышылдап түбән очка төшеп җиткәндә, иске күлмәккә яңа ямау салган шикелле, бер корама барлыкка килде. Тегермән күперен чыкканчы Гыйльметтингә пышылдый-пышылдый бардым да, оялуны җиңеп, аның белән бергәләп җырлап җибәрдек:

Ике юлның арасы — без кайсыннан барасы?
Без барасы юллар булыр — хөррият заманасы!

Сәхәби абзый ялт безгә борылып карады да:

— Менә, менә! Һайт, дба! Һайт, дба! Тагы бер кат җырлагыз шуны! — дип кычкырды.

Ә без, ялан тәпиләр белән җир селкетердәй лап-лоп басып, шуа җыру белән алга атлаган булабыз.

Каравыл өе янына җыелган кешеләрне узып, арыякның югары очын да әйләнеп төштек, тагы җырладык, тагын җырладык ул җыруны. Бу «егетлегем»нән бик канатланып китеп, мин тагын да берәр нәмәкәй укмаштырырга маташып карадым, тик күпме генә көчәнсәм дә, берни чыкмады бүтән.

Бу яңа бәйрәм бик күңелле булса да, әйләнәсе урамнар бетте, Сәхәби абзый әлеге кызыл комачны каравыл өенең өйалды башына кадап куйды. Ә без, борыннарны тарта-тарта, тегермән артына су керенергә йөгерештек...

Алдагы җомга көнне тагын бер сәер хәл булды. Картлар мәчеттән чыктылар да, ни өчендер тәкбир әйтеп, кырга юнәлделәр. Билгеле, андый чакны малайлар ычкындырмый инде — артларыннан иярдек. «Иске тау өсте» дигән басуга менеп, бармак буедай гына яшел кәлшә очлары саргая башлаган сабан җирендә «истиска» намазы укыды алар. Кырга чыгып намаз укуны беренче күрүем — яңгыр намазы икән бу. Намаздан соң Гаяз хәзрәт җир өстенә тезләнгән килеш вәгазь-нәсихәт сөйләде. Аннары алла ризалыгы өчен Хуҗа Баһауттин рухына сәдака бирергә кушып, бик озаклап дога кылдырды. Аннары шау-шу булып алды: челемче Гаптрахман агай тәмәке утырткан, имеш, Пәтти абзыйның иске печән кибәне корылык теләп утыра, имеш. «Юк итәргә!» дип кычкырыштылар. Картлар җир өстеннән юлга чыккач, без аларны узып, шук колыннардай кешни-кешни, тау астына чаптык. Инешкә төшеп, күлмәк-ыштан белән су коендык. Аннары чүмеч, чиләкләр алып чыгып, урам буенча су сибешеп йөрдек. Ә картларның аерата суфи бер төркеме авылда бердәнбер трубкачы Гаптрахман абзый бакчасына кереп, тәмәке дип кыяр кәлшәсен утап чыккан, шулар ук Пәтти агайның печән кибәнен дә ишеп ташлаган. Тик яңгыр әле һаман яумый иде...

Ә менә шуннан берәр атна узгач булган икенче бер бик тә сәер хәл бөтенләй тетрәтеп салды безне. Сәер дип әйтү дә мөмкин түгел, җан өзгеч бер хәл иде ул, кайсы баштан сөйләп бирүе дә кыен аны. Капка төбе себереп ята идем, түбән очтан нииндидер шаулашкан, барабан каккан сыман тавышлар ишетелә башлады. Бер-ике селтәнеп тә өлгермәдем, тавыш һаман якыная төшеп, Юныслар чатыннан бер төркем халык күренде. Шау-гөр килеп мәчет янында тукталдылар. Гыйльметтин капкаларыннан ашыгып чыкты да: «Әйдә, урам киздерәләр!» дип, шунда йөгерде. Себеркене рәшәткә эченә ташлап, мин дә чаптым. Нинди урам киздерү икән ул? Ишеткәнем бар, күргәнем юк. Кемне, нәрсә өчен икән?

Барып җиткәч тә һични аңламый торам: бик күбесе олы малайлар, барысының да күзләре чәйник капкачыдай булган, минем шикелле үк берни аңламыйлар бугай. Ә үзләренә кызык та тоела бу хәл, куркыныч та. Шулар арасында Камил, Хәнәфи, Тәбрис дигән берничә егет күренә, карт-корылардан да өч-дүрт кеше бар, ә төркем башында әлеге дисәтник Сәхәби абзый, аның кулында шомырт таяк. Урталыкта Самат исемле егет белән аңа үги ана тиешле Хәмдениса атлы хатын. Аларның икесен дә корым белән, күмер белән, тагын әллә ни төсле буяулар белән чуарлап бетергәннәр. Түшләренә, муеннарына, терсәкләренә, билләренә, тагын әллә кай төшләренә әллә ниткән пычрак чүпрәкләр, иске чабаталар асканнар, хәтта нииндидер корышып каткан карга үләксәсе дә бар. Битләренә, маңгайларына, муеннарына иң ямьсез төстәге тавык йоннары ябыштырганнар. Саматның башына әйләндергән иске бүрек кидергәннәр, Хәмдениса башында ямьшәеп беткән карама козау, аның түбәсен тишеп иске әрем себеркесе кадаганнар. Бу хәтле шәп таҗ баштан шуып төшеп, бөтен матурлык югалмасын дигәндәй, козау бавын ул бичараның тамак астыннан сагылдырык итеп бәйләгәннәр. Бу тикле дә

әшәке мыскыллауны, бу тикле дә пәри туе әкәмәтен кемнәр генә уйлап тапты икән? Боларның гаепләре шул хәтле дә зур микәнни соң?..

Мәчет янында аларны тәүбә иттерергә теләделәр.

— Тезләнегез, зиначылар, тәүбә итегез! — дип кычкырды Камил. Самат та, Хәмдениса да баскан төшләреннән кузгалмады. Кат-кат кычкырып та үз сүзен итә алмагач, Камил аларны этկәли-төрткәли алга әйдәде, пәри туе кузгалып китте. Кемдер иске чиләк кага башлады. Кемдер әче итеп, буын-буын чыйнатып сызгыра барды, малайлар кычкырышты, Камил гармун уйнады, әлеге егетләр аның янына тезелеп әшәке такмак әйтте.

Шул чакта, каяндыр чабып килеп житкән Һади, кулындагы әле жаны да чыгып бетмәгән мәче үләксәсен, «бездән дә булсын бер садака!» дип, Хәмденисаның жилкәсенә салырга маташты, котлар чыкты безнең Гыйльметтин белән. Нижәли әле генә үзе үтереп алып килде икән? Икебезгә дә күрше Һади, дус Һади, егылганны түбәлиме? Рисвайны мыскыл итәме?.. Гыйльминең иреннәре күгәрде, күзләренә ут чыкты: «Йөрмәле чукынып, көдер тәре!» — диде ул, зәһәр пышылдап. Аннары шундук жаен китереп, тегенең арт ягына бик каты тибеп жибәрде. Һади малайлар аяк астына мәтәлеп барып төште. Башкалар абайлаганчы, ялт кына сикереп торды да: «Суям мин сине барыбер!» дип йодрык янап, төркем эченнән юк булды.

Бу болганчык өермәне әйдәүче кеше — Сәхәби солдат түгел иде бүген. Алдан атласа да, ничектер мескен чырай белән бер кырыйданрак бара ул. Бу әшәкелеккә күңеле рәнжиме, әллә үзеннән бер йорт аркылы гына булган күршесендә ниләр барлыгын белми-сизми калуы өчен пошынамы — билгесез иде. Команда бүген Камил белән аның әшнәләре кулында. Авылның бик этчәенни егете ул. Әллә ни оста гармунчы булмаса да, никрут чакта ук бик шәп кыңгыраулы гармуны бар иде аның. Язгы су ташулары актарылган чакларда чишмә тавы астындагы мунча артында шул гармун сайрый иде. Шунда ук акчалы уйнаганда, илле тиенлек көмеш чәйгеч тә Камил кулында ялтырый иде. Шундагы бакча киртәләреннән суырган озын корык белән боз өстенә кереп, ут ягып, тегермән бөясенә хәтле агып төшүчеләр атаманы да ул иде. Мунча тирәсенә килгән малайларның тубыкларыннан күтәреп, башлары белән жиргә кадаучы да, чишмәгә килгән кызларның бөркәнчеген тартып алып, чиләкләрен өсләренә коючы да ул иде. Өс-башын егетләрчә ыктымат киенеп, кара хәтфә кырпу бүркен кыңгыр салып, киң урамны тар итеп, кызлар башын зар итеп дигәндәй йөрүче дә ул иде. Куш түбәтәйдән тегелгән туп тәгәрәтеп, үр тыкрыкта күкәйле уйнаучы оста да ул иде. Камил бай малае түгел, атасы Хөснимәрдән агай урта тормышлы кеше, башы чалмалы мәчет карты. Әмма шул ук вакытта: «Теләсә кемгә ялган гуаһ булып, башы суттан кайтмый», ди аның хакында безнең авыллар. Камил үзе дә шул егетлекләренә масаепмы, әллә атасы холкы йогыпмы, бик тырбайчык, мактанчык, кыланчык иде. Ул — соклангыч кыюлыкны да, әшәке явызлыкны да, акны кара дип, көчсезгә кул озатып рәнжетүне дә бер үк чамада жиңел эшли ала иде. Аның менә бу кыланышы да малай күңелгә шик салды безнең: «Ай-һай, чын микән бу мескеннәрнең гөнаһысы, әллә Камилләр үзләре уйлап чыгарган мыскыл итү генәме?» дигән уй туды...

Төркем, мәчет янын узып, муллалар турына житүгә, чалма-чапанлы Гаяз хәзрәт капкадан чыкты. Мәчеткә керә идеме, әллә шушы пәри туен ишетеп чыкканмы?

— Бу нинди шаулашу? Бу нинди хәл тагы? — диде ул, ачулы тавыш белән төркемдәгеләрне күзәтеп.— Кем рөхсәте белән? — дип сорады.

— Әссәләмәгаләйкем, хәзрәт! — дип, Камил белән Хәнәфи аның каршына килеп житте.

— Менә бу җир йоткан нәстәкәйләр уйнаш итеп ятканда үзебез тотып, каравыл өенә чыгарып яптык,— диде Камил.

— Иртә белән картлар хөкеме урам киздерергә кушты,— дип өстәде Хәнәфи.

Башта каты сыман күренгән хәзрәткә боларның сүзе житә калды: Самат белән Хәмдениса каршынарак килде дә:

— Һи, йөзекара бәдбәхетләр! Сездәй бозык җаннар аркасында ил тулы кәсафәт, басулар кәеп ята, чишмәләр коргаксый! Бу кабахәт гөнаһларыгыз өчен хода каршында мәңгелек тәмуг кисәве булыгыз! — дип таягын төеп куйды. Инде китә дип торганда гына кабат текәлде дә тегеләрнең йөзләренә «лач!» иттереп бер-бер артлы төкерде. Аннары гына, тагын нидер тиргәнә-сукрана, үз юлына китеп барды. Самат та, Хәмдениса да сүз әйтергә теләп тел кыймылдатмады. Ник алар бер сүз дә эндәшмиләр икән? Шул хәтле җәберләнүгә ничек түзәләр икән? Әллә соң гаепле булулары чынлап та хак микән?

Аларны бергә китереп, терсәкләреннән иске бау белән бәйләгәннәр дә, буш калдырылган арага йомры ботаклы, каерылы имән каерысы асканнар: кача да алмасыннар, тәннәре тәнгә дә тимәсен, имән каерысы беләкләрен дә сыдырып бетерсен, янәсе. Шул хәтле үчлек, шундый кансызлык иясе, әдәм җәзалаудан шундый татлы тәм табучы кемнәр икән ул?

Бу ике бичараның корым-күмер карасы белән чуарланып беткән йөзендә нинди дә булса ризасызлык билгесе, рәнҗү галәмәте, гаепсезлек горурлыгы яки өмет чаткысы сыман берәр нәрсә күрү мөмкин түгел, ул йөзләр ничектер мәңгегә сүнгән, таштай суынган шикелле тоела иде. Шулай да Самат буш кулының бармак очлары белән битендәге төкерекне сыпырып ташлады. Төкерек урыны, боз басып өшеткән түгәрәктәй, корымнан агарып калды. Ләкин үз гомерендә беренче тапкыр йөзенә төшкән ул төкерек — бит уртасын барыбер яндырып торгандыр аның. Никадәр генә тере мәет сыман күренсә дә, шул яндыруга түзә алмавы сизелә иде егетнең. Хәмдениса кыймылдамады. Әйтерсең белгән ул: чөнки урам гиздереп бетергәнче бу төкерек әле соңгысы булмады...

Ниһаять, аларны шулай йөртә-йөртә күпер башына алып төштеләр. «Госел коенсыннар! Госел коенсыннар!» дип этә-төртә, тегермән артындагы суга керттеләр. Бу күргәннәрдән тәмам туеп, изелеп, җан туңып өйгә кайттык.

Гомердә беренче тапкыр дөнья бик күңелсез, бик шыксыз һәм бик шомлы бер бушлык булып күренде. Аның һәр почмагы саен сине сагалаучы ерткыч киекләр бардыр, син кая гына омтылсаң да, үткен тырнаклары белән хәзер үк өзгәләп ташларга әзер торалардыр сыман тоелды...

Безнең эти каядыр киткән иде ул көнне. Ул нәрсә әйтер иде икән? Хәер, нәрсә әйтсен? Үзе гадел яшәргә тырышса да, мир каршында гаделлекне яклап йөри белми иде ул. Аларны әз генә яклапмы, җәлләпме сүз әйтүче бүтән кеше дә авылда табылмады бит. Берәү дә үзе күрмәгән, белмәгән...

Ничектер бик борынгы, бик иске заманда яшим икән шикелле тоелды миңа. Ә, югыйсә әле, бер атна элек кенә кызыл комач күтәреп, «Яшәсен хөррият» дип йөргән идек. Шундый була микәнни соң ул «хөррият заманасы?»... Шушы була микәнни соң «ни кылансаң — шул ирек» дигәннәре?..

Сыек сары чәчле, сыек зәңгәр күзле, буйчан гәүдәле, юаш фигыльле Саматны үсмер чагыннан ук беләм. Күпер башыннан Дусай урамына менгәндә аларның өе сул кулда. Бер-ике торык абзар-куралы бәләкәй генә, иске генә бу йортта ат-сыер булганын хәтерләмим. Атасы Гаптелхәер абзыйның бердәнбер Гаптелсаматы ул. Әнисе үлеп киткәч, атасы

Ишки авылыннан яшь хатын алган иде. Аны сазаган карт кыз дип сөйләделәр. Бала чакта чәчәк белән авырудан бер күзе ярым йомылыбрак калган, ир чыкмавы да шуннан булган, имеш. Олы яшьтәге Гаптелхәер абзый сайлап тормаган, сайлап торырга аның көнкүреше дә фәләнчә генә бит әле. Ике ир-атны карап-тәрбияләп торса, шул ярар дип уйлагандыр. Хәмдениса безнең авылда яши башлагач, бер дә алай телгә керерлек яманат чыгарганы ишетелми иде. Гаптелхәер абзый малае белән көтү көтте, ә бу аларның өс-башын, тамагын карый. Яшь хатын белән ике ел торгач, Гаптелхәер абзый читкә чыгып китте, ул элек тә читкә йөрүчән кеше иде. Ул читтә чакта да яшь хатынның андыймондый кыек-мыегы беленгәне булмады. Әле читтә йөрерлек булмаган Самат сарык көтүе алган иде: кояш чыкканда китә, кояш батканда кайта. Шулай гади генә, тын гына яшәгәндә, кинәт шушы хәл! Менә хәзер үр кырыендагы ул монсу йорт бикле инде. Өч тәрәзәсенә дә агай-энеләре такта кадаклаган...

Этә-төртә инешкә куып керткәч, Камил белән Хәнәфи аларны сәгать буена суда тота. Тегеләр, тунудан иреннәре күгәреп, маңгайларында бала йоннар кабарып чыкса да, баскан урыннарыннан кымшанып та карамыйлар. Яр буенда, күпер өстендә торучыларга бер кызык та калмагач, берәм-берәм таралып бетәләр. Тегермән артында почмакка сөяләп тәмәке тартучы Камил белән Хәнәфи генә кала. Кәмит караучылар беткәч, аларга да кызыгы югала. Камил шул чакта кулындагы төпчеген болар өстенә чиртеп җибәрә дә:

— Менә сизденме инде абзаңның кем икәнен. Хәмдеки? Бер кичен не җәлләгәниен! — ди, имеш. Ләкин бу соңыннан ишетелгән имеш сүз генә. Әйткәнме шулай дип, юкмы, билгесез. Тик шунысы билгеле: Камил белән Хәнәфи дә тегермән артыннан шыпан гына сыздыра. Шуннан соң бу ике мескен судан чыгып, шул бәйләнгән килеш өйләренә йөгерә. Көч-хәл белән кайтып кереп, елый-елый үзләрен рәткә китерергә тотыналар. Шул төндә Хәмдениса үзенең туган авылы Ишкигә китеп бара. Шул танда Самат каядыр чыгып югала. Аның кая киткәнен беркем дә белми...

Бу кара вакыйганы волостьтан килеп тикшерү-фәлән булмаса да, тиз онытылмады, байтак еллар буена төрлечә сөйләп килделәр. Гаепләү түгел, аклау күбрәк иде. Камил белән Хәнәфи әшәке үчлектән генә аларны шулай рисвай итәргә теләп, җәйге кыска төн буе болар лапасында тәмәке пыскытып утырганнар да, таң алдының татлы йокысы иңгәч кенә, өйалды ишеген сак кына тартканнар. Ишек бикле дә булмаган, каракларча тып-тын гына керсәләр: көн буе көтү куып йөргән Самат өйалды идәнендә изрәп йоклап ята, ә Хәмдениса өй эчендә йоклаган була. Камил кулындагы дилбегә белән күз ачып йомганчы Саматны бәйләп, авызына чүпрәк тыгалар да өй эченә ташланалар. Әзмәвердәй ике егеткә зәгыйфь бер хатынны бәйләп ташлау кыен булмый. Аннары үзләре тавыш кубарып, «зиначылар»ны дөмбәсли-дөмбәсли, урамга алып чыгалар да: «Тоттык, уйнаш иткәндә тоттык!» дип фаш итә-итә, каравыл өенә китереп ябалар...

Ләкин бу аларның үз теле белән расланган хәбәр түгел, авыл авызында йөргән имеш-мимеш кенә... Ә инде бу хәлдән өч-дүрт көн соң яңгырлар ява башлап, сабаннар тернәкләнеп киткәч, арыш басулары кучкыл-яшел төскә кергәч, сүз тагын икенче якка борылды:

— Менәтерә, шул шайтан таякларын йолкып аткач, ходай рәхмәте булды бит! — диделәр.

Еллар узды. Бу шомлы вакыйганың төп тамырын беләсе килү күңелне һаман тырнап торды. Мәҗит Гафуриның «Кара йөзләр»ен укыгач, бу теләк кабат көчәеп китте. Авылга кайттым, Камил агайны җайлап-юмалап булса да, туп-туры үз авызыннан ишетәсем килгән иде, ләкин ул миңа һични сөйләмәде. Аның беренче кызы, авылда матур дигән кыз,

унжиде яшен тутыруга ирсез бала тапкан чагы икән. Әлбәттә, бу кызны аның өчен берәү дә урам гиздермәгән, киресенчә, колхоз ат белән Тәкәнеш больнисына илттергән, исән-сау котылгач яшь ананы алып кайткан һәм сабыйны котлап бүләкләр биргән...

Мин Камил агайны шуннан соң күрә алмадым. Белмим, кызының ирсез бала табуын үз башына бик зур хурлык санапмы, әллә колхоз кешеләренең шул хәтле миһербанлы һәм мәрхәмәтле булуыннан оялыпмы, ул бөтен «оясын» төягән дә каядыр Урал ягынамы, Себергәме чыгып киткән...

## Ал бәйлим билләреңә...

Бер имана чәчүлеккә быел без дүртуракчы! Ә җирләрнең барысы да диярлек иңгә бер генә сажин, ничек итеп анда дүрт кеше сыймак кирәк? Әти моны бик тиз аңлап алды: бер-ике көн генә арыш урагына чыкты да кабат җир өстендә күренмәс булды. Их, әни кеше дә йөрми башласа, нинди шәп булыр иде, без ул уракны түтәй белән икебез ялматып кына куяр идек! Яшь хатын булгач, хәйлә белән ялкауланып, әти тирәсендә сырпаланып кына ятса, ни булган! Бер сүз әйтмәс идек, рәхәтләнеп эшләр идек кенә. Басулар нинди ямьле бит: аксыл-зәңгәр нур тулган кояшлы биектән синең баш түбәңә генә тургай үзенең көмеш тавышын сибә, аны күрим дисәң, күз куәте җитми — кояш аны мең чаткылы зөбәрҗәт тузаны эченә күмә. Ниһаять, аның җыры, күңелгә әллә нинди күтәренкелек тутырып, якындарак ишетелә һәм үзе дә төклетурадай гына булып күренә башлый. Сайрый-сайрый шулай төшә дә кинәт уктай атылып арыш төбенә югала. Шуны гына көткән шикелле, бытбылдык, бик кабаланып, бик якында гына кычкыра башлый: «Выйть! Выйть!» Әйтерсең тургай аның оясына килеп төшкән: «Кит! Кит!» дип шуны куа. Алар гынамы соң, мин белмәгән бүтән кошлар да чикерткәләр, кигәвеннәр, «эт көянтәләре» һәм исемсез күп кенә бөҗәкләр дә үз тавышлары белән бары бергә кушылып, басу өстен бөек бер тантана көе белән тутыралар. Менә шул якты моң эчендә үз иркең белән рәхәтләнеп эшләсе, туктаусыз уен-көлке сөйләшәсе, сузып-сузып җырласы килә. Түтәйгә унҗиденче, миңа унөченче яшь. Юк, аның күңеле генә түгел, инде минем күңел дә үзенчә уяна башлаган чак. Туя алмый көләсе, көлдерәсе килгән, тизрәк егет булып җитәсе килә башлаган чак!

Тик болай куанып эшләү никтер насыйп түгел безгә. Әни кешенең теле үч камчысыдай минут саен сыдырып тора. Үзе ул ару-талуны белми торган җен шикелле эшли, урталыктан сыпырып бара: камылын тип-тигез кисеп, артын чип-чиста калдырып, көлтәсен таштай тыгыз бәйләп, һаман алга үрли. Түтәй аннан калышмаска тырышса да, миннән булмый. Сул кырыйдагы минем кишәрлек мескен булып артка сузыла.

— Әйдә-ә, кыймылта-а! Кәҗәң калды би-ит! — дип, тамак төбе белән кырдырып ала ул. Чикләнмәгән нәфрәт тә бар бу тавышта, көл иткеч мыскыл да бар. Күп тә үтми, түтәйгә дә эләгә. Урагын җилкәсенә салып көлтә бавы ясаганда, ярты гына минут озаккарак сузды бугай.

— Катма тәре баганасы шикелле буйтоташ! Әллә күрмәсләр дип куркасыңмы ул сантай гәүдәңне?!

Минем көләсе килә. Каян таба бит сүзләрен дә! Әллә гел шундыйны уйлап кына тора микән ул? Хәер, табигате шундыйдыр инде аның. Өйгә кайткач, түтәйгә яңадан эләкте әле.

Алтыбаш Гасыйм дигән егет, чишмә башында түтәйгә бәйләнеп, бөркәнчеген ерткан, чиләген суга батырган. Түтәй моны әни кешегә

белдермәскә тырышып, бөркәнчеген өйалдында ук салып тәрә дә кишәгә кертеп куя. Ләкин очлы күз барыбер күреп ала, кичке табынга утыргач кына тотына бу:

— Әнәтерә кызың нишләп йөри, чишмә башында җегетләр белән әүмәкләшеп, җаулыгын җыртып кайткан!.. Бөркәнчекне этигә таба ташлый. Табын тып-тын. Түтәйнең ипи сындырганда кулы дерелдәвен сизәм, иренен тешләве дә күренеп куя. Әти әле бер сүз эндәшми, чәй эчә. Әни кеше генә һаман чыжылдый, һаман өсти тора. Әти бу хәлне шул көйгә калдырыр дип курка бугай ул. Калдырмады, ашап туйгач түрдән төште дә өйалдыннан саржин таягыдай бернәрсә алып кереп, түтәйне ишекле-түрле сыра башлады. Түтәй ләм-мим бер җавап кайтармый, өзелеп үкси генә. Мин хәтта шиккә калдым: әллә чынлап та түтәй гаепле микән, миңа дөресен сөйләмәде микән?..

Тик бу шигем озакка бармады, өч көн узгач шундый ук хәлне үзем татыдым. Кичен кырдан кайтып керүгә капка ачык, ишегалдында ниндидер сыер йөри, баскыч төбенә пычратып та өлгергән. Мин аны-моны абайлаганчы, әни кеше амбардан килеп чыкты да: «Ник кумыйсың!» — дип кычкырды. Ул арада түзмәде, стенага кыстырылган янавычны алып, малның арт санына шак итеп китереп сукты. Бер сукты, ике сукты — каты сөяккә эләккән янавыч сабы «чырт!» итеп төптән үк сынып та чыкты. Сыер чыгып чапты. «Ну, эләгә инде әнигә бу янавыч өчен!» — дип елмаерга да өлгермәдем, каяндыр әти кайтып керде. Сынган янавыч та, сабы да чирәмдә ята иде.

— Кем сындырды моны? — диде әти, бик ачуланып. Ул аның печәнгә төшкәндә генә алган яңа янавычы, ә базардан хәзер андый нәрсәне табу үтә кыен иде.

— Кем булсын? Әнә зимагурыңнан сора! — диде дә өйгә кереп китте әни кеше.

Әтигә шул җитә калды: чирәмдәге сынык янавычны алды да шуның белән уңлы-суллы яңаклый башлады мине. Бер сүз әйтә алмадым, әдәм акылы җитез булуына хәйран калып, тик тордым. «Ак эт бәласе кара эткә...»не дә шушында төшендем.

Ничек кенә булмасын, ике уракны да кешедән алда бетереп, агайэнегә кулалмашка да йөрдек. Хәер, бер имана уракның алдан бетүе белән мактанырлык урын юк инде, ике басуга уртача бер дисәтинә җир дигән сүз бит ул. Шулай да эшең алдан беткәч, өмәгә чыккаларга да мөмкинлек була.

Өмәләр...

Җире күп булып та, эш кулы әз булган кешеләр ясый иде урак өмәсен. Байтаклар сугыш җиреннән һаман әле кайтмаганлыктан, быел өмә ясаучылар тагын да күбрәк булды. Яшьләр дигәнең усаллана бара икән хәзер: Сапый белән Гатаулла байлар берсе арыш урагына, икенчесе сабан урагына өмә җыйганнар иде, унлап кешеләре булды микән? «Игеннән амбарлары шартлый, түләп урдырсыннар!» дигән сүзләр ишетелде.

Ә менә безнең күрше Монасыйп абзыйлар ясаган иде, җир өстенә кеше сыймады, әйтелмәгәннәр дә килгән хәтта! Аларның өч малае солдатта, биш имана җиргә ике генә уракчылары бар. Түтәй белән мин дә катнаштым, күрше хакы бит...

Урак өстенең моннан матур көне була микән? Иртүк, кояш белән бергә дигәндәй, җыен яшь-җилкенчәк олы бер төркем булып, гармун белән, җыр белән авылдан чыгып китәсең. Җир өстенә барып кергәнче дәвам итеп, үзенә бер бәйрәм төсен ала ул. Юк, җиңсәләр киелеп, итәкләр ыктымат кына кыстырылып, ураклар чишелеп, камылны кырт-кырт кистерә башлагач та бәйрәм яме югалмый әле. Шаян сүзләр агыла тора, тапкыр такмазалар ява тора, көлү-көлдерүләр гөлдери тора, күңелләр ашкынуы, кояшлы күз җемелдәүләре уйный тора. Бер-бере

белән узышып урулар, «кәҗә калу» көлкеләре, берәүләрнең янәшәдә серле пышылдаулары, икенчеләрнең уртәшкән булулары арасында Сапаның «фииию!» дип озак сузып, әче итеп, матур итеп, тибрәндереп сызгыруы дөньяны ярып сала. Һәркем үз сәләтен күрсәтә белү, башкалардан калышмау теләге белән дәртсенеп-җилкенеп эшләү аркасында, күрми дә каласың, биш-алты саржинлы җир урыла да бетә. Тагын җырлап, гармун сайратып, өмәче егетләр-кызлар, юлга сыймас умарта күче булып, яңа җиргә китә. Басудагы бөтен кешенең күзе бездә. Яшьрәкләр кул болгап, нидер кычкырып кала. Без дә аларга кычкырабыз:

— Армый эшләгез!

— Сары май тешләгез!

— Кисмәгенә төшмәгез!

— Кырына ябыш!

— Сөйгәнең белән кавыш!

Күңелле бу дөнья!

Рәхәт бу дөнья!

Матур бу дөнья!

Минем өчен бигрәк тә сокланргыч: беренче тапкыр кеше арасына кереп барам, житкән егетләр арасына!

Берәү дә әрләми, җәберләми.

Берәү дә таштай каты тырнаклары белән синең борыныңа чиертми. Әллә түтәй булганга микән?.. Ул бит хәзер багалмадай пешеп килә. Ләүхия җиңги шулай ди. «Күз тимәсен, балакаем», дип, түтәйнен аркасыннан сыйпый.

Кичләрен гармун телләре дә безнең тирәдә ешрак тибрәнә төсле хәзер. Өченче көн бугай, җырлап та уздылар.

Капка төбендә торасың,
Билләреңне борасың.
Борып нечкә билләреңне,
Кемне көтеп торасың?..

Ай-яй, шәп! Кайсы мескеннең йөрәгенә шундый кырмыска җибәрде икән ул?

Шул нечкә биле тирәсендә бүген дә берничәсе бөтерелгәли. Тик үзен бик тезгендә тота түтәй. Яшь булганга оятсынамы — берсе белән дә иһаһайланмый...

Төштән соң кыңгыраулы гармунын үкертеп, җир өстенә Камил килеп керде. Басу түрендәге «янык»та ук урып ята идек. Аны Бәбекәй абзый Миңзифасы белән йөри диләр. Ул кыз безнең белән өмәдә иде, Камил якын-тирәдә эштә булганмы, әллә шуны күрер өчен басу түренә үк менәргә дә иренмәгәнме? Алар, межа буендагы куакка чыгып, берхәтле сөйләшеп тордылар да, Камил шул ук межа буйлатып, гармун уйныйуйный, Шыланғыр чишмәсенә таба төшеп китте. Бактың исә, аның йөрәге дә таш түгел икән. Ә куе кара кашлы, әз генә зәңгәрсу күзле, зифа буйлы Миңзифәттәй йөзенә бәхетле ялкын тутырып җир өстенә йөгереп килде дә урагына ябышты. Күрәсең, ул да Камилне ярата. Мондый хәлләр минем малай башка сыеп бетми. Миңа калса, кешеләрне үчлек белән урам гиздергән әдәмнең бәгыре таш булырга, сөю-ярату дигән нәрсәне белмәскә тиеш. Андый егетне кызлар да яратмаска тиеш. Шуңа күрә Миңзифәттәйнең Камил янынннан балкып килүен бер дә хуп күрмәдем мин. «Белми микәнни шуның әшәкелеген?» — дип уйладым. Ә дөнья мин уйлаганча гына түгел, күп тапкыр аңлаешсызрак икән... Бәлки мәхәббәтнең күзе сукыр дигәннәре шушы була торгандыр?..

Кояш кызара башлаганда актык җирнең аргы башына чыгып, актык көлтәләрне бәйләп, җыеп, урта сыртка сосланнар тездек тә, өс-башларны кагынып, уракларны җиңсәләргә төреп иңбашына салгач, юлга төшеп, авылга юнәлдек. Тагын гармун моңы түгелә, тагын җыр яңгырый баш-

лады. Көн буе уен-көлке эчендә бер-береңнән уздырырга тырышып эшләү шактый арыткан булса да, күңел тулы рәхәтлек аны сиздерми. Әйтерсең, без, бөтен авыл яшьләре, җыйнаулашып, күрше авылдагы җыен бәйрәменә барабыз. Иртәдән кичкә хәтле бергә булу — кызлардагы тартынуны да киметкән шикелле, алар да безгә кушылып иркен җырлыйлар. Моң тагын да көчлерәк күтәрелеп, бөтен басуларны айкый.

Ал бәйлим билләреңә,
Гөл бәйлим иңнәреңә.
Син булмагач, серләремне
Сөйлим таң җилләренә...

Ә кайтып керүгә, ишегалдының яшел чирәмендә киң-озын итеп җәелгән өмә табыны, уртадагы зур-зур табаларда өмә бәлеше!

Чырык-чырык кәлешә-кәлешә, су сибешә-сибешә, аннан-моннан гына юынабыз да шул табынга ябырылабыз. Бер заман бөтен дөнья тын кала: табынга килгән ашны, ит-бәрәңгене, бәлешләрне тып-тын сыпырабыз! Ниһаять, тагын шау-гөр башлана: кемнеңдер чәенә тоз салалар, кемнеңдер ипи йомшагыннан күмер килеп чыга... Ишегалдына карангылык төшүе сизелми дә кала. Табындагы ризыкларны ялт итеп куйгач, тамаклар тәмам туйгач, иң элек кызлар кузгалып, таралыша башлый. Егетләр, яңадан гармун күтәреп, урам әйләнергә чыгып китәләр...

## Әйләндерәләр икән...

Кыр эшләре беткәннән соң мине тагын «сәүдәгә» чыгарып җибәрделәр. Шулай йөри торгач, көзнең ахыры килеп җитте. Диләнке кисеп, туң юлдан урман ташулар, асты калайлы шудырма белән яңа боз өстен сыгылдыра-сыгылдыра узышулар, арганчы шара сугулар да үтеп китте. Кар явып кыш керде. Шул көннәрдә ике куаныч берьюлы килде. Каяндыр тышлык, эчлек, мамык юнәтеп, өйгә үзебезнең авыл тегүчесе Галәттин абыйны керттеләр дә миңа бишмәт тектерделәр. Былтыр Пирмедә эләкми калган яңа бишмәт! Төсе бик матур яшькелт-зәңгәр иде аның. Галәттин абый аны кайтарма якалы, туры билле итеп, янача тегеп бирде. Һай, яраттым мин ул бишмәтне! Ничектер кинәт бер буйга үсеп киткәндәй булдым. Шул ук атнада Җамалый абзый итек тә басып бирде. Дөрес, куныčы балтырдан гына, бала-чага итеге төсле ак йоннан гына, шулай да, оек белән кигәч, гел фәкыйрьдән түгел. Нишлисең, сарыгы әз бит аның, ә Шамил белән Лотфулла чират көтәләр әле.

Бер булгач — булсын инде дип уйлады микән, Тауиле базарыннан әти яшел постау тышлы бер бүрек тә алып кайтып бирде. Эче бәрән түгел, ниндидер җәнлек тиресе. Ул ала белә инде әйберне! Шулай итеп, баштанаяк киендереп куйдылар: яшел бүрек, зәңгәр бишмәт, ак итек — менә нинди хәзер абзагыз! Инде чалбар дигән нәрсә дә эләксә, бөтенләй күпис малае булам да куям!

Бактың исә, болар берсе дә тикмәгә генә түгел икән. Көннәрнең берендә әти төп йорттагы Мөхлис абыйлар атын җигеп кайтты да, китап-корьәнем, мендәр-киезем белән чыпталы чанага төяп, Дусай мәдрәсәсенә алып китте. Менәтерә, вәт: ни төрлерәк егеткә әйләнде хәзер абзагыз! Тулбай белән Дусай арасы бер чакрым, шунда чыпталы чанага утырып укырга бара! Җитмәсә, кеше аты, кеше чанасы! Йа алла, миңамы шундый пачут? Соң бит мин анда, укырга булгач, җәяү дә йөгереп кенә барган булыр идем! Юк, монда әти үз дәрәҗәсен дә сак-

лыйсы килгәндер: атлы-тунлы, рәтле-башлы кеше булып күренергә теләгәндер ул. Ничек инде малаеңны җаяу җитәкләп, башка авыл мәдрәсәсенә барып керәсең? Җитмәсә, кайчандыр ул анда Латыйп хәлфәдә үзе дә укыган булган. Хәзерге Нәҗип мулланы да, мәдрәсәсен дә мактап, дәрәҗәле күрсәтеп сөйли. Шулай булгач, үз битенә үзе кызыллык китерергә кем теләр?

Туп-туры ишек каршына килеп туктадык та чанадан төшеп таш мәдрәсә эченә кердек. Тәбәнәк парталар арасына тезләнгән шәкертләр «геж-ж» килеп сабак укыйлар иде. Әти кычкырып сәлам бирде. Алгы парта каршында мендәрдә утырган зур чалмалы, каратут чырайлы мулла аның сәламен алды.

— Хәзрәт, без сезгә килгәниек...— диде әти.

Калын кашлы, калын иренле, дүрт почмаклырак битле, киң гәүдәле ул кеше сул почмактагы бәләкәй такта бүлмәгә күрсәтте.

Без шунда кереп идәнгә тезләндек. Озакламый үзе кереп, каршыбызга утырды.

— Хәзрәт, мин сиңа угылымны гыйлем үгрәнмәккә китердем,— дип башлады әти бик китапчалатып.— Ушбу мәдрәсәдә бала чагымда үзем дә шәкерт булган идем...

Аннары ул, эчке кесәсеннән алып, минем Себердән кайткан шәһадәтнамане аңа тоттырды. Хәзрәт кеше күз йөгертте дә:

— Хуп, хуп, тырыш бала икән, әхлакы гүзәл икән,— дип куйды.

— Әйе, хәзрәт, углым тырыш, тагын да тырышып укысын. Ите сиңа, сөяге миңа,— диде әти.

Минем әле мондый сүзне ишеткәнем юк иде, шунадырмы, колагыма бик рәхимсез булып ишетелде. Аннары әти, бумажнигыннан ун тәңкәлек микулайски акча чыгарып, хәзрәткә сузды, өчәүләшеп бик озак дога кылдык. Монысы да мине шаккатырды: ун тәңкә сәдака биргән кешене, бигрәк тә минем әти кулыннан шул хәтле акча ычкынуны беренче күрүем. Әйтерсең ул Тулбай авылының чергән бае! Нишләгән ул? Башка вакытларда сәдакәлек акчаны миңа ике тиеннән артык бирми иде бит. Хәер, бу юлы ул бәлки уку хакы түләү итеп тә шулай күп биргәндер. Ничек кенә булмасын, аның бу кыланышлары бары да бик шома, бик дәрәҗәле килеп чыкты.

Шулай итеп, мин бу мәдрәсәнең дүртенче сыйныф шәкерте булып киттем. Урын-җирне сәндерәдәге бер буш почмакка куйдык та фатирга киттек. Бу авылда безнең Кәмәли абзый белән Әсхапҗамалттәй диган якыннарыбыз бар икән. Шуларда торып укый башладым. Хәер, тамак туйдырырга гына кайтам, тәүлекнең калган өлеше мәдрәсәдә уза...

Бу җәдит мәктәбе ничектер икегә ярылган сыман иде.

Иртүк караңгыдан торабыз да боз өстенә йөгерәбез. Без тәһарәт алганнан соң андагы бәке тирәсе чуп-чуар нәҗес булып кала. Боздай инеш суында өшергә житкән ботларны уа-уа, кире йөгереп кайтабыз, шундук бөтенебез тезелешеп иртәнге намаз укыйбыз. Моны Вафа мулла укыта.

— Һай, ишәкләр, шыңгырашмагыз! — дип безгә кычкырганда аның озын киң борыныннан чыга торган үз тавышы шыңгырап ишетелә. Үзе белә микән ул аны? Намаз-нияз беткәч, ашап киләбез. Иң элек коръән белән тәҗвид керә. Аларны безгә әлеге олы чалмалы Нәҗип хәзрәт укыта. Коръәнне шәрик белән парлап укыйбыз. Минем шәригем Чыршы арты авылыннан Котдус Хаффаз углы Шаммазов. Бик әйбәт малай, кыланчык түгел, мактанчык түгел, сабакны да бер дәрәҗәдә тигез укыйбыз. Хәзрәтебез бик кырыс, бик таләпчән кеше, кечкенә бер төгәлсезлекне дә кичерми. Алла сүзен мәкам белән, тәҗвид кагыйдәләре белән генә укырга куша. Дөньяда Мисыр мәкаме, Мәккә мәкаме, Мәдинә мәкаме дигән көйләр дә бар икән. Без аларны тиз генә өйрәнеп алып, ул кушканча укый башладык. Иң мөһим дәрес санала иде бу.

Икенче дәрес «Гыйбадәте исламия». Монысын Вафа мулла алып бара. Дин кушканча гыйбадәт кылуның бөтен нигрәләрен, кайсы намазда нинди сурәләр, нинди догалар укырга, һәр төрле төкләрне ничек китәрергә, ничек госел коенырга, ничек тәяммим[1] сугарга, мәсих[2] тартырга кирәклеген һ. б. һ. б. ятлыйбыз. Монысы да бик мөһим сабак. Боларга киткән көч, зиһен, вакытның күпмелеген искә төшергәндә, кычкырып елыйсы килә хәзер!

Төшке тамакны туйдырып, урамда әз-мәз тырай тибеп килгәннән соң кичке ут алгач, мәктәп тормышының иң кызыклы икенче яртысы башлана. Хәзер безне шул ук авылның гади игенче малае Хөсәен абый Габитов укыта. Без имля, инша, хөснехат язабыз. Хәзергечә: диктант, сочинение, матур язу дигән сүз. Ул безне бер генә дә хата җибәрмичә дөрес язарга мавыктыргыч итеп өйрәтә белә. Хисаптан дүрт гамәл чыгарта, тарих укыта, җәгърәфия укыта аннары, кара тактада русча хәрефләр күрсәтеп яздыру, шигырь әйттерүләр дә була. Дөньяда болай башланып китә торган бер шигырь барлыгын мин шунда белдем:

Мужик бара басуга,
Ашлыкларын ташуга.
Аты арык, йөрмәгәч,
Бер кычкыра, бер суга.
Яңгыр ява кар катыш,
Килеп житеп килә кыш.
Яланда ямь калмаган,
Күренми һич очкан кош...

Бу шигырьне ишеткәч, минем күз алдына иң элек үзебезнең авылның Хисамби абзый килде. Ул гел шул беренче дүрт юлда язылганча иде. Аннары үзебезне хәтерләдем. Һаман да шул ат юклыгы аркасында безнең көлтәләр кар катыш яңгыр ява башлаганчы басу түрендә үреп утыра иде.

Бу шигырь шундый җиңел агышлы итеп, нәкъ безнең як теле белән язылгангамы, күңелгә бик тиз сеңеп калды... Шактый еллар узгач, Казанда гади бер кеше белән таныштым: бәләкәйрәк кенә, юка гына гәүдәле, олырак уч төбедәй генә озынча йөзле, кара мыеклы, әз генә чал төшә башлаган чәчле иде ул. Бер дә һаваланусыз ачык чырай белән тиз генә аралашып китә торган бу кеше — Мәҗит абзый Гафури булып чыкты. Шатлыгым эчемә сыймагач, шушы шигырьне бала чактагыча итеп укып чыктым, тагын бик күп шигырьләрен белүем, ә «Нигъмәт ариясе»н авыздан төшермәвем белән мактандым. Кече күңелле Мәҗит абзыйны бик яраткан идем мин, ләкин ул гомерле булмады, без кабат күрешә алмадык...

Хөсәен абый без авыл малайларына мөмкин хәтле күбрәк белем бирергә тырыша, ә без ул биргәнне бик үк сеңдереп тә бетерә алмый идек. Җәгърәфия дәресе керә башлагач та китаптан: «Җир әфлисун кеби түгәрәктер, аның өсти дә лимун кабыгый төсли кабырчыклыйдыр»... дигәнрәк сүзләр укыдык. Бу безнең барыбызны да шаккатырды, берәү дә ышанмады, кич буе бәхәсләшеп утырдык. Ә Хөсәен абый һаман үзенекен итте.

— Җирнең түгәрәклеге бәхәссез,— диде.— Үсәрсез, ил күрерсез; әгәр диңгез ярына барып чыксагыз, карап торыгыз: ерактан килүче корабның иң элек төтене күренер, аннары торбасы күренер, аннары үзе күренер. Кояш баешына таба чыгып киткән сәяхәтчеләрнең кояш чыгышыннан кайтып кергәннәре инде күптән үк мәгълүм. Алай гынамы соң әле: җир кояш тирәсендә әйләнә, шул ук вакытта, бөтереп җибәргән туп

[1] Сусыз чүлдә калган гарәп ике учын комга сугып, бит-күзләрен сыпыру белән тәһарәтләнеп намаз укый ала.
[2] Юеш бармаклар белән читек йөзен сыпырып алу.

шикелле, үз тирәсендә дә әйләнеп бара. Үз тирәсендә бер әйләнгәндә көн белән төнне тудырып, бер тәүлек хасил итә. Кояшны бер әйләнеп чыгуы 365 көндә булып, елны хасил итә...

Монысы инде бөтенләй кеше ышана торган нәрсә түгел, әкият, хәтта көфер сүз иде! Кояшның пәр көнне җирне әйләнеп йөрүен үз күзебез белән күреп торабыз ич! Ә Хөсәен абый көлә генә: безгә генә шулай тоела, имеш, дөреслектә, Җир әйләнеп йөри, имеш! Бу бәхәс тагын да кызыбрак китте һәм ул кичтә генә бетмәде. Икенче кичне Дусайның Әһели малае кесәсенә бик зур һәм түп-түгәрәк бер сары бәрәңге тыгып килгән. Шуның бер башындагы нечкә сабагыннан һавада бөтерә-бөтерә, кичәге бәхәсне яңартып җибәрде.

— Менә без хәзер бу бәрәңгенең астына, төн ягына кереп барабыз инде,— дип китте ул.— Сак булыгыз, озакламый без мәдрәсәбез-ниебез белән астагы караңгы бушлыкка коелып төшәчәкбез! Әгәренки безнең таш мәдрәсә җирдән купмаса, барыбыз да аның түшәменә лап итеп ятачакбыз. Ә инде агач өйләр, ындырдагы салам, печән кибәннәре, ниргәләреннән кубып, түбәнгә очачаклар, менә сиңа җәгърәфия!

Бөтен мәдрәсә шаркылдап көләргә тотынды, Хөсәен абый да елмаеп куйды.

— Бик хәтәр сөйлисең, Фазылҗан,— диде ул.— Ләкин һич нәрсә очмый да, коелмый да шул. Һәммә нәрсә җиргә ябыштырып куйгандай нык тора, чөнки җир аларны үзенә тарта...

Ул бик озак аңлатты, Галилей дигән борынгы бер галимне «Җир әйләнә» дигән өчен хөкемгә тартып, тәүбә иттерүләрен сөйләде. Тәүбә итеп чыккач, галим түзмәгән: «Ә шулай да Җир әйләнә!» дип кычкырып җибәргән, имеш. Без тагын көлешеп алдык. Хөсәен абый көлмәде. «Ә инде Җордано Бруно дигән галимне шул сүзләре өчен утта яндырганнар», дип өстәде ул. Монысы бер дә көлке түгел иде... Без шулай итеп, тагын берничә кич буе Җир, Кояш, Ай һәм башка сәйярәләр[1] турында кызыклы сөйләшүләр алып бардык. Миңа бу яңалык бик гаҗәп тоелса да, ышанмау мөмкин түгел иде. Шулай да бу хакта этигә бер сүз дә әйтмәдем. «Анда сезне көферлеккә өйрәтәләр икән!» дияр дә мәктәптән алыр да китәр.

Менә шушында инде «ахирәт» гыйльме белән «дөнья» гыйльме арасында ничектер аерылыш барлыгы мәгълүм булды. Һәм бу хәл күңелгә беренче тапкыр ниндидер эз сызып калдырды.

Озакламый безнең таш мәдрәсә эченә дөнья хәлләренең өр-яңа бер хәбәре килеп керде: әлеге теге уч төбе хәтле егерме тәңкәлек яңа акча чыгарган Керенски дигән яңа патшаны бәреп төшергәннәр, имеш. Бәлшәвикләр дигән халык бәргән, ди, эш башында хәзер Ленин дигән кеше тора, ди. Бәлшәвикләрнең һәм Ленинның кем икәнен без малайлар ачык кына белә алмадык. Бу хакта Хөсәен абый да безгә ни өчендер бернәрсә дә аңлатмады, безнең таш стеналар эчендәге тәртипләр дә үзгәрмәде әле. Шулай да безнең башка сәер бер уй керде: Җир әйләнү генә искитмәле түгел икән, дөньяның үзен дә әйләндерәләр икән бит әле! Ничәмә йөз еллар буена тәхет тотып килгән патша хәтле патшаны әйләндереп төшерделәр, аның урынына утырганын, «шул ук карачкы» дип, тагын чөеп кенә ыргытканнар, имеш. Менә бу хәлләрне аңлап бетерүе Җир әйләнү бәхәсеннән күп өлеш кыенрак иде безнең малай башларга...

Безне кышкы каникулга тараттылар. Өйгә кайтып керсәм, өр-яңа бер яңалык: безнең эти мәдрәсәдә «гыйлем үгерәткүче» булган! Әйе, әйе, нәкъ шулай! «Иртәгә үләсем исемдәе, әмма бүген мондый хәлне күремен дип уйламаганием», диләр безнең авыл телендә. Мин дә уйламаган идем шул, башка да килерлек түгел бу. Ә менә булган! Җыенда

[1] Сәйярәләр — кояш иярченнәре.

халык сүз күтәргән, имеш: «Гаяз мулла үзе ялкау, үзе надан, рәтләп укытмыйча, балаларны да надан калдыра, хәлфә итеп бүтән кешене куярга кирәк!» дигәннәр.

Корт иледәй гөжләшкән Тулбайлар каравыл өендә: «Кемне дә кемне? Малайларга гыйлемне манный бутка кук итеп кенә йоттырырдай кешене каян табарга?» Уйлаша торгач, кемдер әйтә куйган:

— Андый кеше, әнә, Пәрхулла абзый,— дигән.— Гыйлеме дисәң — капчык-капчык. Холкы-фигыле, тәүфыйгы-инсафы дисәң — ике муллага житәрлек. Каты куллылыгы дисәң — малайларыннан сорагыз... Бала-чаганы бер дә тырай типтереп, эт сугартып йөртмәс. Шуннан да кулай кеше табылмас, җәмәгать!

Шаулаша торгач, бүтәннәр дә бу сүзгә кушылып, әтинең үзен чакыртканнар — риза булган. Вәт җүләрне! Бу хәлләрдән бот чабып көләсе килде минем. Указлы мулланы яраксызга чыгарып, янәсе, бәләкәй генә патша төшерү ясаганнар авылда. Ни дисәң дә, хөррият заманасы шул! Әй безнең әти ниткән «гыйлем иясе» инде ул? Моннан кырык ел элек өйрәнгән иҗеген дә әллә кайчан онытып бетергәндер. Шулай да халык аңа ышанып, балаларын мәдрәсәгә тутырган. Бер-ике көннән соң анда баргач, шаккаттым: юеш борынлы, күзенә төшкән лыпсый бүрекле иң кечеләрдән алып, минем яшьтәгеләр генә түгел, миннән олыраклар да укырга җыелган. Малайлар шундук сырып алды мине.

— Жә, ничек, Дусайда шәп укыталармы, чыбыгы баллымы? — дигән сораулар китте.

— Әле миңа әлеккәне юк, белмим,— дигән булдым. Аннары үзебезнең нәрсәләр уку белән мактанырга тотындым. Мин әйткән яңалыкларны ишеткәч, малайлар аңкау шартлатып куйды.

— Ә без Салсал ләгыйн белән Сәет Баттал газыйны укыйбыз,— диде Сәмикъ.— Ну сугышалар да, ну көч тә соң үзләрендә!

Ул тагын нәрсәләрдер әйтмәкче иде әле, теге гыжлавык тавышлы, төптән юан чыккан Зиннәт бүлдерде аны.

— Ә син нишләп кайттың әле, Шәйхыл? Әллә куып чыгардылармы? — диде ул, мыскыллы гыжлау белән.

Ачу килде, бүртенеп кызарганымны үзем дә тоеп торам. Гел мыскыл итәргә генә тора шул Зиннәт, хәлфә малае дип тә курыкмый.

— Кумасла-ар,— дидем мин, бик ирәеп кенә,— гел бишлегә укыйм. Кышкы тагтилгә кайттым...

— Ничек, ничек, «тагып килгә» дисеңме? Ә-ә, белдем, белдем: «тавык тәпие» тагып килергә икән! Җәндит укыталар ди бит анда, тәһарәтсез намаз да ярый ди!..

Юк, чыдарлык түгел бу Зиннәткә. Үзе кайсыдыр яктан кода тиешле әле ул безгә, үзе шундый әшәке. Турсаеп, бүтән малайлар янына киттем. Шунда ишектән Вәгыйз белән Гыйльми бер кочак дигәндәй чи тал чыбыгы күтәреп килеп керде, берсе-берсе чыбыркы сабы юанлыгы бар. Туңын эретер өчен мич өстенә тезеп салдылар. Шул хәтле күп чыбыкның нәрсәгә икәнен аңлап бетермәдем.

— Шәп чыбыклар икән бу, әллә чуман үрергә өйрәнәсезме? — дип сорадым Гыйльметтиннән. «Ниткән чуман тагы?» дигәндәй күзләрен зурайтып, ул да аптырап калды минем акылсыз сораучга. Аның өчен Вәгыйз җавап бирде.

— Болар, агай-эне, гыйлем кертә торган чыбыклар,— дип башлады ул.— Синең атаң безгә көн саен шуларны кимертеп, аркага белем мае кундыра. Сабагыңны «ык-мык» итеп тордыңмы — ят күлмәгеңне ачып! Берәр малайның колагына чиерттеңме — ят күлмәгеңне ачып! Мендәр белән сугыштыңмы — ят!..

— Кәрәшкәндә хәрәмләләшсәң дә — чаж бер бишне аркага! — дип өстәде Гыйльми.

— Анысы ничек тагы? — дидем мин аптырап.

— Ник, Пәрхулла абзый атнакич үз күз алдында көрәштерә безне,— дип аңлатты ул.— Менә шунда инде аяк чалсаңмы, екмаганны ектым дип маташсаңмы, көт тә тор — чыжлый башлый чыбык аркада. Үзебез ашыйсы чыбыкны үзебез алып кайтып куябыз әле!..

Кычкырып көләсе килде минем. Егет чагында безнең әтине көрәшче булган диләр. Тәбәнәк буйлы, тыгыз-итләч гәүдәле «Пазый Пәрегын» берәү дә ега алмаган, имеш. Шул «гыйлемлегән» малайларга да «үгрәтә» микәнни соң хәзер?

Тик хәлләр көләрлек түгел иде шул. Әтинең тәртип-тәрбия эшендә таяк көченә бу хәтле таянуы бер дә ошамый, күңелне рәнҗетә, үз балаларын гына түгел, мир баласын да җәберләүче шәфкатьсез кеше итеп күрсәтә иде. Ә бит ул андый ук кансыз түгел, әйбәт яклары да барлыгын үзем күреп беләм ич. Аны яклыйсы килә, иптәш малайлар уйнап кына сөйләгәндәй итсәләр дә, елап сөйләгәннәрен дә аңлыйм, яклап әйтер сүз генә таба алмыйм. Хәер, «ите синң, сөяге минң» дигән «закон» яши иде бит ул заманда. Мин укыган җәдит мәктәбе дә оҗмах түгел, Вафа хәзрәтнең «хәсис ишәкләр!» дип «мактый-мактый» аркаларда чыбыркы уйнатуы мондагыдан әллә ни ким булмас. Шулай да әти кешене мондый «укытучы» итеп бер дә күрәсе килми.

Минем бу теләк озакламый кабул булды тагы...

Кышкы каникулдан соң Дусайга җыелып, укуларны дәвам иттердек. Яз килеп җитте. Имтиханнар да тапшырдык. Иң шатлыклы көннәр иде бу. Тагын мактанмыйча булдыра алмыйм: бөтен билгеләре гел бишледән генә торган, «әхлякъ гүзәл» дигән шәһадәтнамә алып, иптидаи (башлангыч) мәктәпнең дүрт сыйныфын тәмамлап чыктым. Язуны әтигә кайтарып биргәч, күз читләренә чаткылар чыгарып, әз генә җемиеп куйды. Мактауга саран иде ул.

Җәй урталарында аны Мамадышка чакырдылар, укытучылар өчен хәзерлек курслары ачыла икән. Ап-ак оек-чабата киеп, өстенә буй-буй күлмәк белән кара яшькелт казаки, башына яңа түбәтәен киеп, кулына бәләкәй генә төенчек тотып, утыз биш чакрымлык юлга җәяүли генә чыгып китте. Укып та кайтты, әмма нинди «гыйлемнәр» алып кайткандыр, ул хакта берни дә сөйләмәде, алдагы көздә яңадан «чыбыклы хәлфә» булу турында сүз дә кузгатмады...

Ә көз көне Тулбайда беренче баскыч эш мәктәбе ачылды һәм авылыбызга беренче мөгаллимә килде. Ул көзне мин Шәмәктә укый башладым. Юк, «ите синң...» дип илтеп бирмәде бу юлы әти, үзем тәпиләп барып язылдым. Тубал чалмалы хәзрәте булган мәдрәсә дә түгел (хәзрәтләр, хәлфәләр кинәт кенә сәхнәдән төштеләр, гомердә булмаган, булыр дип уйламаган хәл), «икенче баскыч эш мәктәбе», совет мәктәбе иде бу! Һәр төрле дин сабаклары да юк монда хәзер, шуны белә торып та минем анда укуга әти каршы төшмәде. Әни кеше генә:

— Кыйтап-хөркәнсез нинди сабак инде ул? — дип шыгырдаган була.

— Укысын,— ди әти.— Әдәм баласына дөнья гыйльме дә бик кирәк.

Бу «денсез мәптек»ләр ачылгач, авыл арасында гомумән төрле сүз күбәеп китте. «Сәвит денне бетереп, урысча укытып, балаларны урыс итмәкче икән, кызларның яулыгын салдырып, чәчен кистереп, кыска җүпке киертеп, маржа итмәкче икән» һ. б. һ. б.

— Юк сүздер ул,— ди әти, бәхәскә кереп.— Төртендерүчеләрне Микулай патша тотадыре. Ә хәзер аның үзен төртендерделәр...

Шуннан ул безнең авылда сәлам хаты яза белүче бары ундүрт-унбиш кеше булуын, наданлык — сукырлык икәнен, кайсы гына телдә булса да гыйлем алу фарыз булуын сөйләп китә дә түш кесәсеннән бәләкәй генә календарь бите чыгара һәм: «Урысча да уку — уку, кытайча да уку — уку»... дигән шигырьне көйләп җибәрә...

Шәмәктәге бу яңа мәктәптә укыган ике кыш иң бәхетле көннәрем булды минем. Мәктәп бинасы үзе генә дә нинди бит: кызыл кирпечтән шәһәрчә итеп салдырган зур, биек йорт, тәрәзәләре капка хәтле диярлек, бүлмәләре яп-якты, бөтен җире сап-сары буяулы, кара парталары өстәл рәвешендә ясалган, кара савытлары эчкә беркетелгән, һәркемгә аерым утыргыч. Мин моңарчы күрмәгән кызык бу. Ә ишегалдына чыксаң — турник, брус, «үгез», бөжралы баулар. Болар һәммәсе дә «физкультура» дигән уен дәрес өчен ясалган икән, тик аны безгә укытучы гына юк. Шулай да без ул «дәрес»не үзебез дә бик яхшы алып барабыз — тәнәфескә чыккан саен ниләр генә кыланмыйбыз без анда. Куып кертмәсәләр — бүтән сабак онтыла.

Барыннан да бигрәк, шунысы гаҗәп: бу бинаны Нигъмәтулла дигән бер бай әле үткән елны гына салдырып бетергән. Аның Шәмәк халкы өчен эшләгән яхшылыгы ул гына түгел, элекке елларда зиратларын таш койма белән әйләндерткән, яшел калай түбәле, стеналары «такта тегүле», сары буяулы мәчет салдырып биргән, авыл ятимнәренә, ярлы карткарчыкларга Бытый Зарыйп дигән «ышандыклысы» аркылы ел саен күлмәк-ыштанлык ситсы өләштереп килгән. Ул үзе кайчандыр шушы авылда көтүче булган, имеш. Аның хакында сүз кузгалганда, бигрәк тә олы-карылар, ул кешене әллә ни төрле әкият серләренә урап, кызыктыргыч бер кыйсса итеп сөйлиләр. Имеш, Нәмәт ятим малай чакта, озын чыбыркы сөйрәп авыл малын көтеп йөргән дә, егет булып җиткәч, авылдан җәяүләп чыгып киткән, шулай җәяүле баштан дөнья гизә торгач, әллә кайдагы Чалкар күле якларына, кыргыз дигән халык арасына барып чыккан. Шундагы бер елкы баена ат көтүчесе булып ялланган. Мең елкылы байның иң яхшы көтүчесенә әйләнеп, тора-бара дәрәҗәгә менгән. Бәхет бер килсә — алды белән дә килә, арты белән дә килә, диләр түгелме? Нәмәткә дә бәхетнең тагын да зуррагы аяк астыннан гына килеп чыккан. Җәйләүдән җәйләүгә мал әйдәгәндә, юлдан бер кәрбән генә күн янчык табып алган, имеш. Кеше югында гына янчыкны чишеп караса, эче тулы алтын да көмеш акча, имеш. Әмма ләкин Нәмәт ул чактук гадел кеше булган икән, янчыкны тиз генә куенына яшермәгән, ә кулында болгап, һәр тарафка өч тапкыр аваз салган: «Хәзинәле янчык таптым, кемнеке-е-е?... Кемнеке-е-е-е?..» Буш даладан җавап килмәгән. Шулай итеп, бу янчык, ходай кушуы буенча, аның үз хәләл малы булып калган. Шуннан соң Нәмәт тау арасындагы бер өяз каласына күчеп, үз кәсебен ачып җибәргән: кыргызыннан, казагыннан тире мал, тире-яры җыеп, Рәчәй ягына озаттыра башлаган. Көтүче Нәмәттән Нигъмәтулла байга әйләнеп киткән. Элекке елкы баеның бик сылу бердәнбер кызы бар икән. Бу сораган, бай биргән, туй булган — кияү кергән. Киткәненә унбиш ел узуга менә шундый бәхетләргә, дәрәҗәләргә ирешкәч инде ул, кыргыз сылубикәсен ияртеп, Шәмәккә кайтып килгән кунак булып. Ул чәчкән прәнник-кәнфитнең, исле сабын, исле май ише нәрсәләрнең, ул тараткан комач малының чуты-чурты булмаган. Озакламый елкы бае үлеп киткән, бөтен мал-мөлкәте моңар калган, шуннан ул мелиянир булып киткән... Кара син аны, шундый байлыкларга ирешкәннән соң да туган җирен онытмаган бит. И шуннан ары да, читтә үлгәнче, авыл халкына гел-гел ярдәм итеп торган. Вәт ни төрле кешеләр була дөньяда!..

Әнә шулай сөйлиләр аның хакында. Ул бай, үз вакытын бик белгән шикелле, революция еллары башлану белән үлеп киткән һәм бик дөрес иткән. Хәзер инде байларсыз да яшәп була торган заман килде. Ә күңелендә гыйлемгә мәхәббәт тотып, авыл балаларына ул заманда шундый әйбәт мәктәп салдыра белгәне өчен — авыр туфрагы җиңел булсын! Хәзер ул яңа бинада Шәмәкләр генә түгел, бөтен тирә-як балалары яңа сабак укый, бөтенләй яңа дөньяга аяк басу өчен яңа белем

ала. Ул «көтүче-бай»ның менә бу хакта, әлбәттә, башына да килмәгәндер...

Бу мәктәптә без хәзер татарча гына түгел, шаулатып урысча да укыйбыз. Әтинең мине урысча өйрәндерү өчен Себер түренә хәтле алып барулары нинди сәер хәл булып калды хәзер. Бактың исә, бер азапсыз, гади генә рәвештә тормышка аша торган теләк икән ул, әгәр дә дөнья куласасын зыр әйләндереп җибәрсәң...

Монда без «Табигыять» дәресләре буенча җанвар-җәнлекләрнең, кош-кортлар тормышының күп кенә кызык якларын «ачып» хәйран калдык. «Елан агачка асылынып балалый», дип сөйлиләр иде, гел ялган икән. Күкәй сала икән ләбаса ул! Әйтерсең Пәрхиттәйнен җиз башлы тавыгы!.. Чакмый торганнары да була икән әле! Менә бит, елан булсын да чакмасын, имеш. Ярканат та кош түгел икән, күзе төнлә генә күрә торган яры канатлы тычкан икән!.. Тереклек дөньясындагы бу хикмәтләрне белеп бетерер өчен дистә еллар укырга кирәктер, ахры...

Әмма хикмәт боларда гына түгел иде әле. Алдагы кышта безне тел-әдәбият дәресләреннән Фарукъ абзый Билалов укыта башлады. Ябык-җыйнак гәүдәле, җирән чәчле һәм җирән чырайлы, бервакытта да сабырыннан чыкмый торган тыныч холыклы бу укытучы, белмим, нәрсәсе беләндер, барыбызны да үз авызына каратты да куйды. Ул безгә «балалар» дип түгел, исем-фамилиябез белән олыларча эндәшә. Чынлап та, безнең күбебез инде унбиш тутырып, уналтыга киткән. Баласытып эндәшсәләр, шундук каш җыерыла башлый.

Икенчедән, ул берәүне дә какмый, иркәләми. Шактый туң маңгайлы кайбер мулла балалары дәрес белмичә «ык-мык» килеп утырганда да чыгырыннан чыкмый, гел кул күтәреп утыручыларга да бик исе китми.

Ә инде әдәбияттан сөйли башласа, вакыйгаларның без бөтенләй белмәгән әллә кай якларына кереп китеп, безне шул хәтле кызыктыра, әйтерсең дөньяда әдәбияттан, шигърияттән дә гүзәл бер нәрсә дә юк! Әллә ни ялкынлы итеп тә сөйләми ул. Шул үзенең тыныч холкы белән тыныч сүзен генә тәртелми-кабаланмый агылдыра бирә, шулай да аны тыңлап туеп булмый.

Хикәяләр буенча инша яза башласак, без ничек тә аңа ошарлык матур итеп, «сурәтлерәк» итеп язарга тырыша идек. Уңышлырак чыккан иншаларны икенче дәрестә класс алдында укытып күрсәтә, бер-ике мактау сүзе әйтеп, күңелне күтәреп җибәрә. Шулай өйрәтә торгач, ул безне үзебез язарга, класста әдәби журнал чыгарырга тәмам «котыртып» җиткерде. Өч кешелек һәйәт тәхририя (редколлегия) сайланды, «Яңа юл» дигән кулъязма журнал чыга башлады. Ул чакта «стена газеты» тумаган иде әле. Таш басмада чыкмаган «журнал» уен гына тоелса да, кызык иде, байтаклар язышa башлады.

Журналга килгән материалның иң күбесе шигырь булып чыкты. Арада: «Тау биекме, син менәмсең...» дип язылган «кеше самаварлары» да очрый иде. Фарукъ абзый безне җыеп, тагын сөйләште. Чын шигырь язар өчен йөрәктән чыккан ялкынлы сүзләр кирәклеген әйтте, ә башкалардан үзләштерүнең «әдәби караклык» дигән хурлыклы исеме барлыгын аңлатты. Хикәяләр дә язарга кызыктырды ул безне.

— Хикәяләрне без бик язар идек тә, ул бит шигырьгә караганда читенрәк, вакыйга кирәк, аны уйлап чыгарырга баш җитми! — дидек без. Шуннан ул тагын сөйләп китте: хикәя, роман, сәхнә әсәре язучы әдип үз әсәрләрендә күрсәтелгән вакыйгаларны, кешеләрне уйлап кына чыгармый, тормыштан ала, ә тормыш эчендә һәртөрле гыйбрәтле дә, көлке дә хәлләр, төрле сыйфатлы кешеләр, яхшысыдыр-яманыдыр тулып ята. Менә әдип шуларны сайлап ала да үз күңеле аша уздырып, үзенә кирәгенчә итеп язып чыгара. Сезнең тормышта да, уйлап карасагыз, шундый хәлләр тулып ятадыр әле. Менә шуларның башта бер

бәләкәйрәген алып, язып карагыз... дигәнрәк сүзләр әйтте, берничә мисал да китереп күрсәтте.

Редколлегиядә без (Разия Гайнанова, Мәрьям Максудова, мин) өч укучы. Ләкин «баш мөхәррирebез» Фарукъ абзый иде. Ул бөтен материалны карап, төзәтеп чыга, кайсын кая, ничегрәк итеп урнаштырырга икәнен өйрәтә. Без төсле карандашлар белән (ул чакта чын буяулар юк иде әле) үзебез булдыра алганча төрле бизәкләр, «чачаклы» хәрефләр ясап, кирәсе әйберләрне дәфтәр битләренә чиста-ачык итеп язып чыгабыз. Шулай өч-дүрт дәфтәрне бергә теркәп, калынрак чүбек кәгазе белән тышлыйбыз да, артына «Һәйәт тәхририя» дип куйгач, журнал әзер була. «Тиражы» бер данә! Ул ике класс эчендә кулдан кулга йөри башлый, күп кенә шау-шу кубара, язучылар тагын да күбәеп китә.

Журнал чыгару белән генә калмадык, декламацияләр, җырлар өйрәнеп, «әдәбият кичәсе» дә ясадык әле без. Малайлар ишегалдында яткан туң такталарны кертеп, классның бер почмагына тәбәнәк кенә «сәхнә» корды, ә кызлар усал булмаган карчыклардан чаршаулар китереп, аны җиһазлап алды. Шулай «әртис» булып, үз һөнәребезне күрсәттек. Җиңги-түтиләр, әби-бабайлар дигәндәй, бер егерме-утыз кеше тыңлап утырды.

Иртәгесен Шәмәк урамыннан кайтып барганда Заһи абый (үги әнинең күп еллар зимагурлыкта йөреп кайткан олы туганы) тотып алды да:

— Әй, син, малакасус, ни кыланып йөрисең анда? — дип, якадан җилпи дә башлады.— Ботыңнан тотып баганага бәрәм хәзер!

Берни дә эшләмәдем, югыйсә. Фарукъ абзый үзе кушкан «Ачы хакыйкать» дигән декламацияне генә сөйләдем. Ни гаебе булсын инде аның? Шулай да котлар алынды. Җилпүеннән бигрәк әтигә ишеттерер дип курыктым. Атна буе шүрләп йөрсәм дә, өйдә ул-бу булмады тагы. Күрәсең, зимагур абый ул хәтле үк түбән төшәргә теләмәгәндер.

Әдәби мавыктырулар белән генә чикләнмичә, Фарукъ абзый безнең күңелләрне дөньяның, заманның икенче якларына да бик оста юнәлтә белә иде. Ул безгә, каникулдан килгәч, беренче дәрестә «Канлы якшәмбе» турында сөйләде. Башкаларга ничек булгандыр, әмма минем өчен тетрәткеч бер яңалык иде бу. Ул үзенең тыныч тавышы белән ашыкмый гына сөйли бирә, ә минем колакта ату тавышлары яңгырый, ә минем күз алдымда: патша күрергә дип агач ботакларына менгән малайларның үле гәүдәләре җиргә коелып төшә. Керфек төпләрен яндырган яшьне яшермәкче булып, башны парта өстенә иям, барыбер тама. Олуг патшаның үз сурәтен күтәреп, бер телем икмәк сорап, кешеләр аның каршына килә... Ул аларга кургаш буткасы ашата... Шуңарчы мин бай белән ярлыны да, эшче белән хуҗаны да әллә ни артык аера белми идем әле. Ә патша инде, ходай нинди биеклектә һәм күзгә күренми торган зәңгәр сафлык эчендә булса, ул да шундый ук изге урында яшидер кебек иде. Җомга намазларына бара башлагач, падишаһ әгъзам хәзрәтләренең исәнлегенә дога кылып йөргән малайлар бит без... Шушы дәрестә бөтенесенең көле килде. Шул көннән башлап дөнья кинәт кап урталайга бүленде. Бер ягында без, икенче ягында алар икән. Шуны белгән көннән алып минем күңелдә ул якка нәфрәт туды. Соңыннан ачыграк төшендем: сыйнфый аң дигән, һич тә сүнми торган изге бер ут икән бу...

Әнә кайлардагы ераклардан килә икән бу ике арадагы авыр тартыш. Әнә күпме канлы, төрмәле, сөргенле заманнардан соң гына халыклар ярсу давылдай күтәрелеп, үз язмышын үз кулына алган икән... Әнә нинди кара еллар арасыннан юл ярып атлый-атлый килеп чыккан икән ул Ленин!.. Ничектер халыкның үзе төсле бик гади дә, акыллы да булып һәм давыллар кубарырга көче җитә торган баһадир да булып,

шул ук вакытта, мин кайчандыр Себердә күргән Гайнеттин абый шикелле бик якын да, үз дә булып гәүдәләнә ул күз алдымда минем...

Сәер икән бу унбиш яшь тулып узу. Итәк-җиңнәре кыскарып, иңбашлары тараеп беткән буяк[1] күлмәгең кабат кияргә ярамый башлаган шикелле, малайлыктан чыгып китү чоры башлана икән. Ничектер үзең дә сизмәгән көннәрнең берендә күз күремендәге дөнья чикләре киңәеп, кызыктыра торган әллә кайларга ерагаеп киткәндәй була икән. Уйларың да, тойгыларың да колач киеребрәк йөзәргә, билгесез чоңгылларга да чумып карарга, бик мавыктыргыч күренгән шул билгесез еракларны әйләнеп чыгарга омтыла башлый икән. Күңел тулы уйлар, моңнар, теләкләр, хыяллар, кабынырга торган күкерттәй дәртләр, беренче тапкыр кичерелә торган сагышлар. Төрле төстәге күбәләкләр болын чәчәкләрендә уйнашкандай, боларның күңелдә кайнашкан чагы — Шәмәк белән Тулбай арасы. Бу бер чакрымлык юлны мин көн саен ике тапкыр узам. Көннәрнең нинди генә чагы булмасын, дөньяның иң тыныч урыны бу, йөрәккә алтын канатлар үстерә торган иң матур җире, көнемнең иң татлы минутлары, кичерешләрем ташкынында тик берүзем кала торган уртаклык бу. Дөнья уртасы! Әйләнә-тирәмдәге ап-ак диңгез дулкыннары өзлексез чайкый мине, әллә ничә якка чайкый...

Берьюлы өч дөньяда яшим бугай мин. Хәер, беренчесендә торам гына. Кояшка җир астыннан карый торган чокыр өй. Шунда тамакка ашыйм, йорт эше карыйм, кече як сәкесендә йоклыйм — өч малайга бер иске толып астында татлы йокы. Мин анда ямьсез, боек уйларымнан башка берни уйлый алмыйм, хыялларым кача, хәтта дәрес хәзерләү мөмкинлегем дә булмый, мәктәптә хәзерлим...

Әле тиз генә төшмәячәк бәләкәй патша бар анда. Шул чокырдагы барлык җан иясенең баш хөкемдары ул. Бер чеметем тозны биш көнгә җиткерү, бер телем ипине артык ашатмау, булмаган байлыкка табыну олы максат итеп куелган бәләкәй бер дөнья бу. Мин шунда торам, ә мәктәптә яшим. Ул икенче дөньям. Аның тәрәзәләре зур, карашы колачка сыйгысыз. Анда көн саен бер яңалык ачыла миңа, фән яңалыгы, тормыш яңалыгы, ил эчендә барган давыллар гөрелтесе ишетелә... Тизрәк каурыйларны җитлектереп, шул куркыныч матур тарафларга очасы килә...

— Революция иске дөньяны җимерүче давыл гына түгел, революция — яшьлек ул! — диде бер көнне Фарукъ абзый.— Кешеләр бәхетле, ирекле һәм тигез яшәсен өчен яңа дөнья кора, шәһәрләр гыймарәт кыла, гөлбакчалар ясый. Сез шул бөек революциянең солдатлары, ташчылары, бакчачылары, мәгърифәтчеләре, җырчылары булырга тиешсез. Өйрәнегез, көрәшче булырга әзерләнегез, каләмнәрегезне очлагыз — яңа шагыйрьләр кирәк бу дөньяга!..»

*Дәвамы бар*

[1] Буяк — күк буяуга мандырган киндер күлмәк.

## Нури Арсланов

### Әйтәсем килә

Корап сырган иске юрган төсле,
Чуарланган дөнья картасы —
Һай, шул кирәкмәгән ямауларның
Барысын да сүтеп атасы!

Яки аның бөтен буяуларын
Юып ташлап океан-суларда,
«Кешелек иле — Бөек республика»
Дип өстенә язып куярга!

Җирне илләр-дәүләтләргә бүлеп,
Төрле чикләр уйлап чыгарган
Кешеләргә рәнҗи кебек Дөнья,
Арынасы килә шулардан.

Талаучылар басып кермәсен дип,
Бикләп куйган йортлар шикелле
Тора илләр,
чиген сырып алган
Сакчылары, кортлар шикелле...

Атлап чыгар булсаң чик-сызыктан —
Күкрәгеңә көпшә төбәлә,
Әзер тора илләр ызгышырга,
Талашырга һәм кан түгәргә...

Тапкан-баккан үзенең улларына
Табигатьнең тигез карашы:
Акмы, карамы — без бертуганнар —
Барыбыз да адәм баласы.

Кайчагында ерак киләчәккә
Күчеп китәм дә бер хыялда:
— Гражданины мин бу планетаның! —
Дип әйтәсем килә җиһанга.

1972

## Кичке этюд

Кермән төбендәге тыныч ярда
Бер кыз басып тора.
Сылу гәүдәсендә бәхет-шатлык
Тулып-ташып тора.

Ул үзенең бик яшьлеген белә,
Киләчлеген белә.
Шуңа, ахры, акчарлаклар белән
Бергә көлә-көлә,

Казан суы көзгесенә карап
Нидер юрый сыман.
Ак болытлар, югарыдан төшеп,
Карый кызга судан.

Батып барган бакыр кояштан су
Кызыл төскә кергән.
Казан суы каннан кызарганны
Кем бар хәзер күргән?..

Җилләр сөеп тарый сылу кызның
Ефәктәй чәчләрен.
Аның бәхете өчен күпме меңнәр
Түккән күз яшьләрен...

Аңа яшьтәш күпме кызлар киткән
Әсирлеккә шуннан:
Озын юлда изге Идел өсте
Аһ-зар белән тулган...

Аның бәхете өчен бу туфракка
Күпме кан саурылган,
Аяк асларында сөякләрдән
Түшәп юл салынган...

Рәнҗемәсен изге сөякләре
Батыр бабайларның:
Яңа туа — туфрак, көлләреннән
Үткән заманнарның.

Октябрьдан килә аның бәхете,
Азат бу яшьлеге,
Ерак, чытык язмыш аша карый
Таңдай киләчлеге...

Тик әлегә уйлар-сагышларны
Кыз бар дип тә белми:
Ул шат, аның гамьсез матурлыгын
Бар табигать көнли!

Фани дөнья! Гамьсезлегең белән
Танылган син күптән:
«Нинди файда, дисең, сагышлардан?
Бар да үткән-беткән!»

Бер карасаң шулай — мәңгелек юк —
Үтәчәк бит без дә...
Тик телибез калуын киләчәккә
Җирдә безнең эз дә.

Бер уянмый калмас йөрәгендә
Сагыш шушы кызның.
Ә хәзергә: аңа таңнар алсу,
Шәфәкъ — комач-кызыл.

1973

## Хаҗи-Тархан

Хаҗи-Тархан[1] утыра яр буенда,
Башына чорнап болыт чалмасын,
Тирән уйга талган, яңа язмыш
Каршысында иеп чал башын.

Уйлый микән узган заманнарын?
Хәзергесе микән уйлата?
Үткәннәр дә, бүгенге дә аңда
Кинәт сәер хисләр уята:

Кырылышканнар монда тугандашлар,—
Тар булган бу сәйран далалар...
Узганнарга рәнҗеп файда юк та,
Ни әйтик соң сезгә, бабалар?!.

Идел дә киң хәзер, ирек тә киң,
Кадерен белә халык ирекнең.
Тик кай ягы белән шул иреккә
Дәхеле[2] бар сезнең ирлекнең?

Тәхет өчен билдән канга батып
Йөргән нугай, татар ханнары!
Сез кайчандыр торган бу җирләрнең
Исеме калса, җисеме калмады.

Хаҗи-Тархан утыра яшел ярда,
Суларында ап-ак кораблар.
Муенын сузган зур краннар аша
Күренә миңа ерак тарафлар,—

Ерак еллар — узган заманалар...
Сибәли дә яңгыр, сибәли...
Хаҗи-Тархан мине тотып алган,
Түзмидер шул сөрән сөйләми.

Ядгәр ханны юлга атландыргач,
Ни гомерләр узган калада.
Аннан — ятлар...
Аннан яулар йөргән,
Ирек даулап «Волга-ана»да.

---

[1] Хаҗи-Тархан — Әстерханның төп исеме.
[2] Дәхеле — мөнәсәбәте, катнашы.

Октябрьда бар халыклар белән
Күтәрелгән халкы бу илнең.
Мамай-курган күкрәгеннән даны
Киң таралган изге Иделнең!

Хаҗи-Тархан, тынычлыгын җуеп,
Торып баса Идел ярына,
Сөйләп туймый миңа үз хәлләрен:
— Ә күпме,— ди,— фашист явына

Каршы мәйдан тотты минем уллар,
Ир-егетләр менде атларга! —
Ул тели күк үткән ялгышларын
Хәзергесе белән акларга...

Ә башында борынгыдан калган
Ефәк төрбән — болыт чалмасы.
Иске вәкил тора яңа заман
Каршысында иеп чал башын.

1973

●

Кайгы, шатлык дуслар кебек җитәкләшеп
Каршы ала, без дөньяга килер-килмәс.

Тәпи баскач та тотынабыз хәйләләргә,
Хикмәт безгә акыл бүлеп бирер-бирмәс.

Бер күрүдә гашыйк булсак Мәҗнүн кебек,
Сүреләбез: «Сөям, бәгырем!» дияр-димәс.

Гыйш-гашрәттә бер-бер артлы уза еллар...
Миннәт кенә — соңра яшәү сөяр-сөймәс.

Хыял тавын күтәрәбез болытларга!
Ул җимерелеп төшә бик еш өяр-өймәс.

Ашыгабыз шатланырга: «Килде, дип, дан!»
Язмыш ега безне, күккә чөяр-чөймәс.

Көләбез шатланып — рәхәт! Ә кай чакта
Авыз елау төсен ала көләр-көлмәс.

Борынгыда кочаклашып күрешкәннәр
Уза ымлап кына,— башны ияр-имәс...

Кеше күпне беләм дип бик масайса да,
Бу дөньядан китә бер көн белер-белмәс.

Борын чөя башлый бәндә дигән хайван,
Җүнләп кеше сыйфатына керер-кермәс.

Үтеп китсә арысландай гаюр чаклар,
Нинди мәгънә яшәвендә үләр-үлмәс?!

Гомер күзе туймый, комсыз нигә? диләр:
Йомылганга дөнья ямен күрер-күрмәс.

Кояш та бер сүнәр диләр галәмендә...
Кояштай ян, йөрәк! Йөрмә сүнәр-сүнмәс.

Һәр ни ага да үзгәрә бу дөньяда,—
Ва дәригаl Бер нәрсә дә мәңге имәс.

1973

## Иделдә

Җил шадралап йөри сулар өстен,
Нинди кызык таба торгандыр?
Күрфәз, утрауларын җәйгән Идел,
Әйтерсең лә диңгез булган бер.

Кояш ватылып сибелгән дә төшкән,—
Кисәкләре суда ялтырый.
Теләсә кая китсен кораб,
юлның
Алды ни дә миңа, арты ни!..

Уңда, сулда — сулар... Тып-тын елга.
Тәмам арынып борчу, уйлардан
Утырам мин, тынычлыкка бирелеп,
Тәнем рәхәт таба шуңардан.

Озаккамы? Бәлки кинәт җилләр
Төшәр үтеп Идел астына,—
Дулкын кубар, кояш парчалары
Сүнеп юкка чыгар барсы да.

Болытларга посар алтын кояш...
Давылларга ачып җанымны,
Ташланырмын мин шул өермәгә,
Һич кызганмый тыныч чагымны!

1973

## Үскән саен

Кояш кебек таң-иртән дә,
Кичен дә кызарасың,
Оялисың да янасың,
Яшь кенә кыз баласың.

Үзең генәме?!.— мине дә
Каушата күз карашың...
Каушау, кыюлыкны бергә
Ничек куша аласың?!.

Кояш күләгәле суда
Дулкыннарның арасын.
Салкын Идел дә сүрелтми
Кояшның ут табасын:

Ул үрләгән саен кыза,
Белми яну чамасын!
Син дә шулай, үскән саен
Пешәсең-кызарасың...
Тылсымлы кыз баласың!..

1973

## Оптимизм

«Истән чыга яхшы кешеләр,
Игътибарга алар мәхрүмнәр.
Соңга калган җылы сүзләрне
Ишетә алмый китә мәрхүмнәр...»
М. ГАЛИЕВ.

Ниндидер мин?
Истән чыккан чаклар
Булгалады...— сабыр эш иттем.
Ләкин, күңелем җылы булгангадыр,
Җылы сүзләр шактый ишеттем.

Андый сүзләр — кадерен белсәң — дәва!
Хасиятләре шундый куәтле:
Мең мәртәбә җәберләнгән жанны
Бер җылы сүз эретеп юатты.

Аз булса да назга җик булмадым,
Өлешләрдән булды уңганым!
Мин ышанам, мәрхүм булганда да
Игътибардан мәхрүм булмамын!

1973

## Сәйфи Сараины укыгач

«Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,
Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли».
Сәйфи САРАИ.

Гөлдерсеннең Сөһәйл тирәсендә
Әйләнүен тыңләп Җиргә ул:
«Җир әйләнә Кояш тирәсендә!» —
Дигән серне әйтеп биргән ул
Коперниктан йөз илле ел элек.

Шәрыкта бу, димәк, күптәннән
Ачык булган. Сараи тик аны
Шигъри чара итеп үткәргән.

Мөмкинме шик тоту Коперникка,—
Тел тидерү аның кебеккә!
Тик гыйбрәтле шунысы — кайчак серләр
Соң ачыла элек белеп тә...

1973

## Йөрәккә

Бер ашыга — дөп-дөп итә,
Бер — тып-тына:
Йөрәк тибә калтыранып,
Куркып кына...

Кабаланма, типче сабыр,
Тигез генә,
Туктама да — котылмассың
Бик тиз генә:

Егетләрдәй әле тагын
«Азасым» бар,
Хәят мактап дәртле җырлар
Язасым бар.

Ат уйнатып — илләр гизеп
Йөрисем бар.
Кешеләргә бәхет-шатлык
Телисем бар.

Хәйям әйткән җамны дәвам
Итәсем бар,—
Иҗат көен көйләп йөзгә
Җитәсем бар...

Санап китсәң — вазифалар
Бетәсе юк.
Шулай булгач — тынгы өмет
Итәсе юк.

Әйдә әле, тип гадәтчә —
Тигез генә,
Уйлама да котылырга
Бик тиз генә!

1972

## Һич булмаса...

«Шаһ-нама»сен кабул итми шаһлар,
Пайтәхетләр, илләр гизсә дә,—
Кире кайта арып-алҗып сәяр.
Төшермиләр озак искә дә...

Еллар үтә. Бер көн Әфган шаһы,
Фирдәүсине никтер хәтерләп,
Бүләкләргә тели кинәт аны,—
Озата бер кәрван хәзерләп.

Кәрван килә. Ләкин язмыш көлә:
Капкалары ачык шәһәргә
Кыйммәт бүләк төяп кәрван керә,
Шагыйрь чыга соңгы сәфәргә...

Мин Фирдәүси түгел... Хәзер инде
Шаһлар да юк андый юклыгын.
Тик шулай да кабатласын иде
Язмыш миңа да шул шуклыгын...

1973

## Кайда сез, әй!..

Ник походта бергә барганнар
Берсе уңга, берсе сулга киткән,
Берәүләре туктап калганнар?
Аптырыйм... бит фәкать алда гына
Без җитәсе гаҗәп кәрваннар!

И күңелсез, уйлап карасаң:
Бер көн шулай ярар иде юлда
Бер ялгызың гына калмасаң...
«Кеше күңеле — кара урман...» диләр,
Аһ, шул урман серен аңласаң!..

Сез бит миңа дуслар идегез.
Элек якын күреп, юаткандай:
«Син талантлы шагыйрь!» — дидегез.
Бар тавышыма җырлый башлау белән
Нигә болай кара көйдегез?

Кайда сез, ир исеме алганнар?
Атланыгыз гүзәл ярышларга,
Зур сәфәргә күңел салганнар!
Алда гына — без җитәргә тиеш,
Без узарга тиеш кәрваннар.

1973

## Борчылу

Мин ачынып уйлыйм: бер болытсыз
Якты көннәр ничек ясарга?! —
Төн шәүләсе бәлки беткәндер дә,
Үз шәүләңнән ничек качарга?..

Вакыт җитте ыгы-зыгылардан
Өстен булып яши башларга! —
Егерменче гасыр! — качып булмый
Мәгарәгә, тауга-ташларга...

Булсачы бер гомерем шәфәгында
Сәнгать белән генә яшәргә!
«Ашау өчен яшәү кирәкми дә,
Яшәү өчен кирәк ашарга»...

Аһ, романтик күңелем сыймый җиргә,
Гел талпына күккә ашарга!
Ачкычлары кайда икән, Җибриль[1],
Күк капусын ничек ачарга?..

Кайгы юкта кайгы тапкан, дисез
Сез — акылдан айнык башлар да:
Борчыламы кеше кайгы эзләп?!
Сыкрыйм сагышым хәттән ашканга!..

1973

## Яшәү шунда

«Булса гөлсез — былбыл өнсез...»
М. ЖОМАБАЕВ.

«Үзем, үзем!» — дип алдама үзеңне,
Кара туфрак ябар бер көн күзеңне...
Чәчәк атмый җимеш бирми агач та,
Чәчәксез — тик соры кош сандугач та.
Сүзең булса чәчәк тыңлаучыларга,—
Яшәү шунда, шагыйрь, истән чыгарма!

1973

## Мактауның да тәэсире төрлечә

Бик борчылыр идем — әгәр миңа
Сез әйтсәгез бер дә ялгансыз:
— Ай-һай, Нури, җырлар, шигырьләрне
Элек нинди матур язгансыз!

Үз-үземнән бераз риза булып
Шатланудан җаным чымырдар,
Сез әйтсәгез әгәр чын күңелдән:
— Ай-һай, сезнең яңа шигырьләр!

1973

[1] Җибриль — илһам фәрештәсе.

## Матәм шигыре

*Җәүдәт Фәйзи истәлегенә*

Ник әле сез, дуслар, бер аяусыз,
Җанны кыясыз,—
Уйларга да авыр — бер-бер артлы
Дөнья куясыз?..

Минем гомер әллә сезнекеннән
Кадерлерәкме?! —
Барыгызга бүлеп бирер идем
Шушы йөрәкне!..

Хәйям әйткән кебек, гүрдә туфрак-
Тузан гына без.
Соңра — шул туфрактан ясап куйган
Бер җам гына без...

Остаз шулай дигән диюен дә,
Күрсә дә алдан,
Үзеннән соң чүлмәк кенә түгел,
Ширбәт тә калган!

Сезнең җамнар эчендә дә балкый
Энҗедәй ширбәт,
Чыңнарыннан гүзәл моңнар ага,
Хисләрне тирбәп!

Күзләремдә һәм җамымда ачы
Бәллүр тамчылар,—
Ялгызлыкта мондый ятимлеккә
Ничек җан чыдар!..

Матәм таптым кайтып язгы төндә,
Таң каршыладым...
Күтәр, Нури, күтәр, зәкъкум[1] түгел,
Яз тамчыларын!..

Уйлама син фани бу хәятның
Сүнәсен, оныт!
Дусларыңның үлмәс рухы белән
Сагышыңны җылыт.

1973


---

[1] Зәкъкум — агу.

Юныс Әминов

# СӘЛӘХ БАБАЙ МӘХӘББӘТЕ

хикәя



Тау битенә салынган бу кечкенә курорт Әлмәттән әллә ни ерак түгел. Шөгер тирәсендә генә. Анда ләм белән дәвалыйлар иде.

Сәләх бабай бирегә килгән көннәрендә күңеленә җылы таба алмый йөдәде. Өендә калган карчыгын, янгын сарае янындагы эскәмияне, шунда гәп сата торган авылдашларын сагынды. Мондагы суы да ошамады: авылдагысы йомшаграк та, тәмлерәк тә иде. Җитмәсә, үч иткәндәй, аның белән килүчеләр арасында сөйләшеп утырырга кордаш кешеләр дә юк. Үзен-үзе тиргәде карт:

— Җитмешкә җиткәндә, аякларым сызлый дип, ни пычагыма юләрләнергә иде! Андый яшьтә кемнең аягы сызламас та кемнең сөяге сыкранмас. Карчыгым атнасына икешәр тапкыр мунча яга, шунда мәтрүшкә аралаштырып бәйләгән каен пиннеге белән чабынсам, узар иде әле...

Сәләх бабай курортның каен катыш чаган агачлары утыртылган берданбер аллеясын килгән көннәрендә тәүлегенә бишәр урады. Бигрәк тә каеннар аның күңеленә хуш килде: үзләре ак, үзләре төз. Яшел яфракларында бер генә саргылт тап та юк.

— Безнең тирәдән алып кайтып утыртканнардыр боларны. Шулай булмыйни, мондый зифа каеннар бездә генә — Сарман якларында гына үсә шул,— дип уйлады карт.

Ул, авылдагы гадәте буенча, биредә дә көтү куган вакытта уяна. Ак халатлы сестралар моның өчен аны әрләп тә, куркытып та карадылар:

— Иртә торуыңны баш врачка әйтербез, дәваламабыз. Тәртип бозасың,— диделәр.

Бабай аларга елмайды гына:

— Сезнең тәртипнең миңа кирәге юк, балалар. Минем үз тәртибем бар. Авыл кешесе җәйге көндә кояштан иртәрәк торырга, кояштан соңрак ятарга тиеш.

Ике-өч тапкыр әйткәннән соң да, бабай барыбер үзенчә эшләгәч, сестралар артык бәйләнмәделәр.

Карт иртән торып бүлмәсеннән чыгу белән тирә-якка колак сала. Беренче булып курортка терәлеп утырган авылның аргы башыннан көтүченең быргы уйнаганы ишетелә. Бабай көрсенеп куя, башын чайкый:

— Быргы елату гына бу. Менә безнең Әхтәрҗан уйнап җибәрсә, яшь чаклар искә төшә, җырлыйсы килә башлый... Юк инде, безнең як көтүчеләренә җитү кая ул!..

Килгәненең өченче көнендә, ахры, ул курортның коймасы буйлап үзе өчен яңа булган сукмактан атлады. Уңда да, сулда да сәрби агачлары тезелешкән. Дәваланучылар тирән йокыда әле. Шылт иткән тавыш юк. Кинәт, картны сискәндереп, куаклар арасыннан бер кош сайрап җибәрде. Бабай туктады. Тынын да алмый тыңлап тора башлады. Ифрат матур итеп, үзәкләрне өзеп, күңелләрне җилкендереп сайрый.

— Безнең яклардан килеп чыккан коштыр бу. Миңа сәлам әйтергә килгәндер. Сайрар, сайрар да, сәламнәрен тапшырып бетергәч, яңадан үзебезнең якларга очып китәр,— дип уйлады карт.

Сайрау тынгач, бабай ике адым атларга да өлгермәде, кошчык куаклар арасыннан канатларын җилпеп атылып чыкты да курортның югары ягына — тау өстенә таба очып китте. Аңа карт чигүле түбәтәен болгап калды:

— Исән йөреп кайт! Миннән дә сәлам тапшыр...

Ул, сукмакны ташлап, хәтфә үлән белән капланган кечкенә аланга чыкты, түбәнгә — тау астына карады: анда күз явын алырдай чәчәкле болын. Чыклы үләннәрдә кояш нуры җемелди. Көтмәгәндә картның күзләре кысыла төште. Болын уртасында җирән ат утлап йөри. Кайсы мәгънәсезе җибәрде икән аны? Җәйнең бу вакытында бер уч печән ашаса, бер потын таптап әрәм итә бит ул.

Күңеленә шомлы уй килде: әгәр үзләре болынында да мондагы сыман атлар фарсит итеп йөрсә? Атлар янына сыерлар өстәлсә?.. Үзе каравыллаганда, печәнен җыеп өймичә, мал аягы бастырмаган иде дә, быел ул каравылчы түгел шул. Яңаны билгеләделәр. Картны курортка җибәрәбез, диделәр, аяклары төзәлсен, янәсе.

Бабай иртәгә үк кайтып китәргә булды, әмма нияте барып чыкмады. Беренче тапкыр ләм ваннасы алгач, кыш буе тынгылык бирмәгән аякларының сызлавы кочәеп китте, икенче ваннадан соң таяксыз йөри алмас булды. Дәвалаучы врачына хәлен сөйләп бирде:

— Ваннагыз килешмәде, кызым. Рәт чыгарлык булмагач, мине газапламагыз инде сез. Кайтарып кына җибәрегез.

Врач ханым бабайның аркасыннан сөйде:

— Авыртуга сөенегез генә, абый. Эшегез уңайга бара, димәк. Авылыгызга яшь солдат кебек шык-шык кына басып кайтырсыз. Апаның да исе китәр әле менә! — Аннан соң бабайның таягын кулына алып карагач, өстәп куйды: — Монысын өегезгә кайтканда безгә калдырырсыз. Истәлек өчен...

Картка, теләсә-теләмәсә дә, курортта калырга туры килде. Өйдән аяк белән чыгып, авылдашлары каршына таяк белән кайтырга гарьләнде ул. Тик күңеле һаман киреләнде: сабан тургае сайравын тыңлаганда да, зифа каеннар янында тукталып торганда да гел туган якка каерды.

Йокысыз төннәрнең берендә моңа кадәр кешеләрдән читләшеп ялгыз гына йөргән Сәләх бабайның күңеленә яңа фикер килде: «Курортта безнең тирәдән мин генә түгелдер. Якташларны эзләп карарга кирәк. Алар белән сөйләшеп утырсам, вакыт та тизрәк узар, өйне юксынудан тыпырчынган йөрәк тә тынычланып китмәсме?»

Икенче көнне иртән, гадәтенчә, тау астына төшеп китте. Болынга күз салды: утлап йөрүче мал-туар күренми. Печәне тәмам күпереп житкән. Иртәгә булмаса, берсекөнгә чабарга керешерләр, мөгаен. Үз авылларында да болынга төшәбез дип чалгы кайрап торалардыр инде.

Карт тирән сулап куйды.

Шулай да әллә инде болын өстендә җирән ат булмаганга, әллә инде терелерсең дип аркасыннан врач сөйгәнгә, бу иртәне аның кәефе яхшырак иде. Ул монда килгәннән бирле беренче тапкыр алдына куелган ризыкның тәмен табып ашады, дегет кебек кара итеп, рәттән өч стакан чәй эчте. Ашханәдән чыккач, аллея буйлап китте. Тизрәк авылдашларын табасы килә иде аның. Алдагы эскәмиядә салам эшләпәле ир утыра. Папирос тарта. Башта шуның белән сөйләшмәкче булды. Янына килеп җиткәч, Сәләх бабай аңа сәлам бирде, әмма эшләпәле сәламне алырга өлгермәде, ютәлләргә керешге. Бабай белә: бу ютәл үпкә авырткannan да, салкын тигәннән дә түгел, тәмәкене чамасыз тартудан. «Тәмәкече ютәле» дип йөртелә торганы. Эшләпәле котсыз итеп, шул кадәр ярсып ютәлли, янәшә үскән каен бөтен буе белән калтырана. Ютәлләүче үзе дә әле артка бөгелә, әле алга сыгылып төшә. Шулай газаплана торгач, әүвәл аның эшләпәсе эскәмия артына тәгәрәде, аннан соң күзлеге аяк астына килеп төште. Сәләх карт күзлекне эскәмиягә алып куйды да кызу адымнар белән аның яныннан китеп барды. Эшләпәле исә, эшләпәсез калса да, дөнья яңгыратып ютәлли бирде.

— Бу бичара безнең як кешесе булырга охшамый,— дип уйлады бабай,— безнекеләр тәмәкене эшләпәләре очканчы, күзлекләре төшкәнче тартмыйлар.

Карт үзәк аллеядан сукмакларның берсенә каерды. Якташлары бәлки андадыр.

Беренче итеп, куаклар күләгәсендә утырган ике хатынны күрде. Хатыннар кызык хәл турында сөйләшәләр иде бугай, икесе дә рәхәтләнеп көләләр, икесенең дә йөзләрендә нур уйный. Түгәрәк ак сакаллы картны күргәч, икесе дә шым булдылар. Берсе тезеннән югары күтәрелә төшкән күлмәк итәген аска таба тартып куйды. Икенчесе, бабайны бар дип тә белмәгәндәй, шактый киң итеп куйган аякларын да кушырмады, өстәвенә, яныннан бабай узганда, авызын кече телә күренерлек итеп, зур ачып иснәп калды.

— Тьфү! — дип җиргә төкерде карт, аларны узгач,— авызы кара мунча ишеге кадәр бар. Анысы безнең якныкы булмас. Ә тегесенең, әдәп белә торганының, күрше-тирәдән булуы ихтимал. Ялгызы гына туры килгәндә кайсы авылдан икәнен сорап карар әле.

Арырак баргач, Сәләх карт ялгыз үскән карт имән янына килеп чыкты. Имән күләгәсендә, үләнгә сузылып яткан килеш, дүрт ир-ат карта сугалар. Алларына җәелгән газета өстендә берәр, икешәр тиенлек акчалар ялтырап ята.

— Карга тугызлыгы кайсыгызда соң? — диде арадан пеләш башлысы.

Уйнаучыларның татар икәнен белгәч, бабай алар янына килде, олыларча тамак кырды:

— Эшнең зурысына тотынгансыз икән...

Пеләш башлысы картка күтәрелеп карады да урын күрсәтте:

— Утыр, бабай, син дә бәхетеңне сынап кара.

Карт сакалын сыпырды:

— Кәртле уйнарга дигән акчам чабата кесәсендә калган шул.

Пеләш баш акланырга теләде булса кирәк:

— Берәр тиеннән генә ул. Биш сәгатькә, күп булса, 20 тиен оттырырсың,— диде.

— Отарсың дисәң, утырыр да идем. Оттырырга булгач басып кына торам инде.

Тегеләр уеннарын дәвам иттерделәр. Бабай аларга күз йөртеп чыкты: кайсысы алар ягыннан булыр икән? Пеләш башлысы шәһәрнекедер: бармагында асыл кашлы йөзеге бар. Авыл җирендә йөзекне хатын-кыз гына кия, шулай булмыйни, ирләр бармагы балдаксыз матуррак бит ул.

Икенчесе егерме-егерме биш яшьләрдәге егет, ә яңакларында кара урман кебек кара сакал. Ияге шәрә. Сакалын түш кесәсендәге тарагы белән вакыт-вакыт тарап куя. Картның чырае сытылды:

— Тумас борын картайган нәмәрсә. Кара сакалны ничек үстерергә дә белми икән, юньсез. Стиляга дип шундый кыланчыкларны тиргиләрдер инде. Юк, безнең ферманыкы түгел бу койрыксыз этәч.

Уйнаучылардан өченчесенең кулында муштук. Муштугы кыз бала кыяфәтендә эшләнгән. Егет кулындагы сигаретын баланың авызына каптыра да, шырпыдан ут элдергәч, шул кызның аякларыннан төтен суыра. Бабайның күңеле болганып китте:

— Бу ахмак бөтенләй безнең илнеке түгелдер. Я француз, я немец булыр.

Дүртенчесе ир уртасы кеше. Каратут йөзле, киң җилкәле, карта тоткан бармаклары ярылып, чатнап беткән. Карт аны күңеле белән якташына юрады. Тракторчы яки комбайнчы булырга тиеш. Тик алдында акчасы аз. Безнең якта оттырышлы уеннар уйнамыйлар шул. Болар арасына ялгыш кына килеп кергәндер.

Муштук суырганы карта өләшкән арада, Сәләх бабай яргаланган куллыдан сорап куйды:

— Кайсы якныкы буласың, энекәш?

— Җәлил шәһәреннән мин, абый. Мәгыйз исемле.

— Шулаймыни! Күршеләр икәнбез, алайса. Сезнең шәһәр безнең районга борын төртеп кенә тора бит. Үзең тракторда эшлисеңме?

— Җир бораулыйбыз, нефть чыгарабыз, абый кеше.

— Нефтьче дә, якташ та булгач, сынатма инде. Алдыңда ике тиен генә калган бит.

Мәгыйз, карталарын кулына алып караганнан соң, бабайны тынычландырды:

— Курыкма, абый. Бу юлы минем бәхет.

Якташы чыннан да вәгъдәсендә торды: тегеләрнең өчесеннән дүрт тиен отып алды. Карт кәефле итеп кеткелдәде:

— Якташ булуың рас икән. Башың эшли.

Җәлил егетен тапкангамы, картның күңеле тагын да күтәрелеберәк китте. Бүген сигез тулу белән ятасы да килмәде аның. Кичке уенны карарга барды.

Ашханә каршында гына зур мәйдан бар. Мәйдан уртасына такта җәеп сәхнә сыман нәрсә эшләнгән. Сәхнәнең дүрт ягында да эскәмияләр.

Карт мәйдан янына килеп җиткәндә, сәхнә тирәсе гөж килә, шаркылдашып көләләр иде. Эскәмияләрдә буш урын юк. Күбесе аяк өсте торалар. Бабай кешеләр арасыннан кыенлык белән генә узды да, нәрсә бар икән дип, сәхнәгә карады. Сәхнәнең ике читендә дә дүртәр урындык. Беренче читтәге урындыклар өстендә берәр чиләк су. Икенче читендәге урындыклар өстендә берәр стакан. Дүрт хатын-кыз, йөгерә-йөгерә, чиләктән кашык белән стаканнарга су ташыйлар. Кемнең стаканы алданрак тула — шул җиңүче була. Бабай сөенеп куйды:

— Безнең як уеннарын хәтта курортларда да яратып уйныйлар икән!

Кемдер йомшак кына аның терсәгенә кагылды:

— Якташ абый, утыр. Караса — Мәгыйз икән. Аңа үз урынын бирә. «Шулай шул,— дип уйлады карт,— безнең якташлар олылар-ны олы итә беләләр». Бабай утырды. Уен кызганнан-кыза барды. Карап торучылар су ташучыларга көч биреп төрле яктан төрле та-выш белән кычкыралар:

— Мәрьям, ваграк атла!

— Әлфия, ашыкма...

— Суны кеше чиләгеннән алма...

Кем җиңәр икән — картның бөтен уйлаганы шул иде.

Сәхнәдә су ташучыларның өчесе урта яшьләрдәге хатын. Дүртен-чесе яшьрәк, егерме ике тирәләрендә булыр. Бабай башта иң өлкән хатынның җиңүен теләде, әмма ул хатын ике әйләнештән соң ук башкалардан күп артка калды. Картның ул хатыннан күңеле кайтты:

— Бер аягын алганчы икенчесе бозга ябышып ката. Безнең як-ныкы булмас.

Хәзер инде, бабайның уйлавынча, муенына кызыл шарф бәйлә-гәне җиңәргә тиеш иде. Тик анысы артык каудар булып чыкты: бер кашык суын ярты юлда түкте, икенче кашыгын стаканга салам дип, әллә кая — читкә салды. Шуннан соң картның күңеле озынча күл-мәк кигән хатынга күчте. Килеш-килбәте дә авылныкына охшаган, йөрешендә дә мәгънә бар. Тора-бара бабай аннан да өмет өзде: тәккә генә йөгерә, стаканына барып җиткәнче кашыгында суы ике генә тамчы кала.

Иң яше җиңеп чыкты. Болай артык кабаланмады да инде үзе, булса булды, булмаса юк дигәндәй генә йөрде, шулай да беренче булып аның стаканы тулды.

— Мәгънәсез кабаланудан файда юк шул,— дип уйлады карт,— ашыкмыйча җитез эшләүдә хикмәт. Кайсы якныкы икән ул кыз?

Җиңүчегә бәби имезлеге бирделәр. Кыз, шаяртып, имезлекне авы-зына капкан килеш, сәхнәне бер әйләнде дә җиргә төште. Сәләх ба-бай янында гына басып тора башлады. Карт урыныннан торды:

— Кил, балам, утыр.

Кыз табигате белән шаян иде, ахры, кычкырып көлде:

— Егетнең асылы икәнсең, абый. Рәхмәт. Минем сезнең белән янәшә утырасым килә,— диде. Аннан соң бабай белән рәттән кунак-лаган, чигә сакалы кара урман кебек егеткә эндәште:

— Чибәр егет, бәлки миңа сез үз урыныгызны тәкъдим итәр-сез?..

Сакаллы теләмичә генә кузгалды:

— Рәхим итегез. Ханымнарга хөрмәт.

Бабай ят хатын-кызга сүз куша торганнардан түгел иде, әмма бу юлы түзә алмады:

— Уңган икәнсең, кызым. Бөтенесенең сиңа исе китте.

Кыз тагын шаркылдады:

— Исләре китүдән тәгәри яздылармы?

— Ачкан авызларын да ябарга оныттылар,— диде бабай.— Кай-сы яктан үзең?

— Барысын да берьюлы белергә телисең икән син, абый,— диде кыз елмаеп.— Бөгелмәдән мин. Официантка булып эшлим. Кирәк булса исемемне дә әйтим: Мөсәббиха.

Кыз ашханәләренең номерын әйтте. Бөгелмәгә килсәң, безгә ка-гылмый китмә, ашның иң тәмлесе бездә, таныш абый итеп чиратсыз сыйлармын, диде.

Бабайның йөзе балкып китте:

— Бөгелмәдәнмени! Якташ икәнсең, алайса. Безнең станса бит

ул. Самолетка дисәк тә, поездга килсәк тә Бөгелмәгә инде.— Аз гына сүзсез торганнан соң өстәде: — Рәхмәт, кызым, рәхмәт.

Мөсәббиха гаҗәпләнде:

— Нәрсә өчен рәхмәт, абый?

— Никадәр кеше арасында җиңеп чыктың. Безнең якның дәрәҗәсен төшермәдең. Менә шуның өчен рәхмәт.

Бу кичне Сәләх бабай яту белән изерәп йокыга китте. Узган төннәрдәге сыман тузга язмаган төшләр күреп тә газапланмады. Иртән торгач, сәрби куагы тезелгән сукмак буйлап аска төште дә болынга карап тора башлады. Колагына моңа кадәр биредә ишетелмәгән тавыш чалынды. Нәрсә тавышы булыр бу?.. Автомашина дисәң дә... Бабай кулларын каш өстенә куйды. Шунда ул, болынның аргы читендә, текелдәп кенә печән чабучы ике «Беларусь» тракторын күрде. Болынга төшкәннәр! Хәерле сәгатьтә булсын! Тракторлар, берсен икенчесе узарга теләгәндәй, җитез йөгерәләр. Йөртүчеләре уңган егетләрдер. Картның кичә җәйләнә башлаган сагышы яңадан ачылды:

— Бездә дә печәнгә төштеләрме икән? Тракторлары сәгать кебек текелдәп кенә йөриме икән?

Их, быел булмады инде, катнаша алмады болын эшенә. Гомерендә беренче тапкыр! Башка елларны болынга чыгасы көнне бригадирлары, мотоциклын пытырдатып, иң әвәл Сәләх картлар капкасына туктар иде. Күзләрен хәйләкәр кыскалап:

— Сәләх абзый,— дип әйтер иде,— зинһар, тракторчыларга күз-колак булсана, кызурак йөрсеннәр, төптәнрәк чапсыннар,— дип әйтер иде. Аннан соң Сәләх абзый мотоцикл бишегенә утырыр иде дә китәрләр иде болын юллары буйлап!..

Сәләх бабай нәрсәдер югалткандай башын күтәрде. Тракторлар тавышын югалткан икән. Икесе дә туктаганнар.

— Тьфү! Чыкмас борын ватылмасалар! — диде карт ачынып.— Машиналарын өйдә чакта юньлерәк карарга ярамагандыр шул... Юк, безнекеләр хәстәрлерәк халык!..

Баскан җирендә карт ярты сәгать чамасы торды, әмма тегеләр урыннарыннан кымшанмадылар. Бабайның яман ачуы чыкты. Шушындый чалт аяз көнне дә җир җимертеп эшләмәгәч... Болай мыштырдасалар, печәннәрен уракка төшкәнче дә җыеп бетерә алмаслар. Ул, туктаган тракторларны күрмәс өчен, кырт кына борылды да тау өстенә менеп китте. Аллеяга җитәрәк таныш гөрелте яңадан ишетелде. Әйләнеп караса, тракторлар тагын куышырга тотынганнар икән. Җилкәсеннән тау төшкәндәй җиңел сулап куйды ул. Имин эшләсеннәр инде.

Аллеяга чыгу белән таныш тавыш ишетте:

— Хәерле иртә, Сәләх абый!

Каршысында Мөсәббиха елмаеп тора.

— Шулай булсын. Рәхмәт, кызым.

Мөсәббиха йомшак куллары белән бабайның кытыршы учын кысты, кашларын кыйгачландырып алды:

— Бүген кәефегез егетләрчә күренә. Төшегездә авылыгызга кайтып килдегезме әллә?

Карт аңа җавап бирергә өлгермәде, яннарына Мәгыйз килде. Ул, исәнлек-саулык та сорашып тормыйча, бармак янады:

— Сәләх абый, кызлар белән йөргәнеңне карчыгыңа язам.

Мөсәббиха картны култыклап ук алды:

— Хат та яз, карточкабызны да җибәр!..

Көлешеп алгач, бабай шатлыгын әйтте:

— Болынга төшкәннәр бит, оланнар, болынга! Безнекеләр генә кичекмәсәләр ярар иде...

Тыныч сәгатьтән соң Мөсәббиха, бабайның әйтеп торуы буенча, хат язды. (Карт үзе яза белсә дә, куллары калтыраганга, хәрефләре танырлык чыкмый иде.) Монда печәнгә башладылар. Сезгә дә вакыттыр. Эшне корырак тотарга тырышыгыз, диде. Шук Мөсәббиха хат читенә чәчәк тә ясап куйды. Монысын бабай өнәп бетермәде:

— Өлкәннәр хатына чәчәк килешми,— диде.

Мөсәббиха Сәләх картны холкы белән үз әтисенә охшата, шуңа күрә аны хөрмәт итә иде. Көлде генә:

— Мондагы болын чәчәге ул, абый. Хуш исе сезнең авылга да барып җитсен.

Шушы ук көнне кичен Сәләх карт тагын бер якташ тапты. Эскәмиядә ялгызы гына трактор гөрелдәвен тыңлап утырганда колагына җыр ишетелде:

Сарман буйкайлары — сары алан,
Печәннәре җитәр бер заман...

Их, туган як моңы! Карт яшьләрчә җәһәт кенә урыныннан торды да җыр ишетелгән якка китте. Аулак сукмак буендагы эскәмиядә янәшә утырып өч кыз җырлый иде.

Беренчесе сары чәчле, сипкелле, куллары ирләрнеке кебек.

— Авыл кызы,— дип уйлады карт.

Икенчесе киң битле, басынкы борынлы, күзләре аз гына кысык, куе кара кашлары бер-беренә тоташкан. Бабай фикеренчә, монысы чын татар кызы иде.

Өченчесе кыска җиңле күлмәктән, аягында кадак үкчәле туфли, иренен кызылга буяган, йомры гәүдәсе шул кадәр җиңел күренә, аны кульъяулыгына төреп, кесәдә йөртергә мөмкин кебек.

— Шәһәр чыпчыгыдыр...

Кызлар ашыкмыйча гына, көйнең бөтен нечкә борылмаларын җиренә җиткереп җырлыйлар. Йөрәктән чыккан моң, тын һавада тирбәлә-тирбәлә, аллея һәм сукмаклар буйлап бөтен курортка тарала. Бабайның үз уйлары:

— Безнең як көен шәһәрдә дә җырлыйлар, авылда да! Кайда җырласалар да, кайчан җырласалар да, үзәкләрне өзә шул безнең як көе!..

Моңнан сихерләнгән кешеләр, җыр беткәч, ярсып кул чабарга тотындылар:

— Тавышларыгыз сандугачны көнләштерерлек. Рәхмәт!..

Тыңлаучылар арасыннан Кадыйр исемле утыз яшьләрдәге егет алга чыкты. Бабай бу егетне белә һәм яратмый иде, чөнки Кадыйр кичке уңайга көн саен кызмача була. Мине башкалар белән бутамасыннар дигән сыман, үзе чуар, үзе сөлге озынлыгындагы галстук бәйли.

Кул чабулар тынарга өлгермәде, Кадыйр кызлар каршында гәүдәсен камырландырып баш иде:

— Талантыгызга дан һәм хөрмәт!

Сипкелле кыз белән кара кашлысы пырхылдап җибәрделәр, кызыл иренлесе ни өчендер башын читкә борды. Ике кызның пырхылдавыннан батыраеп киткән Кадыйр сүзен дәвам иттерде:

— Җырыгызга чиксез ихтирам йөзеннән үзегезне бер үбәргә рөхсәт итегез.

Ул, берсенең дә җавабын көтмичә, хәзер генә аягына баскан сипкелленең биленнән кочаклап алды. Сипкелле көлә-көлә кычкырырга тотынды:

— Үтерәсең бит, җибәр, имансыз...

Бу күренештән бабайның күз кабагы тартышып куйды. Әдәп бел-

гән хатын-кыз ят ир кочагында көлеп торырмы? Монысының кайдан икәнен сорап торасы да юк. Сәләх картларга туган түгел бу.

Кара кашлысы сипкеллегә ярдәмгә килде. Ике куллап Кадыйрның беләкләренә асылынды:

— Җибәр дигәч, җибәр инде...

Сипкеллене Кадыйр кулларыннан ычкындырды һәм шунда ук, бәби күтәргәндәй иттереп, кара кашлының үзен күтәреп алды:

— Аны бушлай гына җибәрдем, ә сине, үпмичә, елассаң да юк!

Кара кашлы, егет кулларында яткан килеш, чәбәләнергә тотынды:

— Кытыгым килә, үләм, үләм...

Сипкеллесе аны кисәтергә ашыкты:

— Аякларыңны болгама инде...

Кара кашлының әллә хәле бетте, әллә Кадыйр кочагыннан тизрәк ычкынасы килде инде, ул йөзен куллары белән каплады да хәрәкәтсез калды. Егет аны, чәчләреннән үбеп алганнан соң, аягына бастырып куйды. Бабай җиргә төкерде:

— Тьфү! Өендә ире, балалары бардыр. Монда исерекләр кочагында... Юк, безнең бакчада мондый әрекмәннәр үсми.

Кадыйр, иреннәрен ялый-ялый, кызларның өченчесе янына килде:

— Хәзер сезнең чират.

Кызыл иренле кыз урыныннан сикереп торды. Аның күзләре ут яна иде:

— Якын килмә!..

Кызның кисәтүенә Кадыйрның исе китмәде, ул:

— Сез назландырырга яратасыз икән,— дип, бер кулын кызыл иренленең җилкәсенә салды. Кыз Кадыйр кулын ачу белән этеп җибәрде:

— Китегез дим! Сездән кәҗә тәкәсе исе килә...

Бу шаяру нәрсә белән бетәр дигәндәй, бөтенесе бер мәлгә тынып калды. Кызның кулны этеп җибәрүе Кадыйрның кызган канын кайнатып чыгарды, ахры, бу юлы кызны ике куллап җилкәсеннән эләктерде:

— Үбәм дигән кызны үпмичә җибәргәнем юк минем...

Ул очлайган иреннәре белән кызның маңгаена үрелде. Кыз һич көтмәгәндә чалт иттереп егетнең яңагына сугып җибәрде:

— Оятсыз!..

Тынлык челпәрәмә килде.

— Егет икәнсең! — дип кычкырдылар кызга. Кул чабарга тотындылар.

Оятыннан җир тишегенә керердәй булган Кадыйр бер агарды, бер күгәрде. Кызга яңадан якынлашмакчы булды. Әмма арага хәзер генә килеп җиткән Мәгыйз керде, кулларын йодрыклап Кадыйр каршына басты:

— Сиңа тагын бер тапкыр аңлатырга кирәкме әллә?

Кадыйр күзләрен аларттты:

— Нигә арага керәсең? Ул кыз кем сиңа?

Җавапны Сәләх бабай бирде:

— Безнең якташ ул. Рәнҗеттермәбез, алла боерса!..

Аннан кызга эндәште:

— Әйдә, балам, китик моннан.

Чиккән түбәтәй кигән ак сакаллы карт белән кызыл иренле кыз аллея буйлап янәшә киттеләр. Кыз, әкрен генә атлаган җайга, чәчләрен төзәтеп алды, ләкин эндәшмәде. Башы түбән иелгән иде. Сүзне Сәләх карт башлады:

— Кулыңа куан, кызым. Кайсы якныкы буласың?

— Мин Казаннан, абый.

— Казаннан булгач, үз кеше икәнсең ләбаса. Яңа Казанның яртысы — безнең Сарман яклары...

Каршыларына Мөсәббиха очрады:

— Менә ышан инде син Сәләх абыйга,— дип сүз башлады ул, алар янына килеп җитмәс борын ук.— Башка кичләрне гел минем белән йөри иде. Бүген кызның чибәррәген эләктергән.

— Көнләшмә, Мөсәббиха апа. Якташлар булып чыктык әле без...

Көннәр уза торды, картның якташлары арта барды. Якташлар арткан саен вакыт тизрәк тә, күңеллерәк тә үтә башлады. Монда кешеләрдән тыш, бабай күңеленә якын тагын бер нәрсә — болын бар иде. Аңа күз салмаган көне булмады аның.

Трактор чабып киткән покосларга ике-өч көннән соң ук төс керде. Дүртенче көнне аларны эскертләргә дә тотындылар. Печән җыючыларны күргәч, картның йөрәге тагын чеметеп алды. Мондый чакта да бригадирлары Сәләх бабайны эскерт яныннан җибәрми иде. Хәйләкәр генә елмая да әйтә иде ул картка:

— Зинһар, эскертчеләрне карабрак тор инде, абый. Син куйган эскертләргә яңгыр чиләкләп койса да су үтми...

Их, быел булмады шул...

Бабай көндезге ашның да тәмен тапмады. Ашханә тәрәзәсенә эленгән челтәрле пәрдәләр аша печән исе бөркелде, өстәл әйләнәсендә чәчәкләр, юкә балы исе аңкып китте кебек, колагына ерактагы авылдашларының көлешкәне ишетелгәндәй булды.

Ашханәдән чыгу белән, болынны карарга дип, яңадан кечкенә аланга төште. Печәнчеләр башлаган эскертләренең берсен бастыргычлап та куйганнар. Тик эскерт бабайга ошамады: түбәсе көтек, беренче яңгырдан соң ук төбенә кадәр су үтәчәк. Кәефе кырылган карт сакалын сыпырды, муенын кашып алды. Атлар-атламас кына аллеяга күтәрелә башлады, тик яраткан эскәмиясенә барып җитмәде — артына әйләнеп карады. Тегеләр шау-гөр килеп һаман эшлиләр. «Берничәсе өрәмәдән бастыргычлар сөйрәп чыкты әнә. Димәк, икенче эскертне дә беренчесе кебек очламакчылар...» Карт чыдамады, җил-җил атлап, алар янына төшеп китте. Ерактан ук таягын болгый-болгый кычкырып җибәрде:

— Туктагыз дим, туктагыз!..

Таяклы картның ачулы тавышын ишетү белән, тегеләр тынып калдылар. Бабай, яннарына килеп җиткәч, бөтенесен дә күзләре белән сөзеп чыкты һәм үзе дә аптырап калды: җыенысы уналты-унҗиде яшьлек кызлар, егетләр. Араларында бер генә карт-коры да юк. Бабай үзе озын, үзе нечкә егеттән сорады:

— Кайсыгыз старшы монда?

Каршына киң чалбар кигән тере генә кыз килеп басты:

— Мин, абый. Закирә Садыйкова.

— Эскертне шулай очлыйлармыни, Закирә кызым? Кан дошманыңа да болай килде-китте эшләмиләр. Кемнәр сез? Кайдан килдегез?

Яшьләрнең бер өлеше кызарынды, башын түбән иде, бер өлеше бала-чага сыман борынын тартып куйды. Бары тик «старшы»лары гына югалып калмады:

— Студентлар без. Шәһәрдән колхозга булышырга килдек.

Сөйләшә торгач, бабайга тагын шунысы да мәгълүм булды: колхоз бригадиры аларга эскертне башларга гына кушкан, очларга оста җибәрермен, дигән. Яшьләр кызып киткәннәр дә, оста килгәнче ике эскертне дә үзләре очлап, бригадирны шаккаттырмакчы булганнар. Картның ачудан агарынган йөзе алсуланып китте: яшь чак — ашкынган чак. Нәрсә әйтәсең инде аларга? Карт, тынычлана төшеп, Закирәгә эндәште:

— Арадан дүрт егет эскерт өстенә менсен.

Аягы авыртканын да оныткан бабай эскерт түбәсенә беренче булып үзе менде, аның артыннан дүрт малай күтәрелделәр. Араларында озын егет тә бар иде. Калганнары эскерт өстенә печән ата башлады. Сәләх карт астагыларга юньле-башлы игътибар итми, өсне карый, өстәгеләрне өйрәтә:

— Бу почмагың йомшак...

— Баскан җирең киртләч кала...

— Печәнне үзеңәрәк тарт... Читкәрәк эт...

Эскерт өстендә торуның серен беренче булып озын егет төшенде. Сәнәге кулында уйнап кына тора, салган печәне дә сыланып кына бара.

Ваннага кереп чыгарлык вакыт уздымы икән — эскертне очладылар, бастыргычлап та куйдылар.

Җиргә төшкәч, бабай, бабай артыннан каз бәбкәләредәй тезелешкән студентлар эскертне әйләнеп чыктылар, аны якыннан да, еракрак китеп тә карадылар. Карт куйган эскертнең сырты чәч пәкесенеке кебек үткен, ян-яклары тигез һәм текә иде. Озын егет көлеп куйды:

— Бу эскерткә яңгыр тамчысы ябышып тора алмас, килеп төшү белән җиргә тәгәрәр дә башы ярылыр...

Елмаешып алдылар. Бабай мактады:

— Сездә җен көче бар, яшьләр. Эш җаен гына белеп бетермисез әле... Хәер, теләк булса, эшкә өйрәнү берни түгел ул...

Карт саубуллашып китеп барды: аягы сыкрый башлаган иде. Таныш эскәмиясенә кайтып утыргач, яңадан болынга карады. Яшьләр, ашыга-ашыга, үзләре куйган эскерт өстеннән бастыргычларны алалар, димәк, беренче эскертне дә икенчесе кебек матур итеп очламакчылар. Дүртесе өскә күтәрелде. Алар арасыннан озын егетне бабай шундук танып алды. Ул егет эскертнең әле бер, әле икенче башына бара, кулларын бутый-бутый, иптәшләренә нидер аңлата. Картның җыерчыклы йөзенә елмаю йөгерде:

— Уңган бала икән. Кайсы якныкы булыр бу?

Бабай анысын сорарга онытты шул. Бәлки якташыдыр?.. Бик ихтимал. Яхшы кешенең якташлары дөнья тулы бит!..

Әлмәт

## Равил Фәйзуллин

# Кыска шигырьләр

### НИ УЙ БЕЛӘН ЯШИМ ДИСӘҢ...

Яшим —
ил, ата-анам хупларлык
бер кылыр эшем өчен.
Гомергә рәхмәт укырлык
бер газиз кешем өчен.

### БӘХЕТ ТОЙГАН БУЛСАҢ

Кылдың икән — инде үкенмә
мәхәббәттә, эшләрдә.
Бу дөньяда гомер түгел,
кабатланмый төшләр дә.

### ТӨШНЕ ОЛЫЛАУ

Өндә син юк...
Төшкә керсәң,
күңелдә — бәйрәм чыңы!
Өнем түгел, син күренгән
төш бугай минем чыным.

### ӘҮВӘЛ ДӘ БУЛГАННАР

Бөекләр булган. Җуйганбыз,
Гасырлар — ерак ара.
Тотабыз да Тукай дибез,—
ул шул яңарак яра...

### ХАЛЫКЛАР ТУГЛАНГАН ЗАМАНДА

Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
давың, януың кирәк.
Януыңны халыкларның
күмәк тануы кирәк.

## ОЧА-ОЧА

Кошлар оча-оча югала.
Аерма шул: кошлар юлы эзсез,
Бездән — азмы-күпме эз кала.

Кошлар оча-оча югала...

## КАР ӨСТЕНДӘ АЛ ГӨЛЛӘРЕМ

Нәфис гөлләр яратасың.
Үзен дә шул бер гөл илдә!
Инде ничәнче кат киләм,
син тагын да юксың өйдә.
... Кар өстендә сиңа дигән
ал гөлләрем яна җилдә.

## ҮЗЕҢНЕ КҮРӘМ ДӘ...

Төнлә шундый кызык уйлар килә.
Иртән искә төшми. Онытылган.
Сиңа шундый сүзләр әйтер булам!
Үзеңне күрәм дә тотлыгам.

## ҖИР ТУЛЫ ЧӘЧӘКЛӘР

Җир тулы чәчәкләр!
Гүзәлләр барсы да!
Кайсына
күз нурын түгәргә?
Мең-мең ел яшәрдәй очына-кагына
бер көнлек күбәләк...

## ИМЕШ, КҮКТӘ ФӘРЕШТӘ...

Юк ул күктә фәрештә!
Безнең хыяллар анда —
җирдә ашмаганы эшкә,
ашканнар шулай өскә...

## КАЙЧАН — ЯКЫН...

Күккә кайчан
иң якын була бәндә?
Сөйгәндә, сөелгәндә!

Әгәр бәхетсез икән —
Хәтта галәмдә очса да,
күктән ул
иң еракта...

## ВАКЫТ ИЛИ...

Кемгә җим — алтын читлектә.
Кемгә — җирдә, чүплектә.
Кемнең сүзе — дан этлеккә.
Кемнең — дан бөеклеккә!

Кайдан ашадың дими —
Вакыт барсын да или!

## ЧАГЫШТЫРУ

Җир яна! Эчтән яна Җир!
Кемгә — Җирнең ут сулавы —
тик факел ялкынлавы...

Шигырьләрем — бер халәте
тәнгә сыймаган җанның!
Кемгә алар — язу бары...

## ТЕЛӘК

Өздереп сайрый сыерчык —
аһәңе колагымда!
Кайтып җитү шатлыгыннан
гыйбадәт кыла бугай.
Туган ягын оныткангa
кош җанын бирсен ходай!

## Ә НИК ТАМДЫ...

Әйттең: «Рәхәт! Нинди хозур!
Нинди бәхет бу яшәү!»
...Ә ник тамды балдагыңа
ике бөртек күз яше?

## БОРЧЫЛМА

Син — тормыштан сугышып алган
илаһи минутларым.
Борчылма — начар уйламам,
боекма — онытмамын!

## САУЛЫК

Бар бит — гәүһәр, алмаз бөртеге дип,
канын, җанын аямаучылар.
Җитәме алар мунча түшәменнән
сау тәнемә тамган тамчыга!

## КОМ СӘГАТЕ

...Вакытың үтсә,
җирең китсә аяк астыңнан,—
мәңгелеккә түгел, беткәнлеккә
ишарәле икән ак комнар.

## БЕР БАНКЕТТА

Бар сөйләнгән купшы тостлардан
мәгънәлерәк иде ал шәраб.
Тагын истә калган — бер сылуның
күзләрендә күргән ишарә...

## КАЙЧАК КИЛӘ...

Кайчак җир серүче буласы килә.
Кайчак — галәм белән юанасы
йолдызчы галим булып. Кайчак килә
гомерлек ярың булып уянасы...

## АЙЫЙММЫ СОҢ!

Гармун — сузар өчен,
гомер — узар өчен,
яшьлек — тузар өчен,
йөрәк — сызар өчен.
Айыйммы соң җанны
туар чын җыр өчен!

## БӘХЕТ

Инешләрнең башы чишмә булыр.
Яхшылыкның асылы — тугрылык.
Яшәү — бәхет, илең — синең өчен,
син — ил өчен булсаң горурлык.

## ИЛЛӘР ОЗАТА

Кошлар очып китә...
Җилләр озата.

Кышлар сызып китә
Силләр озата.

Бөек җаннар китә.
Илләр озата...

## ТЕЛӘСӘҢ НИШЛӘ

Җир чәчәкле. Җилләр талгын. Күк аяз.
Кемнәргәдер дөнья — иртә яз.
Теләсәң нишлә: көл, ела язга карап.
Вакытка барыбер, ул — битараф.

## БЕРГӘ ЧАКТА

Очрашкач — сүз онытыла.
Аерылгач — килә сүз.
Бергә чакта тын тору да
сүздән артык, күрәсең.

## СИҢА

Син улыма кара, күзләренә,
мине сагынганда.
Күңлең керсез булса, күралырсың,
чагылырмын анда.

## КЫЕНРАК...

Кыен бәхет кошын тоту,
оя кору.
Кыенрак — тоткач, коргач,
саклап тору.

## МИН АШЫКМЫЙМ

Рәнҗеттең син бүген, бик рәнҗеттең...
Тик ашыкмыйм хөкем итәргә.
Яхшы чакларыңны уйлар өчен
гомер бар бит әле иртәгә.

## САУ КЕШЕГӘ...

Галәм бар омтылырга.
Шәраб бар онтылырга.
Омтылу да, онтылу да
җыр тудыра.

## ЫШАНУ КЫЕН

Ах, беренче карның яктылары!
Күңелләр шыр ачык — ак-пакька!
Бу чакта —
ышану кыен — кемдер
сөңге төзи, имеш, арт яктан...

Ах, беренче карның яктылары!

## СИН КИТКӘЧ

Түздем. Юри бакмадым мин төбәп
яшерен сер сыйган йөзеңә.
Яз түзмәде: серең алмак булып
гөрләвекләр чапты эзеңнән...

## Ә ДӨРЕСЕН...

Минем яшьләр белән каен елый.
Күңелем белән көлә гөлчәчәк.
Кемдер: «Җаны туңган, беткән...» — диде.
Ә дөресен —
боз эрегәч
дулкын әйтәчәк!

## Галимҗан Латыйп

### Безнең яклар

Бөтерелеп ап-ак карлар ява,
Бер карасаң шундый тын дөнья.
Ак карларны юлдан чөя-чөя,
Кыңгыраулы атлар томырыла.

Туй килә, туй,
Чая яшьлек туе,
Зыңлап тора кышкы урамнар.
Малай булсам,
Мин дә чабар идем
Аргамаклар үткән юллардан.

Алып бара кучер аякларын
Җиргә тидермичә атларның.
Ак юллардан
Ак бәхетләр килә,
Аргамаклар чайкый ак ялын.

Җиккән авыл,
Яшьлек өчен җиккән
Чабышларда җиңгән атларын.
Дыңгырдатмый гына алып килә
Машинада өлкән картларын.

Туй булгач, туй инде,
Яше-карты —
Бөтен авыл купкан тамырдан.
Безнең яклар элек-электән үк
Шул туйлары белән танылган.

Дөбердәтеп туйлар иткәннәр дә
Гөлдерәтеп дөнья көткәннәр.
Зат затына тарткан,
Хөрмәт белән
Хөрмәт ителгәннәр өлкәннәр.

Ак бәхетне каралтырга теләп,
Килсә дошман чит-ят җирләрдән,
Безнең халык мәйдан уртасында
Берәүгә дә билен бирмәгән.

Яшик әле туйлар итә-итә,
Көнләштереп яшик дөньяны.
Шатлыкларын,
Кайгыларын төяп,
Әйләнә ул
Барыбер Җир шары.

## Шаран базары

Дәү әнинең
Җылы шәленә төреп,
Әткәй мине
Шаран базарына
Алып китте дөнья күрергә.
Әкиятләрнең алтын ишекләре
Ачылгандый булды күңелдә.

Ашыктыра дөнья, ашыктыра,
Җирән кашка тарта бар көчкә,
Ходай белсен инде бу дөньяны,
Ни чыккандыр минем өлешкә.

Җирән кашка авыр тоякларын
Юлдан төшермим дип тырыша.
Әткәй аны:
«Әй, син, карт юләр, дип,
Юлдан язасың», дип орыша.

Аннан үзе
Бер көрсенеп куя,
Кимсеттеме әллә ул аны.
Кыен иде безнең ишеләргә
Төшенүе ул чак дөньяны.

Киләләр дә арттан
Чажжт иттереп,
Менеп китә атлар үрләрдән.
Берәүләр шул —
һаман «акыллылар».
Берәүләр шул —
һаман «юләрләр».

Бу дөньяга
Хаклык кирәк иде.
Ә бит аны каян аласы?
Кеше җиргә һаман килә, китә,
Киткәннәрнең кала баласы.

Әткәй миңа:
— Улым, кайгырма,— ди,—
Килеп җитәбез,— ди Шаранга.—
Чәй эчкәч тә,
Сине алып барам
Кыңгыраулы кәмит карарга.

Кәмитен дә күрдем,
Базарын да,
Әй сөенде әткәй, сөенде:
— Без кешедән киммени соң, улым!
Янәсе, ул тапкан көемне.

— Мин,— ди,— әле
Башым исән булса,
Күрсәтермен сиңа җиһанны.
Дөнья һаман гел шул көе тормас,
Әйләнә бит, улым, Җир шары.

Әткәй ул чак
Дөрес әйткән икән,
Алдан сизгән,
Тойган барысын.
Үпкәләми китте ул бу җиргә,
Җырлый-җырлый хөрлек марышын.

## Кышкы урман

Кышкы урман, ап-ак карлар ява,
Зәңгәр кием кигән наратлар.
Әйтерсең лә юлга җыеналар
Каралачак яп-яшь солдатлар.

Төлке эзе, куян, көзән эзе,
Пошый эзе ята ярылып,
Тездән карга бата-бата йөреп,
Бүре куган кебек арыдым.

Зур сугышлар үткән җирләр бит бу,
Чиккән гаскәр, алган яңадан.
Җир һаман да ыңгыраша кебек
Сугышларда алган ярадан.

Очрый монда солдат каберләре,
Бил тиңентен сынган имәннәр.
Алар һаман сызгыралар әле
Каршы яктан искән җилләрдән.

Аяк өсте басып яши урман,
Соңгы чиккә кадәр аумый ул.
Мин сау чакта сайрар кошларың да,
Җәнлекләр дә исән-сау, ди ул.

Можайск урманнары.

●

Су өстендә ап-ак бер көймә,
Көч-хәл белән килә бер көйгә.
Исән чыкса ярар иде дип,
Яр читендә халык гөж килә.

Көрәш бара ике арада,
Кеше белән диңгез тартыша.
Йөгәнсез ат кебек ыргылып,
Таудай дулкын килә каршыга.

Килә-килә көймә дигәнең
Һаман үсә, һаман зурая.
Тугыз баллы дулкыннарыңны
Урталайга тота да яра.

Хәвеф-хәтәр йөрткән дулкыннар
Буйсынырга бер дә теләми:
Ташлар ава, минем гадәтне
Яр буйлары күптән белә, ди...

Юк, югалып калмый кешеләр,
Кешеләрнең җирдә эше бар.
Диңгез белән акыл тартыша,
Бар көченә эшли ихтыяр...

Акчарлаклар оча борчылып,
Канатлары тия дулкынга.
Акчарлаклар шатлык китереп,
Яр читенә төшеп утыра.

●

Мин көньякның янар розаларын
Алып кайтып киләм Казанга.
Кырым исе керсен әле диеп,
Соңлап килә торган язларга.

Яңа шатлык, яңа куанычлар,
Түбәм күккә тиде — сөендем.
Чәчәкләрем соңра боектылар,
Башкайлары түбән иелде.

Ник кузгаттым икән мин аларны,
Уттай балкып яналар иде.
Хуш исләре җанга шифа биреп,
Тирә-якка таралган иде.

Кире илтеп куяр идем дә бит,
Терелмәсләр алар — китмәсләр.
Гел рәнҗерләр кебек алар миңа,
Ни кылсам да гафу итмәсләр.

Тыным белән җылы өреп карыйм,
Өмет дигән нәрсә күңелдә.
Розаларны,
Янар розаларны
Һич бирәсе килми үлемгә.

Бик яшиселәре килептерме,
Назлыйм дипме минем күңелне,
Бер дә бер көн хәлсез тамырларның
Сулыш алулары беленде.

Яна хәзер,
Яна розалар
Бер тамчысы булып Кырымның.
Чәчәкләрнең алсулыкларыннан
Әйтерсең лә язлар җылынды.

## Аккош күле

Аккошлары киткән инде,
Күптән киткән.
Ишетелми иртә-кичен
Аккош җыры.
Болытларга тигән купшы наратларга
Якыная бара һаман металл чыңы.

Авыз тутырып әйтә халык:
— Аккош күле,
— Аккош күле.
Ярата шул матурлыкны
Кеше күңеле.

Ярап тора
Безнең шәһәр кешесенә
Аккош күленә
Барам диеп әйтүе дә,
Аккош күленнән
Кайтам диеп әйтүе дә.

Рәхмәт инде аккошларга,
Рәхмәт димен.
Сагынмаклык булсын дипме,
Исемнәрен калдырганнар.
Шулай итә
Олы җаннар,
Изге җаннар,

Кешеләр дә
Аккошлар күк,
Килә-китә,
Килә-китә,
Җан җылысын —
Яктылыгын
Калганнарга бүләк итә.

Берәүләрнең үзе киткәч,
Истәлекле исеме кала.
Ә берәүләр,
Ә берәүләр
Төтен була да югала.
Булгандырмы,
Юктырмы ул
Бу деньяда.

## Тау чишмәсе кебек якты идең

*Сөббух Рәфиковның якты истәлегенә*

Төшләремә кереп сөйләшәсең,
Өннәремдә мин дә сөйләшәм.
Үтеп барган кешеләргә кайчак
Сөббух диеп һаман эндәшәм.

Сагынуларым шулай чиктән ашып,
Эзләп йөрим сине һаман да.
Киттеңме син әллә Коктебельгә?
Тынычтарак роман язарга.

Мин диңгезне күргәнем юк диеп,
Сөйләгәнең әле хәтердә.
Барыйк әле,
Күрик әле, дидең,
Юлыңа бераз акча әзерлә.

Гел борчулар белән үтте гомерең,
Күпне күрдең,
Күпне кичердең.
Тау чишмәсе кебек якты идең,
Биек йөрттең Кеше исемен.

Иркәләнә-нитә белмәдең син,
Каты куллы булды бу дөнья.
Кайгыларын кешенең уртаклаштың:
— Үтәр әле,— дидең,—
Егылма!

Кешеләргә егылмаска куштың,
Үз иңеңне куйдың терәүгә.
Мәрхәмәтле булыйк җиргә, дидең,
Мәңгелеккә түгел бераү дә.

Синең белән горурланам, Сөббух,
Синең белән яшим мин һаман.
Синең кебек олы җанлыларны
Таңнан торып эзлим дөньядан.

1971

## Роберт Миңнуллин

### Әллүки

Мондый җырны еллар, заманалар
Тыңласыннар
һәм баш исеннәр!
Мәңгелеккә туган җырлар бар бит,
Мәңгелеккә туган исемнәр...
Заманында,
Дөньяларын онытып,
Әллүкине Тукай тыңлаган.
Әллә Тукай сөеп тыңлаганга,
Әллүкиләр һаман тынмаган.
Әллүкине тыңлап,
Моңлангандыр Тукай,
Елагандыр, бәлки, сиздерми.
Елагандыр...
Елатканга микән,
Әллүкиләр безне биздерми...
Заманалар белән бергә һәр чак
Безнең җырлар дөрләп яналган.
Әллүкине мин тыңлаган саен
Гел Тукайны уйлыйм яңадан.
Моң кагыла җанга,
Моң агыла.
Әллә тылсым инде, әллә көй?!
Нәкъ Тукайны тетрәндергән сыман
Тетрәндерә мине Әллүки.

### Россия учаклары

*В. Шлёнскийдан*

Россия,
Синең язмыш ачы камчыларга,
Төрмәләргә барып юлыкты.
Шул чагында сине йөзәрләгән,
Меңәрләгән учак җылытты.

Ул учаклар янды
Сөргеннәрдә...
Учак иде үзе ул чаклар...
Россия,
Сине җылыта һаман
Смольныйда янган
Учаклар!

●

Кешеләр киләләр... китәләр —
Яшәешнең кырыс кануны.
Тик язмыштан сораганым булмас
Мәңгелеккә монда калуны.

Башкалардан артык яшәү нигә?
Түгел лә мин җирнең каруны.
Өстен күрәм исән-имин генә
Вакытында китеп баруны.

Китүләре, бәлки, кыендыр да,
Бу дөньядан әле туймасаң?
... Бер мизгеллек шушы гомернең дә
Иге-чиге юктыр, уйласаң.

## Кларага

Мин сиңа күз яше генә,
Әрнү генәдер инде.
Нишлисең, сөю-сөелү
Әрнү белән бер инде!

Көчәйгән саен мәхәббәт,
Борчулар арта бара.
Безнең йөрәкләр тулыдыр
Сөюдән калган яра.

Кичер бу газаплар өчен.
Әллә миңа рәхәтме?!
Тик беребез дә теләми
Башкача мәхәббәтне.

## Ак әкият

Җир бәхеттән оеп ята.
Нейлон аклык.
Нейлон карлар.
Нәкъ шушы аклык шикелле
Пакь күңелле
Безнең ярлар...
Ак тынлыкта тын калганнар
Ак чаганнар,
Ак чыршылар.
Кагыл гына бу тынлыкка —
Ташып ак моң,
Ак җыр чыгар.
Кыш оеган.
Торганы бер
Ак әкият,
Тылсым инде!
Бу аклыкта, кулы барып,
Кем яманлык
Кылсын инде?!.

## Кылыч

Тоткач чыңлап тора кылыч.
Бер карасаң, гади корыч.

Нинди тыныч — кында чакта,
Тик куркыныч — кулда чакта.

Булмас иде һич куркыныч,
Кем кулында бит ул кылыч?!

## Асия Минһаҗева



*Туган елым — 1952. Туган җирем — Мөслим районы, Метрәй авылы. Мөслим урта мәктәбен тәмамладым. Мәктәп бусагасыннан мәктәп бусагасына — 2 ел Баек сигезьеллык мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыттым. Хәзер университетта әдәбият бүлегенең I курсында укыйм.*

*«Бу юлга кергәннәр кире кайтмыйлар»,— диләр. Ә шигърият — озын юл... юлда калмасам иде, дигән теләктәмен.*

*...Юлга чыктым,*

## Мин гашыйк сиңа, Казан

Ук канатлы карлыгачлар
Төлгәли Казан күген.
Тукай Казаныннан матур
Күренде̧ң миңа бүген.
Баскыч-баскыч ташлы сукмак
Мусага илгән юлың.
Горурланасыңдыр, Казан,
Ул һәйкәл — синең улың.
Туристлар тамаша кыла.
Кремль... Кемнәр салган?
Көч куйган, яшәгән, үлгән...
Җирдә матурлык калган.
Шушымы без яшәячәк
Түребез-почмагыбыз?
Шушы җир иҗат итәчәк
Хурыбыз-оҗмахыбыз?!
...Синең бу сары көзеңә
Килдем мин ерак яздан...
Аңлатып сүзләрем бетмәс,
Мин сиңа гашыйк, Казан!

●

Унсигез яшьлек хисемне,
Беләм инде, табалмам.
Эзләп йөрим аваз салып
Газапларны яңадан.
Соң булса да киләчәген,
Дөньяда барын беләм.
Ризамын, килсә дә кабат
Насыйпсыз яры белән.
Сызыла, күңел сызыла,
Өзелеп китәр кебек.
(Кайда син, гармуның белән
Төшләргә кергән егет?..)
Унсигездәге хис белән
Әллә бәлки яналмам.
Эзлим шулай да... элекке
Газапларны яңадан.

●

Җеп җегерли җиде бала анасы...
Япа-ялгыз. Читтә барлык баласы.

Йон җебеме... Гомер җебе чорнала.
Их, авыр соң ялгыз яшәү дөньяда!

Җиде бала җиде якта, җиде ят...
Әниләрен күрерләрме соңгы кат?

Дөньяныңмы йөге баскан аларны?!
Оныттылар мәллә баккан ананы?..

...Әллә орчык, әллә еллар тавышы,
Җиде җирдә бер ананың сагышы.

●

Бүген минем көнем әле:
Кар ява да кар ява.
Беркем бакмаган хис белән
Карап торам дөньяга.

Тантаналы сорылык бу.
Болытлар иңгән җиргә.
Чаганнарның чыдамлыгы
Сынала бүген җилдә.

Нигә тормыш ак кар түгел?!
Гел җилләр дә, гел җилләр.
(Я сына, я түзә диләр
Сыналган чакта ирләр.)

Соңгы күбәләге көзнең —
Салмак кына кар ява.
Кабатланмас хисләр белән
Карап торам дөньяга.

●

Хатадан хали түгелдер әле без.
Сабырсызлык, мин-минлекме? Бар да бар?
Я ни җитми саф булырга, хаклыкка?..
Кешелеклек, хөрлеккәме урын тар?!

Инде бүтән ялгышмам дип туктагач,
(Нигә шундый мәрхәмәтсез булдың, я?)
Адым атларга куркасың, валлаһи!
Элеп алып, селкеп сала бу дөнья!

●

Хисләремә учак яктым әле
Барлык сагышларны эретеп.
Юкса, яшәү читен бу күңелне
Гел-гел сагыну белән өретеп.

Хисләремне өеп учак яктым,
Сүнгән сөю кабат терелсен!
Янсын йөрәк! Зарый елап-елап,
Парә-парә булып теленсен.

Булмый болай зәмһәрирдә яшәп.
Кыш болай да салкын... туңдыра.
(Гаҗәпмени?! Ярты җәйдә генә
Эреп бетсә ярты тундра?..)

●

Бу дөньяга мин дә кирәк, син дә кирәк,
Ник хаксызга рәнҗетергә сине, йөрәк?
Кайчагында ваемсыз дип, әҗерсез дип,
Күп вакытта бушсың диеп, бәгырьсез дип...
Моңнар җыйна! Сагышсыз бул, чарасыз бул,
Тәндә яра... Хиссияттә ярасыз бул!..
...Булма ләкин сәҗдә кылган коллар кебек:
Иң бәхетсез, сүнгән, сынган кыллар кебек!..
Менә шулай... Кичер, йөрәк! Инде теләк:
Без бит
Үзебезгә-үзебез түгел, чорга кирәк!!

●

«Каз канаты ак була ла,
Ир канаты ат була...»
— Җырламыйча барчы, агай,
Күзгә никтер яшь тула.

Тотынып үсте бит ялга
Илгә туган ир бала...
Сүнгән учак, өзелгән җыр,
Их, кала инде, кала!

Үзгәртте шәһәр, үзгәртте...
Син дә — сакаллы агай.
Кайтса иде яшь гомерләр,
Мин — колын, ә син — малай.

Ир канаты ат була ла,
Никтер күңелләр тула...
Казан. Урамнарны буйлый
Кыңгырау, шөлдер, дуга...

●

...Болынлыкта утлап йөри сылу ат.
(Ир егеткә яуны ташлау, сыну — ят.)

...Җәядәй нык, киеренке халәтле.
(Ә кызыкай ни күрекле, хаятле!)

Бөркет белән алыша алмый карчыга!
(Нибарысы унсигез яшь аучыга...)

Әминәдәй ак күңелле тирмәләр...
(Ник кирәкте кешелеккә төрмәләр?!)

...Кыяк үлән. Сары чәчкә... Сылу ат.
Тарих озын... Ул да булган... Салават!

## Тәнзилә Юлдыбаева



*Җир үзенең сабыена илһамны да, җылыны да бердәй тигез бирә. Шуңа күрә кеше шигырьне дөньяга килгән минутыннан яза башлыйдыр дигән фикердә йөрим.*

*Шигырьләрем беренче мәртәбә дөнья күрсә дә, мин инде чирек гасыр шигырь язам дисәм — ялгышмамындыр, чөнки Башкортстанның Күлләр авылында туып, якты дөньяда яшәвемә чирек гасыр.*

●

Болытларга башым салып,
Урал күкрәгендә черем иттем...
Төшләр мине тирбәттеләр,
Хисләремнең серен сүттем.

Назлы җилләр үрде чәчем,
Ак каеннар талир чулпы такты,
Кашмау япты таңкә нурлар,
Баш очымда ал таң канат какты.

●

Сикереп мендем сиңа тагын,
Кара юрга аткаем.
Әйдә, тулпар, яшьлек илен
Янә бергә айкаек.

Җил-давылдай оча тулпар,
Җиргә тими дүрт тояк,
Ахак сымак ак тоякта
Җем-җем итә нур-чуак.

●

Яшьлек белән җилне мичәп, егет,
Кучер итеп синең җырларны,
Таң кызартып, чаң-болыт кузгатып,
Эзләп киттем синең юлларны.

Төсле ташлар чәчкә булып ята,
Текә карап баса тау-йортлар —
Кама тарих яза ярларына,
Яңа кала йөзә ак утта.

Яшьлек белән җилне мичәп, егет,
Кучер итеп синең җырларны,
Таң кызартып, чаң-болыт кузгатып,
Күреп кайттым синең юлларны.

●

Туй килде, килен төште,
Киленкәе аккоштай.
Ата-бабам йоласы —
Мылтык атчы, кодакай.

Туй килде, килен төште,
Сал әле бер, җиңгәкәй,
Мамык кына мендәрең —
Бассын шунда киленкәй.

Туй көннәрен сагынып,
Әй уфтана бабакай.
Шулай төшә киленнәр —
Белеп тор син, малакай.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**ИЮЛЬ-АВГУСТ, 1972.**

Язучы Иван Пиняев **«Советская Мордовия»** газетасында (1 июль) Кама буендагы удар төзелештән алган тәэсирләре белән уртаклаша. Ул үзенең якташы, комсомол оешмасы секретаре Аня Бибина турында бик җылы, матур итеп яза.

**«Вечерняя Уфа»** газетасында 5 июльдә газета хәбәрчесе «Урал-377» машинасы кабинасында Уфадан Чаллыга сәяхәте турында репортаж бастырып чыгарган. Анда ул Башкортстан кызларының һәм егетләренең автогигант төзүдәге тырышлыклары турында сөйли.

**«Советская Россия»** газетасы 6 июльдә «КамАЗны бөтен ил төзи» дигән баш астында удар төзелеш турында фоторепортаж биргән.

**«Правда»** газетасының үз хәбәрчесе Р. Сабиров газета укучыларын 12 июльдә Чаллыда СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышланган кинофестивальнең «Рус кыры» дигән яңа фильмның премьерасы белән башлануы турында хәбәр итә.

Пермь өлкәсенең комсомол газетасы **«Молодая гвардия»** 14 июльдә тугызынчы бишьеллыкның индустрия гиганты — КамАЗ төзелешен шактый киң сурәтләгән мәкалә бастырып чыгарган.

**«Строительная газета»**ның 3 нче бите тулысы белән КамАЗ төзүчеләренең нигез салуда бораулаган коеларга тимер-бетон субайлар кою ысулын куллану тәҗрибәсенә багышланган. Бу ысулны өйрәнү бөтен Союз алдынгы тәҗрибә мәктәбенә әверелде. Аның чираттагы дәресләре Чаллыда үткәрелде (19 июль).

**«Советская торговля»** газетасының 22 июльдә чыккан санында хезмәт иясе депутатларының Чаллы шәһәр Советы депутаты, комплекслы бригада җитәкчесе Гөлфия Медведеваның мәкаләсе урнаштырылган. Анда автор автогигант төзүчеләргә хезмәт күрсәтүче сәүдә һәм көнкүреш хезмәте оешмаларына эшлекле тәкъдимнәрен әйтә.

**«Московская правда»** газетасының 25 июльдә чыккан санында «Москвичлар КамАЗга» дигән рубрика астында «Бөтен ил белән бергә» исемле мәкалә басылып чыккан. Анда Мәскәү проектчыларының, архитекторларының, машина төзүчеләренең КамАЗ белән дуслыгы, башкала хезмәт коллективларының тугызынчы бишьеллык индустрия гиганты төзелешенә керткән өлеше сурәтләнә.

26 июльдә **«Строительная газета»**да Казан инженер-төзелеш тикшеренүләре тресты баш инженеры М. Горячев «Договор һәм нәтиҗәләр» дигән мәкаләсендә КамАЗда тикшеренү эшләре тәҗрибәсен анализлый.

**ТАСС** хәбәр итә: Минск шәһәрендәге автомобиль, мотор, подшипник һ. б. заводларда КамАЗ заводларында эшләячәк 300 дән артык егетләр һәм кызлар һөнәр үзләштерәләр.

12 августта **«Северный рабочий»** газетасы Мәскәү, Минск автомобиль заводлары һәм Ярославль моторлар төзү заводы коллективлары ясаган КамАЗ автомашиналары үрнәкләрен юлларда сынау барышы турында яза. Яңа машина башкалардан тигез, йомшак йөрешле булды, маневрлыгы, идарә итүдә җиңеллеге белән аерылып тора диләр сынаучылар. Ярославль заводында ясалган двигательнең сыйфаты да иң яхшы бәягә лаек.

Кама автозаводының пресс һәм жыю цехлары корпусларында катлар арасындагы сырлы плитәләрнең зур партиясен Приднепровск тимер-бетон конструкцияләр заводы Чаллыга озатты. Бу турыда ТАСС хәбәрчесе яза.

13 августта чыккан санында «Строительная газета» «Камада... Мәскәү» дигән мәкалә урнаштырган. Мәкаләдә башкала вәкилләренең КамАЗдагы эшләре һәм тормышлары сурәтләнә. Төзелеш көннән-көн яңа позицияләр яулый. Ләкин штурмовщина дигән нәрсә бирелә һич юк, тормыш үз ритмы белән ага. Мәскәүлеләр, башка төзүчеләр кебек үк, нормаль ял итәләр, күңелле, кызыклы итеп яшиләр, дип яза газета.

«Известия»нең 24 августта чыккан санында газетаның махсус хәбәрчесе А. Турбанов завод төзелеше барышы, торак йортлар, культура-көнкүреш биналары салганда туа торган проблемалар турында яза. Чаллы шәһәренең яңа йөзе формалаша,— ди ул.— Анда яшәүчеләр, шат күңелле, шау-шулы егетләр һәм кызлар, яңа кала һәм автозавод төзү белән бергә үзләренең киләчәк тормышларын да төзиләр.

ТАСС хәбәр итә: Чаллыда торак йортлар төзелешендә күрше Удмуртия республикасы вәкилләре ударникларча хезмәт үрнәкләре күрсәтәләр. Күптән түгел Ижевскидан Чаллыга ташчылар, штукатурчылар, балта осталары һәм башка һөнәр ияләре — барлыгы 200 төзүче килде.

Зөлфия Нуриева туган авылыннан удар төзелешкә абыйсына ияреп килә. Абыйсы тәкъдиме белән азык-төлек кибетенә өйрәнчек сатучы булып керә. Тиз вакыт эчендә бу яңа һөнәрен үзләштереп кенә калмый, сәүдә эшендә иң тырыш хезмәткәрләрнең берсе булып әверелә. Бу турыда 29 августта чыккан «Советская торговля» газетасында «Комсомол путевкасы белән» дигән мәкаләдә сөйләнелә.

Казан инженер-төзелеш тикшеренүләре тресты коллективы проект-техник документларны әзерләү буенча договор срокларын кыскартырга, ә «Татгражданпроект» институты август аенда Зәй көпчәк заводы, Чаллыда культура һәм ял парклы чертежларын бирергә йөкләмә алды. «Промстройматериал» тресты коллективы һәм Казанның КамАЗ заказларын үтәүче башка предприятиеләре дә үз продукцияләрен вакытыннан элек җитештерәчәкләр. Удар төзелеш заказларын үтәү срокларын күзәтеп тору өчен махсус контроль постлары булдырылды. Бу турыда ТАСС хәбәрчесе яза.

Украина комсомол Үзәк Комитеты органы — «Комсомольское знамя» газетасы «Татарстанның яңа һөнәре» дигән мәкаләдә (30 август) укучыларын бишьеллыкның удар төзелеше белән таныштыра. Мәкалә авторы Камадагы автомобиль комплексы төзелешенә илебездәге республикалар, крайлар, өлкәләр керткән өлеш турында сөйли.

ТАСС хәбәр итә: КамАЗда Чиләбе машина төзү заводында ясалган 40 тонна йөк күтәрә ала торган ике авыр трайлар эшли инде. 60 тонналы өченче трайларны да Урал машина төзүчеләре вакытыннан элек өлгерттеләр. Ул инде КамАЗ төзелешенә җибәрелде.

«Камада автозавод» дигән гомуми баш астында «Строительная газета» 30 августта удар төзелешнең көндәлек эшләрен сурәтләгән һәм төзүчеләр хезмәте турында зур фоторепортаж бастырып чыгарган.

«Волжская коммуна» газетасы 31 августта чыккан санында соңгы еллардагы ике бөек төзелеш — Тольятти шәһәрендәге Идел автомобиль заводы һәм КамАЗ арасындагы мөнәсәбәт, үзара ярдәмләшү, Куйбышевгидрострой белән Камгэсэнергострой коллективлары арасындагы социалистик ярыш турында «Кама колачы» исемле мәкалә басып чыгарган.

«Вечерняя Пермь», «Вечерние новости» (Вильнюс), «Марийская правда», «Рабочий путь» (Смоленск) газеталары КамАЗ төзелеше барышын сурәтләгән АПН материалын басып чыгардылар.

ТАСС хәбәр итә: Тольятти шәһәрендәге Идел автомобиль заводында Чаллыдан килгән эшчеләр монтаж, станокларны, автомат линияләрне көйләү, ходка җибәрү һәм эксплуатацияләү һөнәрләренә өйрәнәләр. Ел ахырына кадәр биредә 2000 гә якын белгеч әзерләнәчәк.

## Гази Кашшаф

# ДИЛӘРӘ ХАНЫМ

Безнең В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында миңгә якын фән эшчесе санала. Алар арасында исемнәре бик ерак илләрдә дә атаклы профессорлар бар. Язучы каләменә лаеклы дистәләрчә профессорлар, доцентлар, өлкән укытучылар һәм ассистентларны санарга мөмкин.

Фән ул шундый нәрсә, ул бирәүне дә кызганмый, бирәүгә дә ишеген ачып куймый. Аның баскычыннан югары күтәрелү өчен барлык көчеңне салып эшләргә, эзләнергә, тикшеренергә, ачыш ясарга кирәк. Тырышлык, тырышлык һәм тагын бер тапкыр тырышлык! Көчеңне юк-барга сарыф итмичә — эзләнү, тәҗрибә ясау, тикшеренү, чагыштыру... Фән ул үзенә Мәҗнүн мәхәббәтен таләп итә, бүленми торган мәхәббәтне!

Фәнгә фанатикларча бирелгән кешеләр бездә дә күп, алар үсә тора һәм даны планетага таралган Казан университетының традициясен алар алга алып китәчәк. Фәнгә фанатикларча бирелү — ул архивлардан, лабораторияләрдән, китапханәләрдән чыкмыйча утыру дигән сүз түгел. Бездә совет галимнәре, алар фәнне марксистик-ленинчыл методологиягә таянып үстерәләр, үзләре дә тормыштан аерылган, мәгарәдә бикләнеп белем алган һәм халык интересларыннан ерак торган кешеләр түгел. Алар галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре.

Ләкин тормышта һәрбер галимнең үзенчәлеге бар, башкаларда күрелмәгән сыйфатлары бар. Бу яктан мин Диләрә Тумашеваны беренче урынга куяр идем.

Алда без аның фән докторы булу дәрәҗәсенә ничек ирешүен күрербез, ләкин хәзер берничә деталь белән аны башка галимнәрдән аерып аласым килә.

Диләрә Тумашева тарих-филология факультетының бертавыштан сайлап куелган деканы. Ул — хәзер фәннәр докторы, профессор. Гыйльми Совет утырышлары аның җитәкчелегендә уза.

Шунысын да әйтик, факультетның Гыйльми Советы ике. Аның берсе факультетның эчке эшләрен карый, икенчесе диссертацияләр яклау буенча эш алып бара. Соңгысында Казаннан гына түгел, төрле шәһәрләрдән килеп, филология һәм тарих фәннәре буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклыйлар. Докторлык дәрәҗәсе алу өчен яклау соңгы елларда була башлады. Диссертация яклаучылар — тарихчымы ул, филологмы — Советның профессор



Тумашева җитәкчелегендә узын яраталар, янәсе, аның кулы җиңел була, ВАКта (Югары Аттестация Комиссиясе) диссертация озак йөрми, тиз расланып кайта. Яклану Советы җыйнак, эшлекле һәм күңелле уза.

Факультетның икенче Советына күз салыйк.

Тумашевага кадәр дә без бик күп деканнар кул астында эшләдек. Аларның берсе дә начар түгел иде, үзебез сайлап куйган могтәбәр абзыйлар, исемле галимнәр иде. Ләкин Тумашева килгәч, Гыйльми Советларның эшлеклелеге көчәйде. Элек, мәсәлән, чал чәчле яки «фән кимергәндә» чәче бөтенләй коелып беткән кафедра мөдире аягүрә баса да:

— Без кафедрада шулай сөйләштек, Гыйльми Советтан раслауны сорыйбыз! — дия иде.

Гыйльми Совет чал башка ихтирам йөзеннән аның сүз белән әйткән тәкъдименраслый һәм «соңыннан рәсмиләштерергә» мөдирнең үзенә калдыра.

Хәзер мондый хәзерлексез чыгулар бетте.

Тагын шундый кечкенә бер деталь.

Гыйльми Совет утырышлары гадәттә 93 нче аудиториядә уза. Ул аудиториягә бүлмәнең ике башыннан да керергә мөмкин. Профессор Тумашева декан булгач, алгы як ишек утырыш башлануга бикләп куела торган булды. Янәсе, җыйнак булыгыз, Совет утырышы барганда, элеккечә тугарылып, кереп-чыгып йөрмәгез. Докладчыга яки диссертация яклаучыга, утырышны җитәкләүче председательгә комачауламагыз. Соңга калмагыз, калгансыз икән, кешегә күренмичә, арттагы ишектән атлагыз!

Без шулай итәкләрне җыеп йөри башладык.

Студентларның индивидуаль уку планнарын раслауны, теге яки бу спецкурс программасын яки укытучыны раслау кебек, элек җиңел генә узып китә торган мәсьәләләрне декан иң элек җентекләп үзе тикшереп чыга. Кайвакыт мәсьәлә кире дә кагыла.

Элекке Советларда теге я бу мәсьәләнең, әгәр Совет членнарыннан берсе күтәреп чыга икән, каралмыйча калганын мин хәтерләмим. Хәзер:

— Бу мәсьәләне кафедра әзерләп җиткермәгән!

— Иң элек уку-методик комиссиясе карарга тиеш иде моны! — кебек сәбәпләр белән кон тәртибеннән төшеп калалар.

Гыйльми Советның бер утырышында яшь укытучылар белән эшләү һәм аларны тәрбияләү мәсьәләсе каралды. Югары уку йорты киләчәктә бүгенге яшьләр кулына күчәчәк ич, шуңа күрә яхшы алмаш тәрбияләү мәсьәләсе бик мөһим һәм ул Совет членнарының активлыгы белән узды. Яшь укытучыларның практик эшен тикшергән комиссия дә үз сүзен әйтте, кафедра мөдирләре дә үзләрендәге хәлне аңлатып, конкрет тәкъдимнәр ясадылар, карар проекты да укылды. Хәзер инде бер сүз дә өстәргә кирәк түгел шикелле иде. Деканыбызның эшне өстән-өстән генә түгел, чын мәгънәсендә гыйльми, политик югарылыкта хәл итәргә омтылуын без тагын бер тапкыр

күрдек. Ул мәсьәләне Совет карамагына чыгарганчы үзе өйрәнгән, комиссия фикерләренә сукырларча ышанып калмаган һәм яшь укытучылар белән эшнең кайсы кафедрада ничек булуына анализ ясаган. Кайбер кафедралар яшь укытучыларны, әле тиешле методика белән коралланып җитмәгән килеш, башлыча татар бүлегендә эшләтәләр икән.

— Бу — дөрес адым түгел.— диде Диләрә ханым. Совет аның тәнкыйтен кабул итте.

Факультетта интернациональ тәрбия алып баруның торышы — шулай ук Совет утырышында тикшерелгән җитди проблемалардан иде. Бу аңлашыла да, чөнки без милли республика шартларында эшлибез, университетта милли бүлек бар. Дистәләрчә милләт балаларын дуслык-кардәшлек рухында тәрбияләү аеруча әһәмиятле һәм мактаулы хезмәт. Декан үзенең чыгышында идеологик факультетта һәрбер лекциянең интернационализм һәм патриотизм идеяләре белән сугарылган булырга тиешлеген әйтеп, патриотизмның мәгънәсен дә киң рәвештә аңлатырга чакыра. Тар карашлылык интернациональ идеяләргә сыймый, туган илгә мәхәббәте — туган авыл белән чикләнеп, өй артындагы каен яфракларына эленеп калмаска тиеш... Ул Ватанның, халыкның героик көрәше һәм хезмәте, аның интернациональ миссияне үтәү традицияләренә бәйле.

Профессор Тумашева, декан буларак, факультеттагы спецкурслар системасын җентекләп өйрәнә, ләкин бу — мәсьәләнең бер ягы гына әле. Ул спецкурсны кем алып бара, нәтиҗәсе нинди, ни өчен бу кафедрада гыйльми дәрәҗәсе булмаган кешегә тапшырылган ул? Ник тәҗрибәле галимнәрнең еллык лекция сәгатьләре аз куелган? — әнә шундый мәсьәләләр уку процессының сыйфатын күтәрергә булышалар. Мондый мәсьәләләрне тикшергәндә декан Тумашева бик принципиаль позициядә тора һәм шуның белән ул кафедра мөдирләрен дә гыйльми җыйнаклыкка, дисциплинага өйрәтә.

Гыйльми Советта гына түгел, һәркайда уку-укыту процессының сыйфатын күтәрү чараларын эзли, таба һәм аны коллективка җиткерә белә.

Хәтердә әле, факультетның партия җыелышы КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарын өйрәнүгә һәм шул уңайдан факультетның бурычларын билгеләүгә багышланган иде. Докладчы да, чыгып сөйләүчеләр дә бу тарихи карарны бик хуплап сөйләделәр, факультетның филология бүлекләренә йөкләнә торган бурычларны да бик дөрес күрсәттеләр. Ләкин Диләрә Тумашевага нәрсәдер әйтелеп бетелмәгән төсле иде әле. Ул, мамык шәлгә төренеп, зур залның уртасында игътибар белән генә тыңлап утыра. Салкын тидергән булса кирәк. Шулай да ул мондый мөһим документ турында үз сүзен әйтмичә кала алмады. Аның тарихи әһәмиятен төрле яклап ачканнан соң, үзебезнең өскә йөкләнгән бурычларга тукталды:

— Без бит укытучылар, шушы карар нигезендә без үзебез укыта торган программаларны тирәнәйтү турында уйларга тиешбез!

* * *

Татар теле кафедрасын Тумашевага кадәр Мирфатих Зәкиев җитәкләде. Ул университетка сугыштан соң гына студент булып килгән сәләтле егетләрнең берсе. Университетны тәмамлады, аспирантураны тәмамлады, кандидатлык диссертациясе яклады, факультетның партбюро секретаре булып эшләде, шул ук вакытта баш күтәрмичә докторлык диссертациясе яклар өчен киң фронтта гыйльми эзләнү-

ләр алып барды. Докторлык диссертациясе дә якланды, элекке укытучыларының күз алдында ул доктор, профессор, кафедра мөдире дәрәҗәсенә күтәрелде.

Яшь галим университетка, фәнгә бик нык тамыр җибәреп, какшамаслык булып береккән шикелле иде. Юк, калдырмадылар. Синең кебек яшь, энергияле һәм чын фән кешесе башка җиргә кирәк, диделәр. Профессор Зәкиевне Казан педагогия институтының проректоры, аннары ректоры итеп билгеләделәр!

Фән һәм административ эштә уңыш теләп, университет аны данлы юлга озатты. Хәзер мондагы кафедраны җитәкләү мәсьәләсе алга килеп басты. Кем булыр соң ул? Хәер, доцентлар җитәрлек, кирәк икән — телчеләрне Фәннәр академиясеннән дә табып була.

Университетта кафедра кебек урын бушаса, галимнәр арасында гаҗәп җанлану китә. Шул фән өлкәсендә эшләүчеләрнең кызыксынуы аңлашыла да, чөнки аның өчен кафедраны кем җитәкләве проблема! Синең гыйльми тикшерену планыңны ул хуп күрерме, әллә син теләмәгән башка проблемага күчәргә кушармы.

Шунысы гаҗәп, башка кафедра кешеләре, хәтта икенче югары уку йортларында эшләүчеләр дә:

— Ул урынга кем килә?

— Кемне күздә тотасыз?

— Ә фәлән фәләнич берегезнең дә исенә килми булыр?! — кебек сораулар белән сине урамда туктатып, бик озак киңәш-табыш күрсәтәләр.

Билгеле, кафедра чаклы кафедра мөдире урыны бушагач, анда нәкъ мин эшләргә тиеш! — дип йөрүчеләр дә шактый була икән. Шуңа күрә, рәхим итегез, ачык конкурс белдерелә. Гаризаңны бир, документларыңны тапшыр һәм...

Мирфатих Зәкиев киткәннән соң, тел кафедрасын җитәкләргә теләүче галимнәр шактый булган, мин аны соңыннан гына белдем. Ләкин конкурс комиссиясе дә, университет җитәкчелеге дә Диләрә Тумашева кандидатурасына тукталганнар. Гыйльми Совет аны бертавыштан раслый һәм ояшлы көннәрнең берсендә безнең коллектив аны тәбрик итте.

Кешене вакыт сыный, диләр. Вакыт узды. Диләрә Тумашева кафедрасын менә дигән итеп фән юлыннан югарыга таба алып китте. Китап артыннан китап өлгерә, университетның нәшрияты аларны басып бетерергә өлгерә алмый. Әледән-әле фән кандидатлары исемен яулап диссертацияләр яклана. Алар арасында Тумашева җитәкләгән аспирантлар да бар.

Һәм без яшь тел галиме белән юлда очраштык. Юлыбыз университетка таба иде. Мин кафедра хәлләрен, теге я бу иптәшнең хезмәте ничек бара икәнлеген сорашам, ә ул ашыкмый гына җаваплар кайтара.

— Бик әйбәт галим бит ул Диләрә ханым,— ди минем дустым.— Аның урыны миңа дәүләт аппаратында кебек тоела.

Ул башы белән Кремльгә таба ымлый.

— Анда ул җәмгыять өчен күбрәк файда китерер иде дип уйлыйсыңмы? — дим мин.

— Нигә, дәүләт масштабында колач җәеп эшләүче кешеләр анда кирәкмимени?

— Бер уйлаганда, синең сүзләрдә дөреслек бар,— дидем мин.— Тормыш шуңа таба бара: һәр министр кимендә фән кандидаты, алга табарак — докторы булырга тиеш! Ләкин Диләрә ханымның университет коллективыннан китәсе киләме соң?!.

— Әлбәттә, килмәс. Тик тормыш таләбе бар бит әле!..

Тормыш таләбе... Ә тормыш аңа яшь кадрларны тәрбияләү бурычын йөкләгән. Һәм ул аны намус белән алып бара.

Чираттагы Гыйльми Советларның берсен Диләрә ханым бик салкын сүзләр белән ачып җибәрде. Авыру идеме ул, әллә улы авырыйимы, ни өчен борчыла, нинди кайгысы бар?!

Мин арттагы рәттән күзәтәм һәм деканның күңелсезләнеп утыруына үземчә сәбәп эзлим. Трибунада профессор Шофман сөйли, башкалар тыңлыйлар. Диләрә ханым да тыңлый кебек, тик — күренә, күңеле әллә кайда. Ул арада деканатның секретаре кереп, Тумашевага телеграмма тоттырды.

Шундук Диләрә ханым телеграмманы укыды... Я ходай, үзгәрсә дә кеше үзгәрә икән. Шул ук секундта Диләрә ханымның йөзе балкып китте, ул шатланып көлде һәм телеграмманы гыйльми секретарьга сузды.

Аудитория яктырып киткән кебек булды. Ниһаять, Шофман докладын тәмамлауга, декан аягүрә басты һәм:

— Әле генә Алма-Атадан телеграмма килде. Вахит Хаков докторлык диссертациясен уңышлы яклаган! — дип кул чаба башлады. Яңа докторны Совет бердәм тәбрик итте.

Барысы да аңлашылды: Диләрә Тумашева түземсезлек белән яклау нәтиҗәсен көтеп торган икән. Иртән үк килергә тиешле телеграмма көндезге ике сәгатьтә дә алынмагач, коллегасы өчен бик нык борчылган һәм ул аның йөзенә чыккан иде.

* * *

Музыкага баланы кече яшьтән өйрәтә башлыйлар, ә фәнгә? Югары уку йортыннан башланамы ул, аспирантураданмы? Миңа калса, фән дә музыка кебек, иртәрәк керешкәнне ярата. Билгеле, һәрбер атаана үз баласының киләчәген якты итеп күрәсе килә, тик профессорлыкка алдан ук әзерләмиләр булыр. Шулай да яшьлек юлының кайсыдыр бер өлешендә, баланың сәләтенә карап, аның күңеленә орлык салып калдырырга тырыша.

Яшь Диләрәнең күңеленә фән орлыгы кайчан салынган, әйтүе кыен. Шулай да мин бу яктан ата-ананың роле зур дип уйлыйм. Диләрәнең әнисе — Әминә ханым татар мәктәбендә укытучы була, ул үзе Пермь өлкәсеннән, укытуы Түмән өлкәсендә. Дәреслекләр җитми, ләкин бу хәлдән чыгу юлы табыла. Ананың апалары кулдан дәреслекләрне күчерәләр. Моны Диләрә бала вакыттан ук күреп, белеп тора.

Уку яше кергәч, Диләрәне рус мәктәбенә бирәләр, Әминә ханым аны татарча да укыта. Җитмәсә, музыка мәктәбенә дә йөрергә мәҗбүр итә. Диләрә Сәйдәш маршларын, Җәүдәт Фәйзинең «Урман кызы» ноталарын өйрәнеп үсә. Ләкин мәктәптә ул математикадан да бик яхшы укучы исәпләнә.

Әтисе — Гариф абый — шулай ук эшчән кеше була. Ул пароходта кочегар, ФЗУда токарь. Соңыннан һөнәр мәктәбендә укыта һәм пенсиягә чыкканда училищеның директоры булып эшли. Гариф абый мебельләрне үзе ясый, үзе полировать итә; үзенә дә, балаларына да таләпчән була. Шул сыйфатны ул Диләрәдә дә булдырырга тырыша.

Ата-ана тәрбиясе уңдырышлы була: урта мәктәпне Диләрә отличнога тәмамлый. Шуның өстенә ул актив җәмәгать эшчесе: учком председателе, комсомол оешмасының секретаре... укуын җәмәгать эше белән бергә алып бара.

— Анасы укытучы, атасы директор булгач,— дисезме?

Юк, Диләрә кайгы-хәсрәтсез үскән кыз түгел.

— Бишенче класста укыганда, миңа беренче тапкыр елка ясадылар,— ди Диләрә ханым.

Ләкин бу — Әминә ханымның кызын соңгы тапкыр куандыруы була. Март аенда ул туберкулездан үлеп китә...

— Әти белән икәү генә яшәдек. Әни үләр алдыннан әтигә «Диләрә үскәнче» өйләнмәскә кушкан...

Унөч яшьлек Диләрәгә дәрес әзерләп кенә утырырга туры килмәгән.

ВЛКСМ Үзәк Комитетының рекомендациясе буенча Диләрә Җаббарова (кыз фамилиясе) Мәскәү дәүләт университетының көнчыгыш бүлегенә, филология факультетына укырга керә. Отличница буларак, аны имтихансыз алалар.

Мәскәү университеты аны әзлекле рәвештә фән юлына әзерли, чөнки Диләрә Гарифовнада нәкъ әнә шул фән кешесенә кирәкле сыйфатлар күренә. Мәдинә Богдановага ул кыргыз әдәбияты буенча курс эше башкара, төрек, үзбәк телләренең белгече булырга хәзерләнә, шул ук вакытта гарәп, фарсы, француз, немец телләрен өйрәнә. СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты Н. К. Дмитриев аны татар теле белән дә кызыксындыра. Төрек теле буенча университетны тәмамлаган Диләрә Җаббарова аспирантураны татар теле буенча уза.

Университетта биш ел, аспирантурада өч ел Диләрә Җаббарова белән бергә укыган шагыйрь Шамил Мәхмудовтан мин Диләрәнең студентлык еллары турында сөйләвен үтендем. Ул нинди максат белән кызыксынуымны сорады, мин әйттем.

— Алайсаң,— диде Шамил,— мин шагыйрьләрчә җавап бирим. Юкса, мин аның турында яхшы яктан бик күп сөйли алыр идем. Ул — Диләрә — эчтән балкый торган студентка иде. Белеме, культурасы, кешегә яхшы мөнәсәбәте белән балкый иде.

Яшьтән үк Себер татарларының сөйләшүләрен ишетеп үскән кызның игътибарын Н. К. Дмитриев Түбән-Тобол якларына юнәлтә. Аның җитәкчелегендә өч ел аспирантура сизелми диярлек уза. Нәтиҗәдә Көнбатыш Себер татарларының тел үсешенә багышланган диссертация яклана һәм Диләрә, инде Тумашева фамилиясен алып, 1952 елның азагында Казан дәүләт университетына килә.

Ассистент, өлкән укытучы, доцент, кафедра мөдире, профессор, декан... Ләкин бу баскычларны берәү дә бер елда, җиңел генә узмый. Еллар кирәк, аннан да бигрәк фәнгә гашыйк булу кирәк, аның үрләрен яулап алу өчен тырышлык һәм таш яуса да тукталмыйча хәрәкәт иттерә торган эчке яшерен көч булуы — одержимость кирәк. Диләрә Тумашевада шул көч мул булган, күрәсең. Укыту методикасын да ул җиңел үзләштереп ала. Сүз укыту методикасын теоретик белү турында түгел, үз җилкәңдә аның серләренә төшенү турында бара. Диләрә Тумашева беренче лекциясен хәзер юмор аша гына искә ала:

— Ике сәгатькә җитәрлек конспект әзерләдем. Аудиториягә кергәч, ул 20 минутка гына җитте... Студентлар да усаллар, төрле сораулар биргән булып, минем белемне сыныйлар...

Аннан соң... үзенә таләпчән булу, йомшаклык күрсәтмәү, авырлыклар алдында тукталып калмау... Чыннан да аз гына вакыт эчендә ул фонетика, лексика, хәзерге татар теленең морфологиясе, тел белеменә кереш, төрки телләрнең төньяк-көнбатыш группаларының чагыштырма грамматикалары буенча спецкурс, татар һәм төрки телләрнең фигыль грамматик категорияләре буенча спецкурс кебек дисциплиналардан лекцияләр укый. Шуның өстенә өзлексез гыйльми тикшеренү, фәнгә өлеш кертү буенча эш алып бара.

Мәскәү университетында укыган чакта, 1947 елда, Диләрә Себер татарлары яшәгән җирләрдә тел өйрәнү экспедициясенә катнаша. Бу — аның беренче экспедициясе. Беренче авырлыклар белән очрашу аңа беренче куанычлар алып килә: яңаны ачу шатлыгы!..

Шуннан соң ул тоташ егерме ел диярлек бик күп экспедицияләргә катнаша. Хәер, катнаша сүзе бу урында тәгәл мәгънә бирми, чөнки ул экспедицияләрдә Диләрә Тумашева үзе җитәкче, ул — оештыручы, маршрутны, тикшерү методикасын, эчтәлек юнәлешен һәм күләмен билгеләүче.

Бу экспедицияләргә хәзерләнүнең соңгы бер ун елы минем күз алдымда барды. Диләрә ханым кыш уртасыннан ук ул экспедицияләрнең программасын эшли, катнашырга тиешле студентларны әзерли, мәсьәлә кафедра утырышына күчә, аннан деканатка, ректоратның фән бүлегенә. Анда исә акчаны бик нык учлап тоткан булалар, бармак араларыннан сытылып чыккан унлыклар студентлар санын кыскартырга мәҗбүр итә. Чөнки әнә теге кафедра буенча да, монысы буенча да фәнни экспедицияләр шактый... Кеше санын кыскарту — калган катнашучыларның программасына өстәмә йөкләмә булып төшә... Ниһаять, экспедициягә юнәләләр... Кайткач, тагын хисап биреп бер мәш киләләр, экспедиция нәтиҗәләрен эшкәртү исә икенче елга чаклы сузыла. Шулай итеп, Диләрә Тумашевага 18 ел буе ял итәргә туры килми. Еллар узган саен, экспедиция материаллары да катлаулана, тормыш та катлаулана...

Алга китеп шунысын да әйтергә кирәк, кайчандыр Тумашева җитәкчелегендә экспедицияләргә катнашкан студентларның дистәдән артыгы фән юлыннан китәләр. Алар арасыннан фән кандидатлары, ассистентлар, редакция һәм партия эшчеләре үсеп чыкты.

Диләрә ханымның үз балалары да үсеп килә. Аларны да карарга кирәк. Җәйге ялның бик күп өлеше экспедициягә багышланган, яңа уку елы башланганчы атна-ун көн вакыт кала икән, путевкасыз-нисез, кыргыйларча (диким путем, ди бит халык) Кырымга барып чыгалар, монда әни кешегә яңа кайгы өстәлә:

— Ләйсән кая югалды соң, суга бата күрмәсен!..

— Равил,— дип дәшә ул иренә,— Айдар күренми бит, кая китте икән тынгысыз малай?!

Бер елны, яңа уку елы башлангач, без Диләрә ханым белән кафедрада очраштык. Ул миңа бик йончыган, ябыккан кебек күренде.

— Әллә быел да ял итмәдегезме? — дип сорадым.

— Чират тимәде шул,— диде Диләрә ханым һәм ягымлы гына елмаеп куйды.

Мин соңыннан сорашып белдем, Диләрә ханым, бер студентканы ияртеп, экспедиция урнашкан авылдан 16 километр ераклыктагы бер татар авылына барып кайтырга уйлый. 16 километр — Татарстан яки Башкортстан өчен куркыныч маршрут түгел, ә Себердә? Тирә-ягы сазлык белән чолганып алынган, әллә кайда югалып яткан авылга барып чыгу өчен үзеңә канатлар куярга кирәк. Бөтен җанлы тормыштан аерылып яшәгән ул авылга ат белән дә, машина белән дә баруы мөмкин түгел. Самолет утырырлык та урын юк, бары сукмакны белүче махсус кешеләр озатуы белән генә барып чыгарга мөмкин. Авылда клуб мөдире юл күрсәтә:

— Менә шушы сукмактан бер сукыр карчык узган. Сез дә шуның эзеннән китегез!..

Әгәр сукыр карчык таягы белән капшана-капшана сазлыкны узып, авылга барып җиткән икән, безгә — күзле кешеләргә — нигә узмаска! — дип уйлый Диләрә Тумашева.

Чыннан да, юлда андый-мондый хәвеф-хәтәр очрамый һәм Тумашева студенткасы белән кирәкле авылга килеп җитә. Курку авылда башлана:

— Ничек килдегез?

— Тирә-як аю белән тулган...

— Озатучыгыз да юк...

Фән белән мавыккан кайнар йөрәкле кызларга бозлы су коелган кебек була... Ләкин килгәч инде эшне төгәлләмичә киту юк. Кирәкле белешмәләр алына, тел, диалект өйрәнелә, җирле сүзләр кәгазьгә теркәлә. Хәзер инде килгән юлдан экспедиция үзегенә кайтасы гына кала. Ләкин курыкмыйча ничек кайтырга? Кем озатыр? Кирәк чакта аның кешесе дә табылмый бит әле? Бик нык ялынгач, бер сунарчы боларны озатырга яллана. Ләкин ул Тумашеваларны ярты юлга чаклы да озатмый, сазлыкның иң куркыныч җиренә килеп җиткәч:

— Минә бу — аю юлы, менә монысы — сез барасы сукмак, бу якта да аю юлы, тегесе дә аю юлы. Сез шушыннан китегез!..— ди.

Диләрә ханым ул хәлне хәзер куркыныч төш шикелле искә ала һәм:

— Шуннан соң сазлыктан йөрмәскә ант иттем...— ди.

Ләкин бу эштә антка тугрылыклы булу читен икән, Диләрә Тумашевага аны еш кына бозарга туры килә. Чыннан да, Төмән, Омск, Новосибирск, Томск, Кемерево өлкәләрендә берсе икенчесеннән йөзләрчә километр ераклыкта, урман араларында, сазлык уртасында калган утрауларда яшәүче дистәләрчә авылларның һәркайсысын йөреп чыгу һәм фән өчен кирәкле материалны туплау максат итеп куелган икән, ант истән чыгып тора.

Бер елны студентлар, экспедициядән кайткач, Диләрә ханымга сокланып та, аның исеме белән горурланып та болай сөйләделәр:

— Бер авылга һич ничек бара алмадык. Сазлык, сазлык... Диләрә апа вертолет яллап барып кайтты...

Һәм шуннан соң ул авылга вертолет регуляр оча башлый.

Төмән өлкәсендә йөргәндә, Диләрә ханымга бер елганың икенче ягына чыгарга кирәк була, көймәченең алачыгы икенче якта, тик ул каядыр киткән. Ул арада су буен кәтү сырып ала, Диләрә ханым кәтү уртасында кала. Нишләргә? Сөзәргә әзер торган үгезләрне күреп, галим сыерлар арасыннан юлга таба йөгерә. Ул үгезләрнең аңа ларып карауларын башта аңламый, соңыннан гына үзенең кызыл сарафаннан икәнен күреп ала...

Егерме елга якын экспедицияләрдә йөргән кеше нинди генә маҗараларга очрамый, аның барысын яза китсәң, зур бер повесть килеп чыгарга мөмкин.

Кеше аягы тимәгән җирләрдән йөрү, билгеле, җиңел түгел, баштан төрле хәлләр кичә. Ләкин максат зур. Диләрә Тумашева «Себер татарларының диалекты»н тикшерү максаты белән яши. Ләкин тикшерүнең методлары төрле: мәсәлән, яңа бер диалекталь сүзгә очрадың, ди. Аның мәгънәсен ачыклау белән үзеңне чикләргә була, шулай ук диалектны татар һәм башка төрки телләргә мөнәсәбәттә өйрәнергә дә мөмкин. Монысы инде катлаулы эш. Диләрә Тумашева соңгысын сайлый.

Себер татарларының телен өйрәнүнең үз тарихы бар. Башта аны XVIII йөз азагында миссионерлык максаты белән өйрәнергә керешкәннәр. В. В. Радлов исә бу өйрәнүне гыйльми нигезгә сала. Себер татарларының диалектларын беренче булып классификацияли. Н. Ф. Катанов, совет чорында В. А. Богородицкий үзләреннән өлеш кертәләр. Соңгы елларда Л. Җәләй, С. Әмиров, Г. Әхәтов, Н. А. Баскаков бу өлкәдә эшләп киләләр.

Ләкин боларның берсе дә мәсьәләне тулысынча иңләп алып, аның барлык проблемаларына тукталуны максат итеп куймаган. Тюркологлар Себер татарлары диалектларын төрле методика буенча, төрле максатлардан чыгып, һәрберсен башкаларыннан аерып алып өйрәнгәннәр. Шуңа күрә тел системасы гыйльми төстә язылмаган, булган диалектларның фонетик системаларын һәм грамматик төзелешен гыйльми рәвештә күрсәтеп бирергә кирәк була.

Бу бурыч тикшерүчедән Себер яки Көнбатыш Себер татарлары дип аталган барлык төрки тел группаларын комплекслы тикшереп чыгуны таләп итә. Димәк, Диләрә Тумашева Уралдан алып Кемерово өлкәсенә чаклы киң территориядә яшәүче барлык төркемнәрне өйрәнергә тиеш була. Әнә шундый глобаль тикшерү генә диалект массивларын билгеләргә, аларны берсен икенчесеннән аерып карарга мөмкинлек бирә, ваграк диалект берәмлекләренә бүлгәләргә, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, уртак һәм аерымлык сызыкларын билгеләргә юл ачыла.

Мин Диләрә Гариф кызы Тумашеваның докторлык диссертациясен менә икенче тапкыр укыйм. Укыган саен ул миңа кызык, укыган саен аның гыйльми тирәнлеге күбрәк ачыла бара. Узылган юлларның километрын исәпләп чыгарга мөмкин, язып алынган диалектик сүзләрнең санын билгеләргә мөмкин, йокысыз төннәр, укылган китапларның саннарын да ачыкларга була, ләкин бу капиталь хезмәтне башкарып чыгар өчен кирәк булган иҗади көчне һични белән дә тиңләргә мөмкин түгел.

Ихтыярсыз, чорыбызның иң атаклы язучыларыннан берсе, ялкынлы публицисты һәм галиме Мариэтта Шагинян сүзләре хәтергә килә. Ул очерк язар өчен материал туплауның корзинкага гөмбә җыю түгеллеген әйтеп, бу хезмәтне бал кортының эше белән тиңли. Тормыш фактларын күңелеңдә эшкәртмичә, үз ширбәтең белән сыгындырмыйча образ тумый.

Монда да шул ук, йөзләрчә авыллардан язып алынган сүзләрне портфельгә тутырып кайту белән эш бетми, тагын да катлаулырак эш, анализлар, чагыштырулар, үз ширбәтең белән сыгындыру еллар буе дәвам итә.

Шуңа күрә дә мин ул хезмәттә Себер татарларының тарихын, этнографиясен, археологик, антропологик белешмәләрен дә күрәм, этник группаларын һәм аларның диалектларын укыйм. Урыны белән Диләрә ханым статистикага да мөраҗәгать итә, теге я бу төркемнең саннарын күрсәтеп уза. Ул җентекле рәвештә Тобол-Иртыш диалектын, аңа кергән төрле сөйләшләрнең фонетик, морфологик билгеләрен, Бараба диалектын, Томск диалектын — аңа караган аюштә, чат, калмак сөйләшләрен тикшерә.

Без зур хезмәткә рецензия язмыйбыз, шуңа күрә һәрбер проблемага тукталу һәм ул проблеманың нинди яктылыкта бирелүен күзәтү безнең бурычка керми. Ләкин озак еллар эзләнү-тикшеренүнең кайбер нәтиҗәләре укучылар өчен дә кызыклы булыр дип уйлыйм. Мәсәлән, Диләрә Тумашева тикшерү нәтиҗәсендә шундый йомгак ясый: нигездә кыпчак тибындагы төрле кабилә диалектларының йогынтысы-тәэсире, үзара мөнәсәбәткә керү нәтиҗәсендә грамматик структуралары барлыкка килгән диалектларның нык катнаш характерда булулары күзгә ташлана. Күрше (төрки һәм башка) телләрнең тәэсире әле дә тәгәлләнмәгән.

Хәзерге вакытта Себер татарларына татар әдәби телендә хезмәт күрсәтелә. Аларның диалектлары исә татар теленең диалект системасына керә. Себер диалектлары бу очракта кече халыкларның тел үсешенә мисал булып торалар.

Себер татарлары бердәм гомумхалык теле тудырмаганнар, чөнки аларны берләштергән территориаль союзныклы дәүләт төзелеше булып карала алмый, диалектлар исә аларга бердәнбер хезмәт күрсәтә торган тел берәмлекләре булып торалар.

Себер ханлыгы яшәгән чорда ук Себердә татар халкының нигезләре салына. Ләкин тарих дәвамында бу хәл тел һәм территориаль берләшүгә алып килми. Бары Тобол-Иртыш бассейны территориясендә сөйләшләр якынлашалар һәм шул нигездә уртак диалект сыман, фәнчә әйткәндә, «койнэ» барлыкка килә. Ләкин ул да мөстәкыйль тел булып үсми.

Себергә татар теленең үтеп керүе һәм аңа йогынты ясавы Казан ханлыгы дәверендә үк башлана һәм аеруча XIX—XX йөзләрдә көчәя. Экономик һәм культура үсешендә югарырак баскычта торганлыктан, Идел буе татарлары Себер татарларының хуҗалык һәм тормыш-көнкүреш тәртипләренә зур йогынты ясыйлар. Себер формалашып килә торган татар буржуазиясенең тәэсирендә кала. Татарлар һәм бохаралылар балаларын татар китап телендә укыталар. Әнә шул һәм башка факторлар Себердәге татарларның татар милләте белән кушылу процессын әзерли. Әдәби тел үрнәге итеп татар милли телен кабул итүгә китерә, тик бу процесс бары тик Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына тәгәлләнә.

Ә сүзлек? Сез аңа да игътибар итегез. Биш меңгә якын сүз ялгыз сүз берәмлеге булып кына тормый. Сүзнең чыганагы күрсәтелә, кайсы төбәктә язып алынган, татар әдәби теленә һәм рус теленә тәрҗемә ителгән, кирәксә — мисаллар белән ачыкландырылган. Монысы үзе генә дә бер диссертациягә тиң хезмәт.

Соңыннан аеруча зур ачыш булып бәяләнгән бу хезмәтнең башкарылу елларында мин Диләрә ханымга бер сорау биргән идем:

— Шушы эшләнгән кадәресе доктор исеме алырга җитәрлек ич, нигә сузасыз?!

Диләрә Тумашева болай дип җавап кайтарды:

— Җитсә җитәр, ләкин әле диссертацияне яклаганчы минем басылып чыккан китапларым да булырга тиеш...

Бу сүзләрдә Диләрә ханымның характеры күренмимени?!

Диләрә Тумашевага сорау биргән вакытта, аның шушы диссертациягә караган хезмәтләре генә дә университетның гыйльми язмаларында биш-алты исемдә басылган, аерым монография чыккан иде. «Көнбатыш Себер татарларының теле. Грамматик очерк һәм сүзлек» исемле 15 табаклык монография 1961 елда университетның гыйльми эшләр буенча уздырылган конкурсында икенче премия алган иде. Шуның өстенә аның соавторлыгында 1961 елдан алып урта мәктәпләр өчен тел дәреслеге басылып килә. Соңгы елларда IV—V класслар дәреслеген эшләде.

Бер караганда гаҗәп тә. Диссертация темасы буенча егерме табактан артык басма хезмәте булганда иң тыйнак кеше дә:

— Җитәр, инде югары гыйльми дәрәҗә алыр өчен бик күп бу! — дияр иде.

Ләкин фән Тумашеваның стихиясе. Ул ирешелгән белән канәгатьләнеп калмый. Ул һаман тикшеренә, һаман яза. Казан дәүләт университеты басмасында 1964 елда аның «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» исемле югары мәктәпләр өчен дәреслеге басылып чыга. Шунысын да әйтергә кирәк, ул инде күптән библиография дөньясында сирәк очрый торган китаплар рәтендә йөри. Аны сатып алырга мөмкин түгел: басылып чыгуга таралып бетә ул. Укытучылар аны китапханәгә килеп, күчереп алып китәләр.

1968 елда Казан дәүләт университеты нәшрияты Диләрә Тумашеваның «Себер татарларының теле» исемле китабының II кисәген бастырып чыгара, күләме 10 табак чамасы.

Фәннәр академиясенең «Наука» нәшриятында «Хәзерге татар әдәби теле» исемле монография (1969) басыла. Аның «Фигыль» бүлеге Тумашева тарафыннан язылган.

Барлыгы 150 табаклардан арткан хезмәтләр кабинеттан чыкмыйча гына язылмаган. Ул укытучылык эше белән, партия-совет эше белән үрелеп барган. Диләрә ханымның дүрт тапкыр Казан шәһәр Советы депутаты булып сайлануын, райком, партком, партбюро члены булып күп тапкырлар сайланып килүен искә алсак, гаҗәпләнмәскә дә мөмкин түгел. Әйе, ул совет фәне кешесе, таш яуса да билгеләнгән үрне яулап алмыйча үзенә тынгылык бирми торган фән кешесе!

Ниһаять, диссертация тәмам. Ләкин аның әле чит кешегә күренми торган мәшәкатьләре җитәрлек. Минем бер сорашуым шул чорга туры килде:

— Машинкада басылып ята, мин укып барам,— диде Тумашева.— Хәзер бу эшне башкарып чыгуыма үзем дә аптырыйм... Бик нык арылган. Башымда диссертациягә караган проблемалар гына, шулардан арынып булмый. Мине бераз арындыру өчен Равил спектакльгә алып китте. Сәхнәдә комедия бара. Әйбәт кенә уйныйлар да, өсәре дә начар түгел. Залдагы халык рәхәтләнеп көлә, ә мин берүзем көлмим, көлә алмыйм... Үземә куркыныч булып китте, көлү сыйфатымны югалттым шикелле...

Бу — аңлашыла торган хәл, иҗат кешесе дә спортсмен яки чабыш ат кебек. Бер ярсыганнан соң үз-үзеңне тыю кыен була, үзең иҗат иткән стихиядә яши бирәсең. Диләрә ханым, билгеле, көлү сыйфатын югалтмады, тик ул нинди генә оппонент булса да бәйләнерлек урын калмасын дип, ярсып эшләде.

Күп еллык хезмәт, ниһаять, галимнәр хөкеменә күчте. Һәм әйтерсең барлык тел галимнәре Тумашеваның докторлык диссертациясен күтәреп торганнар. Кайдан гына бәяләмә килми ул хезмәт турында! Аз вакыт эчендә. Калганы конвейерга салган кебек тоткарсыз эшләнде. СССР Фәннәр академиясенең тел белеме институты Гыйльми Советында 1969 елның 10 октябрендә яклау була, декабрьда Югары Аттестация Комиссиясе (ВАК) яклау нәтиҗәләрен раслый һәм Тумашевага доктор дигән исем бирә, ә бер айдан — 1970 елның гыйнварында, аны профессор итеп раслыйлар. Мондый тизлекне галимнәргә хыял итәргә генә кала.

Менә мин диссертациягә язылган бәяләмәләрне укып утырам. Алар, әйткәнемчә, күп һәм аларның фикерен монда күчерү кирәк түгел. Шулай да кемнәр югары бәя биргәнлеген әйтеп китү урынсыз булмас: СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты А. Н. Кононов, профессор А. П. Дульзон (Томск), Төркмәнстан Фәннәр академиясенең член-корреспонденты М. Н. Хыдыров, Педагогия фәннәре академиясенең член-корреспонденты М. И. Мәхмүдов, Казагыстан Фәннәр академиясенең тел өйрәнү институтыннан Ш. Сарыбаев, СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтыннан Э. Нәҗип, профессор Э. М. Ахунҗанов, профессор Х. Госманов (Казан).

Венгрия тюркологы, филология фәннәре докторы Г. Хазаи, профессор М. Рагимов (Баку), Башкортстан дәүләт университетының тел өйрәнү кафедрасы мөдире Т. Гарипов, филология фәннәре кандидаты Р. Бердыев (Ашхабад), филология фәннәре докторы В. Решетов (Ташкент).

Шунысына игътибар итегез, бу галимнәрне мактау сүзләре язарга берәү дә мәҗбүр итми, алар бу эшне намус кушуы буенча эшли-

ләр, зур ачышның аларда канәгатьләнү хисе уятуы, сокландыруы, ниһаять, таң калдыруы кулга каләм алдыра.

Әмир Нәҗип үзенең бәяләмәсендә, мәсәләп, Тумашеваны өйрәнелмәгән бик күп сөйләшләрнең генә түгел, бәлки моңарчы билгеле булмаган сөйләшләрнең беренче ачучысы дип таный. Ул саз ягы, тәвриз сөйләшләрен, Кәнчыгыш-Тобол урынчылыгын һ. б. күздә тота.

Венгр тел галиме Г. Хазаи, немец тюркологы профессор Дёрфер фикерен дә кушып, бик матур бәя бирә. Дёрфер: «Болар белән автор тюркологиядә нык һәм хаклы урын алды»,— дигән. Хазаи ул фикергә кушыла. Дёрфер үзенең рецензиясен немец телендә бастырып чыгарган.

«Остяк теленең этимологик сүзлеген эшлибез»,— ди Хазаи. Шул сүзлекне эшләүдә бу хезмәтнең әһәмияте зур булганын әйтә.

Болардан тыш рәсми оппонентлар бар бит әле, алары диссертациянең һәрбер сүзенә игътибар итеп, һәрбер фикернең дөреслеген төрле яктан үлчәп карый торган, «бәйләнергә» сәбәп булырлык йомшак якларны эзләүче галимнәр, алар тагын да таләпчәнрәк, хәтта усалрак та. Рәсми оппонентлар барысы да фән докторлары, атаклы галимнәр: Казагыстан Фәннәр академиясенең действительный члены Смет Кенесбаев, Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы Әхнәф Юлдашев һәм филология фәннәре докторы, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе Эрванд Севортян — барысы да диссертациягә югары бәя бирәләр.

— Әгәр диалектологның — хатын-кызның экспедицияләрдәге әледән-әле күченүләрнең барлык авырлыгын үз җилкәсендә алып баруын искә алсак,— ә ул эш юл газаплары белән, Себер сазлыкларының яңгырдан соң начар һава шартларында юлсызлыгы белән бәйле — без хәзер тикшерә торган хезмәтне төгәлләүнең никадәр катлаулы икәнлеге көн кебек ачык,— ди академик С. Кенесбаев.— Хәтта минем һәрбер материалны җентекләп, бәйләнергә тырышып укуым да нинди дә булса принципиаль тәнкыйть сүзе әйтерлек материал бирмәде.

Кояш елмаюы кебек, мондый югары бәя һәм мактау сүзләре ишетү өчен, билгеле, тырышлык кына җитми, гыйльми-тикшеренү культурасының югары баскычта торуы да кирәк. Рәсми оппонентларның берсе, профессор Э. Севортян нәкъ әнә шул сыйфатның күзгә бәрелеп торуын басым ясап әйтә. Тикшеренү материалларының Тумашевага тарихи-лингвистик концепцияне алга сөрергә һәм аны исбат итәргә мөмкинлек бирүен әйтеп, Севортян, төрки телләрне өйрәнүдә, милли телләрнең формалашу тарихына мондый караш әле бөтенләй диярлек кулланылмаган иде, ди.

* * *

Казан дәүләт университетының Зур Советында Диләрә Гариф кызы Тумашеваны яшерен тавыш бирү юлы белән профессор итеп сайлыйлар. Ул шул Советта үзе дә катнаша. Советтан чыкканда, мин Диләрә ханымны университетның вестибюлендә очраттым. Аның йөзе көлә, күзләре көлә, бите алсуланган, ул тагын да яшәргән, ничектер бөтен барлыгы белән балкып тора. Ул шат иде һәм аны яшермичә:

— Әле генә Зур Совет мине профессор итеп сайлады! — диде ягымлы елмаеп.

Мин аны, күрәсең, беренче булып тәбрик иттем... Борчылулар, юл газаплары, «көлү сыйфатын» югалтулар онытылган иде. Зур

эшне башкарып чыгу шатлыгы аның бөтен күңелен биләп алган һәм ул алдагы гыйльми тикшеренүләр өчен ашкына иде шикелле. Яшермим, күз алдымда зур галим үсеп чыгуын күрү һәм аның инде фән дөньясында танылуын белү, җитмәсә, шул галим белән дус булып яшәү миңа да бик күңелле.

Хәер, миндә генә тумый бит ул андый изге хис — бөтен халык горурлана, бөтен халык шатлана. Шуның бер чагылышын мин Татарстанның 50 еллыгына багышланган юбилей тантанасында күрдем.

Муса Җәлил исемендәге зиннәтле театрның тамаша залы шыгрым тулы. Анда республиканың иң атаклы кешеләре, төрле республикадан һәм өлкәләрдән килгән исемле кунаклар. Үзәктән килгән җитәкчеләр һәм кунаклар...

Тирән дулкынлану белән без КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, Үзәк Комитет секретаре А. П. Кириленконың ялкынлы речен тыңлыйбыз. Ул Партиябез Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы һәм СССР Министрлар Советы исеменнән Татарстанның барлык хезмәт ияләрен республиканың илле еллыгы һәм аның Октябрь Революциясе ордены белән бүләкләнүе уңае белән тәбрик итә.

КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Табеев безне тагын бер кат дулкынландырып доклад сөйли.

Шуннан соң котлаулар башланды... Алар күп. Һәрбер республикадан, һәрбер өлкәдән диярлек...

Котлау сүзләреннән соң КПСС Үзәк Комитетына, Совет хөкүмәтенә, тантаналы мәҗлестә катнашкан барлык котлаучыларга җавап сүзләре яңгырый башлады. Эшчеләр исеменнән, колхозчылар исеменнән, яшьләр исеменнән рәхмәт сүзләре әйтелде. Мәҗлеснең рәисе фән һәм техника эшчеләре һәм гомумән интеллигенция исеменнән җавап сүзе өчен профессор Диләрә Тумашева чыгыш ясавын белдерде.

Диләрә Тумашева зәңгәр ефәк күлмәктән, гади генә, тыйнак кына, ләкин пөхтә кабартылган прическадан, яшьләрчә, җиңел генә трибунага чыгып басты. Ул дулкынлануын басу өченме, әллә тыңлау сәләтләрен киметкән кешеләрне уяту өченме үткен күзләре белән залга карап алды. Зал кинәт сагайды һәм барысының игътибары трибунага юнәлде.

Ул — җыйнак, чибәр. Беренче карауда фәнгә бик үк якын тормаган кеше сыман, бәлки артискадыр...

Юк, профессор, Казан дәүләт университетының кафедра мөдире дип тәкъдим иттеләр ич!..

Күршесе белән нидер сөйләшеп утырган кунак абзый да кинәт трибунага борылды һәм Диләрә Тумашева сөйләп бетергәнче, бөтен зал белән берлектә, аңардан күзен алмады.

Залның күзе трибунада, һәркем күңеленнән, менә бездә нинди фән кешеләре үсеп чыкты, дип горурлана иде!

Ә нәрсә уйлады икән еракта килгән кунак? Бәлки ул бу тамашаны көтмәгәндер, бәлки көтсә дә, болай тәэсирле итеп сөйләр дип уйламагандыр! Ни әйтсәң дә татар хатын-кызларының элек коллыкта яшәгәнлекләрен ул яхшы белә ич. Элек кол хәлендә яшәгән хатын-кызлар вәкиленең берсе — бүген республика каршына басып, бөек трибунага чыгып, саф әдәби рус телендә матур итеп речь сөйли.

Аның рече кыска, ләкин тыгыз эчтәлекле иде.

— Республикабыз хезмәт ияләре, бөек Ватаныбызның барлык халыклары белән бергә, Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә, җимереклектән, ачлыктан, хәерчелектән һәм наданлыктан экономика, фән һәм культура биеклекләренә менүнең авыр юлын намус белән узды.

Ул сүзен шулай башлады һәм Совет власте елларында Казан галимнәренең һәрбер өлкәдә атаклы фәнни мәктәпләр традицияләрен уңышлы үстереп, хәзерге заман фәненең иң алдынгы чикләренә чыгулары турында үтемле итеп сөйләде. Һәм зал Тумашеваның үзен дә фәннең алдынгы сафында баручыларның берсе итеп таныды һәм кайнар алкышлады. Бу алкышлауда Татарстан хезмәт ияләренең дә, кунакларның да горурлыгы яңгырады.

Мондый горурлану чагылышын мин тагын күрдем.

Университетның өченче каты белән дүртенче каты уртасында, киң баскыч шактый зур мәйданга китереп куя, аннан баскыч ике якка аерылып менеп китә. Ике кат уртасындагы стенада расписаниеләр, төрле белдерүләр, афишалар. Алардан да өскә бер вакыт эре хәрефләр белән язылган транспарант менеп утырды:

— «Ленин ордены белән бүләкләнгән профессор Д. Г. Тумашеваны кайнар рәвештә котлыйбыз!»

Бу — студентларның, факультет коллективының чын күңелдән әйтелгән ихтирам сүзләре иде!

Кешене төрлечә өйрәнергә мөмкин: анкетасына карап та, кеше биргән характеристика аша да, эшкә һәм кешегә мөнәсәбәте буенча да, речьләрен тыңлап та. Кайгы-хәсрәтне һәм шатлыкны кичерә белүен күрү дә бик мөһим. Дуслык юлда сынала, диләр, бер үк эшне бергәләп башкарганда тагын да күбрәк күреп, танып була кешене.

Моннан берничә ел элек Татарстанның партия өлкә комитеты безгә бик җаваплы бер эш тапшырды. Без — Диләрә Тумашева, Мөхәммәт Гайнуллин һәм мин — өчәүләп, ул эшне башкарып чыгарга тиеш идек. Безгә шактый авыр һәм четерекле бурыч йөкләнде: заманында саксыз әйтелгән сүзләргә таянып, кайбер галимнәр тарафыннан ямьсез ярлыклар тагылып, кирәкле-кирәксезгә әвәләнә башлаган мәрхүм бер галим һәм җәмәгать эшлеклесенең революциядән соңгы 20—25 еллык хезмәтенә объектив дөрес, партиячел принципиаль бәя бирергә тиеш идек.

Бу катлаулы һәм икеләтә җаваплы эшкә без вакыт кызганмадык. 1919 елдан алып архив документларын күтәрергә туры килде, галим язган мәкалә-хезмәтләрне җентекләп өйрәнергә һәм аларны бүгенге караштан чыгып бәяләргә кирәк булды. Эш эшләнде, тиешле белешмә өлгертелде һәм партия галимнең данлы исемен фәнгә кайтарды.

Эш башкару процессында мин Диләрә Тумашеваның нинди көчле галим булуын күрдем. Аның көчлелеге комиссия утырышларына кичекмичә килүендә һәм актив катнашуында гына түгел, бәлки фикерне дәлилли белүендә. Һәрбер фактның җирлеген, нигезен күрсәтеп, аны гыйльми телгә салып әйтә белү — дәлилләү осталыгын күрдем мин Тумашевада. Формаль белешмә язу өчен һәм аны матур итеп сурәтләп күрсәтү өчен безгә өстә яткан фактлар да җитә иде шикелле. Ләкин тарихка хыянәт итәргә безнең хакыбыз юк, күбрәк фактларны актарып чыгарырга һәм төрле яктылыкка куеп карарга кирәк иде. Хезмәт язылган вакытта ул никадәр актуаль һәм дөрес булган, нинди яңалык китергән, вакыт сынавын ничек узган һ. б. һ. б. яктылыкларга тотып карау тиешле табылды.

Шул чакта миндә Тумашева турында очерк язу теләге уянды һәм мин материаллар туплый башладым. Җыя башлагач, ул шул кадәр үсте, аларны очеркка сыйдырып бетерү мөмкин булмады. Мин галимнең фәнни конференцияләрдә катнашуын, чит илләргә докладлар белән чакырылуын язып тормыйм.

Фән кешесе туктауны белми, ул һаман хәрәкәттә, фән проблемалары эчендә; аның дәреслекләр дә язасы бар, төрки телләр атласы комиссиясендә дә эшлисе бар, яшь галимнәргә җитәкчелек итәсе бар...

Галимнең тормыш иптәше Равил Тумашев — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе — Татар дәүләт республика күчмә театрының баш режиссеры булып эшли. Димәк, аның да гомере тынгысыз эштә, һәр вакыт хәрәкәттә — сәяхәттә үтә. Шунлыктан гаилә тормышын гармонияле алып бару кызыклы проблема булып алга баса. Балалар таза булсын, укуда бер генә юнәлештән китмәсеннәр, эстетик тәрбия, музыкаль белем алсыннар... Вакытында ашасыннар, вакытында уйнасыннар... Гомумән тормышның ул ягын да яктыртасы иде, юкса, Диләрә ханымга тормыш гел көлеп кенә тора икән дип уйлаулары ихтимал.

Юк, тормыш алай елмаеп кына тормый, ул катлаулы һәм кырыс, үзе белән еш кына борчылулар алып килә. Әле Айдар авырып китә, әле үзе, я әтисе грипп ияртеп кайта. Әле студентлар, я студент булып уза алмаган яшьләр килеп балавыз сыга башлый... Укытучыларның мәрхәмәтенә ышанып, җиңел генә имтихан бирергә йөрүче студентлар — бигрәк тә читтән торып укучылар — кемнең эчен пошырмый. Нииндидер сәбәп белән лекциягә килмәгән укытучы деканны борчымыйммы тагын!

— Без студентларның үзешчән сәнгать коллективларын университет дәрәҗәсенә күтәрә алмыйбыз,— диде миңа Диләрә Тумашева бер вакыт.— Бу мине бик борчый. Җырда вокаль культура җитми. Мин бу юлда бик күп эшләдем, шулай да...

Әйе, бу җитди борчылу! Университет студенты үзешчән сәнгать өлкәсендә дә профессиональ югарылыкта торырга тиеш!

Юлбашчыбыз Ленин исемен йөрткән университетта студент булу да мактаулы эш, билгеле. Ләкин һәрбер укытучы яшь студентлардан киләчәк галимне эзли башлый.

— Бер яхшы шәкертем бар иде,— ди Диләрә ханым,— ул да шагыйрь булып чыкты.

— Нигә, шагыйрь булу начар түгел ич!

— Шулай да ул фән өчен туган кеше иде!

Яхшы, перспективалы студентлар күп. Ләкин начар студент каян килеп чыга соң? Конкурс имтиханнары биреп керәләр, кайбер елны бер урынга 5—6, яки аннан да күбрәк гариза алына. Шул биш-алты кешедән иң сәләтлесен, иң зирәген сайлап алган кебек буласың, ә укый башлагач, университет йөкләмәсе егетнең җилкәсен баса, кызларның күз яшьләрен сыгып чыгара.

Хәер, зарланулар җитәр. Минем каршымда бер сорау тора, шуңа җавап биреп, очеркны очлыйсым килә.

Ни өчен мин бу образны сайладым? Диләрә Тумашева татар хатын-кызларыннан беренче тел галиме түгел, ул беренче профессор да түгел. Совет власте елларында өлгергән татар хатын-кыз профессорларын Казанда гына түгел, үзәк шәһәрләрдә дә, төрле фән өлкәсеннән шактый табарга мөмкин (алар турында «Казан утлары» матур-матур очерклар да бастырып килә). «Беренче» дигән сүз белән хәзер кемне дә гаҗәпләндереп булмый. Заманы башка хәзер, эстафета да башкалар кулына күчте. Сыйфат заманы хәзер, чор таләпләренә җавап бирерлек фән үстерү заманы, фәннең алгы сызыгында торып эшләү заманы. Диләрә Тумашева, бердән, әйткәнемчә, хәзерге чор фәненең иң алдынгы сызыгында тора.

Икенчедән, фән диңгезенә чумып, хатын-кыз сыйфатларын югалткан галим түгел. Совет хатын-кызларында булырга тиешле сыйфатлар идеалына ул үрнәк була ала, моңа матурлык идеалы да керә. Бу — минем генә фикерем түгел.

Безнең университетта студентлар тарафыннан бик нык хөрмәт ителә торган тарихчы В. Н. Смирнова бар. Вера Николаевна Смир-

нова «Революциянең демократик һәм социалистик этапларында хатын-кыз мәсьәләсе» дигән темага докторлык диссертациясе тәгәлләде. Шул диссертациянең авторефератын ул, түбәндәге сүзләрне язып, Диләрә ханымга бүләк иткән.

«Тирән акылы һәм нәзакәтлелек дәрәҗәсе белән булмаса да, иҗтимагый тормыштагы активлыклары һәм шул ук вакытта чын хатын-кыз булып кала белүләре белән хатын-кызлар мөмкин кадәр күбрәк Сезгә охшасыннар иде. Минем уйлавымча, хатын-кыз мәсьәләсенең хәл ителүе нәтиҗәдә нәкъ менә шуңа китерергә тиеш тә».

Әйбәт әйткән, хатын-кызны, Диләрә ханымны аңлап, белеп әйткән.

Борын-борыннан ук барлык шагыйрь-язучылар идеаль хатын образын эзләгәннәр. Үзләренең фәлсәфи карашларына, чорның зәвыгына яраштырып аны мактап язганнар. Эллада шагыйре Гомер, мәсәлән, Пенелопа образын Одиссейга тугрылыклы булуы өчен мактап җырлый. Урта гасырда хатын-кыз образы нинди генә кыяфәттә сурәтләнми: ул тормыш бизәге дә, илаһи ләззәт чишмәсе дә, иргә кәнизәк һәм колларча буйсынган кеше дә. Шагыйрьләр аның матурлыгына сокланалар, зирәклеген мактыйлар, кайнар мәхәббәт белдереп баш ияләр... Ләкин нигездә хатын-кыз ирнең хезмәтчесенә, аның уенчыгына әйләнеп кала.

Социаль мөнәсәбәтләр үткенләнгән саен хатын-кыз образын җанландыруга да төрле һәм катлаулы үзгәреш керә. Хатын-кызның социаль йөзе, иҗтимагый тормыштагы роле, аның аяныч язмышы һәм хатын-кыз азатлыгы мәсьәләләре күтәрелә.

Татар әдәбияты тарихына килеп, XIX йөзнең икенче яртысыннан гына — Муса Акъегетзадә, К. Насыйри, З. Бигиев әсәрләреннән алып тикшерә башласаң да, хатын-кыз образының сурәтләнү эволюциясен күзәтү гаҗәп кызыклы булыр иде. Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Камал, М. Фәйзи әсәрләрендәге бәхетсез язмышлы татар хатын-кызлары безне уйландырмыймыни?! Ә совет чоры хатын-кызлары?

Шунысы характерлы, Совет власте елларында хатын-кызның социаль актив ролен Г. Ибраһимов укытучы кызлар образы аша күрсәтә башлый. Революциянең беренче еллары өчен укытучы хатын-кыз образы идеаль иде һәм бу табигый хәл, чөнки алар, беренче булып, социалистик революциянең савыктыру җилен аңлау югарылыгына күтәреләләр һәм беренче булып революция идеяләрен массага җиткерүче пропагандистлар булалар.

Шәхси бәхет өчен түгел, халык бәхете өчен көрәшүче, революцион пафослы хатын-кыз образларын кайсы шагыйрь җырламаган?

Шулар арасыннан минем Һади Такташны аерып аласым килә. Гаилә тормышы, иҗтимагый хезмәт һәм җәмәгать эшенең социаль гармониясенә ирешү турында ул нинди борчыла һәм хыяллана иде!

Бүгенге көндә дә кешенең матурлыгы һәм аның социаль йөзе иҗтимагый хезмәтеннән аерым карала алмый. Матур гаилә төзү, иҗтимагый эштә дан казану — аның җәмәгать эшенә дә бәйле. Димәк, матур гаилә тормышы — иҗтимагый хезмәт һәм актив җәмәгать эше белән үрелеп барырга тиеш. Моны хәзерге тормыш үзе таләп итә һәм шул өч матурлыкның гармоник берләшүенә бөтен мөмкинлекләрне тудыра.

Иҗтимагый хезмәт бик җитди фактор, ул һәр нәрсәгә материаль җирлек әзерли. Социализм җиңгән илләрдә хатын-кызлар экономик яктан ирләренә бәйләнмәгән. Аларга ирләре белән бер үк дәрәҗәдә квалификация алырга мөмкинлек бирелгән һәм чынлыкта тормыш фактлары урта яки югары белемле хатын-кызларның саны ирләргә караганда югарырак булуын күрсәтәләр, димәк, аларның квалификацияләре дә — экономик бәйсезлекләре дә югары.

Гармоник тормыш өчен бу фактор хәлиткеч роль уйнаса да, ул әле җитми. Мәхәббәт мәсьәләсе дә мөһим. Моннан ике ел элек «Литературная газета» «Гаиләне нәрсә беркетә?» исемле репортаж бастырган иде. Аның авторлары Варна шәһәрендә уздырылган VII халыкара социологлар конгрессында катнашучы галимнәр белән очрашканнар. Андагы галимнәр мәхәббәт — гаиләне беркетүдә беренче урынны тота дип карыйлар. Билгеле, мәсьәләне мәхәббәт кенә хәл итми. Атаклы поляк социологы Ежи Пиотровский тагын шул мәсьәләгә туктала:

«Тәҗрибә күрсәтә,— ди ул,— йорт хуҗалыгы белән генә шөгыльләнгән хатынга караганда, хезмәт итүче хатын-кыз үзенең тышкы кыяфәте, туалеты, манералары турында күбрәк кайгырта. Акыллы, белемле, социаль актив, югары даирәдә теләсә нинди әңгәмә алып бара торган, үзенең тышкы кыяфәте белән һәр вакыт яхшы, матур, тормыш тонусы булган кеше — минә хәзер шундый хатын идеалга якын тора».

Мин Диләрә Тумашевада идеалга якын торган хатын образын түгел, бәлки безнең Советлар илендә, Коммунистлар партиясе тарафыннан тәрбияләнгән бүгенге алдынгы актив хатын-кыз образын күрәм. Ул гаиләне, фәнне, иҗтимагый хезмәтен һәм җәмәгать-партия эшен бергә гармоник куша белгән хатын. Ул социаль актив, зур һәм кыю омтылышлы галим, тәрбияче һәм ана, гаиләне цементлаучы көч, үзенең кышкы кыяфәте белән матур-мөлаем, теләсә нинди югарылыкта, теләсә нинди темага әңгәмә алып бара белүче идеаль хатын!

Моны мин һичбер ташлама ясамыйча әйтәм. Чөнки Диләрә ханым аңа мохтаҗ түгел!

# ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ

Риза Ишморат — татар совет драматургиясе үсешендә зур урын тоткан күренекле язучыларыбызның берсе. Ул — утыздан артык комедия һәм драма авторы. Аларның һәрберсе үз вакытында профессиональ һәм үзешчән театрлар сәхнәләрендә уңыш белән бара. Татар сәхнәләреннән тыш, аның кайбер пьесалары башкорт, казакъ, рус, чуваш, үзбәк һ. б. театрларда да популярлык казана.

Заман сулышын тоеп, яңалыкны актив пропагандалау, илебез тормышы белән тыгыз бәйләнешле закыйгаларны үз вакытында яктырту — Р. Ишморат иҗатының иң характерлы яклары. Аның бөтен әсәрләре диярлек тормышның актуаль мәсьәләләрен сурәтләүгә багышланган.

Риза Фәхретдин улы Ишморатов 1903 елның 1 ноябрендә Башкортстанның Яңавыл районы Бәдрәш авылында туа. Аның әтисе башта муллалык итә, балалар укыта. Аларга бөтен семьялары белән бер урыннан икенче урынга күчеп йөрергә туры килә. 1913 елда Фәхретдин агай, муллалык итүен ташлап, Татарстанның Актаныш районы Уразай авылына — үзенең туган якларына кайта. Ризаның да шуннан соңгы тормышы бай табигатьле шул яклар белән бәйләнеп китә.

Ризаның яшүсмер чоры, әдәбият һәм сәнгать белән ныклабрак кызыксына башлаган чоры революцион хәрәкәтләр, халык азатлыгы өчен көрәш куерган давыллы елларга туры килә. Октябрь революциясе, Совет власте Ризага да киң юл ача. Үзенең белемен тирәнәйтү өчен, егерменче еллар башында ул Уфага килә. Шунда комсомол сафына кабул ителә. 1920 елда, коммунистлар отряды составында, контрреволюцион бандаларга каршы көрәшә.

Бу чорда Уфа газеталарында Р. Ишморатның беренче шигырьләре күренә башлый. Боларда яшьләрне комсомолга керергә өндәү, азатлык, бәхет өчен көрәшкә чакыру мотивлары яңгырый. Р. Ишморат иҗатында яшьлеккә дан җырлау, совет яшьләренең нык ихтыяр көчен, тормышка кайнар мәхәббәтен, туган илгә бирелгәнлеген, бөек идеаллар белән яшәвен гәүдәләндерү мотивлары башта ук көчле була һәм бөтен иҗаты буенча кызыл җеп булып сузылып бара.

Уфада бу елларда татар театры уңыш белән эшләп килә. Аның барлык спектакльләрен карап барган Р. Ишморатта артист булу теләге көннән-көн ныграк урнаша. Шул ук теләк 1923 елда аны Казанга, яңа ачылган татар театр техникумына алып килә. Бу техникумда өч ел белем алу, атаклы артистлар, язучылар: Ф. Әмирхан, З. Солтанов, К. Тинчурин, С. Сәйдәшев белән якыннан аралашып яшәү Р. Ишморатның иҗат юлын театр сәнгатенә борып җибәрә. Иҗат дәрте ташып торган яшь шагыйрь тора-бара артист, режиссер һәм драматург булып китә.

1926 елда аның «Йокы патшалыгында», «Өтек философ» кебек беренче комедияләре языла һәм шул ук елны үз режиссерлыгында Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела. Сатирик юнәлешле бу комедияләр кеннең актуаль мәсьәләләрен күтәреп чыгулары, Совет власте дошманнарын фаш итүләре, агитацион рухта язылулары белән аерылып торалар. Шул чор тәнкыйте дә бу әсәрләргә карата үзенең уңай мөнәсәбәтен белдерә. Мәсәлән, «Йокы патшалыгында» комедиясе куелу уңае белән

журналист һәм тәнкыйтьче М. Парсин, «бу әсәр безнең сәхнәбез өчен яңа һәм кадерле бүләк» [1], дип язып чыга.



Р. Ишморатның «Йокы патшалыгында» һәм «Өтек философ» кебек комедияләре ул чорларда киң таралган агиттеатр әсәрләренең типик үрнәге булып торалар. Сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан алар әле әллә ни югары булмый. Реализмнан бигрәк, формализм белән мавыгу күзгә ташлана. Тормыш фактларын гомумиләштереп бирә алмау сизелә. Р. Ишморатка иҗади осталыгын камилләштерүдә 1927—30 елларда Ленинградның сәнгать тарихы институтында укуы зур ярдәм итә. Ул А. А. Гвоздев, В. Н. Всеволодский-Гернгросс, И. И. Соллертинский, С. С. Мокульский кебек күренекле сәнгать белгечләреннән осталыкка өйрәнә. Бу вакыт эчендә ул «Ун ел тулганда» (1927), «Пожар» (1929) һәм «Данлы чор» (1930) драмаларын яза. Р. Ишморатның беренче сәхнә әсәрләре комедиячел ситуацияләргә корылган булса һәм аларда шартлылык зур урын алса, боларда исә драматик конфликт үзәк планга куела, тормыш конкретрак, тирәнрәк, калкурак чагылдырыла.

Егерменче елларда һәм әле аннан соң да ил хуҗалыгында корткычлык күренешләре, Совет властена теләсә нинди юл белән аяк чалырга тырышучылар күп була. Җиңелергә теләмәгән сыйнфый дошман, соңгы көчен җыйнап, Совет властена каршы мәкерле һәм астыртын хәрәкәт итеп килә. Бу тема Р. Ишморатның «Ун ел тулганда», «Пожар», «Данлы чор» драмаларында бигрәк тә калку гәүдәләнә. Аларда социалистик хуҗалык вәкилләре белән хосусый милекчелекне яклаучылар, капиталистик җәмгыять калдыклары арасындагы кискен көрәш тасвирлана. Бу әсәрләр мавыктыргыч ситуацияләргә һәм көчле конфликтка нигезләнүләре, вакыйгаларны реаль җирлектә сурәтләүләре белән игътибарны җәлеп итәләр. Шуның белән бергә, драматург әле һаман формализмнан да аерылып җитә алмый. Бу бигрәк тә «Данлы чор» драмасында үзен нык сиздерә. Бу әсәрне Р. Ишморат соңыннан яңадан эшкәртә һәм аның «Мәдинә» исемендәге яңа варианты барлыкка килә. Р. Ишморатның башлангыч чор иҗаты югарыда телгә алынган әсәрләр белән тәмамлана дисәк тә ярый. Моны осталыкка өйрәнү, чыныгу чоры дип карарга кирәктер, мөгаен.

Язучының иҗат юлы һәр вакыт диярлек әдәбият һәм сәнгать оешмаларында җитәкче эшләрдә эшләү, тегеяки бу оешмада җәмәгать эшләре алып бару белән параллель рәвештә дәвам итә. 1930 елда Ленинградтан кайтканнан соң, ул башта Татарстан мәгариф халык комиссариаты каршындагы сәнгать бүлеге мөдире булып эшли, аннары Татар дәүләт академия театрының художество җитәкчесе һәм режиссеры итеп билгеләнә. Академия театрында күп еллар оештыру эшләре алып бару белән бергә, Р. Ишморат татар һәм рус драматургларының күп кенә әсәрләрен үзе дә сәхнәгә куя. Мисал төсендә К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» һәм «Алар өчәү иде», Г. Иделленең «Дәүләт Бәдриев», С. Батталның «Сынау», В. Киршонның «Икмәк» һәм «Искиткеч эретмә», В. Шкваркинның «Чит кеше баласы» әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләрне китерергә мөмкин. Р. Ишморат театрда эшләгән чорында һәм аннан соң да яшь драматургларны үстерүгә нык игътибар бирә, аларга һәрьяклап ярдәм итә.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасы. 1926 ел. 9 ноябрь.

1940 елның көзендә ул яңадан сәнгать эшләре идарәсенә күчерелә һәм анда театр бүлеге мөдире хезмәтен алып бара.

Утызынчы елларда Р. Ишморатның драматургик эшчәнлеге ил язмышына кагылышлы тагын да зуррак, киңрәк проблемаларны сурәтләү белән бәйле рәвештә камилләшә бара. Ул елларда илебездә барган үзгәрешләрне, халкыбызның фидакарь хезмәтен, яңа кеше тәрбияләнүен, яңа тормыш төзелүен чагылдырган әсәрләр белән бергә, драматургиядә илне тышкы дошманнардан саклау темасы үзәк планга калкып чыга. Бу халыкара хәлнең кискенләшүе, дөнья сугышы кабыну куркынычы туу, ил чигендә булып торган канлы бәрелешләр көчәю белән аңлатыла. Р. Ишморатның «Ил өчен» (1936) һәм «Ватан» (1938) драмалары да нәкъ менә шушы темаларга язылалар һәм бу юнәлештә татар драматургиясендә җитди адым булып саналалар.

«Ил өчен» пьесасында яшьләрнең туган илне саклау өчен үз теләкләре белән Кызыл Армиягә китәргә әзер торулары, патриотик хисләре, омтылышлары чагылдырыла. Пьесада үзәк планда алдынгы тракторчы Зәки образы бирелә. Колхоз кырларында матур күрсәткечләргә ирешкән бу яшь егет үзе теләп армиягә китә. Пьесаның нигезен тәшкил иткән шушы патриотик тойгы хезмәт кешеләрен, яшен-картын үз тирәсенә туплый, вакыйгалар уен-көлке аша һәм оптимистик рухта сурәтләнә.

Европада фашизм котырынган вакытта кешеләрне уяулыкка өндәгән «Ватан» драмасын язучының бу чордагы аеруча зур уңышы итеп санарга кирәк. Вакыйганың сугыш барган чорга күчереп сурәтләнүе көчле драматизм белән сугарылган зур проблемалы, тирән эчтәлекле әсәр тудырырга мөмкинлек биргән. Зур бер завод коллективының сугыш барган чорда тылдагы фидакарь хезмәте, фронтка ярдәме, заводта оялаган контрреволюцион элементларны — фашизм ялчыларын фаш итү драматург тарафыннан катлаулы образлар системасы аша яктыртылган. Әсәрдә халыкка хезмәт итү, азатлык өчен көрәш турында фәлсәфи фикерләр бар, анда шулай ук үрнәк булырлык образлар бар.

Р. Ишморат туктаусыз эзләнә, тормышта үзен борчыган һәм киң җәмәгатьчелекнең омтылышларына туры килгән актуаль мәсьәләләрне төрле жанрларда чагылдырырга омтыла. Ул лирик комедия һәм драмаларның авторы буларак та таныла бара. Аның бу юнәлештәге уңышлы әсәрләреннән берсе — тормыш-көнкүреш темасына багышланган «Гөлзадә» (1939) драмасы булды. Лирик-драматик характерда язылган бу әсәрдә яшьләрнең укуга, семья һәм мәхәббәт мәсьәләләренә, иҗтимагый тормышка мөнәсәбәтләре сурәтләнә.

«Гөлзадә» драмасында драматург, нинди дә булса вакыйганы сурәтләүдән бигрәк, геройларның рухи дөньясы, эчке кичерешләре белән кызыксына, яшьләр арасында яңа совет морале урнашу процессын лирик-драматик төсмерләрдә тасвирлый. Бу алым шулай ук драматургның иҗат алымнары бай булуы турында сөйли. Билгеле, драматургның бу әсәре дә аерым кимчелекләрдән азат түгел. Мәсәлән, «Ил өчен» пьесасында конфликтның беркадәр йомшаклыгы, кайбер персонажларның үзара мөнәсәбәтләрендә урынсыз беркатлылык сизелә, җыр-биюләр артыкка китә, «Гөлзадә» драмасында исә сюжет таркаулыгы күзгә ташлана. Аерым кимчелекләре булуга карамастан, Р. Ишморатның 1926 елдан башлап иҗат иткән сәхнә әсәрләре татар совет драматургиясенә сизелерлек өлеш булып керә, республикабыздагы һәм башка бик күп өлкәләрдәге татар театрлары репертуарын баетуга нык ярдәм итә.

Утызынчы елларда татар драматургиясе һәм театры тормышның төрле якларын һәм актуаль проблемаларны яктырту юнәлешендә үсә бара, заман темасы һәр вакыт үзәк планда тора, халкыбызның үткәнен, үсеш тарихын, революцион көрәшләрне, сыйнфый каршылыкларны тасвирлау буенча җитди адымнар ясала. Бу чорда төрле милләтләрнең әдәбият һәм сәнгатьтәге казанышларын Мәскәүдә күрсәтү практикага кертелә башлый. Татар әдәбияты һәм сәнгате дә бу яктан өлгереп җитә. Декада үткәрү өчен конкрет чаралар күрелә. Ләкин, кызганычка каршы, декада булмый кала. Фашист илбасарларының туган илгә бәреп керүе комачаулый. Бөек Ватан сугышы башлана. Бөтен халык фашизмга каршы көрәшкә күтәрелә.

Төрле профессия кешеләре, шул исәптән язучылар, драматурглар, сәнгать эшлеклеләре үзләре теләп фронтка китә башлыйлар. Шулар арасында танылган

драматург һәм режиссер Р. Ишморат та була. Р. Ишморат сугышның башыннан ахырына кадәр диярлек фронтта була. Ул Беренче Украина фронтында биш телдә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасының редактор урынбасары булып эшли. Бу газетада аның алгы сызыкта торып язылган бик күп очерклары басыла. Боларда ул совет сугышчыларының батырлыкларын тасвирлый, аларны җиңүгә рухландыра, фашизмның җиңеләчәге турында өмет уята. Фронт белән бергә Р. Ишморат Берлинга кадәр барып җитә һәм Берлин өчен барган урам сугышларында каты яралана. Госпитальдә ятып сәламәтләнгәч, яңадан частька кайта һәм 1946 елга кадәр армия сафында була. Сугышны гади солдат булып башлаган Р. Ишморат майор дәрәҗәсенә күтәрелә.

Ватан сугышы чорында Р. Ишморатның иҗаты очерклар язу белән генә чикләнми. Ул драматургик эшчәнлеген дә дәвам иттерә һәм сугыш чоры рухын чагылдырган «Дошман лагерендә» (1941), «Ватан кызлары» (1942) һәм «Кайту» (1942) драмаларын иҗат итә. Болардан бигрәк тә соңгысы зур игътибарга лаек, һәм ул — Р. Ишморат иҗатында яңа этап башлануын күрсәтә торган әсәр. Бу драмада тыл һәм фронт темасы үзенчәлекле чагылыш таба. Колхозчы крестьяннарның, авыл халкының тылдагы тырыш хезмәтен, сугышка бәйле булган уй-теләк һәм омтылышларын тасвирлаган «Кайту» драмасы тиз вакыт эчендә бик күп театрларда популярлык казана. «Кайту» драмасы сугыш чорындагы авыл тормышын, хатын-кызларның, картлар һәм яшьләрнең колхоз кырларындагы фидакарь хезмәтен чагылдырган уңышлы әсәрләрнең берсе булып драматургиябез фондына керде.

1946 елда тыныч тормышка кайтып яши башлау белән Р. Ишморат яңадан сәхнә әсәрләре язарга тотына, бу өлкәдәге эшчәнлеген нык активлаштыра. Аның иҗаты төрләнә, байый, ул актуаль мәсьәләләр күтәргән драма һәм комедияләр тудыра. Аның иҗат диапазоны киңәюне, сурәтләү ысуллары баюны, камиллашуне күрсәткән героик драма жанрындагы әсәрләре барлыкка килә.

Р. Ишморатның сугыштан соңгы иҗаты беренче чиратта тыныч тормышны, хезмәт фронтын, семья һәм мәхәббәт мәсьәләләрен тасвирлау, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтендә булган күркәм сыйфатларны ачу, кимчелекләрне тәнкыйтьләү юнәлешендә бара. Бу циклга аның «Бүләк» (1947), «Якты юл» (1947), «Якын дус» (1949), «Бистә кызы Гөлсинә» (1951) һ. б. пьесаларын кертергә мөмкин.

Билгеле булганча, бу елларда драматургиядә «конфликтсызлык» шаукымы көчәеп ала. Күпмедер дәрәҗәдә бу «авыру» Р. Ишморатка да кагылмый калмый. Мәсәлән, партия һәм хөкүмәтебез куйган таләпләрдән чыгып, авыл хуҗалыгын алга җибәрү, иген уңышын күтәрү өчен көрәшне яктырткан «Якты юл» пьесасында конфликт кирәгеннән артык көчсезләндерелгән иде. Әмма бу тенденция драматургның башка әсәрләрендә артык сизелмәде.

Әгәр Р. Ишморат драматургик эшчәнлеген комедияләр белән башлап, аннан соң рәттән күп санлы драмалар бирсә, илленче елларда аның комедия әсәрләре язудагы осталыгы яңадан өскә калкып чыга. Мәсәлән, аның «Шайтан таягы» (1954) һәм «Серле моң» (1959) комедияләре бу жанрның үзенчәлекле мисаллары булып тора.

Сатирик юнәлешле «Шайтан таягы»нда, бер яктан, кеше хисабына яшәргә, җиңел юл белән үз кесәләрен калынайтып, үз тормышларын гына җайларга омтылучы әрәмтамаклар фаш ителсә, икенчедән, яшьләрнең семья һәм мәхәббәт мәсьәләләренә уяу карарга тиешлеге турында әһәмиятле фикерләр үткәрелә. «Серле моң» комедиясе исә үзенең лирикасы һәм юморы белән характерлы, монда намуслы хезмәткә һәм саф мәхәббәткә дан җырлана. Р. Ишморат бу комедияләре белән дә сәхнәбезне, драматургиябезне баета, аларда тормышчан һәм конкрет ситуацияләр гәүдәләнә, шуңа күрә дә алар күп санлы укучы һәм тамашачы тарафыннан яратып кабул ителә.

Р. Ишморат, бүгенге тормышның төрле якларын, эшче, колхозчы һәм интеллигенция вәкилләрен, аларның үзара мөнәсәбәтен, характерын, язмышын, тормышта тоткан ролен тасвирлау белән бергә, тарихи шәхесләрне, героик вакыйгаларны гәүдәләндерү юнәлешендә дә актив эшләп килә. «Үлмәс җыр» (1956), «Алар дүртәү иде» (1961) һәм «Давылга табан» (1963) героик драмалары аның бу юнәлештәге эшчәнлегенә ачык дәлил була ала.

Сәхнә әсәрендә башлап М. Җәлил образын тудыручы кеше Р. Ишморат булды. Аның «Үлмәс җыр» героик драмасы Җәлил һәм җәлилче каһарманнарга дан җырла-

ган әсәр буларак сәхнәгә килеп керде, күп театрларда куелды, шушы драмасы белән Р. Ишморат союз күләмендә танылды. Драманың үзәгендә Муса образы тора. Автор аны күпкырлы һәм калку итеп бирә. Муса яхшы ата һәм саф күңелле ир дә, талантлы шагыйрь һәм үз иленең чын патриоты да. Бер үк вакытта ул оста оештыручы, кешеләрне көрәшкә күтәрүче курку белмәс каһарман да.

Һәр яңалыкны Р. Ишморат үз вакытында тотып ала һәм сәхнә әсәрендә чагылдыра бара. Мәсәлән, Тын океанда 49 тәүлек үлем белән көрәшкән дүрт совет солдатының батырлыгын кем генә ишетмәде һәм моңа кем генә сокланмады! Бу вакыйгадан соң күп тә үтмәде, Р. Ишморат «Алар дүртәү иде» героик драмасын язып чыкты, әсәр Казанда, республикабызның күп кенә татар һәм рус театрларында куелып, популярлык казанды.

Ниһаять, төрле жанрларда һәм төрле чорларны, проблемаларны чагылдырган әсәрләр иҗат итеп тәҗрибә туплаганнан соң, Р. Ишморат 1963 елда «Давылга табан» драмасын тәгәлли. Бу — аның иң өлгергән һәм иң җитди әсәрләреннән берсе. Бу драма өстендә автор озак еллар эшли һәм нәтиҗәдә тирән эчтәлекле, киң масштаблы тарихи-революцион драма барлыкка килә.

«Давылга табан» драмасы В. И. Ленинның Казандагы тормышын һәм революцион эшчәнлеген яктырта. Бу әсәрдә студент яшьләрнең, бигрәк тә Казан университеты студентларының югары уку йортларында хөкем сөргән мәрхәмәтсез тәртипләргә, хокуксызлыкка һәм гаделсезлекләргә, патша самодержавиесенә каршы чыгулары чагылдырыла. Р. Ишморат бу драмасында күп эзләнүләр һәм архив материаллары нигезендә XIX йөз ахырындагы Казан тормышын, халыкның тормыш-көнкүрешен, уй-хыялларын, омтылышларын тирән яктырта. Монда акыллы һәм олы йөрәкле ана Мария Александровна, студент яшьләр, төрле карашлы профессорлар, авыр тормышта яшәгән һәм азатлык өчен көрәшкә тартылган эшче образлары бирелә. Драмада бөтен персонажларны, вакыйгаларны тоташтыручы үзәк фигуралардан берсе итеп яшь Володя образы алына.

«Давылга табан» драмасын иҗат итеп, Р. Ишморат татар драматургиясен һәр вакыт актуаль яңгырый торган тагын бер тарихи-революцион әсәр белән баетты. Әсәр идея-художество дәрәҗәсенең югарылыгы, тормышны тарихи планда танып белү өчен кирәклеге һәм тәрбияви кыйммәтенең зурлыгы белән дә аерылып тора. Бигрәк тә яшь буынны Ленин шикелле бөек шәхес, иң кешелекле кешеләрнең берсе үрнәгендә тәрбияләү өчен аның әһәмияте зур.

«Давылга табан» драмасы татар драматургиясен бөтен союз аренасына алып чыкты. «Үлмәс җыр»дан соң бу Ишморатның иң уңышлы әсәре булды, татар һәм рус телләрендә кат-кат басылды, бик күп театрларның репертуарында урын алды. Мәсәлән, ул Казанда Качалов исемендәге зур драма театрында, Башкорт дәүләт академия театры сәхнәсендә һәм Ташкентта Ниязи исемендәге үзбәк дәүләт академия театрында куелып, уңыш белән барды.

«Давылга табан» драмасын Р. Ишморатның чагыштырмача еракрак чорларны эченә алган бердәнбер әсәре дияргә була. Аның бөтен иҗаты заман, шул әсәр иҗат ителгән чор белән тыгыз бәйләнгән. Аның күпчелек әсәрләре язучы күз алдында, үзе яшәгән чорда барган вакыйгаларны чагылдыралар. Ул үзенең пьесаларын гүя җанлы вакыйгалар эзеннән яза. Ләкин бирелә шуны да истә тотарга кирәк: әгәр сайланган материал бөтен яклап уйлап җиткерелмәгән һәм тиешенчә әдәби эшкәртелмәгән булса, әсәрнең уңышсызлыкка да очравы мөмкин. Әмма Р. Ишморат тормышны һәм драматургия кануннарын яхшы белгәнлектән, аның әсәрләре тамашачыны кызыксындырырлык була һәм нигездә әйбәт яңгыраш ала.

1967 елда Р. Ишморатның яңа шәһәр төзүчеләр тормышына багышланган һәм мораль-этик теманы эченә алган «Шаулыйлар дулкыннар» драмасы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелды. Әсәрнең геройлары — әле тормышка яңа гына аяк баскан, үз көннәрен үзләре күрергә, үз бәхетләрен үзләре табарга тырышып йөрүче комсомол яшьләр. Драматург бу әсәрендә кешеләр рухланып эшләсеннәр, үзләренә яңа, матур тормыш корсыннар, бер-берсен иркәле һәм саф мәхәббәт белән сөеп яшәсеннәр, ялгышмасыннар өчен җәмгыятьне бозык һәм мәрхәмәтсез кешеләрдән арындырырга тели. Мораль яктан саф һәм һәр вакыт намуслы булырга чакыра, коммунистик тәрбия бирүдә коллективның уңай роль уйнаганлыгын күрсәтә.

1971 елда Минзәлә дәүләт театрында драматургның «Хикмәтле Сәйфи» исемле яңа комедиясе куелды. «Хикмәтле Сәйфи» комедиясе, өлкән яшьтә булуына карамастан, Р. Ишморатның иҗат эше белән янып һәм уңышлы гына эшләп килүе турында сөйли. Хәзер дә ул бүгенге көн проблемаларына багышланган яңа әсәр өстендә эшли.

Шул рәвешле, Р. Ишморат 50 елга сузылган әдәби эшчәнлеге дәверендә төрле жанрларда бик күп сәхнә әсәрләре иҗат итте, теге яки бу чорның конкрет вакыйгаларын, актуаль мәсьәләләрен уңышлы яктыртып килде. Р. Ишморат, сәхнә сәнгатендә катлаулы, каршылыклы юллар үтеп, күренекле драматург дәрәҗәсенә күтәрелде. Аның әсәрләре татар һәм рус телләрендә кат-кат басылды һәм басыла. Театрлар да Р. Ишморат әсәрләренә репертуарда һәр вакыт зур урын биреп килделәр, аның драма һәм комедияләре төрле милләт сәхнәләрен иңләп чыкты, күп санлы тамашачының югары бәясен алды. Әдәбият һәм сәнгать белгечләре дә Р. Ишморат әсәрләренә уңай бәя биреп килделәр. Аның әсәрләре, иҗаты турында М. Парсин, Т. Гыйззәт, Г. Иделле, Г. Халит, Мин Шабай, Б. Гыйззәт, М. Гайнуллин, С. Сафуанов, Г. Гоян, В. Пименов, С. Антонов, Я. Винецкий, Ю. Розенталь, А. Кеслер кебек әдәбият һәм сәнгать белгечләренең күп санлы мәкаләләре басылды.

Драматург һәм режиссер буларак күп хезмәт күрсәткән Риза Ишморатның әдәбият-сәнгать тәнкыйте өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Ул әдәбият һәм сәнгатьнең торышы, тоткан юлы, бурычлары турында бик күп мәкаләләр, төрле темаларга очерклар язды. Аның аерым язучыларга багышланган мәкалә-истәлекләре хәзер дә әледән-әле матбугатта чыгып тора. Болардан тыш, Р. Ишморатның 1957 елда басылып чыккан «Бәхет турында сөйләшү» диган бик кызыклы һәм әһәмиятле китабы барлыгын да әйтергә кирәк. Дөрес, аның күләме зур түгел — ике табактан артмый. Әмма монда язучы яшәүнең мәгънәсе турында киң планда һәм тирән итеп уйлана.

Шул рәвешле Р. Ишморат драматург, режиссер, тәнкыйтьче һәм публицист буларак танылды, театр сәнгатебезне, әдәбиятыбызны үстерүгә, укучы һәм тамашачыны заман рухында тәрбияләүгә зур өлеш кертте. Ул һәр вакыт заман сулышын тоеп иҗат итеп килде, илебездәге үзгәрешләргә теге яки бу формада үзенең мөнәсәбәтен ачык рәвештә белдерә барды, әдәбият һәм сәнгатьнең гел алгы сызыгында булды. Әнә шул заман сулышын тоеп, яңалыкны тотып ала белүе, башкалардан да шуны таләп итүе, һәр нәрсәдә принципиальлеге, чын мәгънәсендә партиячел художник булганы өчен ул күп мәртәбәләр Язучылар союзы каршындагы драма секциясенең җитәкчесе итеп сайланды.

Р. Ишморат, өлкән яшьтә булуына карамастан, туктаусыз иҗат итә, киләчәк өчен дә зур иҗат планнары белән яши. Үзенең белемен, тәҗрибәсен, осталыгын драматурглар, театр эшлеклеләре, үзешчән коллективлар белән бик теләп уртаклаша, аларга төрле яктан ярдәм итә.

**ҺӘНҮЗ МӨХМҮТОВ.**

Риза Ишморат

# САРАШ АВЫЛЫНДА

ИСТӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН



Ерак басуда солы урган чакта, кичке әбәткә туктап, тәмләп кенә чәй эчеп утырганда, әти җир өстендә яткан көлтәләргә күз төшереп алды да:

— Көз якынлаша, улларым, сабакка төшәр чакларыгыз җитә, әмма ләкин...

Сүзен әйтеп бетермәде, Зыя абый белән миңа карап, уйланып калды. Әтинең шул сүзләрен ишетүгә минем йөрәк жу-у итеп куйды. Үзенең шыксызлыгы, шапшаклыгы, сабагыңны белмәсәң, шартына китереп тәһарәт алмасаң, тал чыбыгы, я пеше таяк белән аркаңны каезлый торган усал хәлфәләре белән Янбарыс авылы мәдрәсәсе күз алдына килеп басты.

Юк, надан мужик булып калырга риза мин, дин сабагын белмәгән өчен «теге дөньяга» баргач җәһәннәм утында янарга да риза, тик шул мәдрәсәгә генә барырга булмасын. Белеп торам, Зыя абый да бу мәдрәсәне пәри кебек күрә. Теләсә нинди сабакны миңа караганда тизрәк отып ала торган, төпле акыллы, зирәк шәкерт булса да яратмый. Хәер, әти үзе дә бер дә яратмады үткән кыш без укыган Заһид мулла мәдрәсәсен. Яз башында безне Янбарыстан Йосыф авылына алып кайтканда ук әйтә-әйтә кайтты.

— Ни кадим, ни җәдит! Ни аллага, ни муллага бу мәдрәсәдән,— диде.— Юк,— диде әти ул чакта,— киләсе көзгә сезне мин, насыйб булса, икенче мәдрәсәгә бирәм. Заман өчен лаеклы белем бирә торган мәдрәсәгә.

Сизәм мин, аның «әмма ләкин» дигәннән соң уйланып калуы һаман шул заманга лаек мәдрәсә турында.

Ләкин нинди була соң ул заманга лаеклы мәдрәсә? Нәрсәләр укыталар анда? Ничек укыталар?

Минем баштан әнә шундый уйлар үткән арада әти өзелеп калган сүзен дәвам итте:

— Заһид мулла мәдрәсәсенә түгел, башка мәдрәсәгә бирәм мин сезне,— диде ул.— Я шкулга бирәм. Хәзерге заманда урысча укымасаң, бер кая да барып булмый...

Урысча уку... Бу инде әти авызыннан беренче генә кат чыккан сүз түгел. Шулай да бу әллә ничегрәк тоела миңа. Ай, кыендыр ул урысча уку. Әти белән Гундыр базарына баргач озын чәчле ике урыс бабаеның сөйләшеп торганын күргәнем бар минем. Һи-и, малай...

Әкәмәт икән ул урысча... Тудый да судый, чәпчи дә бичи... һич аңлар хәл юк. Мужет анысы, яхшырак укытсалар, бара торгач бәлки аз-маз сукаларсың да, тик башка ягы да бар бит әле. Картый[1] әйтә, урысча укыганнарның күңеле карала, ди, күңеле каралганнар ислам диненнән бизә, ди. Ә ислам диненнән бизгәннәргә әлеге шул теге дөньяда оҗмах ишеге бөтенләй ябык, ди.

Монысы да шәп түгел. Мөселманча укыган малайлар оҗмахка кереп хөрмә белән өрек кенә ашап торганда, син оҗмахның ишеге төбендә, тышкы якта каңгырып утыр әле. Тик шулай да теге дөнья дигәннәре әллә бар аның, әллә юк. Хәзергә әле безгә бу дөнья кадерле. Хәзергә әле, аллага шөкер, катык, сөт ашап, җир өстендә, якты кояш астында яшибез...

Ул арада уйларымны тагын әти өзде:

— Әйдәгез, урылган көлтәләрне җыйнап чүмәләгә салыйк та кояш баеганчы тагын берәр кишәрлек урырбыз,— диде. Аннары, амин-фәлән дә тотып тормый табыннан кузгала башлаган әнигә карап: — Син, анасы, бар, ура тор. Көлтәләрне без балалар белән үзебез генә дә җыеп өярбез,— диде.

Сүзгә караганда, эшкә дәртрәк, уракны да әтигә караганда ике өлеш артыграк ура торган әни әти сүзен кире кагып тормады.

— Ярар, атасы, ярар. Улларың инде җиткән егет хәзер, булышырлар,— диде дә көлтәгә кадап куйган урагын алып, иңсәсенә салды һәм, башындагы яулыгын төзәтеп бәйли-бәйли, җирнең аргы башына, урылмаган урынына китте.

Зыя абый белән без ярыша-ярыша көлтә җыярга тотындык.

Кыр эшләре бетеп тә өлгермәде, безне укытыр өчен яңа мәдрәсә эзләп, әти якын-тирә авылларның байтагына барып кайтты. Аксәеткә барды. Гундырда да булды. Чокыр авылына да барды. Күрдемгә дә сугылды. Тик үз күңеленә ошаган, заманга лаеклы белем бирә, тәрбия итә алырлык мәктәп-мәдрәсә таба алмады. Аңа мәктәпләрнең әле бер ягы, әле икенче ягы ошамады. Шулай да әти бер көнне бик дулкынланып кайтып керде. Ул без яшәгән Йосыф авылыннан яхшы ук еракта, Гәйнә иле дип йөртелә торган якларда, Сараш[2] авылында, бер-ике ел гына элек ачылган русско-татарская школа барлыгы турында ишетеп кайткан икән. Бигрәк тә бу школаның укытучылары Казанда Татар учительләр семинарын тәмамлаган яхшы укытучылар — агалы-энеле Шәриф һәм Сәгыйт Сүнчәләйләр булуы ошаган әтигә. Ул елларда татар телендә чыккан барлык газета-журналларны укып барган әти Сәгыйт Сүнчәләйнең Габдулла Тукай, Мәҗит Гафурилар шикелле үк шигырь язуын яхшы белә иде. Димәк, Шәриф белән Сәгыйт Сүнчәләйләр милләтебезнең алдынгы кешеләре.

Әти әнә шуларны сөйләгәч, Зыя абый белән мин шатлыгыбыздан нишләргә дә белмәдек. Әтинең фикере белән бик тиз килешә һәм безнең киләчәктә укыган кеше, бәхетле кеше булуыбызны тели торган әниебез дә шатланды моңа. Тик Сараш авылының бик еракта, алтмыш чакрымнардан да артыграк җирдә булуы борчыды аны. Һәм ул күзләренә килгән яшь бөртекләрен бездән яшереп кала алмады...

* * *

Дөресен әйтергә кирәк, Янбарыс мәдрәсәсенең җан өшеткеч тәртипләре, уку-укыту ысуллары белән якыннан танышып, бер кыш укып кайтканнан соң, Сарашка да бераз куркыбрак бардык. Нинди булып чыгар бу шкул. Бигрәк тә укытучы абыйлар? Сабакны бел-

---

[1] Картинәйне бала чакта без шулай дип йөртә идек.
[2] Сараш — Пермь өлкәсенең Барда районындагы бер авыл.

мәгән өчен бәлки алар да чыбык белән аркага сыздыра торганнардыр? Коръән, хәдис укытмасалар да, анда урысча укыталар. Хәзергә кадәр бер сүз дә урысча белмәгән башың белән ничек урысча укыйсың да ничек аңлыйсың ди аны... Шундый сораулар куркытты безне.

Ләкин куркуыбыз юкка булган икән. Гариф исемле кешенең ике катлы өенең югары катындагы зур ике бүлмәгә парталар тезелгән. Монда школа. Бүлмәнең зуррагында беренче, икенче класслар, ә кечерәгендә өченче класс укый икән. Зыя абый белән мине, гәрчә моңарчы ике ел сабак укып, татарча укый-яза белсәк тә, хәтта гарәп телендә язылган коръәннең кайбер сүрәләрен, шулай ук намаз-нияз шартларын яхшы ук үзләштергән булсак та, русчаны бөтенләй белмәгәнгә күрә, учитель абзыебыз Шәриф Сүнчәләй беренче класска урнаштырды. Без инде моңа да бик шат. Урысча укыйбыз ич без! Кыш буе укып яз көне авылга кайткач, бергә уйнап йөри торган дусиш малайлардан Миңнемөхәммәт, Гарифҗан, Хәтмуллаларның авызын урыс сүзләре белән генә томалаячакбыз. Аннан безнең белән бергә беренче класста укучы малайлардан һәм кызлардан (монда малайлар белән кызлар бергә укыйлар) яшебез белән дә аерылмыйбыз. Миңа сигез яшь тулып килә, абыйга тугыз. Беренче класс укучылары күпчелеге шул яшьтәгеләр. Унбердәгеләр, уникедәгеләр, хәтта аннан зурраклар да бар. Ләкин андыйлар күп түгел. Безне иң шатландырганы — монда дин сабакларының булмавы. Коръән сүрәләре, төрле догалар ятлап, намазлар укытып берәү дә сине азапламый. Монда тик, әти әйткәнчә, заманга лаеклы дөнья гыйльме. Русча да, татарча да дөрес итеп укый-яза белү. Аннан арифметика, җәгърафия, табигать белеме, тарих. Стеналарда җәгърафия карталары эленгән. Төрле ерткыч хайван сурәтләре — аю, бүре, төлке, куян... Тагын без гомеребездә иштмәгән ерткычлар, төрле җәнлекләр. Парталар алдында кара такта. Һәрбер партада карасы түгелми торган кара савытлары. Кыскасы, безнең өчен өр-яңа дөнья, өр-яңа тәртип. Котсыз Янбарыс мәдрәсәсе белән чагыштырганда бу — хан сарае. Ә укытучылар? Шәриф абый белән Сәгыйт абый? Аларны Заһид мулла һәм Мәгъсүм хәлфәләр белән янәшә куеп чагыштырып карау да зур гөнаһ булыр кебек. Шәриф Сүнчәләй... Ул чагында әле 25 яшендәге мәһабәт сынлы, чем-кара һәм озын чәчле ир-егет. Ул чәчләрен яхшылап тарап уң як читеннән аерып куя да үзенең мөлаем карашы белән сихерли сине. Тирән акыллы, сабыр холыклы, үзенең бөтен укучыларына яхшы белем һәм тәрбия бирергә, аларны чын кеше итәргә тырышкан бу хөрмәтле зат беренче танышуда ук безнең ихтирамыбызны яулап алды. Ул чакларда һәр укымышлы кешегә мулла дип хөрмәтләп дәшү гадәт булганга, без аңа да Шәриф мулла абый дип дәшә идек. Әгәр бераз кызурак канлы, кырысрак табигатьле булуын искә алмаганда, шул ук хөрмәтләү сүзләрен Сәгыйт абый Сүнчәләйгә карата да әйтер идем мин.

Беренче класстан алып дүртенче классны тәмамлаганчы, ягъни 1911 елның сентябреннән 1915 елның май урталарына кадәр укыдым мин бу школада. Русча да, татарча да укырга, язарга өйрәндем. Арифметика, җәгърафия, берникадәр тарих фәне, табигать фәне белән таныштым. Халкыбызның атаклы әдипләре, шагыйрьләре — Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал һәм башкалар турында ишеттем, аларның күп кенә әсәрләрен укыдым. Рус әдипләре Толстой, Тургенев, Некрасов, Гоголь, Пушкин, Лермонтов, Кольцов, шулай ук Гейне кебек дөнья классикларының да кайбер әсәрләре белән таныштым. Гейненең Сәгыйт абый татарчага тәрҗемә иткән «Әлмәнсур»ның берничә битен яттан да белә идем әле. Моңа Шәриф һәм Сәгыйт Сүнчәләйләрнең үзләре генә тү-

гел, бәлки аларның әнисе Һаҗәр әби тәрбиясендә яшәү дә ярдәм итте.

Шушы дүрт ел эчендә Шәриф абый ник бер генә тапкыр тән җәзасы бирсен. Хәтта тавышын күтәреп тиргәми дә иде ул безне. Зыя абый белән миңа карата гына түгел, үзенең барлык укучыларына да шундый яхшы мөнәсәбәттә иде ул. Дөрес, безнең кайчак артык шаярып, хәтта әйберләр дә ватып, аның ачуын китергән чакларыбыз була иде. Кайбер укучылар дәресләрен дә белми, өйрәнмичә киләләр. Андый хәлләрдә ул укучыны ашсыз-әбәтсез калдыра һәм, дәрестән соң, барлык укучылар өйләренә кайтып киткәч, аны ике сәгать чамасы вакыт класста утырта, өйрәнмәгән дәресен өйрәнергә мәҗбүр итә. Я аны үзе өйрәтә. Монысы да укучы өчен авыр җәза. Бөтен иптәшләрең кайтып киткәч, берүзең класста утырып кара әле син. Бигрәк тә карының ачкан килеш. Шуңа укучылар Шәриф абыйның бу җәзасыннан бик куркалар һәм һәр вакыт дәресләрен белеп килергә тырышалар иде.

Ә Сәгыйт абыйның талкан бераз корырак. Дәрес вакытында шаяртсаң, я сабагыңны белми килсәң, колагыңны борып та куйгалый, шып итеп маңгайга да чиертеп ала. Кулында линейка булса, кайчакта шуның белән дә элактереп ала. Кырысрак холыклы иде ул. Ә шулай да укучылар аны бик яраталар. Чөнки ул дәрестән соң, атна кич махсус билгеләнгән дәрес вакытында бөтен укучы балаларны бергә җыеп җырларга өйрәтә һәм шул вакытта бик матур итеп, моңлы итеп скрипка уйный. Без, укучылар, аңа кушылып җырлыйбыз. Дәрес саен яңа көй, яңа җыр өйрәтә безгә Сәгыйт абый. Ә безгә инде бергәләп, күмәкләшеп җырлау рәхәт! Дөньябызны онытып җырлыйбыз, җыр тавышыннан Гариф бабайның өй тәрәзәләре селкенеп тора.

Күбрәк Тукай шигырьләрен җырлыйбыз без. Һәр шигырьгә аерым көй. «И бәһале, и кадерле...» дип башланган җырны «Сәлим бабай» көенә җырлыйбыз. Ә «Туган тел» шигыренең үз көе бар. Ул аеруча дәртле булып яңгырый. Аны яттан белмәгән һәм аның көен үзләштермәгән бер генә укучы да юк.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле,
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы...

Безнең белемебез, яшәвебез, бәхетебез әнә шул матур телебезгә, туган телебезгә бәйләнгән кебек тоела иде безгә.

Кайвакытларда Сәгыйт абый үз шигырьләренә язылган үз көен дә өйрәтә иде. Мәсәлән:

И тәгалә, рәхмәтеңнән безне мәхрүм кылма син,
Күңелебезнең ак күгәрчендәй догасын тыңла син!

Авыррак өйрәндек без бу көйне. Шулай да бер өйрәнгәч, һәр вакыт яратып җырлый идек.

Ә кайчакта Сәгыйт абый укучыларга скрипкада «Тәфтиләү», «Зиләйлүк», «Карурман» шикелле озын-озын көйләрне дә уйный һәм без аларны бөтен күңелебезне биреп тыңлыйбыз. Скрипка уйнаган чагында Сәгыйт абый бөтен дөньясын оныта. Смычогы белән бергә аның бөтен гәүдәсе хәрәкәт итә. Бигрәк тә иреннәр хәрәкәттә. Смычок барышына карап кыйгаялар, тагын төзәяләр. Башта балалар моннан көләләр дә иде. Ләкин Сәгыйт абыйның усал гына итеп бер карап куюы аларны көлүдән туктатты. Менә шулай безне сихерли иде Сәгыйт абый.

Укучыларны үзенә тарта торган аның әле тагын бер сыйфаты бар. Ул дәрес алып барганда кычкырып, артистларча бик әйбәт итеп, ши-

гырьләр укый иде. Күбрәк Тукай шигырьләрен укый. Ул укыганда без бу шигырьләрнең мәгънәсен тагын да тирәнрәк аңлый идек, матурлыгын да ныграк тоя идек.

— Сәгыйт мулла абый, Тукайның үзен күргәнең бармы синең? — дип сорау бирде аңа бер көнне укучы малайларның берсе.

— Бар. Без аның белән бик якын танышлар гына түгел, хәтта дуслар да. Үзара хатлар да алышабыз,— дип җавап бирде Сәгыйт абый. Казанга барган саен (ә ул укулар беткәч үк Казанга китеп бара торган иде), Тукай белән очрашып, сөйләшеп йөрүен, үзе язган шигырьләрне Тукайга укып күрсәтә баруын сөйләгәч, безнең аңа карата булган хөрмәтебез тагын да артып китте. Әнә кем бит ул безнең Сәгыйт абыебыз... Тукай белән хатлар алышып тора... Үзе дә шигырьләр яза... Укытучыбыз шундый шагыйрь кеше булу безнең өчен зур горурлык иде.

Ә безнең Шәриф абый? Сабыр холыклы, дөньядагы бөтен гыйлемне дә яхшы белә торган Шәриф абыебыз? Ул Сәгыйт абыйга да абый. Дөрес, ул шигырь язмый, ләкин бөтен шигырь язучыларны укытырлык зур белеме бар аның. Ул да Тукай белән яхшы таныш. Казандагы башка шагыйрьләр, әдипләр, галимнәр белән дә таныш. скрипканы да шундый оста уйный. Дөрес, уйнаганда аның гәүдәсе Сәгыйт абыйныкы кебек бөргаланмый, иреннәр дә чалышаймый, ләкин шулай да бик моңлы яңгырый аның кулында скрипка. Ул да безгә шигырьләр укып күрсәтә. Артык кычкырып та җибәрми, кулларын да селтәп куймый. Сәгыйт абый укыгандагы кебек озын чәчләре дә тузгаланмый. Гадәти генә укыган кебек ул. Шулай да шигырьнең мәгънәсе безнең йөрәккә ярып керә. Дулкынландыра безне. Кайчакларда күзләребез яшь белән тула. Әйе, әйе... «Көзге җил»не укыганда нәкъ шулай булды.

Көзге төн, мин йоклый алмыйм,
Өй түрендә җил җылый.
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

Шәриф абый укып кына да калмый. Тукайның нәрсә әйтергә теләгәнен, халкыбызга, кешеләргә карата мәхәббәтен бик гади генә итеп аңлатып та бирә.

Аеручa Тукайның балаларны яратуы турында сөйли. Үзенең сүзләрен раслар өчен, Тукайның балалар өчен дип махсус язган шигырьләрен укып күрсәтә. Уку өчен, ятлап килү өчен шигырь басылып чыккан китапларны өйгә дә биреп җибәрә. Тукайны гына түгел, башка шагыйрьләрнең шигырьләрен дә укый. Мәҗит Гафури, Дәрдмәнд, Укмасый... Икенче, өченче классларда укый башлагач ул безгә рус шагыйрьләре Пушкин, Некрасов шигырьләрен дә укый, алар турында да сөйли иде. Без барын да аңлап бетермибез. Шулай да күбесен аңлыйбыз...

Әйт әле, күбәләк,
Сөйләшик бергәләп,
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек.

Бала чагында беренче классларда ук ятланган бу шигырь безгә бик аңлашыла һәм без аны һәркайчан, һәр җирдә кычкырып укып йөри идек.

Беренче классны тәмамлаган чакларда без инде русча да үзебезгә күрә ярыйсы сукалый идек.

Жил-был у бабушки
Серенький козлик,

Вот как, вот как
Серенький козлик,—

ны рәхәтләнеп кычкырып укып йөри идек. Бигрәк тә безгә, абый белән миңа, раз, два, три, четыре, пять,— дип башланган шигырьнең азагы:

Пиф, паф! Ой, ой, ой!
Умирает Зайчик мой,—

дигән сүзләре ошый иде.

Сараш авылында укыганда, безнең өчен аеруча зур бәхет Шәриф абыйлар белән бергә яшәү булды. Шәриф абый Галәветдин исемле бер бай кешенең зур гына өендә, икенче катта, фатирда тора иде. Кап урталай бүленгән өй. Сул ягында зур зал, аның бер почмагында кечкенә бүлмә. Шәриф абыйның йокы бүлмәсе. Залда ашау-эчү өчен дә, язу-сызу өчен дә хезмәт итә торган зур өстәл. Савыт-саба тутырылган пыяла ишекле матур шкаф янында китап шкафы, бер почмакта киң диван, урындыклар... Сәгыйт абый үзенең хатыны Фәридә апа һәм улы Фәрит белән күршедә, Мәшрәф-Мәшкә кушаматлы кешеләрдә яши. Гаиләсе Казанга киткәч, Шәриф абый янына, залга күчте. Өйнең икенче яртысында, түр бүлмәдә, зур кухня. Анда аш өстәле, зур сәке. Бу бүлмәдә Һаҗәр әби яши. Ә ишекне кергәч тә әз генә бүленеп куелган һәм зур гына ян сәкесе булган бүлмәдә Зыя белән мин яшим. Сәке яхшы ук киң, урын-җир дә каты түгел, йомшак. Кыскасы, иркен безнең яши торган урын. Ашау-эчүне барыбызга да беррәттән Һаҗәр әби әзерли. Коедан су алып керү, утын ярып керү кебек эшләргә без булышабыз. Хәер, утын яру безгә бик әләкми дә. Атна кич сабактан кайткач (ул көнне гадәттәгедән бераз иртәрәк кайта идек) өелеп куйган бик яхшы әрдәнәне, чыршы һәм каен утынын, Шәриф абый үзе яра иде. Ә безгә, малайларга, ярган утынны ташырга гына кала. Утынны ташып, чоланга өеп кую берни түгел иде безгә. Җитмәсә әле, Галәветдин бабайның кече малае Гаптрәхим дә булыша иде. Ну шайтан малай да иде ул Гаптрәхим. Яшькә дә миннән бер яшь кечкенә, буйга да тәбәнәк. Ә үзендәге көч! Һи-и... Карахмәт батыр көче бар диярсең. Шулай булмый, муен юан, җилкә киң шул аның. Гәүдә дә базык, калын. Шуңа кочагына утынны алагаем итеп төйи дә җилдерә генә. Гаптрәхим белән минем кочакка утынны гадәттә Зыя абый төяп тора. Абый кеше бик хәйләкәр: утынны күтәреп баруга караганда төяп тору җиңелрәк шул!

Сәгать ярым-ике сәгать эчендә бер атнага җитәрлек итеп ярылган утынны чоланга ташып өеп тә куябыз. Шәриф абыйның һәм Һаҗәр әбинең рәхмәтләрен ишеткәч — әйдә! Уенга! Дөнья безнеке ул чак. Кайларга барып, нинди генә уеннар уйнап бетермибез. Кышларын тау шуабыз. Сараштa, шул авылдагыча «шуабыз» дип түгел, «елабыз» дип сөйләшә идек. Сөйләшкәндә дә үзебездәгечә «әнә ич», «менә ич» дип түгел, «әнә кый», «менә кый» дип кыелдап кына җибәрәбез. Күп чакта шуарга авыл уртасындагы тауга барып түгел, ә ишегалдыбызда, кардан өеп үзебез ясаган тауда шуабыз. Ул тауны без кар төшү белән үк ясый башлыйбыз. Ә кыш урталарына коймадан да биегрәк итеп җиткерә идек. Бу тау асылда Сәгыйт абыйның беренче улы, безне үз туган абыйлары кебек якын күргән, холкы белән дә, күз карашлары белән дә сөйкемле малай — Таһир өчен эшләнә иде. Тау ясаганда да, шуганда да башлап йөрүчеләрнең берсе Гаптрәхим була. Сабыр холыклы бу малай дәшми-тынмый гына йөрергә ярата. Эшен җиренә җиткереп эшли. Гадел, акыллы, туры сүзле. Юккабарга ачуланыша да белми. Ләкин бер ачуландымы инде, саклан! Кирәгеңне аласың аңардан. Муеныңнан кочаклап ала да җиргә ега да сала. Шунда ук тәпәли дә башлый.

Упкәләшәбез дә кайчак. Ләкин безнең үпкә озакка бармый. Шул ук көнне, Гаптрәхим, әйдә, уйнарга чык дип, мин барып керәм аңа, я тәрәзәдән кычкырам. Я ул үзе кереп җитә, үзе чакыра. Без, арабызда берни дә булмагандай, тагын дус кына уйный башлыйбыз. Шулай итеп дусларча уйнап, шаярып, ара-тирә тәпәләшеп тә алып, 4 ел яшәдек Гаптрәхимнәр өендә. 4 елдан соң аерылыштык. Ул Сарашта торып калды. Гомерем юлы мине икенче җирләргә алып китте. Гаптрәхим турында сүз чыккач, ул турыда сүземне төгәлләү өчен, аның белән икенче очрашуыбыз хакында да әйтеп китим инде.

Бу хәл 1967 елны булды. Нәкъ илле ике елдан соң үземнең бала чакларымда 4 ел укыган, дөньяны танып белә башлаган җирем — Сараш авылына барып чыктым. Язучы буларак, мәктәптә (хәзер инде анда зур урта мәктәп) укучы һәм укытучылар белән очрашырга дип бардым. Ләкин мине, барыннан да бигрәк, бала чагымда уйнап, бергә укып үскән кешеләр кызыксындырды. Кешеләр генә дә түгел, ул чактагы өйләр, каралтылар, урамнар, анда үскән агачлар барысы, барысы да. Билгеле инде, иң беренче, иң кызыксындырганы Шәриф абыйлар белән бергә яшәгән өй һәм анда исән-сау калган кешеләр булды. Әйтергә генә ансат. Бу илле ике ел эчендә ниләр генә булып узмады. Беренче империалистик сугыш, революция, гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы... Күпме кешеләрне алып китте алар. Ә Сарашта хәлләр ничек? Кем бар, кем юк? Өйләр бары да яңа. Элеккедән сакланып калган нибары берничә өй дә таштан салынган, элек кибет булып хезмәт иткән биналар күренә. Сарашның үзәк урамнарында элек-электән икешәр кат итеп салынып, түбәләре калай белән ябылган яхшы өйләр байтак иде. Сәүдәгәр һәм байлар өе иде алар. Хәзер инде алар урынында өр-яңа өйләр. Шулай ук матур итеп салынган, я калай түбәле, я шифр белән япкан өйләр. Анда колхозчылар яши. Зиннур сәүдәгәр өе урынында колхоз идарәсе йорты. Каршысында унъеллык мәктәп. Элек, без укыган чакта, школа өчен махсус бина юк иде... Колхоз идарәсеннән ерак түгел генә җирдә, урамның икенче ягында, Галәветдин бабайлар, Гаптрәхимнәр өе булырга тиеш. Дөрес, әле дә ул өй бар. Ләкин тиз генә танырлык түгел. Яңартылган, шәп итеп, бер генә кат итеп салынган өй. Сорашып белдем, анда үзенең хатыны һәм балалары белән Гаптрәхим яши икән. Моны ишеткәч сөенүемнең иге-чиге булмады. Сарашка килеп төшкән беренче сәгатьләремдә үк Гаптрәхимнәргә барырга ашыктым. Килеп ишек төбенә туктадым да дәшәм:

— Гаптрәхим өйдәме? Күрергә мөмкинме аны?

Кемдер берәү ишекне ачып кына карады да кире кереп китте. Озак та үтмәде, минем алдымда инде таза гәүдәле, киң җилкәле, түгәрәк битле, үзенең юан беләге, зур куллары, кыскасы, тышкы кыяфәте, килеш-килбәте белән цирктагы көрәшче батырларны хәтерләтә торган мәһабәт ир басып тора иде.

Коңгырт күзләренә сорау галәмәте чыгарып, минем белән кызыксынучы бу кеше кем икән? — дигәндәй миңа карады...

Мөгаен, бу каратут йөзле, күз карашларыннан ниндидер ягымлылык, яктылык бөркелеп торган мәһабәт кыяфәтле кешене кайда да булса икенче бер җирдә очратсам — Гаптерәхим дип уйламаган да булыр идем. Ә мин инде Гаптерәхим икәнен белеп килгәч, бигрәк тә күзләрем аның күз карашы белән очрашкач, ул минем бала чагымдагы дустым булуына әз генә дә шигем калмады. Мин аңа әле кичә генә аерылышкандай гади генә итеп:

— Исәнме, Гаптрәхим! — дип кулымны суздым.

— Бик исән әле хәзергә...— дип җавап кайтарып, юан бармак-

лары белән ул да минем кулымны кысты да, мин сине танымыйм бит, син кем буласың соң дигәндәй, миңа карап торды.

— Әллә танымыйсың инде мине, Гаптрәхим?

— Таныйм да кебек, тик кем икәнеңне тәгаен генә әйтә алмыйм.

— Хәтерең начар икән...

— Соңгы вакытта начарлана төште шул,— дип, минем кем икәнемне хәтеренә төшерергә тырышты. Сизеп торам, ул минем кемлегемне якын тирәдән һәм якын үткәннәрдән эзли.

Мин инде аны артык азапларга теләмичә әйтәм:

— Бу өй сезнең кайчандыр ике катлы иде.

— Әйе,— ди Гаптрәхим,— ләкин бик күптән инде аңа.

— Әйе, күптән,— дим, аның сүзен хуплап.— Өйнең икенче катында кайчандыр Шәриф белән Сәгыйт Сүнчәләй һәм аларның әниләре тора иде.

— Әйе,— ди Гаптрәхим.— Сәгыйт абыйның әле Таһир исемле малае да бар иде,— дип өсти.

— Әйе, онытмагансың, молодец! Ә менә анда синең белән бер яшьтәрәк ике малай тора иде, аларын оныткансың...

— Риза белән Зыянымы? Юк! — ди бу кинәт ачылып. Күзләре дә, йөзе дә, иреннәре дә балкый моның. Әйтерсең аңа нәкъ шушы минутта гамьсез бала чагы әйләнеп кайтты.

— Ризасымы, Зыясымы син? — ди бу, кинәт минем ике кулымнан ук кысып алып.

— Ризасы, Ризасы,— дим аңа, ашыгып.

Без кочаклаштык. Шатлыгыбыз эчебезгә сыймады. Яшь тамчысы булып җиргә дә тамды ул шатлык хисләребез.

Әле моннан берничә ел элек кенә булган шушы вакыйганы сөйләгәннең соңында, мин сезне тагын борынгы Сарашка, борынгы заманга кире кайтарыйм әле, хөрмәтле укучылар.

Шәриф абыйларда торган чорда иң кызыклы, иң истәлекле сәгатьләрнең берсе — атна кич була иде. Шәриф, Сәгыйт абыйларның үзләреннән бигрәк бу кичне без, Зыя белән мин, сагынып көтеп ала идек. Иртәгәге көнгә тыңлатырга дәрес әзерлисе булмаганы өчен түгел, ул кичне иң тәмле ашлар пешерелеп, алардан безгә дә өлеш чыкканы өчен дә түгел, ул кичне Шәриф абыйларга авылның, авылның гына түгел, якын-тирәнең иң хөрмәтле һәм укымышлы кешеләренең кунакка килеп, күңел ачу мәҗлесләре үткәрүе була иде. Өстәл тулы ризык, Һаҗәр әби кулы белән пешерелгән төрле-төрле камыр ашлары... Бик әз генә, безгә, малайларга, күрсәтмәскә тырышып кына эчә торган шәраблары да була иде, ахры... Юк, Зыя абый белән миңа аларның ашап-эчеп утыруларын карап тору кызык түгел, ә иң кызыгы аш, чәй килгәнче һәм чәйдән соңгы хәлләр.

Кызып-кызып төрле темаларга алып барылган сүз-бәхәс. Дөнья хәлләре, әдәбият, театр, музыка турында гәпләшү. Сәгыйт абый үзенең яңа шигырьләрен кунакларга кычкырып укып күрсәтә. Аларның бу шигырьләренә карата фикерләрен тыңлый. Я булмаса яңа алынган «Аң» я «Ак юл» журналында басылган берәр шигырьне кычкырып укый... Тукай шигырьләрен укый, Тукайның ничек яшәве турында сөйли. Барыннан да күңеллерәге — ашау-эчүдән соңгы мәҗлес. Ике-өч кешенең берләшеп, төрле инструментларда уйнаган көйләре. Сәгыйт абый инде бик оста скрипкачы, мандолинада да әйбәт уйный. Шәриф абый да скрипканы начар уйнамый, ләкин ул күбрәк гармунда уйнарга ярата. Гармун телләре аның кулында сайрап кына тора. Фатих абый мандолина уйный белә. Менә сиңа трио. Скрипка, гармун, мандолина. Озын көй дә, кыска көйләр дә уйный алар. Ләкин иң хәтергә кереп уелып калганы «Мәхәббәтем» көе. Та-

тарның беренче романсы. Ул Сэгыйт абыйның шэхси тормышына, аның беренче мэхэббэтенэ бэйлэнгэн җыр.

Йолдыз нуры,
  Оҗмах хуры —
    Син, Бибкэй!
Таҗым-даным —
  Гомерем-җаным
    Син, Бибкэй.
Мине ник үптең?
  Үптең дэ киттең,
Ник күп сөймэдең?
  Үптең дэ киттең.
Кайдан килдең,
  Кайдан инде,
    Бибкэем?
Ник сөйдердең,
  Ник көйдердең...

Сэгыйт абый бу көйне мондый кичэлэрдэ генэ түгел, ялгыз калган минутларында да дулкынланып уйный һэм авыз эченнэн генэ моңаеп, җырлап та куя торган иде.

Бу көйне уйнаганда, сүзлэрен дэ авыз эченнэн көйлэгэндэ, Сэгыйт абыйның ниндидер бер моңсулыкка бирелүен, күңелендэ авыр сагыш кичерүен сизэм...

Лэкин Сэгыйт абыйның үзеннэн бу җырның, бу көйнең ничек тууы турында сораша алмадым. Андый уй хэтта башыма да килмэде. Бу җыр белэн безнең бик нык мавыгуыбызны күреп, үзе дэ бу көй башкарылганда артык нык дулкынлана һэм тирэн кичереш үткэрэ торган Һаҗэр эби:

— Бу шигырьне Сэгыйт Таһирнең энисе Сэлимэ үлгэч язды. Көен дэ үзе чыгарды,— диде.

Шуңа мин озак еллар буе «Мэхэббэтем»не Сэгыйт абый үзе чыгарган көй дип йөрдем. Тик егерменче еллар уртасында гына аның җырчы һэм артист Фэттах Латыйпов тарафыннан язылуын белдем.

...Кичэнең без түземсезлек белэн көтеп алган иң кызыклы өлеше Нурулла мулла абзыйның сандугач булып сайравы була торган иде. Я ходай! Бу кадэр могҗиза булса да булыр икэн кешедэ. Сайрар алдыннан ул түшэмгэ асылып куелган 30 лы зур лампаны бераз батыра. Бүлмэ бераз караңгыланып, кичке эңгер-меңгер вакытын, я иртэн таң сызылып килэ торган чакны хэтерлэтэ. Бүлмэдэгелэр, хэзер ниндидер бер тылсымлы моң көйлэнэ башлануын сизенеп, бары да тын калалар. Шуннан соң Нурулла мулла ике кулын ике яңагына, дересрэге, авызы янынарак куя да экрен генэ сызгырып сайрый башлый. И-и! Булса да булыр икэн. Гэүдэгэ дэ тупас, юантык, битлэре дэ итлэч, иреннэре дэ бераз калын булып турсаебрак торган кеше бит, югыйсэ, Нурулла абзый. Э сайрый башладымы — нэкъ сандугач! Үзенең нэфис моңы белэн синең йөрэгеңне өзэ. Үземне белэ белгэннэн бирле урман, эрэмэлек кочагында яшэп сандугач сайрауларын күп тыңлаганга күрэ, аның моңы белэн яхшы таныш мин. Үзе бик сак һэм бик үк сылу булмаган, кыяфэтен кешелэргэ бик күрсэтэсе килмэгэн нэни генэ кош ул сандугач. Нэни һэм шундый нэфис тавыш. Э Нурулла абзыйда бит нинди гэүдэ! Сөйлэгэндэ дэ тавышы гөбедэн чыккан тавыш белэн гөрелдэбрэк чыга, э сайрый башлагач, энэ нинди бит ул... Юк, сандугач үзе дэ мондый оста итеп сайрый алмый. Кая аңа Нурулла абзыйга җитэргэ. Нурулла абзый сандугач булып сайрап кына калмый, скрипка я гармунда уйнала торган телэсэ нинди көйне дэ сандугач булып көйли. Сандугач тавышы белэн сайралган көйлэр тагын да тээсирлерэк булып ишетелэ иде безгэ. Нурулла абзыйны күплэр сандугач Нурулла дип йөртэлэр иде.

Үзенә күрә бер әдәби һәм музыкаль кичә сымак булып үткәрелгән бу мәҗлесләр хәтеремдә нык сакланып калдылар. Һәм, әлбәттә, шигырь һәм музыкага карата тирән мәхәббәт тудырдылар.

Шәриф абыйларда яшәгән чорда Зыя абый белән минем күңелемә хуш килгән тагын бер нәрсә бар иде. Күп кенә газета-журналлар белән бергә, Шәриф абый балалар өчен махсус чыгарыла торган «Ак юл» журналы ала иде. Төрле хикәяләр, шигырьләр басылган бу журналны без дүрт күз белән көтеп ала һәм аны шунда ук, хәтта дәрес әзерләүгә зарар китереп булса да, укып чыга идек.

Шул елларда Сәгыйть абый Сүнчәләй Генрих Гейненең «Әлмәнсур» исемле пьесасын тәрҗемә итте. Ул китапны шул кадәр яратып, бирелеп, кат-кат укыдым мин. Хәтта күп кенә битләрен ятладым да аның. Әле дә беренче битләре исемдә. Яшьлек елларымны искә алганда, я Генрих Гейне исеме ниндидер уңай белән телгә алынса, «Әлмәнсур»ның беренче юллары исемә төшә.

Я бабайларның сарае син элек нинди идең,
Иске булсаң да хәзер, җанга сөекле һәр җирең.
Бу менә изге бабайлар таптаган хәтфә палас,
Мескенем кискән көя, беткән нәфис рәсмең синең...

Атна кичләр әнә шулай матур уза. Ә җомга? Бу көнне укымыйбыз, ял көне, бәйрәм. Ул көн үзенә башка ямьле. Урамда уйныйбыз, тау шуабыз. Чанабыз булмаса, агачтан үзебез ясаган таш табаныбыз (коньки) бар. Дөрес, аның үзебез генә ишеп ясаган бавы өзелеп тә азаплый. Таудан шуганда егылып борынны канаткан чаклар да әз булмый. Салкынрак көннәрдә куллар да өши, бит очлары да, колаклар да туңа. Ә шулай да без сер бирмибез, туңдык дип елап кайтып китмибез. Уеныбыз уен, шууыбыз шуу. Шуның өчен малайлар ла без! Ике чабата бер кием, ике дөнья бер тиен безгә. Кайткач безне Һаҗәр әби яхшы ук кыздырып та ала. Шәриф абыегызга әйтеп колагыгызны бордырам дип куркыта. Безнең аңа артык исебез китми. Шәриф абыйның безнең колакны бормаганын беләбез лә без. Аптырагач, әтиегез килгәч, әтиегезгә әйтәм, дип карый. Ләкин беләбез, Һаҗәр әби бик яхшы күңелле карчык, әтигә әләкләми ул. Куркыта гына. Әти килгәч, гел мактап кына тора безне. Малайларың бик уңганнар, йомышымны бик тыңлыйлар, дәресләрен дә тырышып укыйлар, ди...

Җомга көннәрнең иң кызыклы чагы Мулланурларда уйнап үткәргән минутлар була иде. Мулланур — безнең белән бергә укый торган малай. Укучылар арасында үзенең бик сөйкемле йөзе, иптәшләренә булган ягымлы мөнәсәбәте белән аерылып тора. Дәресләрен дә ул безнең барыбызга караганда да яхшырак белә. Өйгә бирелгән эшләрен дә бик яхшы итеп әзерләп килә. Дөрес, дәрес әзерләүгә килгәндә абый белән мин дә начар түгел. Хәзерләмәс идек, Һаҗәр әби дә, Шәриф абый үзе дә гел күзәтеп кенә тора. Ә Мулланур үзе әзерли... Хәер, аның да күзәтеп торучылары бар икән. Аның бер туган абыйлары, безгә кадәр үк инде школаны тәмамлаган егетләр, Сәүбән белән Зиннур. Апалары Шәмсенур белән Маһруй да дүртенче класста укыйлар. 13—15 яшьтәге кызлар. Ярым шәһәрчә киенеп йөрүче матур кызлар... Мулланурның үзенең киеме дә ярым шәһәрчә. Чөнки әтисе Гайса бабай, дөньяның уңын-сулын аңлый торган, яңалыкны хуплап каршы ала торган крестьян һәм шуның белән бергә сәүдә дә итә. Бик үк зур булмаса да, ике катлы өйләре бар. Безнең өчен барыннан да яхшырагы — бик җыйнак итеп, кечкенә өйгә охшатып салынган мунчалары бар. Ишегаллары да уйнар өчен бик иркен һәм чиста. Без күп вакыт аларның әнә шул мунчаларында уйнарга яратабыз. Сукыр тәкәле дә уйныйбыз, йөгерешеп, сикерешеп тә уйный-

быз... Кайчак, тыныч кына утырып, лото уйныйбыз. Биеп тә, җырлап та җибәрәбез. Хәтта үзебезчә театр уеннары да уйныйбыз. Кунакка килгән бабай, әби булып кылынабыз. Егетләр белән кызлар булып та уйныйбыз. Күп чакта безнең уенга Мулланурның сеңелесе Фәүзия дә катнаша.

Ничектер бервакыт безнең кулга «Кайнана өйдә булса, эшнең асты өскә килә» дигән пьеса килеп төште. Без аны шул ук мунчада кычкырып укып чыктык. Чиратлашып укыдык. Ә кайбер урыннарын артист булып кыланып уйнап та карадык.

Гомердә бер тапкыр театр уйнаганны күргән булмыйча, бары тик Шәриф абый, Сәгыйт абыйларның сөйләвеннән генә ишетеп белгәнгә генә, уенybызның рәте-чираты булмады. Шулай да бу үзенә күрә бер театр уены иде.

Мулланурның кызыклы бер ягы шунда, ул, белмим, каян өйрәнә торгандыр, төрле такмаклар, әйтемнәрне күп белә. Менә минем аңардан язып алган һәм ятлап хәтеремдә калган бер әйтем, такмак:

Чыптыр-чыптыр, вәлхәмдики, тәңкирү, тәңкирү, тәңки сүли, тәңки сүли тәбләвәй, тәбләвәй. Анда көндә юша, көндә тур-тур, Әзнәби, туди-суди чәбчи-бичи, кәйдер, кәйдер француз.

Бала чакта ятлаган бик күп шигырьләр, җырлар, такмаклар онытылды. Ләкин менә бу мәгънәсе белән берни дә сөйләми, ләкин эчке яңгырашы белән кош сайравын, сандугач җырын хәтерләтә торган такмак минем хәтеремдә мәңгегә сакланып калды. Сараш авылыннан, аның малайларыннан откан бик күп истәлекләр арасында ни өчендер бу такмак иң кадерлеләрдән булып саклана.

Шушы такмакны укысам, келт итеп, Мулланур һәм Сараш авылының дус малайлары исемә төшә.

1967 елның маенда анда укып үткәргән көннәремне сагынып Сараш авылына баргач, урта мәктәп укучылары һәм укытучылары белән очрашып, үземнең иҗат юлым һәм Сараш авылының бәрәкәтле тәэсире турында сөйләгәндә бер тыннан шушы такмакны да укып күрсәттем. Балалар бик кызыксынып тыңладылар, кул чаптылар. Мин аларга бу такмакны үземнең «Гөлзадә» исемле пьесамда файдалануымны һәм аның пьесаны бизәкләргә ярдәм итүен аңлаттым.

Сараш авылы. Бик зур һәм ямьле авыл ул. Бер ягында калын карурман. Чыршы, нарат урманы. Аркылысы гына да аның 7—8 чакрым, буйга йөзәр чакрымга сузыла. Ә икенче ягында түбәләрен чыршы һәм каен агачлары каплаган бик биек тау. Аның итәгендә зур гына елга — Тол елгасы. Тауның күп кенә урыннарында агач юк. Ялангач ул. Ташлы кызыл балчык. Читтән киң юл шикелле күренеп тора. Ләкин ул юл түгел. Анда арбалы ат түгел, ялгыз атлар да менә алмый. Текә, бик текә ул. Кайчакларда без, малайлар, үрмәли-үрмәли булса да, аның башына менәргә тырышып карыйбыз. Ләкин урта бер җиренә җиткәч, борылып карыйбыз да, котыбыз очып, тукталып калабыз. Аннан тәгәри-тәгәри кире төшеп китәбез.

Сәгыйт абый Сүнчәләй үзенең «Тау биекме» дигән шигырен дә шушы Сараш тавын күргәч язды, ахры.

Тау биекме, син менәмсең,
Мен, менә алсаң, туган, мен,
Күр яланнар, күр япаннар,
Күр бу дөньяның ямен.

Гөнаһны яшерми генә әйткәндә, минем беренче тапкыр шигырь язып каравым да Сәгыйт абыйның шушы шигыре белән бәйләнгән. Бик тырышып язып, икенче көнне үк ертылып ташланган сигез юллык «шигырь»нең баштагы юллары менә болайрак иде.

Биек тауларга менәм мин,
Киң яланнар күрәм мин,
Дөньяларның ямен күргәч,
Кире әйләнеп төшәм мин.

Яздым да Сәгыйт абыйга укыганчыга кадәр шигыремне Һаҗәр әбигә укып карарга булдым. Укыдым. Ул тыңлап торды да:

— Юк, әйбәт түгел шигырең. Бу авыл җыры гына. Шигырь түгел. Аннары син моны Сәгыйт абыеңны үртәп язган кебек. Күрсәтеп торма аңа, ертып ташла,— диде. Югыйсә, бер дә үртәмәдем инде Сәгыйт абыйны. Ул үз шигырендә тауга менеп кара, ди, ә мин тауга менәм, дөньяның ямен күрәм, дим. Күрәм дә кире төшәм. Бары шул гына. Аның киңәшен тотып, ул кушканча эшлим дә шул турыда шигырь язам. Һаҗәр әби аны авыл җыры ди. Ә мин җыр белән шигырь арасындагы аерманы белми идем әле ул чакта. Хәер, мин бик күп еллар буе аларның аермасын белә алмый йөрдем. Миңа калса, һәрбер яхшы җыр, мәгънәсе ягыннан тирән, яңгырашы белән музыкаль булган җыр — шигырь һәм һәрбер яхшы шигырь — җыр булып күренә иде. Әнә, Сәгыйт абыйның үзенең үк «Мәхәббәтем» шигыре шигырьме ул? Әллә җырмы? Минемчә, шигырь дә, шул ук вакытта җыр да. Ә бу фикер, бу мисал шул чакта башыма килгән булса, һичшиксез, аптыраштa калдырган булыр идем әле мин Һаҗәр әбине. Нишлисең бит, башыма килмәгән. Һаҗәр әбинең сүзенә ышандым да шул беренче язган шигыремне Сәгыйт абыйга да, Шәриф абыйга да күрсәтеп тормыйча, ертып ташладым. Ул чакта шигырь язарга омтылу шуның белән тәмамланды. Икенче омтылуым Уфада булды. Анысы турында сүз алда булачак. Хәзер Сараш авылында укыганда күңелгә сеңеп калган истәлекләремнең тагын берсен сөйләп китим әле. 1913 елның апрель ае иде бу. Карлар эреп, елгаларда су ташыган чак. Каеннар яңа гына яфрак ярып, яшеллеккә төренеп килә. Кояш үзенең җылы нурлары белән яңа гына башларын күтәреп дөньяга елмаеп карый башлаган умырзаяя чәчәкләрен иркәли. Бар табигатьнең уянган чагы, сыерчыклар һәм сабан тургайларының безнең якларга кайтып моңая, сайраша башлаган чагы.

Тиздән безгә, мәктәптә укучы балаларга да, зур шатлык киләчәк. Укуларыбызны тәмамлап, җәйге каникулга, ялга таралачакбыз. Ә Зыя абый белән мин үз авылыбызга, Йосыф авылына, әниебез, әтиебез янына, туганнарыбыз янына кайтачакбыз. Бик сагындык әниебезне. Бергә уйнап үскән иптәш малайларыбызны да сагындык. Шундый кадерле минутларны көтәбез. Апрель артыннан тагын да җылырак, чәчәклерәк, хуш ислерәк җылы май ае, аннан июнь киләчәк, әнә шундый зур шатлыклар көтә безне. Һәм кинәт безнең йөрәкләрне генә түгел, бөтен җирне, җирне генә түгел, хәтта ай, кояш йолдызларны да тетрәтерлек (һәрхәлдә, ул чагында безгә бу шулай тоелды) шомлы хәбәр килә. Белмим, кем китергәндер бу хәбәрне, телефонмы, телеграфмы, газеталармы... Ләкин ул шул кадәр тиз таралды, әйтерсең бөтен дөньяны яктыртучы нурлы кояш сүнде... Безнең күләч йөзләребезне генә түгел, бөтен табигатьне караңгылык басты. Вакыйгаларның нинди тәртип белән агышы анык хәтеремдә түгел, ләкин йөрәгебезне тетрәткәне шул булды: Шәриф абый барлык укучы балаларны бер бүлмәгә җыйды да:

— Балалар! Зур кайгы килде. Сез бик яратып шигырьләрен укый торган, җырлый торган, балаларны да, халкыбызны да чын күңелдән яратучы бөек шагыйребез Габдулла Тукаев вафат булды. Бу зур талант иясен безнең халкыбыз беркайчан да онытмас. Үзе үлсә дә, аның шигырьләре беркайчан да үлмәс, халкыбыз күңелендә мәңге яшәр! — диде.

Яшьле күзләрен сөртә-сөртә, хөрмәтле укытучыбыз сөйләгән бу сүзләр безнең йөрәкләргә кереп мәңге онтылмас булып калды. Шәриф абый гына түгел, бу хәбәрне ишеткәч, без, балалар да, күз яшьләребез белән еладык. Хәтерем алдамаса, без ул көнне укымадык та шикелле. Башларыбызны иеп, йөрәкләребезгә авыр хәсрәт төяп өйләребезгә таралдык. Кайтып керсәк, өйдә тагын шом. Һаҗәр әбиебезнең күзләрендә яшь һәм куркыну.

— Балалар, барыгыз әле, тиз генә су буена йөгерегез. Сәгыйт абыегызның хәле ничек икән? — ди.— Көн озын үкереп өйдә елап утырды да елга буена төшеп китте. Алай-болай онытылып суга төшә күрмәсен. Аның холкын беләсез бит...

Кая инде белмәгән!.. Шигырь язган чакларында да, «Әлмәнсур»-ны, я башка шигырьләрне кычкырып укып йөргән чакларында да дөньясын оныта торган гадәте бар иде аның. Дәрт, моң, хис кешесе Сәгыйт абый. Һаҗәр әби сүзләрен ишетү белән, каршыбыздагы иске зират аша турыдан гына су буена йөгердек. Җәен гади бер инеш кенә булып кала торган бу елгачык яз җиттеме — котыра. Әллә кайлардан, урман араларыннан, басулардан, ерганаклардан җыйналган суларны җыеп зур ташкын булып җәелеп ага. Аның бу дуамал гадәте Зыя абый белән миңа яхшы таныш. Моннан алдагы гына елны зур бозга утырып агып барган җирдән, бөтереп-бөтереп чак кына боз астына алып кереп китмәде ул мине. Зыя абый белән Хөрмәтулла кулында озын таяк булып, аны миңа сузарга өлгермәсәләр, бәлки инде мин якты дөнья белән саубуллашкан да булыр идем. Ярый, бәхет бар икән әле...

Йөгерә-йөгерә килдек Зыя абый белән су буена. Елга үткән елдагыча котырынып ага иде. Ары карыйбыз, бире карыйбыз, су буенда күренми Сәгыйт абыебыз. Әйдә, өскәрәк, арырак барыйк әле, бәлки яр буйлап шунда киткәндер ул дибез. Кызу-кызу атлап бара торгач, ишетәбез — кемдер ыңгыраша, елый кебек. Карасак, Сәгыйт абыебыз зират коймасы буенарак, әле яңа гына борнап килгән яшел чирәмгә яткан да елый:

— Тукай җаный, бәхилләә мине! — дип кычкырып та куя.

Без аңа якын килергә кыймыйча басып торабыз. Бик кызганабыз аны. Чөнки без Тукай аның якын дусты да һәм шигырь язарга ярдәм иткән кеше дә икәнен, аның Тукайдан хатлар да алгалап торганын яхшы беләбез. Озак басып тордык без. Сәгыйт абыйга дәшәргә кыюлыгыбыз җитмичә. Ниһаять, үзе безгә таба әйләнеп карагач, мин эндәштем аңа.

— Сәгыйт мулла абый, аш ашарга кайт, Һаҗәр әби чакырды...

Ул минем әйтеп бетергәнне дә көтмәде, кулын да, башын да берьюлы селкеп:

— Барыгыз, кайтыгыз, кайт! — диде коры гына.

Без, читкәрәк китеп, кайтып китәргәме, юкмы дигән бер карарга килә алмыйча койма буенда тагын байтак кына басып тордык. Безгә бит Сәгыйт абыйны ашарга алып кайтудан да бигрәк Сәгыйт абыйны күзәтеп торырга кушты Һаҗәр әби. Без әле бәлки тагын бик озак вакыт шулай басып та торган булыр идек, ләкин Сәгыйт абыйның яткан җиреннән кинәт кенә торып утыруы, башы белән генә ымлап безгә хәзер үк китәргә кушуы безне кайтып китәргә мәҗбүр итте.

Без кире өйгә кайтып үзебезнең күргәннәребез турында сөйләгәч, Һаҗәр әби:

— Казанга үткән баруында Сәгыйт абыегыз Тукай белән үпкәләшеп кайткан. Соңгы күрешүләре булган икән шул бу... Тукай белән яхшылап татулашып та, бәхилләшеп тә кала алмаганына шулай үкенә, өзгәләнә ул,— диде.

Инде бу хәлләргә ярты гасырдан ары вакыт үтте. Ләкин Шәриф абыйның Тукайның үлеме турындагы хәбәре, аның күзенә тулган мөлдерәмә яшь, Сәгыйт абыйның су буена төшеп үксеп-үксеп елавы, бу хәбәрне ишеткәч үзебез дә кичергән авыр минутлар бүгенгедәй хәтеремдә әле. Тукай үлеме әнә шулай сакланып калды минем күңелдә. Сараш турында сүз барганда тагын шуны да сөйлисем килә.

Сараш мәктәбе, Шәриф һәм Сәгыйт Сүнчәләйләр, алар белән якыннан аралашу без — балаларның гына түгел, әтиебезнең тормышына да зур йогынты ясады. Кыш көннәрендә азык-төлек китергән арада әти Сараштa, безнең янда ике-өч көн торып китә һәм Шәриф абыйларда үткәрелә торган атна кич мәҗлесләрендә дә катнаша иде. Дөрес, ул җырлый да белми, нинди дә булса музыка коралында да уйнамый, ә инде тыңларга дисәң — аны куш. Шул кадәр бирелеп тыңлый иде ул музыканы. Аеруча скрипка моңын ярата иде ул. Шуңа күрә дә Шәриф абыйларның ике-өч скрипкаларының берсен сатып алды да, безне, аеруча мине, скрипка уйнарга өйрәнергә кушты. Һәм мин аз булса да Шәриф абыйдан скрипка уйнарга да өйрәндем. Инде әйткәнемчә, әти бер төрле музыка коралында да уйный белми, җырлый да белми, Нурулла мулла кебек сандугач булып та сайрамый. Ләкин сөйләшеп утырырга, дөнья хәлләренең барышы, дөньядагы хәл-әхвәлләр турында әңгәмә алып барырга дисәң — монысына инде безнең әти оста. Ул барыннан да хәбәрдар. Чөнки ул татарча басыла торган газета-журналларны җентекләп укып бара. Укый бару гына да түгел, ул һәр нәрсәдә яңалык тарафдары. Ул чын мәгънәсендә мәгърифәтче-тәрәккый пәрвәр кеше. Шуның өчен дә ул татарның яңа тип зыялыларына, укымышлыларына, хәзергечә әйтсәк, интеллигенциясенә чит кеше түгел. Ә әти өчен Шәриф Сүнчәләй укытучы буларак — идеал. Ул безне дә киләчәктә әнә шундый укытучылар итеп күрәсе килә. Милләткә, халыкка хезмәт, халыкның тормышын, көнкүрешен җиңеләйтү өчен, кешеләрне югары әхлаклы, кешелекле кеше итү өчен, тәрбиячегә иң әлек үзенә белем, культура кирәк икәнлеген әти яхшы аңлый иде.

Тәлгат Галиуллин

# МАТУРЛЫККА БАЙ УЛ БЕЗНЕҢ ЗАМАН...

И. Юзеевның иҗат портретына эскизлар

## Табигатем минем ерганактай...

Илдар Юзеев татар поэзиясенә «Таныш моңнар» поэмасы белән килеп керде. Шаулап килеп керде һәм тиз арада яшьләрнең яраткан шагыйре булып китте. Дөрес, бу — аның беренче әсәре түгел. Шигърият өлкәсендәге гәүгә адымнарын ул илленче елларның башында ук ясый башлый. Әмма ул әсәрләр шагыйрь иҗатында сизелерлек эз калдырмаган.

Илдар Юзеев «Таныш моңнар»дан соң да йөзләрчә шигырьләр, дистәләрчә поэмалар, баллада һәм җырлар иҗат итте. Ләкин хисләренең киеренкелеге, лирик аһәңе, мавыктыргыч сюжеты һәм геройларының самимилеге ягыннан чыгып караганда, бу поэма һаман да шагыйрь иҗатындагы иң уңышлы әсәрләрнең берсе булып кала килә. Коры риторикадан, тормышны натуралистик кабатлаудан баш тартып, бу поэмасында шагыйрь психологик анализны алгы планга чыгара. Көндәлек дәфтәреннән, хатлардан өзекләр кертү, кешe хисен, мәхәббәтнең матурлыгын җыр һәм моң аша ачу, диалог һәм эчке монолог алымнарын кичерешләр үсешен сурәтләүгә буйсындыра белү шул хакта сөйли.

«Таныш моңнар» бик вакытлы язылган, көтеп алынган поэма була. Кешенең рухи халәтен, эчке дөньясын табигый камиллегендә сурәтләүгә омтылыш ахырдан шул еллар поэзиясенең үсешен билгеләгән юнәлеш булып китә. Ш. Галиев, Г. Афзал, Х. Камалов, Ә. Баянов һәм И. Юзеев шикелле «беренче дулкын» шагыйрьләр иҗатында бу сыйфат аерата ачык төсмерләнә. Әлеге шагыйрьләр сугыштан соңгы поэзиядә нык тамыр җәйгән декларативлыкка, шаблон фикерләргә каршы чыгалар, «укучы белән гади һәм табигый тонда, күптәнге дуслар кебек сөйләшергә»[1] тырышалар.

Шул еллар тәнкыйте И. Юзеевны бертавыштан «яшьлек һәм романтика» җырчысы дип атый. «Илдарнең иҗаты башыннан ахырына чаклы яшьлек турында,— дип яза Сибгат Хәким,— аның чордашларыннан бу теманың стихиясенә кереп, үзенең тәмам романтикасына әйләндергән башка бер шагыйрь дә юк. Ул картайганчы яшьлектән аерылмый торган шагыйрь булып калачак»[2]. Дөрес, И. Юзеевның

[1] Р. Мостафин. Җаваплылык хисе. «Казан утлары» журналы. 1972 ел. 1 сан. 170 бит.

[2] С. Хәким. Үз тавышың белән. 1969 ел. 208—209 битләр.

«Тынлык белән сөйләшү», «Соңгы сынау», «Язылмаган поэма» кебек әсәрләре белән таныш укучының соңгы җөмләдәге фикерләр белән килешеп бетмәве дә мөмкин. Чөнки аларда ул, яшьлектән аерый алмый торган автор булудан бигрәк, гомум гуманистик төшенчәләр белән эш итә, батырлыкка дан җырлый, фәлсәфи киңлеккә омтыла торган җитди шагыйрь буларак күз алдына баса. Хәзергә бер нәрсә бәхәссез: шагыйрь олы поэзиягә яшьлекнең күркәм сыйфатларын, матур бүгенгесен һәм тагы да гүзәлрәк киләчәген романтик биеклеккә күтәреп җырлаган әсәрләре белән килеп керде. «Таныш моңнар» янына «Миләүшә», «Таймас», «Фәрит-Фәридә», «Өчәү чыктык ерак юлга»... шикелле поэмаларын, дистәләгән шигырь-җырларын өстик. Үзәктә шул ук яшьлек, мәхәббәт, әхлак һәм батырлык темалары ята.

Яшьлек, мәхәббәт темасы әдәбиятыбызның буеннан-буена кызыл җеп булып сузылып килгән иң үзәк темаларның берсе. Яшьлек хисләре белән рухланмаган, бу хакта бер генә булса да әсәр язмаган сүз остасын табуы ифрат кыен эш. Башка әдипләрнең шул ук темага багышланган әсәрләреннән И. Юзеев поэмалары кайсы яклары белән аерылып торалар соң?

Беренчедән, аның әсәрләренә мөлаем лиризм, самимилек һәм тирән моң хас. Үз замандашының характеры ныгу, дөньяга карашы формалашу турында шагыйрь салкын һәм ваемсыз тон белән түгел, ә тирән борчылып, дулкынланып, кирәк икән әсәрләнеп яза. Шагыйрь белән аның геройлары арасында тирән аңлашу, әхлакый һәм эстетик якынлык хөкем сөрә. Лирик «мин»нең әнә шундый активлыгы әсәрнең ышандыру көчен, шигъри сөйләмнең эмоциональ тәэсир көчен арттыра, шул ук вакытта аны җанлы сөйләм теленә якынайта.

Икенче үзенчәлек шуннан гыйбарәт, яшьлек И. Юзеевны гадәти бер халәтендә генә кызыксындырмый. Ул сюжет канвасы итеп мөһим сынау, әхлакый борылыш моментын ала һәм, аны соң чиккәчә үстереп, геройларын куе буяулар аша хәтергә сеңеп калырлык итеп тасвирлый. Шагыйрьне, вакыйга-хәлләр агышыннан бигрәк, шәхеснең рухи дөньясы, киеренке әхлакый эзләнүләре, давыллы, яшенле каршылыкларның чишелеш процессы кызыксындыра. И. Юзеев поэзиясенә хас психологик романтизмны менә шул үзенчәлекләр тудыра да инде.

Композициясе һәм ритмик аһәңе буенча гаять үзенчәлекле булган «Өчәү чыктык ерак юлга...» поэмасында тормышта үз юлыңны эзләү һәм табу мәсьәләсе үзәккә куела:

Сезнең алда ике юл бар,
Теләсә кайсын сайлагыз
Үзегез, ди көккүк!
Алда әле борылмалар бик күп, көк-күк!
Я түзегез,
Я китегез
Кирегә,
Хәл итегез
Үзегез, ди көккүк! Көк-күк!

Яшьлек — кеше гомеренең кабатланмый торган иң гүзәл һәм шул ук вакытта иң җаваплы бер чоры. Бер яктан, җиңел тормыш сандугачлы бакчалары белән яшьлекне үзенә тартып, кызыктырып тора. Ә икенче якта — авыр юллар романтикасы, кырыс тормыш реализмы. Шагыйрь әлеге юллар арасындагы киеренке каршылык турында җитди уйлана.

И. Юзеев бу поэмасында үзен композиция һәм форма остасы итеп тә таныта. «Өчәү чыктык ерак юлга...»ның ритмикасы тормышның үзе шикелле үк күп тавышлы: бер урында ул, челтерәп аккан тау чишмәседәй, уйнак, дәртле, тынгысыз, икенче бер төштә, ләйсән яңгыры кебек, йомшак, назлы, уйчан.

Илдарның яшь герое ярты юлда туктала кала торган булдыксыз кеше түгел. Ул — көчле шәхес. Мисал рәвешендә «Светлана», «Шундый безнең егетләр», «Табигатем минем ерганактай», «Ике малай китә армиягә», «Ул әлегә фамилиясез йөри» кебек шигырьләрен атап булыр иде.

Тау башында ул җыелып торды,
Һәм бер көнне, ашап ташларны,

Тын суларны әйдәп үз артыннан,
Биек таудан аска ташланды.

. . . . . . . . . . . . . .

Җил үткәрмәс тауга ышыкланып,
Күлләр генә акмый тын тора...
Табигатем минем ерганактай,
Шау-шуларга, алга омтыла.

(«Табигатем минем ерганактай...»)

Кеше язмышы хакында уйлану рәвешендә язылган «Светлана» шигыренә тукталыйк. Яшьлек елларын кире кайтарып булмавын аңлаудан туган җиңелчә сагыш та, кешелекле моң һәм үкенеч тә бар биредә. Ләкин шигырьнең композицион үзәге ул түгел.

Шагыйрь тегермәнче кызы образында гади халык вәкилләренә хас чаялыкны, тәвәккәллекне һәм тормышка чиксез мәхәббәтне күрсәтергә ниятли. Геройга характеристика биргәндә, тарихи җырлардан килә торган традицион чагыштыру да урынлы яңгырый, ул шигырьнең эмоциональ рухына, гомуми интонациясенә ятышып тора:

Тегермәнче кызы Светлана
Атылып киткән җитез ук иде,
Ул йөрмәгән урман, ул менмәгән агач,
Ул шумаган таулар юк иде.

«Ике малай китә армиягә» шигырендә И. Юзеев башка бер сыйфаты белән ачыла:

Язгы ташуларда
Аккан бозга басып,
Икәү килә елга буйлатып;
Берсе җырлый шашып,
Изүләрен ачып,
Икенчесе килә уйнатып:
— Сау булыгыз, кызлар,
Сагынырсыз, кызлар,
Таң атканда инде булмабыз.

«Шушы бер күренеш һәркемдә әллә никадәр хис уята. Кыю, батыр, шашкын яшьлек»[1] хисе уята. Биредә бер генә артык сүз юк. Һәммәсе үз урынында, кирәк җирендә. Автор шигъри сөйләмне соң чиккәчә тыгызландыра, аның эчке җегәрен ача һәм прозада берничә бит таләп иткән күренеш-картинаны берничә юлга сыйдыра. Ике егетне табигый фонда төгәл һәм колоритлы итеп күз алдына бастыруы, пластик сурәте белән шигырь рәсем сәнгатенә якын. Ил сакларга китүче өлеге яшьләрне тот та бөтен килеш-килбәтләре белән киндергә төшер.

И. Юзеев лирик табигатьле шагыйрь, дидек. Ул поэмаларында да, хәтта драматик әсәрләрендә дә төбендә лирик булып кала. Шул ук вакытта шагыйрь, дилбегәне тулысынча «лирик стихия» кулына тапшырып, үз хисләрен, кичерешләрен сурәтләү белән генә дә чикләнми. Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, автор хәтта лирик шигырьләрендә дә вакыйгалы сюжетка таяна, характерлар тудырырга омтыла.

Шагыйрь яшьлек турында яза икән, димәк, ул мәхәббәт коллизиясен дә читләтеп үтә алмый. Чөнки яшьлек үзен күбрәк шул олы һәм изге хис аша таныта. Илдарның «Таныш моңнар», «Таймас», «Миләүшә» кебек поэмалары, дистәләгән шигырьләре мәхәббәтне олылауга багышланган.

«Миләүшә», «Таймас» поэмалары сәнгатьчә үзенчәлекләре ягыннан «Таныш моңнар»га якын тора. Ләкин алар арасында аерма да бар. Тәнкыйтьче Р. Башкуров бик

[1] С. Хәким. Үз тавышың белән. 208 бит.

хаклы рәвештә болай дип язган иде: «Таныш моңнар» һәм башка шундый беренче әсәрләрендә конфликт нигездә кеше хисләренең үзара эчке бәрелешенә корылган. «Миләүшә», «Таймас» поэмаларында исә яшь геройларның тирән өметләре, заманыбызга хас идеаллары драматик вакыйгалар белән кискен бәрелешкә керә, шул бәрелештә ныгый һәм чыныга»[1].

Шунысын да әйтергә кирәк, әлеге тематикага караган әсәрләр арасында «Таныш моңнар» үзенә бер үр булып калды. Аннан соңрак язылган әсәрләрендә ясалмалык, сентиментальлек шактый нык сизелә. Үз вакытында уңай бәя алган «Миләүшә»гә әйләнеп кайтыйк. Биредә ике кешенең мәхәббәте Илдарча бер иплелек, нәзакәтлек белән сурәтләнә.

Укучы яшьләр үзара аңлашыр, мәхәббәт чәчәк атар, дип көтә. Менә шунда арага өченче берәү — хром итекле, галстуклы, ялыктырып бетергән традицион тискәре герой — Хәмзә килеп керә. Миләүшә Хәмзәгә «текәп карамый, күңелендә аның башка егет». Шуның аркасында конфликт та үзенең тормышчан нигезен югалта шикелле. Ләкин ул да түгел, шагыйрь хыялы яңа ситуация тудыра. Хәмзә иң тупас әшәкелеккә бара: Миләүшәне көчләп хатынлыкка урлап китә. Лиризмны комик ситуация алыштыра. Җитди белән көлкене, лиризм белән юморны кушарга омтылу юлында ясалган эксперимент кызыклы һәм үстерелергә тиешле алым булса да, поэманың мондый бетеме укучыны ышандырмый. Хәтта Шамил белән Миләүшә мәхәббәтен дә баштагы шикелле җитди кабул итми башлыйсың.

Мәхәббәт белән батырлык, яшьлек белән үлемсезлек янәшә атлыйлар. «Фәрит-Фәридә» поэмасында И. Юзеев шул хакта уйлана. Башыннан ахырына чаклы романтик алымда язылган бу поэмада «яңа гына ачылырга торган чәчәкләрне» хәтерләткән мәхәббәт белән явыз ерткычлык, яктылык белән караңгылык, көн белән төн бәрелешә. И. Юзеев яшьләрнең сөешүен, батырлыгын күе төсләр аша тасвирлый. Романтизм стиленә хас булганча, ул вакыйга-хәлләрне мотивлаштыруны, тормыш канунна рына яраштыруны да кирәк тапмый. Мәсәлән, күгәрчен, халык җырларындагыча, төрмәдә утыручы яшьләр арасында хат йөртә, туган табигать яшьләрнең җырын еракларга илтә. Фәритеннән аерып торган төрмә стенасын Фәридә түбәндәгечә күрә:

> **Ул еракта...**
> **Ай, бик еракта,**
> **Биек таулар,**
> **Бозлы карурманнар**
> **Каплап тора аны ул якта.**

Романтик шартлы алымнарга таянып, автор сугышка, явызлыкка нәфрәт уята, шәхси омтылыш белән иҗтимагый идеаллар бердәмлеге нигезендә туган батырлыкка дан җырлый. Шагыйрь алдагы елларда да шул нигездәге эзләнүләрен дәвам иттерә. «Авылым легендасы», «Идел-Даугава», «Язылмаган поэма», «Тынлык белән сөйләшү», «Соңгы сынау» әсәрләре шул юлның мәгълүм үрләре булдылар.

И. Юзеев поэзиясенең халыкчан нигезләре елдан-ел тирәнәя бара. Ул үзен халык күңеле, халык рухы, халык тормышы, халык тарихы белән бәйли торган җанлы җепләрне ныгытырга, камилләштерергә тырыша. Шуңа бер үзенчәлекле дәлил рәвешендә шагыйрьнең художество деталенә, тормыш-көнкүреш нечкәлегенә игътибарлы булуын атап үтәргә мөмкин. Сәнгатьчә детальләрдән һәр шагыйрь файдалана. Ләкин күпчелек шагыйрьләрдән аермалы буларак, И. Юзеевта ул әсәрнең үзәк идеясен һәм шәхеснең психикасын, кичерешләр тезмәсен ачып бирү чарасына әверелә. «Тып-тын иртә», «Ике күз карый дөньяга...», «Ертылган рәсем», «Ап-ак клавишларга кагылдың да...», «Әтнә истәлеге», «Толымнар» шигырьләрен искә төшерик. Бу әсәрләрендә шагыйрь үзенең конкретлыгында зур гомумилек көченә ия булып, нурлар уйнатып торган тыгыз мускуллы тормышчан детальне үзәккә ала. Әйтик, шагыйрь сугышка каршы булган нәфрәтен чагылдырырга ниятли. Бу хакта, газета мәкаләләрендәге шикелле, җәелеп сөйләргә дә мөмкин. Әдип башкарак юлны сайлый,

---

[1] И. Юзеев. Миләүшә. Казан. 1968 ел. 128 бит.

ул тынын бер иртәдә урамнан атлаучы инвалидка игътибарын юнәлтә, протез шыгырдавын теш сызлавына тиңләп, гомумирәк фикер әйтергә җай таба:

Тып-тын иртә.
Һәр шыгырдау искә төшерә таза чагын,
Шыгырдый ул, шыгырдый ул адым саен.
Тып-тын иртә.
Таяк гүя Морзе кебек хәбәр йөртә,
«Сак булыгыз дошманнардан!» — диеп үтә.

И. Юзеев халык иҗатына тирән мәхәббәт тотучы, аның энҗеләрен хуҗаларча саклап, кирәк урыннарда гына аннан файдалана белүче шагыйрьләрнең берсе. Хикмәт фольклорның традицион образларын, символларын шигырьгә кочагы белән алып керүдә, ритмик бизәкләрен яңача яңгыратуда гына түгел. Шагыйрь борынгыда туган сәнгать белән бүгенге көн арасында якынлык эзли, чагыштыра, бәхәсләшә, исбат итә... В. Терешкованың космоска очуы уңае белән язылган «Көянтәңне куй да...» шигыре халык арасында киң таралган легенданы искә алу белән башланып китә. Легендада сөйләнгәннәргә караганда, ятимә кыз Зөһрә, үги анасының кыерсытуына, җәберләвенә түзә алмыйча, айдан аны үзенә күтәреп алуын үтенә. Ай ятимәне кызгана һәм Зөһрәнең ярлыкасын кабул күрә. Менә шул рәвешле, татар кызы көянтәсечиләге белән мәңгегә айда торып кала.

Шул легенда ярдәмендә укучы күңелендә үзенә кирәкле тойгылар уяткач, И. Юзеев совет кызының космоска очу вакыйгасын тасвирлауга күчә. Шигырьнең композициясе катлаулана, әгәр шулай әйтергә ярәсә, икенче мәгънәви баскычка күтәрелә, халык хыялының җимеше чынбарлыкка урын бирә. Автор төрле иҗтимагый шартларда яшәгән ике шәхес язмышын чагыштыра, аларны капма-каршы куя. Әкият, легенда мотивларына, халык иҗатының үзенчәлекле сәнгатьчә ысулларына таянып, И. Юзеев колоритлы, романтик омтылышлы, халык характерының асыл сыйфатларын үзенә җыйган образлар тудыра. Кеше рухының олылыгына дан җырлый. Күтәренке патетик рухлы һәм йөгерек телле балладаларында шагыйрь халык иҗаты гәүһәрләренә бигрәк тә киң таяна. «Егет һәм курай» балладасында ул матурлыкны сиземли белә торган, хискә, тойгыга бай җанлы табигать баласын иҗат итә. Егет, җәбер-золымнарны, кара көчләрне өстеннән ташлап, яңа тормышка аяк баса. Туган ил белән бердәмлек шәхескә бәхет алып килә. «Авылым легендасы»нда шагыйрь кешегә дан һәм рухи үлемсезлек алып килгән идеаллар турында уйлана.

Ниһаять, И. Юзеев иҗатының тормышчанлыгын, аның халык сөенече, халык көенече белән яшәүче шагыйрь икәнен раслаучы тагы бер мисал китерик. Мин шагыйрьнең замана каршында җаваплылык тоеп, ил сулышын, иҗтимагый-тарихи прогрессны иҗатында чагылдырырга омтылышын күздә тотам. Көндәлек тормышның һәр вакыйгасы турында рифма коюга керешмәсә дә, чор алып килгән шатлык һәм низаглардан шагыйрь йөз чөерми. Ул фән-техника үсеше, космосны яулау турында дәртләнеп шигырь яза («Ул әлегә фамилиясез йөри»), физиклар белән лириклар арасында кабынып киткән бәхәскә катнаша («Ризалар»). Соңгы әсәрендә әдип физика ачышлары белән поэзиянең кеше йөрәген чагылдыру юлында ясаган ачышлары арасында эчке якынлык, бердәмлек таба:

Галәмчеләр,
    батыр очучылар
Лириканы канат итәләр;
Планеталар
    яңа физикларны,
    яңа лирикларны көтәләр.
Фәнгә гашыйк булган очучылар
Эчтән шигырь ятлап узалар...
Бәхәс тынды...
Физиклар да,
Лириклар да инде ризалар.

Борчулы-уйчан интонациясе, гуманистик пафосы һәм тормышка җитди карашы белән И. Юзеев иҗаты бүгенге совет сәнгатенең югары казанышлары белән янәшә тора.

## Сакмы йокың, Кеше!

Тормыш ыгы-зыгысы артыннан йөреп аруның соңгы чигенә җиткән яшь ана изелеп йокыга талган. Сабыйның исә монда гаме юк. Ул үз эшендә — уйнавын белә. Уен белән мавыгып, бер вакыт ул биек караватның читенә үк килеп җитә. Менә-менә сабый бала идәнгә егылып төшәр дә тавыш күтәрер... Иң начары — имгәнер, гомерлек гарип калыр...

Көндәлек бер вакыйга, артык гадәти бу эпизод шагыйрьгә укучының күңел кылларын чиртү һәм контрастлы символик сурәт тудыру өчен кирәк. Баксаң, газиз бала язмышы белән җир шары язмышы арасында нинди дер эчке якынлык, уртаклык бар икән:

Кеше хәзер Җир-анадан
Көчлерәк.
Кеше — ана, ә Җир — сабый
Төслерәк.
(«Сакмы йокың, Кеше?»)

Җир шары һәм сабый бала... Төрле яссылыктагы төшенчәләрне бу рәвешле якынлаштыру, янәшә куеп чагыштыру көтелмәгәнчә булуы белән игътибарны үзенә тарта. Шагыйрь Җир шарының киләчәге, язмышы өчен тирән борчыла, дулкынлана. Сакмы йокың, Кеше? Кулларыңнан Җир шары ычкынмасмы соң? кебек риторик сорауларның кабатлана-кабатлана килүе дә шул хакта сөйли. Планетабызның язмышы кеше кулында, ди шагыйрь.

Әлеге идея И. Юзеев иҗат иткән байтак әсәрләренең лейтмотивы булып бара. Шартлы, романтик алымнарны реалистик сәнгать казанышлары белән синтезлап, сәнгать белән тормыш арасындагы бик күп катлаулы мөнәсәбәтләрне үзәккә алган «Тынлык белән сөйләшү» поэмасына тукталыйк. Поэма сугыш уты белән уйнаучыларга, атом маньякларына һәм гомумән кешегә явызлык теләүче иҗтимагый көчләргә каршы юнәлдерелгән. Үзәктә Бөек Ватан сугышы тора. Бу афәттән соң чирек гасырдан артыграк вакыт узуга карамастан, сугыш яралары һаман да саркып тора, аның куркыныч күләгәсе халык күңеленнән һаман да китми әле. Сугыш афәте әле дә кешеләрне куркытып, шомландырып тора. Вьетнамда кан коею дәвам итә. Газеталар кеше үтерә торган яңадан-яңа кораллар хакында хәбәр итәләр. Кыскасы, сугыш кылычы, менә-менә төшәм дип, баш очында эленеп тора. Мондый фаҗигале киеренкелекнең сәбәбе нәрсәдә соң? Шагыйрь аны бер сүз белән билгели: гамьсезлек! Фашизмның йогышлы чире тамыр җибәргән вакытта да гамьсезлек, ут әле безнең капкага килеп капмаган, күрше чыксын дип, бер дә пошынмыйча яшиләр бирган. Ә соңыннан инде соң булган: 50 миллионлап кешенең гомере киселгән. Гамьсезлек әле бүген дә сугыш чукмарлары тегермәненә су коюны дәвам итә. Шагыйрь кешелек тарихын, аның үсеш перспективасын революцион гуманизм позициясеннән килеп яктырта. Пассивлык фәлсәфәсен, язмышка баш бөгеп яшәүне кискен кире кагу белән бергә, коммунизм идеаллары белән рухланган әдип дөньяның киләчәгенә тирән ышаныч белән карый.

Сугыш афәтенә каршы чыгу мәгънәсезлек, язмыштан узмыш юк дип яшәүче кешеләрдән аермалы буларак, шагыйрь кешедәге сәламәт һәм актив башлангычны хуплый.

Гуманизм һәм явызлык темасына И. Юзеев еш кына бөтенләй көтмәгәндә, уйламаганда килеп чыга. Менә лирик герой бөтен барлыгы белән онытылып, сихерләнеп һәм әсәрләнеп Америка пианисты Ван Клиберны тыңлап утыра. Кинәт моң өзелә. Музыкаль ноталарны «Пентагонның янап җибәрелгән» ноталары алыштыра, колакка бомбалар шартлаган тавышлар ишетелә башлый...

Һәрбер узучыны үзенә тартырлык, кызларны көнләштереп, «уф алла» дип әйттерерлек чәч толымнары икенче бер картинаны тудыра:

Без кинода,
Ут сүнә...
...Әнә...: Фашист шундый матурлыкка
Вәхши кулы белән үрелгән.
«Үлем фабригында», тау-тау булып,
Озын кара чәчләр өелгән.

(«Толымнар».)

Шигырьләрнең композицион алымы «Сакмы йокың, Кеше?» әсәре белән уртак. Үзәк вакыйганы, идеяне гадәти бер тормыш күренеше тудыра, ике төрле халәт капма-каршы куела, кискен контрастлы-килешүсез сурәт туа. Антитеза табигатьтә, чынбарлыкта барган каршылыклар көрәшен образлар аша чагылдыра. Шигырьдән-шигырьгә кучә-күчә килгән бу алым — контрастлар антитезасы — вакыты белән кабатлануга, стереотиплыкка алып килсә дә, күпчелек әсәрләрдә уңышлы яңгырый, И. Юзеевның романтик сәнгатенә ятышып тора.

Сугыш турында язылган әсәрләренең нигезе итеп И. Юзеев үзе яхшы белгән янсә кат-кат сыналган вакыйга-хәлләрне генә ала. Үзәктә реаль чынлык, хәтта документальлек ята. Ф. Кәрим, Х. Мөҗәй, М. Җәлил турындагы әсәрләрне искә төшерик. Барысы да реаль фактларга таянып язылган шигырьләр һәм поэмалар.

«Язылмаган поэма»сын И. Юзеев үзе дә бик ярата бугай. Укучылар белән очрашулар вакытында гел шул әсәрен укый, һәр юлын-сүзен яңадан кичереп, дулкынланып, татар шагыйре Мөҗәй өчен горурланып укый. Поэма мөрәҗәгать-монолог алымы белән башланып китә. Фашистлар тарафыннан крематорийда яндырылырга хөкем ителгән шагыйрь-коммунист Хәйретдин Мөҗәй тормышының соңгы минутларында Иделенә, Казанына, яңа буын татар шагыйрьләренә мөрәҗәгать итә. Алдагы юлларда поэма тагын да ачылып, тармакланып китә. Күп сыйдырышлы композиция, бер яктан, эре штрихлар белән тирәлекне, фонны сурәтләргә мөмкинлек бирсә («Германия. Дахау. Концлагерь»), икенчедән, батырның тормыш баскычларын иңләп алырга җай тудыра. Үлем җәзасын көткәндә Мөҗәй яшьлек җырын («биек-биек тауның башларына менәселәр безнең бар әле...»), тормыш иптәшенең җылы куенын, карурманда дөрләткән учакларын, анасының йомшак түшәгендә күргән татлы төшләрен исенә төшерә... Шунда ук патетик киңлек, караңгы Европа күген томалап торган кара болытны алып ташлап, киләчәккә ыргылган оптимистик гомумиләштерү:

Дөрләп яңа-яңа:
«Тормышымның
«Дәвамы бар!» — диеп кычкырам.
Баеп барган кояш нурларында
Каннарыбыз яна, күрегез!
Безнең януларны Кызыл Байрак итеп,
Киләчәккә илтеп элегез!

Мөҗәйнең батырлыгы сирәк очрый торган илаһи бер хәл итеп каралмый. Совет илендә тәрбияләнгән һәм авыр сынау көннәрендә биек идеалларына турылыклы калган геройлар меңләгән, ди шагыйрь. Мөҗәй дә үлеме алдыннан дан турында, тарихта исемен калдыру турында уйламый. «Язылмаган поэма» — романтик стильдә иҗат ителгән әсәр. Ләкин поэманы укыганда аның шартлылыгын бөтенләй сизмисең. Ул бер тын, бер сулыш белән укыла. Бу инде олы эчтәлеккә бәрабәр форма, дәрескә, алар арасында тулы гармония табылган дигән сүз.

«Соңгы сынау» поэмасы да әле генә карап үткән әсәргә бик якын тора. И. Юзеев, Муса Җәлилнең төрмәдәге көрәше һәм батырларча үлеме турында сөйләгән чыганакларга таянып, герой-шагыйрьне иң авыр һәм хәлиткеч бер моментта сурәтли. Шул мизгелдә аның туган иленә тугрылыгы, намусы һәм рухы соңгы сынауны кичерә. Буйсынмас рухы һәм киләчәккә ышанычы белән ул тираннан да көчлерәк. Бу ситуациядә Мефистофель образының поэмага килеп керүе дә аклана. Фантазиясенә нигез итеп шагыйрь бер тормыш детален алган: «М. Җәлил үлем җәзасы алдыннан Гете-

ның «Фаустның соратып китерткән. Гете трагедиясендәге шикелле үк Мефистофель монда да явыз һәм хәйләкәр рухлы булып калган. Сыналган чаралары ярдәмендә ул шагыйрьне алдарга тырыша: аның алдына гүзәл таң кызын китереп бастыра, шәраб вәгъдә итә, туачак көннең дәһшәтләрен сурәтли, шагыйрьнең көчле ныклыгын, идеалын какшатырга хыяллана. Мефистофельгә шагыйрьнең җаны, элеккеге иманыннан йөз чөерүе кирәк. Шуның бәрабәренә ул аңа йөз ел гомер вәгъдә итә. Гаҗәп хәл: шагыйрь рухи ныклыгы, гуманизмга һәм үлемсезлеккә омтылышы белән иблистән дә куәтлерәк булып чыга. Мефистофель мәхбүскә мондый көчнең туган җирдән, Алып батырлардан, Алпамышлардан килүен аңламый. Явызлык, караңгылык социалистик идеал белән көрәштә чигенергә, җиңелергә мәҗбүр була.

Без алдарак И. Юзеевны яшьлек һәм мәхәббәт җырчысы дигән идек. Соңгы елларда ул илһамын ешрак сугышка һәм иҗтимагый явызлыкка каршы юнәлтә икән. Шул ук вакытта шагыйрь иҗатының бу ике тематик юнәлеше арасында фәлсәфи уртаклык күрүе дә кыен түгел. Вәхшилек яшьлекнең һәм матурлыкның явыз дошманы. Ул утлы күсәген яшьлекнең изге хыялларына, күркәм омтылышларына каршы күтәрә. Яшьлекне романтик калкулыкка күтәреп җырлау сугышны реалистик фаш итүгә, ләгънәтләүгә алып килә.

## Урам буйлап җырлап үтәм мин...

И. Юзеев иҗатын музыкадан, җырдан башка күз алдына китерүе кыен. «Таныш моңнар», «Фәрит-Фәридә», «Өчәү чыктык ерак юлга...» поэмаларында, мәсәлән, яшьләрнең тирән тойгыларын, характерларын һәм дөньяга карашларын ачуда көй белән моң мөһим роль уйный. Әйтелмәгән мәхәббәт хисен, сагышны җыр тәгърәк, күркәмрәк итеп җиткерә. «Миләүшә» поэмасында җыр ике кеше арасында элемтәче, арадашчы ролен үти торган символик үзәк образ дәрәҗәсенә күтәрелә. Мондый илаһи һәм гүзәл, иртәнге авыл һавасы шикелле саф мәхәббәтне гади сүзләргә күчерсәң, ул матурлыгын югалтыр иде сыман.

...Яшь егет, яшел тугайларын, зифа шомыртларын, туган авылының борылмалы-сыгылмалы юлларын һәм «зәңгәр косынкалы» сөйгәнен калдырып, читкә китә. Хисләр аның ахыргача тартылган скрипка кыллары шикелле. Алар ташып, ярсып китәргә генә торалар.

Артка карадым да каерылып,
Түзәлмәдем, җырлап җибәрдем:
«Син каласың миннән аерылып,
Я, хуш инде, җаным, чибәрем».
Туган якларымның чәчәкләре,
Ак каеннар,
таллар,
тирәкләр,
Сау булыгыз...
(«Җырлап уздым урман арасын...»)

Халыкта якын кешеңә чәчәк бүләк итү гадәте бар. Поэмада шагыйрь шул йоланы үзгәртә, аның герое сөйгәненә истәлек итеп гөлләр калдырмый, чөнки алар шиңәчәк. Ул яратканына җырлар бүләк итә:

Җырлар бирәм,
Гүзәл җырлар бирәм,
Җил дә алмый
һәм кырау да тими аларга.
(«Җырлар бирәм».)

Бу җырлар — М. Җәлилнең палач балтасы астында язылган җырлары. Җыр биредә, үзенең төп функциясен яңартып, көрәш коралы, азатлык идеалы буларак сурәтләнә.

Җырга, моңга мәхәббәт ул — табигый матурлыкка, туган җиргә мәхәббәтнең бер чагылышы.

Әмма җыр ярату, аның белән илһамлану әле бер хәл. Композиторны рухландыра алырлык җыр тексты язу бөтенләй башка әйбер. Дистәләрчә шигырь язучы авторларның бик сирәге генә җыр жанрында уңышлы эшли. Яшь шагыйрьләр бу катлаулы, авыр жанрны ерактан ук әйләнеп үтәләр.

И. Юзеев — халык теленнән төшми торган уңышлы җырлар авторы. «Төнбоек», «Яшь наратлар», «Кайтам инде», «Шофер» шикелле җырлар, спектакльләргә язган күп кенә җырлары халык илһамы тудырган лирик әсәрләр белән бер абруйда йөри. Аларга образ ачыклыгы, фикер тыгызлыгы, эмоциональ куелык һәм ритмик пөхтәлек хас. Шагыйрь милли җыр стихиясенә киң таяна, аның эчке гүзәллегенә тирән үтеп керә.

«Төнбоек» җырының үзәк шигъри образы — әдипнең үз иҗат җимеше, үз казанышы, халык җырларында таралган образ түгел. Шул ук вакытта төнбоек сурәте, мәгънәви һәм стилистик функциясе, яңгырашы буенча, халык рухы тудырган традицион образларга якын тора, дәресрәге, шулардан үсеп чыга. Төнбоек, халык җырларындагы үзәк шигъри образлар шикелле үк, туры һәм күчерелмә мәгънәләрендә алынган. Лирик сюжетның агышы да күп мәгънәлек белән бәйле. Җырның эчтәлеген лирик геройның эмоциональ төсмергә бай һәм динамик үсештә алынган мәхәббәт кичерешен сурәтләү тәшкил итә.

Иң әүвәл шагыйрь, «төнбоеклар, төнбоеклар күзләрен йомып йоклар» дип, табигатьнең тыныч, гүзәл бер күренеш-картинасын күз алдына бастыра. «Сөйгәнеңне төнбоекка карап сагынырга кала» дигән юллар сурәтне киңәйтә, алдагы юлларның мәгънәсен, хикмәтен ачыклый, дәлилли төшә. Төнбоек сөйгән яр, аны өзелеп ярату, моңаю символы буларак үстерелә. Эмоциональ хисне табигать образы аша чагылдыру җырга күркәмлек, лиризм бөрки, кичерешне лирик җырда мөмкин булган чикләрдә әзлеклелек белән күңелгә сеңдерергә җай тудыра. Шуның өстенә, соңгы куплетта беренчел семантик төсмердә кабатланган төнбоек образы алкалы композиция төзи:

**Килер көтелгән минутлар,**
**Уяныр төнбоеклар.**
**Алар, кояшта елмаеп,**
**Безнең кавышуны котлар.**

«Яшь наратлар», «Карлыганым, бөрлегәнем» җырларында да шул ук алым өстенлек итә, кичереш «дилбегәсе» табигать сурәтенә ышанып тапшырыла.

И. Юзеев эзләнүләрен төрле юнәлештә алып бара. «Кайтам инде» җырында, туган ил матурлыгын сурәтләүгә зур әһәмият ителсә дә, үзәк шигъри образ юк. Әсәргә шәхес турыдан-туры үзе килеп керә:

**Кайтам инде, сез көтегез,**
**Болыннар,**
**Җәйге таңнар,**
**кара күзләр,**
**толымнар...**

«Казан — Алма-Ата» җырында әдип, әлегә кыюсыз гына булса да, публицистик һәм иҗтимагый җыр традицияләренә якын килә. «Лира җыры» да — игътибарга лаек әсәр. Биредә эпик колачлы мәһабәт табигать кеше рухының катлаулы тибрәлеш-дулкынлануларын җисемләштереп сурәтләргә мөмкинлек бирә. Тарихи тәҗрибәне үзенә сеңдерә килгән карт тирәк белән Лира арасындагы диалог җырга романтик рух бөрки, галәм киңлекләренә алып чыга:

Карт тирәкләр әйтә: «Җидегән йолдыз
Сүнәр инде, йокла, сеңелем...»
Минем өчен яңа йолдыз балкыр,
Юк, сүрелмә: минем күңелем.

Иң соңыннан йолдыз яңа мәгънәдә ялтырап ачыла: «шикләнүләр, уфтанулар белән үз йолдызын кетә күңелем». Үзәк шигъри образның шул рәвешле үсеше, баскычтан-баскычка катлаулана баруы җырга аерым бер нәфислек бирә, психологик анализ алымнарын баета, кеше белән табигать арасындагы рухи һәм физик якынлыкны тоярга мөмкинлек бирә.

Кыскасы, И. Юзеев җыр жанрын үстергә зур өлеш кертә. Замандашыбыз аңардан тагын да кыюрак фикерле, тирән хисле, кешене яшәешнең төрле чагылышларында (мәхәббәт сферасында гына түгел) сурәтләгән җырлар көтәргә хаклы. Шагыйрь үсә барган саен аңа куелган таләпләр дә катлаулана һәм арта төшә.

## Такташ һәм мин...

Әдәби җәмәгатьчелек И. Юзеевны бик тиз күреп ала. Әмма аның «Таныш моңнар», «Тау инеше» шикелле тәүге җыентыкларына бәя төрлечәрәк була. Берәүләр яшь каләмне дәррәү күтәреп хуплый, үз темасы, үз моңы, үз шигъри күреме булган әдипләр исемлегенә терки. Икенчеләре исә бу мәсьәләгә башкачарак карый. Алар фикеренчә дә, Илдар Юзеев, һичсүзсез, сәләтле шагыйрь, яшьләрнең рухи әзләнүләре, мәхәббәт-нәфрәтләре, ләззәт-сагышлары турында дәртләнеп, күңел кылларын тибрәндерерлек итеп яза белә торган шагыйрь. Ләкин урыны-вакыты белән ул Такташ интонациясен кабатлый, остазының табышларын әсәрләренә турыдан-туры алып керә... Мондый фикер, мисаллар ярдәмендә исбат ителмичә, интуициягә, сиземләүгә генә таянып әйтелсә дә, күпләрнең игътибарын үзенә тарта. И. Юзеев «Такташ һәм мин» шигырендә бу хакта үзе дә язып чыкты:

Шагыйрьләр күп бездә,
Сукмаклар да...
Йөреп булмый сукмак салмыйча.
Мин каңгырып йөрим, Такташ абый,
Үз юлымны таба алмыйча.
Әйбәт кенә үзем җырлый башлыйм —
Егылам да сиңа тотынам...
Үзем сизми калам,
Кайчагында
Шигъри карак булып тотылам.
Синең юлдан тагын чыгып китәм,
Атлап карыйм — тагын егылам.
Һәм кулларым белән, ярдәм сорап,
Синең чабуыңа сузылам.

И. Юзеев Такташтан поэзия дәресләре алуын, аның иҗаты белән сокlануын, ямь алуын яшерми.

Шул ук вакытта ул әлеге тәнкыйтьчеләр белән полемикага керә, әдәбиятта үз урынын, үз юлын раслау өчен көрәш алып бара:

Юл чатында тора тәнкыйтьчеләр,
Ә берсенең авыр чукмары,
Синең юлны таптап йөргән өчен,
Ай-һай, малай, каты тукмады.

(«Такташ һәм мин».)

Вакыт барысын да үз урынына куйды. Такташ шигъри мәктәбенең талантлы вәкилләреннән берсе саналса да, хәзер берәү дә И. Юзеевны эпигонлыкта гаепләргә җөрьәт итмәс. Поэзиясе идея-эстетик яктан камилләшкән, «тәпиләре ныгыган» саен И. Юзеев шигырь-поэмаларының «тышкы киеме» буенча Такташ стиленнән ераклаша, ләкин фикерләү үзенчәлекләре, поэзиясенең эчке хасияте буенча остазының иҗади рухына тирәнрәк үтеп керә бара.

Бу ике шагыйрьнең табигый талантларында (сүз талантларының дәрәҗәсе хакында бармый, әлбәттә) эчке якынлык бар. Бу якынлыкны лиризмның иркен агышында, тормыш драматизмын күрсәтә белүдә, тематик һәм жанр диапазонының киңлегендә, эчтәлеккә зарар китермичә, иркәле ритмикага, сөйләү формасына киң таянуда ачык сиземләргә мөмкин.

Ләкин биредә Такташны кабатлау турында сүз бармый. И. Юзеев өчен Такташ лирикасы кыю эзләнүләр юлында якты маяк, үзенә бер илһам чыганагы. Еш кына Такташ идеяләре, аның эстетик эзләнүләре И. Юзеевның хыялын, зиһенен уятып җибәрә, яңа шигырь тудыра. И. Юзеев революция шагыйренә яшьлек һәм тормыш романтикасын дәртләнеп, теманың эченә, кабатланмас стихиясенә кереп җырлый, табигый гүзәллекне калку итеп сурәтли белүе белән якын. «Таныш моңнар», «Миләүшә», «Таймас», «Өчәү чыктык ерак юлга...» кебек поэмаларында ул Такташ әле «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу», «Мокамай», «Бүгенге матурлык» шикелле әсәрләрендә башлап җибәргән эзләнүләрне дәвам иттерә. Икесенең дә максатлары уртак: революция һәм яңа иҗтимагый мохит алып килгән әхлакны кешенең канына, психологиясенә сеңдерү, шәхеснең рухында бөреләнә, туа килгән яхшы сыйфатларны чәчәк аттыру, үстерү. Проблема уртаклыгы ачык ярылып ятса да, аны чишүдә һәр ике шагыйрь үзгәрәк юл белән атлый.

Такташ, чор зарурияленнән чыгып, кеше аңыннан тотнаксызлык, җавапсызлык, үзенне генә ярату шикелле искелек калдыкларын, тумыш тапларны кысрыклап чыгаруны беренче планга куя. «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында ул социалистик җәмгыятьтә интим-шәхси мөнәсәбәт бөтенләй башкача, яңача булырга тиеш дигән фикерне ассызымлап үтә.

И. Юзеевның «Таныш моңнар»ында мәхәббәт уртаклыгы мәсьәләсе янына иҗтимагый идеаллар бердәмлеге коллизиясе килеп кушыла. Зөфәр белән Резеда бәхетне һәркайсы үзенчә аңлый. «Егет күңеле — далада, кыз күңеле — калада» дигәндәй, Зөфәр тракторчы хезмәтеннән, «тузан, май, эчендә» үткән көннәреннән ләззәт һәм канәгатьләнү таба. Дөньяга карашы тәмам формалашып, «акылга утырып» җитмәгән чуар йөрәкле Резеда бәхет муллыгын мәктәп партасыннан югары уку йорты өстәленә күчеп утыруда гына күрә:

> **Резеданы көтә институт,**
> **Театрлар, асфальт урамнар,**
> **Шәһәр парклары, яңа дуслар,**
> **Татлы уйлар, татлы хыяллар.**

Резеданың бу татлы хыялларын тормыш челпәрәмә китерә, ахыр чиктә, бәхетнең дипломда түгел, ә үзеңнең иленә һәм кешеләргә кирәклегеңне тоеп яшәүдә икәнне аңларга булыша.

И. Юзеевның тормышны иңләбрәк сурәтләргә омтылган «Тынлык белән сөйләшү» һәм «Соңгы сынау» поэмалары бер дә юктан һәм буш урында барлыкка килмәде. Ул, әлбәттә, үзен Такташ традицияләре белән генә чикләми, рухына якын бик күп шагыйрьләрдән илһам-ямь ала. «Тынлык белән сөйләшү» поэмасы кайбер яклары белән «Җир уллары» трагедиясенә барып чыга. Турыдан-туры чагыштыру, параллельләр үткәрү кыен, шулай да алар арасындагы якынлыкны инкарь итү фәнни булмас иде. Ике әсәрнең дә үзәгендә сәнгатьчә шартлылык ята. Ситуацияләре генә түгел, образлары да романтик, шартлы. Икесендә дә чорның катлаулы проблемалары, иҗтимагый коллизияләре укучыга метафорик сюжет аша җиткерелә. Такташ җир шары һәм галәм белән әңгәмә алып барса, И. Юзеев егерменче гасырны тетрәткән вакыйгаларның уртасыннан атлый.

Шунысы кызыклы, романтик-фәлсәфи драма формасына Такташ, яшьлегендә ки-

леп, соңрак аңардан читләшә. И. Юзеев катлаулы форма ишегенә «Такташ яшен» узып киткәннән соң гына шакый башлый.

Такташ белән И. Юзеев иҗатлары арасындагы якынлык һәм аерма табигать күренешләрен сынландыруда да ачык күренә. Бу өлкәдә татар совет поэзиясенең классигы ясаган сыйфат революциясе һәркемгә мәгълүм. Ул бакый чынбарлык күренешләрен образлар аша сынландыру белән генә чикләнмичә, табигать сурәтен еш кына мөстәкыйль сюжет сызыгы итеп ала.

И. Юзеевта табигать сурәте мондый мөстәкыйльлеккә ия түгел. Аңарда табигать сюжетка яраклаштырып алына, ул таләп иткәнчә үзгәрә, төрләнә, шәхес кичерешен җисемләштереп сурәтли. «Фәрит-Фәридә» поэмасында ак каен иң әүвәл үзенең нәфис күлмәген чибәр кыз Фәридәгә салып бирә. Фәридә батырларча һәлак булгач, каен ак күлмәкне, аның тәсе итеп, үзендә калдыра. Романтик поэмада батырлар каны тамган чәчәкләр, гөлләр үзгәрәләр, ал байрак төсен алалар.

һ. Такташтан аермалы буларак, И. Юзеев иҗатында табигать сурәтен юмористик планда үстергән әсәрләр очрамый. Шулай да төп бер ноктада бу ике шагыйрь үзара якынлашып китәләр. Икесендә дә табигатьнең төп функциясе шәхеснең рухи дөньясын, идеалын җанлы камиллегендә сурәтләү. Әлеге якынлык үз чиратында образлар системасының, сурәтле фикерләү алымнарының уртаклыгына алып килә.

Такташ табигатьнең ике сурәтен аеруча якын итә: алар — ай һәм җил. Халык җырларында мәхәббәт һәм сабырлыкны, аерылышу һәм хәбәрләшүне символлаштырган бу образлар Такташта мәгънәви һәм экспрессив функцияләрен киңәйтеп кулланылалар.

Җил сурәте Такташтагыча хәрәкәтчән, «тынгысыз характеры» белән И. Юзеевның иҗат рухына, образлы фикерләү манерасына ятышып тора. Бу символ еш кына «шаян җил», «җитез җил» шикелле эпитетлар аша гадәти функциясендә кулланыла. «Чәчәкләрен алып китәр шаян җил генә... Син җилләргә карап калырсың да оныгылырсың...» («Җырлар бирәм».) «Яшьлегемне иснә төшергәндәй, дәфтәр битен кичке җил ача» («Фәүзия җыры») һ. б.

«Вагонда туй» шигырендә җилгә юмористик төсмер беркелә. Биредә Такташ өлгесе ачык сизелеп тора:

...Менә вагон эче тынып кала.
Торып кала егет, кыз гына.
Тышта җилләр генә
Ике яшькә
«Ачы-ачы!» — диеп сызгыра.

Традицион сурәт аша И. Юзеев табигыйлеккә, фикер һәм хис бердәмлегенә, композицион гармониягә ирешә. Менә «Ертылган рәсем» шигыре.

Ертып ташланган рәсем кисәген җил урам буйлатып йөгертә. Лирик герой игътибарын шуңар юнәлтә. Аның карашы «сагыну, яратулар ташып» торган уйчан күзләргә, күе кашларга төшә. Рәсем лирик сюжетны тоенләп, хисләрне куертып җибәрә. Яшьлек, беренче мәхәббәт хатирәләре яңара. Лирик сюжет үсешенең иң киеренке бер ноктасында җил сурәте яңадан шигырьгә әйләнеп кайта, алкалы композиция төзи һәм җитди әхлакый нәтиҗә чыгарырга җай ача:

Бик еш шулай тормыш иртәсендә
Яшьлек белән яшьлек хушлаша.
Мәхәббәтнең кадрен белмисең шул,
Үз сөюең җилдәй очмаса.

Такташның И. Юзеевка ясаган мөнәсәбәте аерым өйрәнүне сорый. Төс бизәкләрен яратып куллануда да, шигырь-поэманың композициясен туктаусыз төрләндерүгә, рифма-ритмик байлыкларын хис агышына буйсындыруга омтылышында да И. Юзеев остазына якын юлдан атлый. Чор идеалларына, кеше характеры байлыкларына тирән үтеп керә белгәнгә, әдип Такташ традицияләрен иҗади үзләштерә, аның шигъри куәтен үзенә сеңдереп, яңа шартларда үстерә, баета.

# Нәтиҗә ясарга иртә әле...

И. Юзеевның язганнарын яңадан күздән кичерәм. Уйчан һәм моңлы, дәртле һәм омтылышлы, назлы һәм кырыс шигърият сине бик тиз үз артыннан ияртә, олы хисләр дөньясына алып керә. Кеше шатлыгы өчен сөенү — романтик омтылыш; дөнья язмышы өчен борчылу — фәлсәфи тирәнлек, шәхес бәхете турында уйлану изге моң уята. Шигырь юлларыннан персонажлары белән кулга-кул тотынып Илдар үзе килеп баса...

Күзләренең уйчанлыгын калын пыялалы күзлеге дә яшерә алмый. Шаяртканда да ул мәгънәле һәм төпле итеп, берәүне дә рәнҗетмичә, сүз кыстырып куя белә, ә ешрак, елмаеп, тыңлап торуны, кеше әйткәнне хәтер капчыгына төенләп куюны мәгъкульрәк күрә. Әсәрләренә хас лиризм, моң һәм табигый аһәң шагыйрьнең үз характерыннан юл ала шикелле. Поэзия иҗатчысының табигатеннән, характерыннан һәм йөрәгеннән шытып чыкканда гына ышандыра, уйландыра, вакытны үтеп, тарих киңлекләренә чыга ала. Тукай, Такташ, Җәлил, Кәрим поэзияләре шуңа үрнәк.

И. Юзеев иҗатының төп сыйфаты нәрсәдә соң? Мин аны бер сүз белән югары мәгънәсендәге кешелеклелек дип атар идем. Илдар Юзеевның герое ничек кенә ялгышмасын, идеалыннан тайпылмасын, зәңгәр планетабызда үз урынын эзләп ничек кенә хәвефләнмәсен, ахыр чиктә, аңарда акыллы, сәламәт башлангыч җиңеп чыга.

И. Юзеев поэзиясе күләгәле таплардан да азат түгел. Ул вакыты белән кабатлана, сентиментальлеккә өлеш чыгара (бу нәрсә яшьлеккә багышланган поэмаларында үзен сиздереп куя), уңышлы табышларын бер шигырьдән икенчесенә күчереп утырта (мәсәлән, шигырьне гади бер тормыш детале белән башлап җибәрү алымы, шигырьнең композицион үзәге итеп табигать символын алу), шигъри образын артык куерта һ. б. Нәтиҗә ясарга иртә әле... Ул үсештә...

Күптән түгел кырык яшен тутырган Илдар Юзеев әле һаман да яшьләр рәтендә йөри. Баксаң, санасаң, ул инде егерме ел буена татар поэзиясенә намус белән хезмәт итеп килә икән... Татар әдәбиятының, бөтен совет поэзиясенең гүзәл казанышларына таянып, Илдар Юзеев шигъриятебезне яңа образлар һәм сурәтләр белән баетты. Шул ягы белән аның иҗаты игътибарга, хуплауга һәм өйрәнүгә лаек.

# ГҮЗӘЛ СӘНГАТЬ БЕЛӘН ОЧРАШУ

*М. Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрының Казан каласындагы гастрольләре уңае белән.*

Кызганычка каршы, тамашачының күңелен тетрәндерә торган спектакльләр сирәк туа. Берничә ел моннан элек «Сүнгән йолдызлар» спектаклен караганда тамаша залының киеренке тынлыкта утырганын күргән идем. Кәрим Тинчуринның ул трагедиясе татар театрында әле дә булса зур уңыш белән бара. Казан тамашачылары Казакъ академия драма театры гастрольләре вакытында Җәүдәт ага Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясен караганнан соң да шатлык хисләре кичергән иде.

Һәм, ниһаять, менә бүген дә тамаша залы Башкорт академия драма театры спектакльләрен карап шундый ук тойгылар кичерә. Мирхәйдәр Фәйзи әсәре нигезендә эшләнгән «Галиябану» спектакле тәмам булгач та, тамаша залында беравыкка тынлык урнашты. Гүзәл сәнгатьнең сихри тәэсиренә бирелеп, тамашачылар өнсез калганнар иде. Бер мәлдән соң зал дәррәү кул чаба башлады.

Нәрсәсе белән тетрәтә соң «Галиябану» спектакле? Исмәгыйльнең җинаяте тетрәндерәме? Тамашачы автор тудырган үлемсез әсәргә сокланамы? Актерлар осталыгы шулай тәэсир иткәнме? Я булмаса режиссер яки рәссам хезмәтенә шулай сокланамы халык? (Спектакльнең режиссеры Рифгат Гафаров, рәссамы — РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСР дәүләт премиясе лауреаты Галия Имашева.)

Бу пьеса республикабызның бик күп театрларында барган һәм бара. Бүгенге көндә Татар академия драма театры сәхнәсендә дә уйнала. «Галиябану»ны куймаган бер генә үзешчән драма коллективы да юктыр. Димәк, Казан тамашачысы пьеса белән таныш дияргә тулы хакыбыз бар. Тамашачы өчен бу әсәрнең сюжеты да, ни белән тәмамланачагы да мәгълүм, әлбәттә. Исмәгыйль Хәлилне атып үтерә. Галиябану сөйгәненең үле гәүдәсе янында кан-яшь түгә.

Һәр вакытта диярлек «Галиябану»ны мелодрама итеп уйный торганнар иде. Бүгенге спектакль башкалар белән чагыштырганда бик нык аерылып тора. Режиссер әсәрне мәхәббәт турында легенда итеп куйган. Бу спектакль татар-башкорт театры сәнгатендә зур яңалык булып туган.

Тамаша залына килеп кергәндә үк күңел кыллары режиссер камертоны тавышына көйләнә башлый. Бөтен сәхнәне матур итеп чигелгән зур пәрдә билəп тора. Бу пәрдәне күргәч, күңел гүзәл сәнгать белән очрашуны сизенеп тибрәнә башлый. Бу сизенләү, бу дулкынлану оркестр уйный башлагач тагын да арта төшә: күз алдында сәнгать тудырган могҗиза башлана.

Беренче пәрдә мохитендә әле бәхетсезлек аһәңе һич ишетелми. Бәдри карт белән Галимәбану арасында тыныч, гадәти әңгәмә бара. (БАССРның атказанган артисты Хәй Фәхриев һәм БАССРның халык артисткасы Асия Нафикова.) Искиткеч матур куелган күренешләр, актерларның оста уены, башкаручылар тарафыннан оста табылган матур, табигый мәзәкләр тамашачыны рәхәтләнеп көлергә мәҗбүр итә. Бу өлешләр — чын комедия, зур зәвыкъ белән эшләнгән комедия.

Алга таба без Галиябану белән Хәлилнең очрашуларын күрәбез. (БАССРның ат-

казанган артистлары Нурия Ирсаева, Фидан Гафаров.) Шигърият һәм нәфислек белән сугарылган, романтикага кадәр күтәрелгән зур мәхәббәтне күреп тамашачы сокланулын яшерә алмыйча аһ итә. Артистлар тиз арада тамашачының күңелен билэп алуга ирешәләр. Каһарманнарны тамашачы никадәр көчле яратса, шул кадәр үк теләктәшлек белдерәчәк, алар өчен җан атып утырачак. Артистларның бу казанышы спектакль азагындагы тетрәнүгә әзерлек булып тора. Артистларның тавышы йомшак, моңлы тавыш. Тавышлары көчле булса да, алар сак кыланалар, салмак сөйләшәләр, моңлы итеп җырлыйлар. Әйтерсең лә бу җырны алар түгел, ә мәхәббәт үзе җырлый, ике гашыйкның йөрәкләре бергә кушылып җырга әйләнә кебек. Мәхәббәт аңлатышу күренешләре гаять зур саклык вә нәфислек белән эшләнгән. Мәхәббәт гүзәле Галиябану-Нурия дә, мәхәббәт каһарманы Хәлил-Фидан да баштанаяк гыйшык утына чумганнар. Уңышлы мизансценалар, пластик хәрәкәтләр һәм актерларның үз уеннарына ныклап инанулары — барысы бергә тупланган. Музыка да ике гашыйкның хисләрен тоеп соклана кебек: чак ишетерлек итеп кенә оркестр уйный, әйтерсең лә музыка бу чиста мәхәббәтне өркетергә теләми. Музыка каядыр тирәндә, мәхәббәтнең үз эчендә яңгырый сыман. Болар һәммәсе, бер югары максатка буйсынып, спектакль-ансамбль тәшкил итәләр.

Тагын Бәдри белән Галимәбану. Тамашачы тагын елмая, тагын рәхәтләнеп көлә башлый. Галиябануга яучы булып Бәдига карчык килә. (БАССРның атказанган артисткасы Фәридә Камалетдинова.) Галиябануның ата-анасы яучыны Исмәгыйль йомышы белән килгән дип уйлыйлар. Комедия жанрына хас булган буталчыклык туа. Әле һаман да фаҗига күренми дә, ишетелми дә. Барысы да ачыкланыр, барысы да берберләрен аңларлар да бар да яхшы тәмамланыр шикелле тоела башлый.

Якынаеп килгән фаҗига хакында музыка иң беренче хәбәрне сала (спектакльнең музыка өлешен Рим Хәсәнов эшләгән). Фаҗига турында искәртеп торучы бу аһәң бертуктамый алга бара, үсә бара. Шулай итеп, шул музыка белән фаҗига образы сәхнәгә керә. Оркестр биредә сак уйный. Булачак афәт тавышы еректан, тирәннән ишетелә. Ләкин, еракта булса да, фаҗига аһәңе ныклы адымнар белән якынлаша. Тора-бара бу афәт аһәңе азакка чаклы барып җитә. Артист Гайса Хәсәнов башкаруында Исмәгыйль коеп куйган явыз образ түгел. Исмәгыйль сабыр. Ул акыллы. Ул — мәһабәт һәм горур кеше. Исмәгыйль-Хәсәнов чын-чынлап Галиябануга гашыйк. Горур кыяфәтле, җиргә нык басып йөри торган егет ул Исмәгыйль. Көр, ләкин салмак тавышлы, үз абруен белеп кенә яши торган ул Исмәгыйль. Шул егет Галиябану алдына тезләнергә мәҗбүр була. Логик үсештә бирелгән катлаулы образ буларак истә кала Хәсәновның Исмәгыйле. Яшь актер ышандыру көченә ия булган образ иҗат иткән. Менә шушы көчле характерлы, үзсүзле, каты буынлы кешенең горурлыгына тап төшәргә тора: Галиябану Хәлил белән вәгъдәләшкән, Исмәгыйль бу хәлгә түзеп тора алмый. Ул бер дә исе китмичә генә Хәлилгә ата. Актер ышанычлы адымнар белән рольнең үтәли сызылган юлыннан Исмәгыйльне финалга кадәр китереп җиткерә.

Спектакльнең иң тәэсирле, иң тетрәндергеч урыны үлем ярасы алган Хәлилнең егыла бару күренешендә.

Бөтен сәхнәгә җете кызыл утлар сирпелә. Әйтерсең лә бөтен кеше ут-хәсрәт эчендә калды. Сәхнә уртасында, менә егылам дип, яралы Хәлил басып тора. Ян-якларда кайгыдан катып калган кешеләрнең шәүләләре. Режиссер кино алымнарын уңышлы кулланган. Егетләр-кызлар туктап калган кино кадрларын хәтерләтә, Хәлил акрынайтылган кинокадрлардагы кебек салмак кына, акрын гына шуышып җиргә егыла бара. Оркестр кылларга тияр-тимәс кенә, үзәк өзгеч итеп лейтмотив уйный. Бу күренеш гаять зур тәэсир көченә ия. Бу алымнар шаккаттыру өчен генә эшләнмәгән. Бу күренеш спектакльнең асылыннан килеп чыккан.

Тамаша залында киеренке тынлык. Тамак төбенә менгән әче төер тамашачыларның тынын каплаган. Өнсез калган тамашачы бераздан кул чаба башлый. Һәр тамашачының йөзендә яшь аралаш елмаю чаткылары яна. Кешеләргә гүзәл сәнгать тәэсир иткән. Кешеләрне актерларның оста уены, режиссерның талантлы эше, рәссамның хезмәте сихерләгән!

Кылынган җинаятьнең сәбәбе нәрсәдә соң? Исмәгыйльнең мәкерендәме? Бәдринең комсызлыгындамы? Миңа калса, төп сәбәп боларда түгел. Хәсәнов Исмәгыйльне усаллыктан күзе томаланган кабахәт кеше итеп уйный. Бәдри карт та чын күңелдән кызына бәхет тели, югыйсә. Бәхетне ул Исмәгыйльнең байлыгында дип уйлый. Исәп-хисапка

корылган вак крестьян психологиясе Бәдрине үз кызын ирексезләп бай кияүгә бирергә этәрә. Әгәр дә башта ук буталчыклык чыкмаса, башта ук Бәдри хыялында алтын сарайлары кормаса, бәлки Хәлилне кияү итүдән дә ерак йөрмәс иде.

Сәбәп тирәндәрәк, сәбәп социаль мохит шартларында. Фаҗига патша режимы вакытындагы татар авылында бара. Дөньяны рәхимсез, дуамал байлар тотып тора. Төп каһарман капитал биредә. Ирексезләү, сату-алу, ришвәтчелек белән дөнья тулган. Йөрәк яргыч җинаятьләрне йомып калдыра торган заман. Исмәгыйль һич икеләнмичә кеше үтерә. Чөнки ул киләчәктә җәзадан котылачагына ышана. Без аны шундук күрәбез. Старостаның ришвәтче икәнлеге моңа ачык мисал. (БАССРның атказанган артисты К. Назаров.) Хәлилне Исмәгыйль үтерүе расланды. Шаһитлар җинаятьчене җәзага тартуны таләп итәләр. Ләкин староста Исмәгыйльне үз канаты астына ала. Сүз белән түгел, эш белән. Егетләрнең берсе бу хакта кычкырып әйтә. Староста кирәмәйләп торып зур кулы белән егетнең авызына суга да егетне бер янга алып ата. Икенче төрле итеп әйткәндә: староста йодрыгы дәрәслекне әйтергә ачылган авызны томалады!

Староста Исмәгыйльне алып китә. Хөкем итәргә түгел, йолып алырга.

Мәхәббәт һәлак булды. Тамашачы күзендә яшь. Ә йөзендә елмаю. Кунакларның уңышына сөенүдән туган шатлык чаткылары ул елмаю. Гүзәл сәнгать белән очрашудан алган бәхет очкыннары ул елмаю!

**Роберт БАТУЛЛА.**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# ӘЙДӘ БАРЫЙК, КЫЗЛАР КАРЫЙК...

*Фольклорчы блокнотыннан*

## Бетховен һәм Казиле Зариф

Мин йөз фатирлы йортта торам. Бу йортта яшәүчеләрнең күбесе кырык яшьлек чамасы кешеләр. Күбесенең балалык вакыты сугыш елларына туры килгән — алар авыр тормышта үскәннәр. Аннан соң бу йортта яшәүчеләрнең күпчелеге — авылдан килеп белем алган, зур укыган кешеләр. Фән кандидатлары, булачак һәм булып ятучы докторлар... Әлбәттә, һәрберсенең бер кызы, бер малае бар. Бөтенесе китаптагыча. Ул кыз, әлбәттә, өендә пианинода дәрес ала, спорт мәктәбенә йөри, махсус чит тел мәктәбендә французча геометрия өйрәнә. Бакча яшеннән чыгып килә торган малай да инде төнге чүлмәген башына киеп кунак бүлмәсенә килеп кереп әнисен кызартмый, ә скрипкада Брамсның берәр шаккаттыргыч әйберсен уйный. Кичләрен бөтен йорт мелодия белән тула. Бер яктан Бетховен, астан Сен-Санс, форточкадан Чайковский ишетелә. Һәр фатирның түр бүлмәсендә пианино. Әйе, кичләрен безнең йорт мәһабәт бер консерваториянең уку классларына охшап кала. Мин бу тавышларны сокланып тыңлыйм һәм уйлыйм: әле чирек гасыр гына элек чабатага күтәрмә тагып кырда черек бәрәңге җыеп ашап, күрше авылга җидееллыкка йөргән малайларның балалары бүген зур, якты бүлмәләрдә Бетховенны, Григны уйныйлар! Никадәр үсеш, никадәр алга сикереш бу! Әлбәттә, минем шул Брамслар, Григлар арасында «Баламишкин» яки «Алмагачлары»н да ишетәсем килгәләп куя. Ләкин бу теләкне мин кешегә әйтмим, чөнки «искелекне яңалыкка каршы куясың» дип әйтүләре бар. Һәм мин кешегә белгертмичә генә хәтерлим, искә төшерәм...

Утыз сигезенчеме, утыз тугызынчымы еллар. Я, шул еллардагы хөрлек, бөтенлек! Колхозлар бөтен төрле кызамык авыруларын уздырып ныгыдылар, авыл тулы ирләр — сытып эшләүче көч. Менә сабан туй вакытлары җитә. «Фәлән колхозда фәлән көнне сабан туй икән» дигән хәбәр бөтен авылны дүрт итеп аякка бастыра. Бодайлар юыла, чормадагы каклаган казлар кыймылдый, тәкәләр, көтүгә куылмыйча, аерым ашатыла. Менә авылга берәм-берәм кунаклар кайта башлый. Ни арада, кем хәбәр иткән! Нәкъ шул сабан туй атнасына кайтып төшәләр.

— Күкчәтаудан Сәлимә белән Ахияр кайткан! — дигән хәбәр бөтен авылны дерелдәтеп ала. Чөнки Ахияр — безнең авыл кияве — гармунчы. Бер анда гына венский гармун бар. Бер ул гына «Алмагачлары»н җиренә җиткереп уйный белә. Бер ул гына урамның билгеле бер турысыннан, әдәп саклап кына, ялгыз гөрләтеп уза белә.

Менә сабан туйга инде ике генә көн калды.

Инде колхозда даими эштә булган кешеләр генә эш киеменнән йөри. Болар: ат караучы, фермада эшләүче, амбар каравылчысы, кәнсәләр дежуры... Башкалар инде чыж да чыж пешереналәр, инде кызмача йөрүчеләр дә бар. Кичләрен капка төбе тулы кеше. Карт-коры ризык карап, тегесен рәтләп, бусын рәтләп йончый, кичтән үк кереп зирәк йокыга тала. Бала-чага егетләр, кызлар уенын күзәтергә су буена чаба. Узган ел гына өйләнгән ирләр әдәп саклап капка төбендәге бүрәнә өстендә кич утыралар. Инде төнгә таба авышып килә, инде беренче әтәч кычкырды, инде су буеннан яшьләр таралыштылар, капка төпләре дә бушап калды. Иртәгә эшләр бик күп, иртүк торып камыр басасы, симергән тәкәне дә тәвәккәллисе бар, кибеттән чәй-шикәр алырга кирәк... Шул мәшәкатьләргә әзерләнеп дөнья тынып кала. Кинәт! Аһ, бу фани дөньяның тынлыгы! Кинәт бу тынлыкның кайдадыр бер кылы өзелде. Өзелде... Шуның белән вәссәлам! Бу икән — Күкчәтау Ахияр үзенең гармунын күтәреп чыккан да түбән оч урамында кыска гына аккорд биргән. Әйе, шуның белән төнге авылда икенче тормыш, рухи тормыш башланды. Ахияр гармунны үзенчә уйный. Гармун аның корсагында да түгел, күкрәгендә дә түгел. Ул урамның бер кырыннанрак югары очка таба атлый, ә гармунны ул бите турысынарак күтәрә. Гармун аның гәүдәсеннән аерым. Сул кулы белән аның мехларын сузганда да ул аны янга түгел, ә гармунны кыегайтып, телле ягын аска, бәкалы ягын күккә каратып борып бетерә. Аның гармунындагы бакалар кадәр көчле, моңлы бакаларны минем беркайчан да ишеткәнем булмады! Гармун телләреннән бигрәк әнә шул бакалар моңланалар, шулар елый торганнар иде. Ахияр бер генә көй уйнап уза — «Алмагачлары». Моны хәзәр Ахияр төсле итеп бер генә кеше дә уйный алмый. Менә гармун тавышы якыная, аның бакалары үкерә-үкерә елыйлар. Ахияр үзе дә урамның билгеле бер турысында җырлап җибәрә (үзе уйнап үзе җырлый ала торган гармунчы ул елларда бик сирәк очрый торган хәл иде). Җырлавы да аның үзенчә. Җырның сүзләре аның өчен һич тә аерым сүзләр түгел, ә бары тик аерым музыкаль кисәкләр генә. Шуңа күрә ул аларны теләгән җирендә бүлеп, теләгән авазын кушып, теткәләп бетерә. Кыскасы, Ахияр белән гармун кинәт кенә икесе ниндидер бер сихри музыкаль инструментка әйләнә дә куя. Бу инде кеше генә түгел, бу инде гармун гына да түгел, бу — татар халкының гасырлар буе килгән моңы, рухи куәте, музыкаль потенциясе, бу — татар халкының оркестры, филармониясе, консерваториясе... Урамнан әнә шундый могҗизалы көч килә һәм бу көч алдында бөтен тереклек дөньясы сихерләнә. Карт-коры агач караватын шыгырдатып әйләнеп ята, авыр сулый, сөйгән егете белән үпкәләшеп кайткан яшь кыз бу тавыштан әсәрләнеп мендәрен тешләп кайнар яшь түгә, кичтән генә киленен рәнҗеткән усал кайнананың күңелендә шәфкатьле хисләр уяна...

Ә урам кырыеннан Ахияр бара.

Суб-буй-енда бак-кал-лар  
Баталар дә калкалар.  
Шуш-шык-кейн-нем-мат-тур-ритеп  
Әйт-тә Марьям-мапал-лар...

Авылдагы бетен халыкны әсәрләндереп урамнан Ахияр узды. Ул күп җырламады, югары очка киткәндә аның тагы бер җыры ишетелеп калды.

Әй-дәб-бар-рыйк, кызлар карыйк,  
Орчы-гыр-лаганнәрен [1],  
Ай-йаз кенн-дәй-йәш-шен суксын  
Ег-гет сөймәг-гәннәр-рен...

Бетте. Нибары менә шулар гына иде. Ул иртәгә дә шулай бер-ике җыр җырлап узар, берсекөнгә дә.

Ә аннан, сабан туйлар беткәч, Ахияр хатынын, гармунын алыр да яңадан үзенең эшенә китәр. Авыл халкы исә аның моңын, аның көен киләсе елгы сабан туйга кадәр саклар. Бәлки Ахияр үзе дә әнә шул чыклы җылы төннәрдә авыл урамыннан гармунын колак янына күтәреп бер-ике генә узу өчен монда кунак

[1] Орчык эрләгәннәрен, ягъни җеп эрләгәннәрен.

булып кайтадыр? Бәлки ул да ел буе әнә шул якты истәлек белән рухланып, дәртләнеп яшидер? Кем белә?

Ахияр да, аның гармуны да сугышта беттеләр. Инде безнең авыл урамында ул көй яңгырамый.

...Сабан туй көнне авылга күрше-тирә авылларындагы нәсел-нәсәп җыела. Карт-коры да кызып ала. Сабан туйга барганчы урамда хәрәкәт кызулана, сиртмәләргә тәялеп, чатыр-чабып инде китә дә башлыйлар. Ә бертерле кеше сабан туйга бармый. Нәрсә ул сабан туй? Әйе, әйе. Менә, мәсәлән, бөтен кеше дә Ахияр булып бетә алмый, әмма авыл урамының кыл уртасыннан сигез телле тальян белән узасы килә. Бармаклар каткан, бер бармак бер басканда ике-өч телне бергә баса — зыян юк. Көйнең ниргәсенә килсә ярый. Хикмәт андамыни? Хикмәт — хөрлектә, музыкага мөнәсәбәттә. Менә мин дә бу авыл кияве. Дөрес, Ахияр кебек яшь түгел, аның кебек серле түгел, аның кебек оста түгел. Ләкин — мин дә кияү. Бу — минем дә бәйрәмем. Кыш буе колхозда салам ташыдым, яз көне симәнә чыгардым, аннан басу түренә тирес түктем. Мин йөргән басулар хәзер яшел хәтфә белән капланды. Нәрсә, шушы атнада әллә минем дә бер җон-ябаганы коясым килмиме?

...Бусын — безнең авыл кияве, Казиле Зариф сөйли. Чыннан да, ул үзенең тыны беткән сигез телле тальянын өзелердәй итеп тарта, хәлле-хәленчә тегеннән тавыш чыга, әмма Зариф түбән очтагы кайнагаларыннан чыгып югары очтагыларына кунакка бара. Аңа сабан туй кирәк түгел, менә шунысы кирәк. Зариф кияү урамнан берүзе тальян күтәреп югары очка узды. Зариф кияү — гармунчы... Зариф кияү — хөр күңелле кеше. Әйе, яше иллегә җитеп килүгә карамастан... Бу утыз сигезенчеме, утыз тугызынчымы елларда әнә шулай иде. Мин алтмыш сигезенче елның җәендә сабан туй вакытында авылда булдым. Ни күрим... Урамның урта бер җиреннән, көн эссесендә берәү бара — кулында коргаксып беткән тальян гармун. Өстендә саргылт толстовка, башында аксыл, уңган фетр эшләпә. Гармуннан «Алмагачлары» чыкса да чыга, чыкмаса да чыга.

— Бу кем? — дип сорадым.

— Казиле Зариф бит,— диделәр авылдашлар.— Сабан туйда бер шулай узмыйча калмый ул...

— Ничә яшь соң аңа? — дип сорадым.

Бер аяксыз Ватан сугышы инвалиды көлеп болай диде:

— Зарифка ничә яшь икәнен кем белсен? Менә без малай вакытта шушы урам уртасыннан сабан туй вакытында гармун тартып уза иде ул Зариф, әле дә шулай. Елына бер тапкыр — гомер буе. Ә бит карт инде, сабакы... (Сабакы — бу инвалидның телендә ихтирам сүзе икәнен белә идем.)

...Минем бүлмәмә стена аркылы Брамсның «Венгр биюе» ишетелә. Күршемнең тугыз яшьлек кызы скрипканы елата гына... Үземнең кызым пианинода «дың-дың» бәреп Бетховенны уйный. Ә мин уйлап утырам: Брамс — бөек, Бетховен — бөек, ләкин «Алмагачлары»н иҗат иткән халык та бөек! Шулай булмаса, илле ел буе Казиле Зариф аны сабан туй көнне урамнан уйнап узмас иде!

## Кичке мәктәп

Әйе, шундый мәктәп ул вакытта да бар иде. Ләкин ул мәктәптә китап-дәфтәр, журнал булмый иде. Анда барысын да халык күңеле хәл итә иде. Халык күңеле сорый, җавап бирә, хөкем чыгара. Барысы да җыр белән. Җыр мактый, яманлый, көлә, тәнкыйть итә, исеңә төшерә, кисәтеп куя — тик сине мәсхәрәләми генә. Шәхесеңне рәнҗетми.

...Сабан туй көнне кич. Су буе. Ул, мин сиңайтим, кунак кыз, ул кунак егет. Түгәрәк уенның моның кадәр зур булганы юк иде!

Монда — үзенә бер дөнья. Үзенә бер закон. Син инде йөрәгең җитеп түгәрәк уенга кердеңме, рәхим итеп, аның канунныарына буйсын. Бу — язылмаган закон. Моның үзенең эчке тәртипләре бар. Монда син үзең турында җәмәгать сүзен ишетерсең. Сиңа әнә теге Ташкичүдән килгән кунак кыз ошыймы? Кемгә булыр икән бу дип баш ватасыңмы? Сабыр ит, сиңа моны да әйтеп бирерләр. Син кызлар

арасында үзеңнең дәрәҗәң ничек икән дип уйлыйсыңмы? Ике тиен бер акча! Син бүген моны да ишетерсең. Тик уен беткәнче түгәрәктән генә чыкма. Әйе, чыкма...

Түгәрәк кузгалды. Уртада гармунчы һәм егет белән кыз. Боларга түгәрәк халкы бер җыр җырларга тиеш. Аннан түгәрәк хәрәкәттән туктап кала. Уртадагы пардан берсе җавап бирергә тиеш. Бу — җәза дип атала. Ямьсез сүз, ләкин нихәл итмәк кирәк, әгәр син җырчы түгел икәнсең, бу, чыннан да, җәза. Аннан, шул җәза үтәлгәч, түгәрәк аларга тагын бер җыр җырлый. Шул вакытта уртадагы егет белән кыз үзара сөйләшәләр:

— Кемнәрне кертәбез? — ди егет.

Кыз инде үз ягыннан уйлап куйган була. Бераз киңәшәләр дә, җыр туктагач, кыз түгәрәктән бер егетне, егет түгәрәктән бер кызны чыгара. Уен дәвам итә. Әгәр уртадагы егет белән кызның серләре килешсә, алар берәзлексез сөйләшеп торалар. Әгәр болай гына, кеше чыгарганга гына туры килгән булсалар, бер-берсенә яннары белән торалар. Моны түгәрәк халкы бик яхшы аңлый. Әгәр боларның уртада беренче очрашулары булса (бигрәк тә, берсе кунак булса), боларга киңәш бирәләр, танышырга әйтәләр, бер-берсенә лаек дип мактыйлар. Кыскасы, һәр очракка җыр әзер. Менә уртада чибәр егет белән көләч кыз.

Х о р:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мортаза.
Айлар калыккан дип торам,
Сез икәнсез уртада.

Түгәрәк туктый, егет «җәза» үти.

Җырла, җырла дип әйтәсез,
Сезгә нинди җыр кирәк.
Сезнең алларда җырларга
Сандугач теле кирәк.

Түгәрәк тагын кузгала, егет уңышлы гына җырлый алганына горурланып янындагы кызга карый. Янәсе, сизденме, кем белән уртада торганыңны...

Х о р: Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Габделбарый.
Сандугач теле кирәкми,
Үз телләрең дә ярый.

Икенче парны кертәләр. Күрше авыл кызы. Үзебезнең авыл егете. Нәрсәгәдер кырынрак торалар. Димәк, егеткә кыюрак булырга кирәк.

Х о р: Ал булсагыз да ярый,
Гөл булсагыз да ярый.
Сез икегез пар килгәнсез,
Яр булсагыз да ярый.

Түгәрәк әйләнеп торганда егет кунак кызга бер авыз сүз дә дәшә алмады. Кыюсыз! Инде нәрсә дип җавап бирергә? Ләкин... егет — хитри.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Унны да, тугызны да.
Мәк сәчкәләре күк күрәм,
Дуслар, барыгызны да,—

дип котыла.

Уен кыза бара. Шактый кызмача олы гына яшьтәге берәү уенга килеп керә. Әһә, бу — шахтадан кайткан Котдус икән. Ул егет булып йөргән заманда болай үк шәп булмый иде уеннар. Хатыны Шәмсия уен читендә иренең пиджагын тотып

күлемсерәп тора. Янәсе, бар җир, мамыгыңны коеп кара, ләкин дә, җаным, барыбер файдасыз: минем кулда инде син, белдеңме шуны...

Ялт! Котдусны балдызы белән парлап уртага кертеп бастыралар. Гомуми генә бер җыр җырлыйлар. Түгәрәк туктый. Бу шахтер мәхәббәт турында нәрсә әйтер икән диган сыман су буе тынып кала. Котдус та гармунчыга ым кагып карлыккан тавыш белән җыр башлый.

Агыйделдән прахут килә
Уралып саллар белән.
Сталинга рапорт бирик
Уңышлы саннар белән.

Хор: Иртә торып тышка чыксам,
Клуб уты сүнмәгән.
Бу нинди күңелләр икән
Картайгач сүрелмәгән?

Котдусны ай күрде, кояш алды. Бер читтә хатыны Шәмсия генә тантаналы рәвештә елмаеп тора иде. Шәп иттеләрме, янәсе.

Бераздан тәнәфес була, егетләр бер читкә китеп тәмәке көйрәтеп алалар. Шул арада кызлар «Суда сусар үстердем»[1] диган җырлы уен башлап җибәрәләр. Монда инде уртага ялгыз гына керәләр. Безнең авылда бу уен вакытында менә мондый җаваплар була иде.

Хор: Суда сусар үстердем,
Сусар бүрке тектердем.
Нургали дус, Вәсиләдән
Сәлам хаты китердем.

Аллар алыр үзеңә,
Гөлләр алыр үзеңә.
Сөясеңме Вәсиләне,
Әйтеп бирче үземә.

Җавап (егет горур кыяфәттә башын югары күтәрә, билләренә таяна яки чалбар кесәләренә кулларын тыгып гармун көенә селкенә-селкенә җырлый):

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Галләм түгел.
Сөям, дуслар, ялган түгел,
Кешедән калган түгел.

Егет үз урынына бер кызны кертә. Моңа карата да бер җыр һәм даими булган ике строфа җырлана. Әгәр бу кызның (егетнең) анык кына сөйгән кешесе юк икән, даими строфа бераз үзгәртелә.

Минсара дус, бер егеттән
Сәлам хаты китердем.
Аллар алыр үзеңә,
Гөлләр алыр үзеңә.
Сөясеңме, ярың бармы,
Әйтеп бирче үземә.

Кыз да бирешми. Әгәр, чыннан да, аның хәле шулай мактанырлык ук түгел икән, ул да сер бирми, сүз уйната.

---

[1] Хәзерге фольклорчылар аны «Сусар үтердем» дип язалар. Ләкин халыкта алай түгел. Җырда «үтердем» сүзе матур яңгырамый, халык алай саксыз түгел.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр дрова.
Кеше хәлен тикшерергә
Каян килде права? —

дигән була.

Икенче берәүнең сөйгәне белән үпкәләшеп йөргән вакыты. «Сөям» дип әйтер иде — горурлык җибәрми. «Сөймим» дияр иде, эшне бөтенләйгә бозып куюың мөмкин. Шуңа күрә андый категориядәге хәлләр өчен дә җыр бар.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нургали.
Беләсегез килә икән,
Белми торыгыз әле.

...Уртага Гөлсәхрәне керттеләр. Узган атнада юктан гына тавыш чыгарып Хәкимҗан белән бозылышканнар иде. Хәкимҗан шуңа үч итеп күрше авыл кызы янына йөри башлады, хәзер су буенда бөтенләй күренми. Ә Гөлсәхрә яратудан түгел, өчуын басар өчен инде Хәкимҗаннан соң ике егет белән сөйләште. Хор өчен бу — материал.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр семечка.
Яр өстенә яр сөясең,
Бу нинди привычка?

Суда сусар үстердем,
Сусар бүрке тектердем,
Гөлсәхрә дус, Хәкимҗаннан
Сәлам хаты китердем.

Аллар алыр үзеңә,
Гөлләр алыр үзеңә,
Сөясеңме әле дә булса,
Җавап бирче сүземә.

Гөлсәхрә — чая кыз. Җавап ничек кенә бирелмәсен, бу — иртәгә үк Хәкимҗанга мәгълүм булачак. Әнә түгәрәкнең кырында гына Хәкимҗанның яшүсмер икесеңелесе йотлыгып тыңлап торалар. Ә Гөлсәхрә алар белән элек ничек дус иде. Җавап кискен булырга тиеш...

Ашыйм алма, ашыйм хөрмә,
Ашыйм чияләрен дә.
Үзен түгел, сөймим аның
Фамилияләрен дә.

Бу инде — карар катгый, шикаять бирелми дигән сүз. Уенның бу төре уртага Айсылуны чыгарып бастыру белән тәмамлана. Айсылу — укытучы кызы, авылда иң сылу, иң тыйнак кыз, аның әле уенга керә башлаганына да беренче генә ел. Ул әле генә унынчы классны бетерде, шәһәргә укырга китәргә йөри. Аның бик яшерен генә яратып йөргән Габдрахманын кыш көне хәрби училищега алдылар. Алар, ничмасам, бер генә тапкыр иркенләп сөйләшә алдылармы икән? Бигрәк яшьләр бит? Айсылу нәрсә дип әйтер икән? Туктале, мондый кеше астыртын була, сынап карыйк... Сорадылар. «Сөясеңме Габдеринең?» — диделәр, ә Айсылу үз гомерендә беренче мәртәбә оялып кына түгәрәк эчендә җырлады.

Җиделе лампа якты янә
Магазин алларында.
Мөмкин булса тотар идем
Көн дә үз алларымда.

Аһ, әгәр мөмкин булып бу җырны Ерак Көнчыгыштагы Габдрахман тыңлый алса иде! Аһ, дөньяда бу җырга кергән сагышның көчен үлчи торган берәр нәрсә булса иде!

Безнең якның кызлары-егетләре бик тәмле телләләр. Әгәр синең яшьләр арасында абруең бар икән, әгәр син кеше күңелен рәнҗетерлек эш эшләмәгәнсең икән, уртага кергәч, син ниләр генә ишетмәссең...

И дускаем, кашың кара
Каләм каралары күк.
Сез бит нәселегез белән
Былбыл балалары күк.

Менә шулай кечкә уенның башыннан-ахырынача яшьләрнең теленнән энҗе коела.

## «Җиде йат»... ул кем?

Башка якларда ничектер, әмма безнең авылда «йат» сүзенең эчке мәгънәсе коточкыч иде. Җитмәсә, аның тагы да көчлерәге бар — анысы «җиде йат» дип йөртелә. Без кечкенәдән җырлап үстек, «уф алла» арбасын кара-каршы бәйләп дүрт тәгәрмәчле арба ясый идек тә чиратлап этеп тәялешеп йөри идек. Менә шунда җырлана иде инде барысы да. (Ләкин, ни хикмәттер, безнең авылдан бер генә композитор, бер генә опера артисты чыкканы юк — ул арбада җырлап йөргән малайлар хәзер барысы да колхозның тоткасы.) Менә шунда без «йат», «җиде йат» белән таныштык. Баштарак бу бик абстракт төшенчә иде.

Утын йотып, (э) рәхәтен
Йатка калдырмам әле.

Чыннан да, нинди кеше икән ул «йат»? Ихтимал, кешелек җәмгыятенең башлангыч чорында ул чит кабилә, чит ыругларга карата кулланылгандыр. Аннан, дәүләтләр оешкач, икенче бер дәүләт, икенче бер халык мәгънәсендә йөргәндер. Кыскасы, бу төшенчәне безгә әнә шул «кечкә мәктәп» — җырлы уеннар ачып бирергә тиеш иде.

Нурми иртәгә армиягә чыгып китәсе иде. Аны сөйгән кызы белән уртага керттеләр. Нурми шактый кызган, үзен бик кыю тота. Борчыла. Кызы бик чибәр шайтанның. Син анда ике-өч ел буе айт-дәвага басып йөргәндә тыныч кына көтеп тора алырмы бу? Моңа бит килгән бер кунак егет сүз катачак. Ярый, үзебезнекеләр синең өчен дип сакласыннар да ди...

Куәтле тавыш белән Нурми җыр башлады:

Китәм инде, китәм инде,
Китәм армияләргә.
Үзем киткәч, ярым кала
Йатлар тәрбияләргә.

Әһә, «йат» синең иң газизеңә, иң кадерлеңә кул сузучы, күз салучы була икән...

Чү... Тау башында Нәби тавышы ишетелде. Нәби су буена төшкәндә һәр вакыт гармунга җырлап төшә. Горур җырлый. Үз тавышының матур икәненә аның иманы камил. Аннан соң ул нәрсә генә җырласа да, аны игътибар белән тыңлаячакларына да шикләнми. Шуңа күрә вакарь белән генә, җырның матурын, мәгънәви яктан куәтлесен генә җырлый. Әнә бүген дә шулай.

Алмагачы кырларда,
Парлап яхшы җырларга.
Җиде йатны үз итәргә
Чурт та кушмый кызларга.

Бу инде Нурми жырына җавап сыман булды. «Йат»ның мәгънәсе ул кичне коточкыч тирәнәйде, киңәйде. Шуның өстенә, уен таралып яшьләр кайтырга чыккач, Нәби тагын бер-ике хикмәтле җыр җырлады.

Алма биреп ашатырлар,
Ашама, бәгырькәем.
Ашатырлар, ташлатырлар,
Ташлама, бәгырькәем.

Бу җырда да сүз ниндидер «йат»лар, явызлар турында бара иде. Шулай «йат» образы күңелләрдә тәмам формалашты. Без үскән саен ул образ да үсте һәм кырык беренче елны ул инде илебезгә басып кергән дошман төшенчәсенә барып кушылды. Шуның белән «йат»ның ямanлыгы да артты.

## Җыр дәвам итә...

Гөрләгән су буйлары тынып калды. Шыксыз көз җитте. Сугыш башланганнан бирле болай да тынып калган авылдан соңгы партия кешеләрне окоп казырга җибәрделәр. Кая ул җыр, кая сиңа уен! Егетләр — сугышта, кызлар — урман эшендә, окоп казуда. Авылның тыны кысылды. Хәсрәт, сагыш эчке җыелды. Бер ел үтте, ике ел... Әле сугышның очы-кырые күренми. Менә бөтен матурлыгы белән кырык өченче елның июне җитте. Шул ук таңнар, шул ук сандугачлар, су буенда шул ук чыклы үлән, түгәрәк уен уйный торган урын. Менә бер кичне монда дүрт-биш кыз төште. Икенче көнне — күбрәк. Баксаң, ике ел эчендә авылда ике оя кыз өлгергән икән. Ике оя малай үсеп җиткән икән... Һәм түгәрәк уеннар башланды. Бераздан боларга инде олыгая башлаган, теге, тыныч елларда чын егетләрнең көчле кулларын тотып чын уеннар уйнаган кызлар да кушылдылар. Бу — йөрәкне баса икән. Ичмасам, егетең үзе янында булмаса да, исемен телгә алалар. Ичмасам, аның туган авылының, суының исемен телгә алалар. Бу — сагышлы йөрәккә шифа. Әлбәттә, уенның нәрсәседер җитми. Тозы чыкмаган аш шулай була. Шикәрсез эчелгән чәгендер чәе шулай була. Ләкин — юк инше түгел. Түгәрәктә кызлар, уртага да бер кызны кертәләр. Теге соңгы «выпуск» малайкалар әле уенга кермичә читтә авыз ерып торалар. И, адәм мәсхәрәләре, үзләренә күрә түгел! Сугыштагы егетләр кайтса буранагызны очыртырлар иде!

Моңсу гына, бертөрле генә җыр.

Ямьле Ташкичү буйлары,
Ямьле, төмле шул Ташкичү сулары...

(Янәсе уртадагы кызның сугыштагы егете Ташкичү авылыннан, шуны искә алалар.)

Ямьле Казиле буйлары...

(Монысы үз гомерендә Казиленнән бер егет белән дуслашкан иде, каһәр төшкән сугыш аяк чалды. Ярый инде, хет телгә алалар, ни хәл итәсең...) Менә шул. Уенның бу төре туйдыра. Им өчен бер егет булсачы!

Икенче уен башлана.

Монысында да теге, кайчандыр бу кызга тегелейме-болаймы мөнәсәбәте булган егетнең исемен кушып җырлыйлар.

Галимҗаннар су буена туктаган...
Туктаган, туктаган,
Су буена туктаган.
(Э) Рәхилә, Мәгърифә, Гарифә
Иелми, бөгелми,
Матур баса түгелми...

Кайчандыр Галимҗан исемле егетнең бик кадерлесе булган Факиһә түгәрәк уртасында «Иелми, бөгелми» дигән вакытта ялгыз бии башлый. Биегән вакытта ул әнә шул Галимҗанны гына уйлый. Аңа бүтән берни дә кирәкми. Кайбер шаянрак кызлар шыпырт кына җырны болай дип тә сибәләр (аны хор эчендә кем әйткәнен дә сизмисең):

Туктаган, туктаган,
Факиһә белән йоклаган...

Кем белә, бәлки яшьлек мутлыгы белән теге тыныч заманда анысы да булгандыр. Менә үзе хәбәрсез югалды бит әле, бәлки йоклаган да булыр иде...

Кайвакытта тәссез генә, тонык кына уен уйнала. Монысының да максаты бер генә, җай чыгарган булып әнә теге фронтта йөргән егетнең исемен телгә алу, хыялда гына булса да кыз белән егетне җырда кавыштыру. Җырның сүзләре дә искиткеч гади, крестьянча колорит белән сугарылган...

Алай түгел, болай ул,
Арпа түгел, бодай ул.
Миңнисламнарның туенда
Менә шулай була ул.

Шуны әйткәндә уртадагы кыз әйләнеп бии.

Икенче җәйдә сугыш вакытында калкып чыккан егетләрне дә уенга ала башладылар. Уенның тавышы кәрәйде. Яңа көйләр, яңа уеннар чыкты. Мәсәлән, яшь егетләрне уртага болай алалар: кызлар түгәрәк булып әйләнәләр. Яшь егетләр гамьсезләнеп читтә тәмәке тартып торалар. Уртадагы ялгыз кыз янына читтәге теләсә кемне кертергә хорның көче җитә.

Ну-ка, Миңләхмәт, бас әле,
Ну-ка, Миңләхмәт, бас әле.

(Шул вакыт Миңләхмәт тәмәкесен ташлап уртага кереп китә.)

...Сугышка кадәрге түгәрәк уеннарында башлап йөргән өлкән кызлар инде картая башладылар. Яшьләр үскән саен аларга инде уңайсызрак була башлады. Ул арада инде кайсы егетнең үлгәне, кайсының гарипләнеп госпитальгә әләгүе турында да хәбәрләр килде. Күңелдә бу уеннар гына төзәтә алмаслык җәрәхәтләр ясалды.

...Менә бер көнне бакча башыннан гына уен карарга дип Айсылу да төште. Кече лейтенант Габдрахман кырык беренче елда Мәскәү янында һәлак булган иде. Айсылу ул вакытта оборона эшендә иде. Кырык икенче елның мартында шуннан авырып кайтты. Зифа буйлы, шомырт кара күзле бу кызга сокланмаган кеше авылда юк иде. Менә хәзер ул инде ике елдан бирле урын өстендә үлем көтеп ята. Элеккеге тулылыкның эзе дә калмаган. Күзләрдә хәят чаткылары сүнгән. Йөзләр саргайган. Нәрсәгә төшкән ул монда? Бәлки ул үзенең яшьлек таңында бөреләнә башлап ачыла алмый калган мәхәббәтен эзлидер? Бәлки ул сагашып йөридер? Әллә ул үз гомерендә беренче тапкыр кешеләргә ачыктан-ачык җыр белән әйткән мәхәббәтенең эзләрен сагынып йөриме? Әллә ул, гомумән, тормыш белән саубуллашып йөркме? Менә кемнәрдер аның янына килделәр, кемнәрдер аны уенга алып керделәр. Бераздан ул инде уртада басып тора иде. Аңа «җәза» үтәттеләр. Ә ул болай дип җырлады:

Аклы ситса күлмәгемнең
Караласы юк аның.
Йөрәгемә кан урнашкан,
Тараласы юк аның.

Бу — Айсылуның халык алдында яшь гомере белән саубуллашуы иде, шул җәйне аның гомере өзелде. Аның яшисе килә иде, ләкин ул дөньяны каргамыйча үлде. Ул үзенең үлемен Ватан өчен, халык өчен эшләнгән эш дип сыкранмыйча, еламыйча дөньядан китте. Аһ, мин әгәр дә аның шул соңгы җырын ишетмәгән булсам! Аһ, әгәр дә минем сабый йөрәгем шул вакытта бу җыр тәэсирендә телгәләнмичә калган булса! Халыкның җырлы уеннары турында язганда минем күз алдымда табигатьнең нәкъ шул гүзәл бер фәрештәсе, сугышның нәкъ шул рәхимсез корбаны тора.

Безнең авылның су буенда уен җырлары нәкъ шулай тормышның җанлы шаһитләре булып сугышны тәмамладылар.

## Урамда җырлап йөрү

Монысында егетләр генә була. (Хәер, Новосибирск өлкәсенең бер татар авылында мин хатын-кызларның да урамнан гармунга җырлап узганнарын күрдем.) Болар урамның тигезрәк, тузансызрак җиреннән җайга гына атлыйлар. Бер гармунчы янында бердән алып 15—20 гә кадәр егет җырлап бара. Егетләрнең саны 5—6 дан артса, аллы-артлы тезеләләр. Сабан туй көннәрендә, рекрутлар йөргән вакытларда икешәр гармун белән, икешәр кат тезелеп тә урам әйләнәләр. Кечкенә уенга барганчы бер кат үзәк урамнарны әйләнеп чыгалар. Урамда йөргәндә авызга тәмәке кабылмый, әдәпсез җырлар җырланмый. Авылның, колхозның могътәбәр кешеләре капкасы турысыннан узганда җыр өзелеп тора. Берәүнең өендә көчле авыру булса — алар турысында да җырламыйлар. Җырны бер урамнан барганда бер егет, икенчесеннән барганда икенче егет башлый. Яки кочаклашып тезелгән уңайга чираттан да башлыйлар. Капка төпләрендә кемнәр утыра; кемнәр турысыннан узасың; бу кешеләр белән җыр башлаучы нинди мөнәсәбәттә — җырлар әнә шуңа карап сайлап алына. Мәсәлән, капка төбе тулы җиткән кызлар утыра. Монда инде җырның мәгънәлесен, куәтлесен сайлап җырларга кирәк. Монда синең дә, минем дә җанаш утыра. Егетләр андый вакытта аеруча төмле телле булалар.

Биек тауның башларында
Төркем-төркем таллар бар.
Безнең илләр — сәхрә җирләр,
Сөйсәң асыл ярлар бар.

Кызлар бу егетләрне үзләре янына туктарлар дип өмет иткәннәр иде, тик гармунчы туктасы итмәде. Гармунчы — иң зур дәрәҗәле, иң абруйлы егет. Аның сүзенә буйсынмыйча булмый. Тукта, кызлар үпкәләсә ни хәл итәрсең? Җыр башлаучының теленә шайтан гына төкергән!

Урамыгыз матур икән
Алма тәгәрәтергә.
Хәтерләрегез калгандыр,
Ничек бәхилләтергә!

Алда бер төркем яшь кызлар берәүнең капка төбендәге эскәмиягә тезелешеп утырганнар. Болар әле су буендагы уенга кермиләр, читтән-миттән чыркылдашып йөриләр. Ләкин... Яшь димә, бала димә, киләсе җәйгә шулардан да сылу кыз булмас! Бәс, шулай икән, рәхим ит, күңелләрен күреп кит.

Ал да була, күк тә була
Буяучының буявы.
Йөгереп чыгып суырып үбә
Яшь кызларның уявы.

Кызлар чыркылдаштылар, пәкин җыр инде үзенекен эшләде. Ул инде яшьлек мутлыкларына искиткеч үткен ишарә ясады, кызлык гомеренең серле, мәгънәле, сихри дөньясына чакыру ташлады...

Менә алдарак чат буендагы капка төбендә тәмәке утлары җемелдәде. Төркемдәге җырчы егет бу капка төбендә кемнәр утырганын бөтен тәкләре белән сизде. Монда аны һәм гармунчы дусын яратмаган агалы-энеле ике абзый утыра. Бу ачу күптәннән килә, моның очы теге абзыйларның сеңелләренә барып бәйләнә. Арага керделәр... Ну, ярый, сез шулай дошман булып яши бирегез әле. Ә без... безне бер нишләтә алмассыз. Чөнки:

Безнең дуслар шундый дуслар,
Бер-берсен ташламаслар.
Безнең башлар балык түгел,
Пешереп ашамаслар.

Гармунчы бүтәннәр башлаганчы дип ашыгып икенчесен үзе үк башлады. Чөнки күңелдәгесен әйтеп үтәсе килә.

Безне дошманнар куралмый,
Талдан читән үралмый.
Үреп карый, сүтеп карый,
Берни дә булдыралмый.

Катырак әйтелде булса кирәк. Инде боларның турысыннан узгач бераз йомшартыбрак алганда да зыян итмәс.

Сандугачлар җыелганнар,
Без алай җыелмыйбыз.
Дуска түгел, дошманга да
Без кара коелмыйбыз.

Менә шулай капка төбендә, өендә утырган яше-карты, кызы-килене белән сөйләшә-сөйләшә, урамнан егетләр узәлар. Кич белән урамнан җырлап узу — егетлек чорының почетлы бер акты, урамнан гармун белән узган төркемгә халык зур ихтирам, соклану белән карый. Урамнан килгән бу төркемгә атларын читкә борып атлылар юл бирә, карчыклар капка ярыгыннан гына борыннарын тыгып бу төркемне карап кала. Монда көч, монда бердәмлек, монда халык акылы, халык моңы. Бу — илдә иминлек билгесе. Бу — татар халкының мең еллык тәҗрибәсен туплаган шигърияте, халык операсы...

Кичке уен тарала... Егет кеше өчен иң зур дәрәҗә — авылыңда сөйгән кызың булу. Әйе, ул синеке, аңа беркем дә, берничек тә кулын сала алмый. Егетләр үз кызларын озата киталәр. Менә бер капка төбендә пар күгәрчен гөрли. Икенчесендә... Башка якларда ничектер, әмма безнең якларда кызның үз капка төбендә генә утырыла иде. Әлбәттә, әтисе шушы хәлгә түзә торган кеше булганда инде... Менә төн уртасы җитә, аерылышулар, вәгъдәләр. Шул вакытта урамнан, су буйларыннан ялгыз җырлап кайтучыларның тавышлары ишетелә. Менә шунда инде кешенең бөтен эчке дөньясы ачыла! Егет әкрен генә атлый. Урам тын. Эт тә өрми. Сагыш, сагыш...

Менә берәү үзенең кызы белән ачуланышып аерылышты. Кызы бик кискен итеп:

— Гаеп итештән булмасын, моннан соң син мине белмисең, мин сине белмим,— диде. Арага кемдер кергән... Егет искиткеч каты хәсрәткә батып акрын гына җырлап кайта.

Күп эзләдем, таба алмадым
Имән яф(ы)ракларын.
Эзләп кара, тапмассыңмы
Миннән яхшыракларын...

Әнә аргы як урамнан карт егет Галиәхмәт җырлап кайта. Ул инде болай гына йөри, аның сөйгән кызы үпкә авыруы белән газап чикте-чикте дә хәзер салкын кабергә керде. Галиәхмәткә бөтен дөнья салкын бушлык булып күренә, ул һәр кичне соң гына шулай җырлап уза.

Бәгырем, сине төштә күрдем,
Караватта ятасың.
Йөрәгемнең уртасында
Алсу чәчәк атасың...

Авыл йоклый, ләкин аның рухи тормышы яши.

Иртәгесен көтү куганда карчыклар, хатыннар моны дәвам итәрләр.

— Һай, бу Галиәхмәтнең үзәкләремне өзүләре. Һич кенә дә оныта алмый бит Зөләйхасын...

— Әйтмә дә, сөйләмә дә. Шуның җырыннан соң төне буе йокым кермичә елап чыктым.

Урамнан җырлап узу — авыл тормышының аерылгысыз бер кисәге иде...

## Йомгак урынына

Кичке җырлы уеннар, урамда җырлап йөрүләр инде бетте. Тормыш шулай үзгәрештә. Боларны инде һич тә кире кайтарып булмый (һәр заманның үз гадәте бар), сүз ул турыда бармый. Сүз — әнә шул җырларны, шул гадәтләрне, тарихи материал буларак, кәгазьгә төшереп калдыруның кирәклеге турында гына бара.

Һәр нәрсә агышта, һәр нәрсә үзгәрештә. Тормышның кануннары шундый...

Менә бу язмаларымны тәмамлап утырам. Күрше бүлмәдә кызым телевизорны кабызды. Анда яңа заман авазы белән сугарылган классик музыка галибанә яңгырап бүлмәне тутырды. Ниндидер биеклек, югарылык... Скрипачлар ансамбле Дмитрий Шостаковичның яңа әсәрен башкара икән. Мин, каләмемне куеп, ирексездән музыка дөньясына чумам һәм күзләремне йомам... Шул вакыт минем күз алдыма үзәнең калын җилкәсе белән сугыш авырлыкларын җиңеп чыккан сыкранмас халкым килеп баса. Әнә алар тальян гармун белән эштән соң урамда җырлап йөриләр. Әнә алар җырлый-җырлый сөешәләр, кавышалар, бәйрәм итәләр. Җыр белән алар изге Ватанны сакларга сугышка чыгып китәләр. Җыр белән үләләр. Ватан өчен үләләр...

# ХАЛЫК МОҢНАРЫНА һӘЙКӘЛ

Гадәттә, халыкның музыкаль фольклорын популяр җырлар һәм йола җырлары дип йөртелгән зур ике төркемгә бүләләр. Шуларның беренчесе — популяр җырлар — бездә ярыйсы ук нык өйрәнелгән. Моңарчы чыккан җыентыклар нигездә шундый җырлардан төзелә килде. Бер аларга таянып кына татар халкының катлаулы һәм ифрат бай музыкаль культурасы хакында төпле фикер йөртеп булмый, билгеле. Төпле фикер әйтер өчен, археологлар кебек, күп казынырга, «моң чишмәләре»нең астагы катламнарын күтәрергә һәм, фольклорга булган романтик карашлардан арынып, фәнни нигезләргә күчәргә кирәк булды.

Аннан соң халыкның музыка мирасын Казан татарлары белән генә чикләргә теләү дә фәнгә шактый зыян китерде.

1950 нче елларда керәшен татарларының «Суда балык йөзәдер» җыры яңгырый башлагач, күпләр аптырап калды. Колакта ниндидер таныш, ерак моңнар чыңлап киткәндәй булды. Мишәр татарларының җырларында күп кенә үзенчәлекле аерымлыклар барлыгы беленде. Шуның өстенә, себер татарларының безнең колакка ятрак интонацияләре барлыгы ачыкланды. Музыкаль фольклорга караган барлык бәхәсле якларны фәнни нигезләрдә хәл итү мәсьәләсе көн тәртибенә басты. Шушы максатлардан чыгып булса кирәк, 1958 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты каршында халык музыкасы кабинеты оештырылды. Бүген кулыбызда шул кабинетның беренче фундаменталь хезмәте — «Татар халык җырлары»[1]. Аларны җыючы һәм фәнни нигездә тикшерүче кеше — музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов[2].

Бу китап чыкканчы, автор магнитофон белән Горький, Пенза, Саратов, Волгоград һәм Әстерхан өлкәләрен, Мордва һәм Татарстан АССРның күп кенә авылларын аркылыга-буйга иңләгән. Йөзләгән җыр-көйләрнең күп төрле вариантларын язып алган. Ахырдан, шуларның иң оригиналь үрнәкләрен нотага салып, әлеге җыентыкны төзегән.

«Төзүчедән» дигән зур булмаган бүлектә татар халык музыкасын җыю һәм бастыру тарихы яктыртыла. «Кереш сүз»дә Казан татарлары, мишәр һәм керәшен көйләренең стиль аерымлыклары һәм уртак яклары тикшерелә. Җыентыкның ахырында һәр көйнең кемнән, кайда һәм кайчан язып алынуы хакында тулы мәгълүмат бирелә, аерым көйләрнең интонация һәм лад үзенчәлекләре аңлатыла.

Татар халкының хезмәт белән бәйләнгән җырлары моңарчы бер кайда да басылганы юк иде. Алар белән беренче тапкыр без М. Нигъмәтҗанов төзегән шушы җыентыкта танышабыз. Шулардан берсе — «Тула басулары авыр эш» дигәне әле 20 нче елларда да Мамадыш районында яшәүче керәшен татарларының тула басу өмәләрендә еш яңгыраган. Аларда печән чапканда, урак урган вакытларда башкарыла торган махсус җырлар булган («Урсам —

---

[1] М. Нигметзянов. Татарские народные песни. Рус телендә. «Советский композитор» нәшрияты. Мәскәү. Редакторы А. С. Ключарев.

[2] Җыентыкта фольклор галиме Х. Ярми, композиторлардан Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин һәм И. Шәмсетдинов язмалары да файдаланылган.

уракларым утмидер»). Боларга өстәп, сөрән көе булуын да әйтеп үтәргә кирәк.

Шунысы кызык, хезмәт җырлары нигәдер керәшен татарларында гына сакланып калган. Аларның нигезендә өч, дүрт яки биш тавыштан торган лад формалары ята. Үз чиратында, бу формалар Казан татарларының традицион фольклорына да хас. Димәк, ул җырларны Урта Идел татарлары фольклорының иң борынгы үрнәкләре дип карарга була.

Халкыбызның йола поэзиясеннән кыз елату һәм туй җырлары филолог-фольклористлар тырышлыгы белән шактый тулы өйрәнелгән иде. Алар башлаган эшне М. Нигъмәтҗанов та дәвам иттерә. Әйтергә кирәк, уңышлы дәвам иттерә.

Туй йоласына караган җырлар арасында кыз елатуга багышланганнары аерым игътибарга лаек. Алар турында филолог-фольклористлар шулай ук шактый күп язды[1]. И. Надиров бу гадәтнең мишәр һәм керәшен татарлары арасында киң таралган булуын һәм кыз елату җырларының төрле җирләрдә төрлечә («Таң кучат», «Әҗәл итеп елау», «Әтеки әйттерү», «Тудыкайлар») йөртелүен әйтә. И. Надиров китабында мишәр татарларының бу йолага караган үрнәкләре күп булса да, керәшен татарларына караган бер генә мисал китерелә.

М. Нигъмәтҗанов китабында да кыз елату җырларына күп урын бирелгән. Монда кызны елатырга килгәч («Саулармысез»), өйдән бирнә чыгарганда («Аппак, аппак карлар ява»), кызның үз өе белән саубуллашканда һәм егет өенә барганда башкарыла торган («Айникәрәм») җырлар бар. Керәшен татарларыннан да ике үрнәк китерелгән. Тик бу үрнәкләрнең турыдантуры кыз елату йоласы белән бәйләнгән булуына гына ышанып бетәсе килми.

Кыз елату җырлары Казан татарлары арасында очрамый диярлек. Күргәнебезчә, керәшеннәрдә дә бар белән юк арасында гына. Әллә бу йола аларда бөтенләй булмаганмы? Күп кенә тикшеренүчеләр, шул исәптән М. Нигъмәтҗанов та, кыз елату җырларының Казан татарларында сакланмавын шәригатьнең мәҗүси йолалар һәм ышанулар белән бәйләнешле һәр нәрсәне тормыштан кысрыклап чыгаруы белән аңлаталар. Мондый фикер җырларның башка төрләренә карата да еш кулланыла. Һичшиксез, дин әһелләре мәҗүсилек чорыннан килгән иске йолаларга каты каршылык күрсәткән. Тик кыз елату җырларының сакланмавын дингә генә бәйләп аңлату ышандырып җиткерми. Дин әһелләре күпме генә кысмасын, скрипкә, курай, кубызны юкка чыгара алмаган, җыеннарда җырлауларны, яшьләрнең җәйге уеннар вакытында, язгы һәм көзге кичләрдә, аулак өйләрдә музыка, җыр һәм биюләрне тыя алмаган. Җитмәсә, соңгы гасырның икенче яртысында, ислам куйган киртәләрне җимереп, татарларга тальян гармун килеп керә. Яңа җырлар да чыгудан туктамый. Ислам татар музыка культурасын юкка чыгара алмаган. Чөнки халык иҗатының үзенең объектив үсеш законнары бар.

Җыентыкның зур өлешен мәҗлес җырлары билән тора (халкыбызның кунакчыллыгы җырларда да урын тапкан). Шуларның егерме икесе керәшен татарларыннан язып алынган. Ә берсе («Чү-чү, абзыем») кайчандыр Казан ханлыгыннан качып киткән татарларныкы (хәзер алар Волгоград өлкәсендә яшиләр). Авыл халкының сөйләвенә караганда, бу мондагы татарларның иң борынгы көйләреннән берсе икән. «Ике кисәкле булуы һәм ладның субдоминанта-тоника юнәлешендә үсүе белән бу көй Казан татарлары фольклорына якын тора», ди автор.

Мәҗлес җырлары белән танышкач, күңелдә тагын сорау туа: ә соң Казан татарларында бу жанрга караган җырлар булмаганмыни?!. Бу сорауга халыкның үз җыры белән үк җавап биреп булыр иде кебек:

Мәҗелесләр күркәм булсын,
Җырлап утырыйк әле.

Мондый куплетлар иксез-чиксез. Ә көйләргә килгәндә? Казан татарлары арасында махсус мәҗлес көйләре очрамый диярлек. Мондый очракларда алар төрле жанрга караган көйләрдән файдаланалар. Бу хәлне халык җырларының күп кырлы һәм көнкүрештә төрле вазифаларны үти алырлык булып камиллләшүе белән аңлатырга кирәктер бәлкем? Көйләрнең беркетелгән махсус сүзләре булуы һәм бары тик бер уңай белән генә башкарылуы — борынгылыкка ишарә булса кирәк. Бер жанрның икенчесенә бәйләнеп китүе, бер көйгә күп һәм төрле мәгънәдәге куплетлар җырлануы татар музыка культурасындагы гаять кызыклы күренеш. Ул үзенең тикшеренүчеләрен көтеп ята.

---

[1] И. Надиров. Татар халык җырлары. Казан. 1965. 26—27 битләр; Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан. 1967. 195—198 битләр.

Җыентыкта уен җырлары да шактый. Менә керәшен һәм мишәр татарлары арасында киң таралган «Нардуган» дигән йола җыры. Яңа елны каршы алуга багышланган бу йола татарлар яшәгән аерым районнарда XX гасыр башларына кадәр саклanып килгән. Ул вакытта төрле җырлы уеннар уйналган. Китапта шуларның берсенең нота язмасы бирелә. Бу бүлектә хәзерге заман уен җырлары да байтак. Тик «Гармунчы булсын ярың» дигәне генә безне бераз аптырашта калдырды. Искәрмә бүлегендә көйне (димәк, сүзсез генә) композитор З. Хәбибуллин язып алганлыгы әйтелә. Шундый ук көй, ләкин башка сүзләр белән А. Ключарев төзегән җыентыкта да бар[1], исеме дә бүтән. М. Нигъмәтҗановның З. Хәйруллина төзегән «Халык җырлый» җыентыгына таянуы да нигезле дип әйтеп булмый. Анда бары тик сүзләре генә китерелә, көй турында мәгълүмат юк. Димәк, безнең заман җырларына да зур саклык белән якын килергә кирәк икән.

Әлеге җыентыгында М. Нигъмәтҗанов, фольклорчылар арасыннан беренче булarак, бәетләрнең этнографик үзенчәлекләрен тикшерә, бу үзенчәлекләр аларның лад төзелешләрендә ятканлыгын ачыклый. Монда традицион «Герман», «Япон» һәм «Җиде кыз бәете», урманнарда качып яшәп, тирә-якны дер селкетеп торган каччкын «Ташкай» (Горький өлкәсе, Сергач районында язып алынган), ябышып чыккан кыз («Кызыл билбавым») һәм мишәрләр арасында иң яратып башкарылган җырлардан «Абдельман купич»[2] бәете һ. б. тикшерелә.

Әстерхан татарларының бәетләргә якын торган, речитатив характердагы кушавазлары бар. Аларны думбрага кушылып көйләп сөйлиләр. Тик нигәдер ике кушавазның да көе генә бирелгән, ә сүзләре юк. Сүзләрен дә китерергә кирәк иде. Чөнки аларның борынгы чичәннәребез иҗаты белән бәйләнеше булуы бик мөмкин.

Йола белән бәйләнмәгән зур бер өлешне лирик җырлар тәшкил итә. Җыентыкта вариантлары белән борынгы 248 исемендәге көй булса, шуларның 186 сы лирик җырлар. Монда «Алтын кармак», «Чатырлар», «Абау, гөлкәем», «Тал читәннәр», «Сәхраләргә чыксам», «Сагынам сине», «Көләү Гайшә» һәм киң массага мәгълүм булган «Гөлҗамал», «Су буйлап», «Умырзая» кебек җырларны очратырга мөмкин. Лад, ритм һәм интонация төзелешенең киңлеге һәм катлаулы булуы белән аерылган, тарихи, этнографик һәм стиль катламнарын үзенә сеңдергән гаять күп кырлы жанр ул лирик җыр. Җыентыкны уйнап-җырлап чыкканнан соң, беренче мәртәбә мишәр татарларының лирик җырларга бай хәзинәсен бөтен тулылыгы белән диярлек күз алдына китереп була.

Җыентыкта шулай ук рекрутлар һәм көнкүреш җырлары һәм төрле уен кораллары башкаруында язып алынган көйләр тупланган. Аларның һәрберсенә бәйнәбәйнә тукталып тормыйбыз.

Җырларның текстлары турында берничә сүз. 190 җырның 51 е берәр куплет белән генә бирелгән, җидесенә филологфольклористлар язып алган куплетлар өстәлгән. Иҗади ярдәмләшү мәслихәт эш. Тик өстәлгәннәрнең дә икесе (№ 15, 117) берәр генә килеш калган. Әгәр филологлар ярдәмгә килмәсә, алар «сүзсез җыр» булып калган булырлар иде.

Җырларны басып чыгару гына җитми, аларны пропагандалау турында да кайгыртырга кирәк. Радио-телевидение, филармониянең музыкаль лекторие һәм, ниһаять, И. Шакиров кебек халык моңнарын «чын безнеңчә матур, милли көй» итеп башкарырга сәләтле талант иялəребез бар. Тик... бер куплетлы җырны сәхнәдә җырлау кыен булачак бит! Автор «лирик җырларда текст белән музыканың бәйләнеше һәр вакытта да абсолют түгел» икәнлеген әйтә, һәм бу караш күптән яшәп килә. Шулай булгач, бер үк дүрт юллык ике җырда очраса да, кабатланудан курыкмаска кирәк иде. Мәсәлән,

Утырдым ла көймә әй түренә
Карадым ла суның төбенә,—

дип башланган җырның берничә оригиналь көе бар. Сүзләре кабатлана дип, без ул мөстәкыйль көйне җырламаска һәм китапка кертмәскә тиеш булабызмыни?

Ике «Түгәрәк уен көе» (№ 191 һәм 192) җыр көйләре бүлегендә. Искәрмәдә уникe кешелек ирләр һәм хатын-кызлар группасыннан язып алынганлыгы әйтелә. Ә институтның фондында сакланган язмада ике җыр да сүзләре белән. Х. Ярми язып ал-

[1] Татар халык көйләре. Төзүчесе һәм жыючысы А. Ключарев. Казан. 1955 ел. 58 бит.

[2] «Ташкай һәм «Абдельман купич» җырларын филолог-фольклорист Ф. Урманчиев тарихи җырларга кертә. Кара: «Казан утлары». 1969 ел. 3 сан.

ган «Үги ана җыры» белән дә шундый ук хәл. Бу нәрсә, ашыгумы? Бәндә хатадан хали түгел, ди халык. Мондый искиткеч авыр хезмәтне башкарып чыгучылар да шулай (чөнки музыкант-фольклористларны бер уку йортында да хәзерләмиләр бит).

Ләкин югарыда әйтеп үтелгән кимчелекләр генә бу хезмәтнең асылын күрергә комачауламыйлар. Ә җыентыкның асылы, безнеңчә, ике зур этник төркемнең — керәшен һәм мишәр татарларының күңелендә яткан һәм гомумтатар халык иҗатының ике зур булеген тәшкил иткән, ә шулай булуга карамастан, нигездә безнең көннәргә кадәр киң җәмәгатьчелек өчен генә түгел, фән өчен дә һәм композиторлар, музыка белгечләре өчен дә «томан артында» булган бай музыка культурасы мирасын ачуда. «Татар халык җырлары» — зур һәм җитди фәнни хезмәт. Ул әле күп яклы тәфсилләп тикшерүне таләп итәргә бик хаклы. Без андый максатны үз алдыбызга куймадык. Бу киләчәк эше дип уйлыйбыз.

**И. КАДЫЙРОВ.**

# БАРЫБЫЗ ӨЧЕН ДӘ КИРӘКЛЕ КИТАП

Әдипләребез елдан-ел күбәя, алар иҗат иткән әдәби әсәрләрнең дә исәбе-хисабы юк. Ләкин, шулай булуга да карамастан, моңарчы әдәбият бакчабызның бер чите сөрелмичә дә, чәчелмичә дә ята иде. Мин моны урман-кырларыбызда, елга-күлләребездә яши торган кошлар, җәнлекләр, балыклар һәм бөҗәкләр, бездә үсә торган үсемлекләр турында язучы әдипләребез булмавын күздә тотып әйтәм. Ниһаять, менә шул яткын җиребез дә сөрелә башланды. Һәм ул шактый ышанычлы куллы, тәҗрибәле кеше тарафыннан сөрелә башланды. Сүз инде акыл утырткан, тормышның ачысын-төчесен күп күргән, бала чагыннан ук табигатькә гашыйк һәм хәзер дә кышын-җәен табигать эчендә — Казан тирәсендәге коллектив бакчаларның берсендә каравылчы булып яши торган Гарәфи Хәсәнов турында бара.

Гарәфи Хәсәновның беренче китабы 1968 елда чыккан иде. «Унике матур» дигән ул китап балаларга адресланган булса да, мин аны рәхәтләнеп, бер тын белән «йотып» җибәргәнемне әле дә яхшы хәтерлим. Китапның эчтәлеге дә истә. Елның унике ае турында сүз бара анда. Бер карaганда, бик гади генә. Чыннан да, елның унике аен кем белми дә, ул айларның алай шаккатмалы нәрсәсе бар инде? Китапны кулга алганда мин әнә шундыйрак фикердә идем. Ләкин берничә битен уку белән бу уемның дөрес булмаганына төшендем. Күрә белгән кешегә тоташ буран-җилләрдән һәм чатнама суыклардан гына торган январь аенда да искиткеч кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр була икән ләбаса! Нәкъ әнә шул утыз-утыз биш градуслы салкын көннәрдә кайбер кошлар күкәй салып, ояларында басып утыра, кайбер балыклар уылдык чәчә, тагын әллә ниләр, тагын әллә ниләр эшләнә икән табигатьтә. Без уйлаганча, салкын һәм караңгы ай гына түгел, кайбер тереклек ияләренә тормыш китерә торган бик мөһим, көтеп алына торган ай да икән ич әле ул. Унике матурның берсе икән. Ә башкалары тагын үзенчә матур икән. Тик ул матурлыкны күрә белергә, игътибарлы булырга гына кирәк икән.

Менә шул табигатькә игътибарлы булганы өчен, аның серләрен аңлый белгәче өчен һәм үзе белгәнне, үзе күргәнне безгә — укучыларга да иләп кенә, ялыктырмыйча гына сөйләп бирә белгәче өчен яратып укыган идем мин Гарәфи Хәсәновның «Унике матур»ын.

Ниһаять, байтак көттергәннән соң, быел аның икенче китабы — «Җирем-суым»ы басылып чыкты. Мин аны, әлбәттә, кызыксынып һәм шул ук вакытта бераз сагаеп та укырга тотындым.

Нигә кызыксынуым аңлашыла булса кирәк. Ә борчылуымның сәбәбе болай: автор әдәбиятыбыз өчен бик тә тансык булган табигать темасына хыянәт итмәгәнме? Әгәр шул ул табигать турында язган булса, иҗатында алга китеш бармы?

Китапны алга таба укыган саен бу шикләрем кими барды. Ә укып чыкканнан соң бөтенләй бетте. Юк, бу китабында да үз темасына хыянәт итмәгән Гарәфи Хәсәнов. Шул ук үзебезнең Татарстан табигате. Безгә таныш урман-кырлар, шул ук елга-күлләр. Шул җир-суда яшәүче җәнлекләр,

кош-кортлар, бөҗәкләр, шунда үсә торган үсемлекләр. Без аларның байтагын үз күзләребез белән күргәнебез дә бар. Ә кайберләрен ишетеп, китаплардан укып яки кинофильмнардан күреп беләбез. Ләкин бөтенесен дә түгел. Күбесен белмибез икән әле. Аннары шунысын да игътибарга алыйк: безгә бик таныш булганнарының да без белмәгән бик күп хикмәтләре бар икән әле ул кош-кортларның. Җәнлекләрнең, балык һәм бакаларның да безгә мәгълүм булмаган бик күп кызыклы һәм гыйбрәтле яклары бар икән.

Әйтик, минә авыл җирендә үсә торган, һәр кешегә яхшы таныш булган төнбоек. Без аның турында нәрсәләр беләбез? Тәпинкә итеп су өстенә җәелгән ямь-яшел яфракларын һәм яфраклары арасында әллә кайдан ук күзгә күренеп, талгын дулкында тирбәлеп утыра торган зур һәм ак чәчәкләрен. Ә алар холыкларын белгән кешегә моннан тыш та күп нәрсә «сөйли» алалар икән: «Төнбоекларны өркетмик без,— дип яза китапның авторы.— Көннең нинди буласын шуларга карап беләбез. Куш йодрыктай чәчәк төймәләре бергәләп өскә калыкса — көн менә дигән булачак, күтәрелми торса — көн бүген йөзен чытачак, яңгыр башланачак...»

Шул ук төнбоекның тагын мөһим гадәте бар икән әле: кырау төшәсе булганда хәтта көннәр бик нык җылыткан язларда да аның яфраклары су өстенә калыкмыйча тора, ә яфраклары күтәрелдеме — ул язда инде бүтән кырау төшми икән!

Яки менә язучыларыбыз җае туры килгән саен үз әсәрләренә кыстырып җибәрергә ярата торган артышка игътибар итик. Без аны шул артыш куагы, артыш таяк буларак кына беләбез. Гарәфи Хәсәновка аның тагын бик күп хикмәтләре таныш икән. Беренчедән, артышның, кайда үсүенә карап, буе ике-өч кенә метрлылары да, унбиш метрга җиткәннәре дә, ике йөз генә ел яши торганнары да, ике меңгә җиткәннәре дә була икән. Аннары тагын: «Артыш җиләген кышын безнең якларда үткәрә торган кош-кортлар, җәнлекләр ярата. Төньяктан кайткан чәрелдәвек, карабүрек, корташар ярата. Баркылдык, божыр, көртлек һәм урман тавыгы ярата. Төлке һәм бүре халкы да, поши да читләтеп үтми бу татлы җиләкне. Бу хикмәтле куакның сихәтен без дә күргәли торабыз. Артыш җиләгеннән ясалган баллы суга чак кына спирт кушып, тәнеңне шуның белән уасың икән — буыннарыңның сызлавын бетерә. Ник дисәң, ул кырмыска маена, һәртөрле кислоталарга да бай икән. Серкә һәм алма кислотасы, кырмыска кислотасы, аның өстенә чәер һәм балавыз да бар икән анда... Ашап та ашың сеңмәсә, шул инде булыша. Тәнеңне бизгәк калтырата башласа, я нервларың какшаса, шул инде савыктыру китерә. Әле тагын корчаңгыны бетерә... Ләкин җиләге генә димәгән: кыяр я гөмбә тозлыйм дигәндә, артышның мунчаласы ни тора! Мичкәне шуның белән юсаң, бөтен күксегәнең юк итә, төрле яман исләрне куып чыгара. Итне һәм балыкны артыш төтененә ыслыйлар. Иткә һәм балыкка шул татлы тәм бирә, бозылудан саклый... Сөткә ул әчергә ирек бирми, бүген сауган кебек тота...»

Бу «Артыш» дигән бүлектән нибары бер абзац кына, ә шунда укучы өчен никадәр яңа мәгълүмат бирелгән. Китапка кертелгән башка хикәяләр дә менә шушылай информацион яктан тыгыз, ягъни аз сүз белән күп мәгънә аңлатып язылган.

Алда китерелгән өзекләрдән чыгып, бу китап җир-су һәм андагы тереклек иясе турында шулай коры сөйләп чыгуга гына кайтып калган икән дип уйлый күрмәгез тагы. Юк, һич тә алай гына түгел. Дөрес, «Җирем-суым» билгеле бер сюжетка корылган китап түгел. Ләкин ул барыбер әдәби әсәр. Әдип каләме белән язылган, әдәби әсәрләргә куела торган таләпләргә җавап бирә торган әсәр. Чөнки андагы бүлекләрнең һәркайсында авторның табигатькә, андагы күренешләргә үз карашы, үз мөнәсәбәте бар. Шуның өстенә авторга кирәк чакта ярдәмгә аның «үзенең» өч улы бар. Табигать турында, андагы җәнлекләр, кошлар һәм үсемлекләр турында шулар сөйли. Китапта бәян ителгән һәр нәрсәне мин шулар күзе аша күрәм. Рас шулай икән — бу инде чын мәгънәсендә әдәби әсәр дигән сүз. Чөнки фәнни китапларны укыганда да, дәресләкләрне һәм һәртөрле белешмәлекләрне укыганда да әнә шулай геройларны күзаллап, аларча фикер йөртеп уку мөмкин түгел. Бу китапка кергән әсәрләрне мин үзем табигать турында хикәяләр дип атар идем. Хәер, ахыр чиктә, эш аларның исемендә түгел, җисемендә ләбаса. Ә Гарәфи Хәсәновның бу китабындагы әсәрләренең җисемнәре әйбәт, нык нигезгә корылган һәм алар, минем күңелгә хуш килгән кебек ук, бүтән күп кенә китап сөючеләрне дә канәгатьләндерер дип уйлыйм.

Әле күптән түгел генә, шушы китабы

басылып чыгу уңае белән һәм Гарәфи Хәсәновның гомумән иҗаты турында сөйләшүне күздә тотып, Язучылар союзының проза секциясе утырышы үткәрелгән иде. Анда Гарәфи Хәсәновның иҗаты һаман үсә, камилләшә барганлыгы, бу китабы элеккесенә караганда әдәби эшләнеше ягыннан әйбәтрәк икәнлеге өлкән әдипләребез тарафыннан да, яшьләр тарафыннан да бердәм рәвештә билгеләп үтелде. Ләкин шул ук вакытта Гарәфи Хәсәнов акрынрак, азрак яза, тизлеген арттыра төшсә шәбрәк булыр иде, дигән фикерне әйтүчеләр дә булды. Иптәшләр белән нигездә килешсәм дә, мин үзем авторны ашыктыру ягында түгел. Әдәбиятта ашыгып эш итүнең уңышка китерүенә шикләнәм мин. Ә Гарәфи Хәсәнов яза торган өлкәдә ашыгып эш итүнең зарарлы булачагы алдан ук билгеле. Теге яки бу җәнлек, теге яки бу үсемлек ясә кош турында өч-дүрт битлек әйбер язу өчен генә дә иң элек ул кош яки җәнлекнең тормышын, гадәтләрен бик җентекләп өйрәнергә кирәк бит аңа. Аннары шул кош ясә җәнлек турында язылган фәнни әдәбиятны, аңа кадәр башка әдипләр язганнарны укып чыгарга кирәк. Шунсыз ул хәзерге заман укучысын канәгатьләндерерлек хикәя яза алмаячак. Көч саен газета-журнал укып, радио тыңлап, телевизор карап бик күп яңа мәгълүмат алып бара торган бүгенге укучының күңелен җәлеп итәрлек әсәр язар өчен, бигрәк тә табигать турында әсәр язар өчен, әлбәттә, әдип ул укучыдан күбрәк белергә тиеш. Ә моңа җиңел генә, ашыкпошык кына ирешүне мин күз алдыма да китерә алмыйм.

Әлеге проза секциясе утырышында үзенең әйтүенә караганда, Гарәфи Хәсәнов хәзер шушы «Җирем-суым» дигән китабының дәвамын язып утыра икән. Бик әйбәт, хуплауга лаек эш бу. Табигатьтәге барлык файдалы җан ияләрен һәм үсемлекләрне саклап калу өчен илебез күләмендә генә түгел, хәтта бөтен дөнья күләмендә эш башланган хәзерге чорда бу хезмәтнең әһәмияте икеләтә артык булачак. Алдан ук ышанып әйтеп куя алам: Гарәфи Хәсәновның «Җирем-суым» исемле китабының инде басылып чыккан шушы беренче кисәген генә укып чыкса да, таш йөрәкле ук булмаса, ул кеше табигатькә бөтенләй башка күз белән, аны яратып, үз итеп карый башлар. Китап шуңа өйрәтә, аның кыйммәте әнә шунда.

Сүземне йомгаклап, тагын шуны гына өстисем килә: гәрчә титул битенә зур хәрефләр белән «Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен» дип язып куелган булса да, «Җирем-суым» балалар өчен генә түгел, барыбыз өчен дә кирәкле, барыбыз өчен дә кызыклы китап.

**Вакыйф НУРУЛЛИН.**

# ТӘЛГӘШЛӘРДӘ СУСЫЛ ҖИМЕШЛӘР

Зиннур Насыйбуллин иҗаты белән татар укучысы беренче мәртәбә 1969 елда танышкан иде. «Казан утлары»ның җиденче санында аның шигырьләре басылып чыкты. Кереш сүздә Зиннур: «...Хәзер Башкортстанның Чакмагыш районы газетасында эшлим. Кәрексәнәк, балта-пычкы, гайка ачкычы кебек эш коралларын каләмгә алыштырганчы шактый вакыт узды. Армиядән соң читтән торып урта мәктәпне бетердем. Башкорт дәүләт университетында укуны читтән торып дәвам итәм... Казан күңелне тарта»,— дип язган иде.

Бу аның кыскача тормыш юлы. Күренгәнчә, шигъриятькә ул, Уфа университеты белән бергә, «тормыш университетларын» да бетереп килгән кеше. Ә «Казан күңелне тарта» дигән сүзләре чынлап да хак булган икән, озак та тормады, Зиннур Насыйбуллин Казанга күчеп килде һәм менә аның беренче җыентыгы дөнья күрде[1].

Зиннурның иҗаты турында уйланганда, ирексездән, миләш агачы күз алдыма килә. Башка җимешләр шербәткә туенганда, миләш әле өче була, авызны бәреш-

[1] З. Насыйбуллин. Тәлгәш. Шигырьләр. Казан. 1973.

терә. Миләш шулай соңрак, башка җимешләр коелып яки кибеп беткәндә, көзге салкыннар башлангач кына өлгерә. Әмма бер өлгергәч кышкы салкында да үз төсен, үз тәмен югалтмый.

Зиннур Насыйбуллин да шулай, миләш кебек, «соңга калыбрак» өлгергән шагыйрь. Тик соң өлгерсә дә, аның «Тәлгәш»ендәге җимешләр сусыл, һәркайсының үз яме, үз тәме бар, аларның нигезенә авторның тормыш тәҗрибәсе һәм дөньяга олыларча карашы салынган. Моның шулай икәненә тәлгәштәге җимешләрне авыз итеп карау белән үк ышанасың.

Авыз итеп караганчы, тагын бер генә сүз. Берәүгә дә сер түгел, җыентык төзи белү үзе бер осталык ул. Автор бу осталыкка да ия икән. Һәр тәлгәшкә тематик яктан бер төсле шигырьләр тупланган, һәм автор әйтергә теләгән фикер шигырьдән шигырьгә үсә, тулылана, камилләшә бара. Бу — инде укучы күңеленә ышанычлы күпер салу дигән сүз.

Беренче тәлгәштән аңлашылган төп фикер шул: тормышның, яшәүнең асылы, кешенең кешелеге нидә? Шагыйрь әледәнәле шушы сорауны куя һәм аңа төрле ноктадан торып җавап бирергә омтыла. Тормышта яшәве авырмы? Авыр, әгәр:

... Йөрәксезләр өчен йөрәк булсаң,
... Кулсызларның сыңар кулы булсаң,
... Аяксызга терәк-таяк булсаң,
... Яманлыкка үчле-тешле булсаң.

Әйе, «җиңел түгел яшәү. Кеше булсаң». Юк, бу тормыштан зарлану, авырлыктан качарга өндәү түгел, бәлки мәгънәле яшәүгә, кешенең олылыгына мәдхия. Моны түбәндәге юллар да раслый:

Ләкин кеше башын салса салыр,
Кешелеген барыбер саклап калыр.

«Кешелекне саклап калу» берәүгә дә җиңел бирелми, «күкрәк киереп сынны туры тоту» кайчак авырга да туры килә, хәтта ныклык символы булган имәннәрне дә җил тегеләй дә, болай да бөгә. Ләкин кеше, киресенчә, «җилнең каршысына авыштыра үзенең гәүдәсен». Яныл, ялкынланып, тормышын сөеп яши алучы кеше генә әнә шулай давылларга бирешми. Менә аның тормыш фәлсәфәсе:

Язгы ташкын булып, ташып, тулып,
Яшәү кирәк кайнап күңелдә:
Аның, җаным, эшем — яшәү өчен,
Тәнем генә калыр үлемгә.

З. Насыйбуллинның шигырьләре иң элек тормышчан булулары белән игътибарны җәлеп итәләр. Ул шигъри бизәкләрне күктән дә чүпләми, бармак очыннан да суырып чыгармый, ә тормыштан ала. Аның илһамчысы — тормыш үзе.

Менә аеруча характерлы бер мисал. Һәр яшь кеше өлкән буыннан «тормыш йөген» кабул итеп алырга һәм аны гомере буена — киләчәк буынга тапшырганчы намус белән иңендә күтәреп барырга тиешле. Бу — шәхеснең кешелек каршындагы изге бурычы, — бу яшәү диалектикасы. Зиннур Насыйбуллин менә шушы гади тормыш күренешендә дә шигърият күрә.

Җиде диңгез кичкән чая ирләр
Кайтмас юлга китәр алдыннан
Бу дөньяның бөтен мәшәкатен
Мирас итеп безгә калдырган.

... Тик курыкмый йөкнең зурлыгыннан
Ата улы булган беркем дә —
Йөк төялгән көймә — тотрыклы,
Ә буш көймә — дулкын иркендә.

Шушы берничә юлда да шагыйрь тормыш дәреслеген, чор сулышын, яшь буынның уй-хыялларын бирә алган. Һәм, гомумән, бүгенге көн сулышын күрсәтергә омтылу Зиннур өчен хас төп сыйфат. Ул:

Хиросима
Син үткәне микән,
Киләчәге микән дөньяның,—

кебек бөтен кешелекне борчып торган проблемаларны күтәрә һәм аңа кискен җавап та бирә:

Мин ышанам:
Төтәп яткан бикфорд шнурларын
Безнең тешләр өзә алырлар.

Болар аның шагыйрь буларак кына түгел, шәхес буларак та өлгергәнен күрсәтәләр инде.

Икенче тәлгәштә төп урынны Бөек Ватан сугышына караган шигырьләр алып тора. Сугыш... Аның яралары әле дә төзәлеп җитмәгән. Алар шагыйрьнең күкрәгендә «җөйсез яра» булып әрниләр, алар «шагыйрь күңелендә әнисенең иңбашыннан шуып төшкән», ничәмә еллар инде «сөйрәлеп барган кара шәл сыйфатында уяналар»[1]. Ләкин совет кешесе дошман алдында тез чүкмәде, азатлык өчен көрәштә батырлык үрнәге күрсәтте. Аның бу сыйфаты «Исем турында баллада»да бик дөрес һәм дулкынландыргыч итеп күрсәтелгән.

---

[1] Н. Арслановның әлеге китапка язган кереш сүзеннән.

...Көтте палач
Кискән агач кебек,
Корбанының авып төшкәнен.
Ләкин кеше ерткыч йөзгә төбәп
Тәнердә тик сынган төшләрен.
...Түзде кеше.
Газап авазына
Нәфрәтенә төенеп, үченә,
Авызындагы каны белән бергә
Исемен дә йотты эченә...

«Безнең көнгә карый Спартак», «Яшьтәшләрең китә армиягә», «Җәйсез яра», «Юк, билгесез түгел» кебек шигырьләрдә дә җиңелмәс көрәшче образы гәүдәләнә. Һәм Зиннур бу шигырьләре аша:

Ваш июне белмәгәне өчен
Баш исән дә ярый кешегә,—

дигән фикер үткәрә.

Бу идеягә автор өченче тәлгәштә дә турылыклы булып калган. Мәхәббәттә аның өчен, барысыннан да бигрәк, сафлык, турылык һәм тигезлек кадерле. Шушы фикерләрне яклап ул:

Барысын да уртаклашып, безгә
Гомер юлын бергә үтәргә.
Тимер юлда рельслар да шулай
Бөтен йөкне уртак күтәрә,—

ди.

Әмма кулдагы бармаклар тигез булмаган кебек, тәлгәштәге җимешләр дә тигез пешмәгән әле. Андагы кайбер шигырьләр (мәсәлән, «Кешенең бит табигате шундый», «...Тынычлан дим, йөрәгемә», «...Шундый чаклар була», «...Качар идем кайчак дусымның» кебек шигырьләр) образлы этләүгә түгел, ә бәлки нинди дә булса фикерне шигъри калыпка салып сөйләп чыгуга корылганнар. Һәм, һичшиксез, мондый шигырьләрнең күпчелегендә «дип», «диләр» кебек артык сүзләр килеп керә, ә шигъри тукыманы булдыруда аларның бернинди әһәмияте булмый. Әйбәт кенә язылган «Колларга һәйкәл» шигырендә дә бу кимчелектән котыла алмаган шагыйрь:

Пирамидаларны төзегәндә
Каннан, диләр, измә изелгән.

Биредә «диләр» ник кирәкте икән? Билгеле инде, буш урынны тутыру өчен. Ә шушы урынсыз кулланылган бер сүз күзгә кергән чүп кебек (бу урында Зиннурның үз сүзләрен искә төшерик: «Күзләрем бөтен дөньяны болганчык күргән иде, ә бит күземә нибары чүп кенә кергән иде) күңелне тырнап, шигырьнең эмоциональлеген киметеп тора.

Тынычлан, дим, йөрәгемә,
Ярсыма, дим, ярсыма:
Барыбер, дим, син дигәнчә
Булып бетми барсы да.

Бу юллардагы «дим-димнәр» дә тутәлдә үскән әрем кебек.

Зиннурның бик шәп әйтелгән сүзләре бар.

Сандал белән чүкеч арасында
Кылыч туа.

Күренгәнчә, шигърияттә үткен кылыч булып җитәр өчен Зиннурның тагын да чүкелəсе бар әле. Шагыйрь үз сүзләрен онытмас дип ышаныйк.

Н. ГАМБӘРОВ,
Казан дәүләт университеты студенты.

Шәүкәт Галиев

## Хәерле юл!

Барабыз да без бергә,
Басабыз да бер үргә,
Поезд көтеп алабыз,
Куллар болгап калабыз.
Таныш түгел абыйлар
Кайчак яулык болгыйлар,
Я болгап та тормыйлар...
Без барыбер киләбез,
— Хәерле юл! — диябез.

Вагоннар тиз үтәләр,
Җил чыгарып китәләр.
Шунда киләсе килә,
Поезд күрәсе килә;
Кычкырып узып китсә,
Әллә-әллә нишләтә...
Үсеп җитәрбез әле,
Үтеп китәрбез әле
Вагоннарга төялеп,
Тәрәзәгә сөялеп...
Юлга чыгарсыз әле,
Куллар болгарсыз әле!

## Иң беренче сүз

Бер сүз дә булмаган чакта
Кем сүз уйлап чыгарган,
Ничек бик тә дөрес итеп
Исемнәр кушып барган?

Ничек «бүре» димәгән ул,
«Куян» дигән куянга.
(Чыгарлар иде куяннар
Бүреләрне куарга!)?

Алманы «алма» дигән бит,
«Суган» диеп куймаган.
(Башта ашап карагандыр,
Ә а[illegible]ры уйлаган.)

Тып-тын чакта әкрен генә
«Ты-ынлык» диеп торгандыр.
Шарлавык тавышын басып:
«Шаулый!» дип кычкыргандыр.

Мөгаен, зу-ур елга күргәч,
Искитеп: «И-дел!» дигән.
Чиксез урманнар, кырларны
Яратып: «И-лем» дигән.

Ә иң-иң-иң-иң беренче
Әйтте микән ни диеп?
Ашыйсы килеп уянгач,
Дәшкәндер: «Әни!» диеп...

## Безнең киң күңелгә...

Күп безнең
Дускайлар —
Яраткан
Кошкайлар.

Китәләр
Көз белән,
Кайталар
Яз белән.

Киткәндә —
Бик моңсу,
Көткәндә —
Ямансу,
Кайтканда —
Күңелле!

Монсын да
Күр инде:
Чатнама
Суыкта
Ачыккан,
Боеккан
Чыпчык та,
Песнәк тә.
Ни генә
Күрсәк т[illegible]

Илдә бит,
Бергә бит,
Бер туган
Җирдә бит!

Моңайтып
Китмәгәч,
Сагынып
Кайтмагач,
Яшәгәч
Гел бергә,
Юк мәллә
Кадер дә?

Алай ук
Түгел лә,
Яраткан
Күңелгә
Һәммәсе
Оялар!
Безнең киң
Күңелгә
Филләр дә
Сыялар!
Жирафлар
Сыялар!

## Яшьнә, яшен!

Кило яшен
Чатыр-чотыр,
Кукри күкләр
Шатыр-шотыр,
Бөтен дөнья
Калтыр-колтыр...

Курка мәче,
Курка акбай,
Курка күркә,
Курка атлар.
Мин дә азрак
Куркам хәтта.

Айкап йөрсен,
Чайкап йөрсен,
Игеннәр ник
Уйлап бирсен —
Аларга бит
Сулыш иркен!

Күкрә син күк,
Күкрә, диләр,
Безне читләп
Үтмә, диләр.
Яшьнә, яшен,
Яшьнә! — диләр.

Яшьнәп азот
Ясый бит ул,
Җиргә азык
Ташый бит ул,
Яшен җирне
Ашлый бит ул!

## Ак күләгәләр

Күрәсең кайчак
Көтү куганда —
Ак күләгәләр
Төшкән урамга:

Ак рәшәткәләр.
Ап-ак капкалар,
Өй мыеклары,
Юлда яталар...

Ак таплар, әнә,
Арба астында,
Бүкән янында,
Мичкә артында.

Ул урыннарны
Читләтеп үтәм,
Күләгәләргә
Кермим мин иртән;

Кырау качырып
Ята күләгә —
Салкын була ул
Шуңа күрә дә!

## Ни кирәген мин беләм

Машина ничек чаба,
Ничек тиз алга бара?
Шәп йөгерсен дип аңа
Шоферы бензин сала.
Бетеп китсә бензине,
Тукталасы билгеле —
Тагын өстәргә кирәк!
Машинага гел аңа
Бензин эчәргә кирәк!

Ә үземә, үземә
Ни кирәген мин беләм —
Һәйбәтләп сөт чөмерәм,
Машина күк йөгерәм!

## Телевизор булды баш

Әти-әни кунакта,
Калдык та без аулакта,
Әй карадык кинонь!!
Кинонымы, киноны
Бик яратам мин аны!

Карый торгач каралган,
Тәмам зиһен таралган —
Төш узган да кич булган,
Инде сәгать биш булган!
Ашарга да онытылган,
Эчәргә дә онытылган,
Торып китеп карасам —
Йөрергә дә онытылган!
Телевизор шикелле
Баш үзе гүләп тора —
Авыз йомык, күз йомык —
Күрсәтеп, сөйләп тора...
Кино белән тулды баш,
Телевизор булды баш!

Әйе, карый торгачтын
Караганбыз шул кадәр —
Күренер күк сезгә дә
Авызны ачсам әгәр!..
Утырып — укый алмадым,
Ятып — йоклый алмадым,
«Чама кирәк!» дигәнне
Шунда гына аңладым...

## Миңа дигәне кайда?

Салават белән Илгиз
Агалы да энеле.
Ни алсаң да аларга,
Тигез була, билгеле.

Тигез өлеш тигәнгә
Тәмам күнегеп беткән —
«Салават күпере» дип
Төртеп күрсәткәч күктән,

Бәйләнә калды Илгиз,
Һич кенә килми җайга:
— Салаватка бирдегез,
Миңа дигәне кайда?

## Чага торган күчтәнәч

Килде безгә посылка,
Эчләрендә ниләр бар?
Бигрәк тәмле исләре —
Әллә җимеш, әллә бал?

Бик әкәмәт тартмасы,
Шундый тишек-тишекле,
Якын килсәң — безелди!
Әллә ялгыш ишеттем?

Ачкач тизрәк сузылсам,
Ботыма төште котым:
Җимеш тә юк, бал да юк,
Тартмада бит бал корты!

Миңа рәхәт булмады,
Ә бабакай шатланды:
— Исән генә килдеме
Җылы як кунаклары!

Китмә, улым, күр әле,
Безгә нинди мал килде,
Карый белеп карасаң —
Тәпән-тәпән бал килде!

## Һауһауэтдин белән Мыекбикә

Эт белән мәче очрашты...
Калганы сезгә таныш —
Бер-берең не өнәмәсәң,
Юктан да чыга тавыш.

Маэмай әйтә: — Мыекбикә,
Мияулыйсың бик нечкә,
Мин авыз тутырып өрәм,
Син көчәнәсең көчкә!

Дугаланып куйган мәче,
Мыекларын тырпайткан:
— Һауһауэтдин йоклап ята,
Мин тычкан тотып кайтам!

— Ах, ялагай-ябышкаклар,
Тычкан, имеш, кит әле —
Без каракны да тотабыз,
Мактанмыйбыз бит әле!

Карап-карап торамын да
Тагын бер карап куям,
Икесен дә ачуланып,
Бармак та янап куям:

— Ә бит мин сезне яратам,
Сез яратасыз мине.
Уртак дусың булган чакта
Дошманлашалар димә?!

## «Ертkыч»

Уйнап йөри
Нәни песи,
Чынлап баксаң,
Бәби песи.

Нарасый шул,
Бик бәләкәй.
Кайдан чыкты
Бу бала, әй! —

Килә маэмай —
Бозау хәтле,
Башкайлары
Кызау хәтле!

Дугаланып
Басты песи,
Авызын зур
Ачты песи.

Гайрәт чәчте,
Усалланды.
Бозау-маэмай
Узалмады.

Кире сызды
Шома гына...
Песи һаман
Шунда гына —

Дугаланып
Баскан көе,
Авызын зур
Ачкан көе —

Тураерга
Чамасы юк,
Кузгалырга
Чарасы юк...

Аңга килгәч
Йомшап төште —
Тими тора
Тешкә теше...

...Маэмай кайта!
«Котылдым, дип,
Алды ерткыч
Котымны...» дип.

## БРЯНСКИДА СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Ленин премиясе, СССР дәүләт премияләре лауреаты, күренекле шагыйрь һәм публицист, «Советский Союз» журналының баш редакторы Николай Грибачев житәкчелегендәге язучылар бригадасы Брянск өлкәсендә совет әдәбияты көннәре үткәрде. Әдәбият бәйрәме Брянск өлкәсенең фашистлардан азат ителүенә 30 ел, Ф. И. Тютчевның тууына 170 ел тулуга багышлап уздырылды. Мәскәү, Ленинград, Казан, Ярославль, Ставрополь һәм Брянск язучылары өлкәнең тормышы, тугызынчы бишьеллыкның хәлиткеч елында Брянск хезмәт ияләре ирешкән уңышлар белән таныштылар. Дятьково хрусталь заводында, «Дормаш» машиналар төзү заводында, Фокино цемент заводында, уку йортларында, культура сарайларында, колхозчылар алдында чыгышлар ясадылар.

Брянск жирендә туып-үскән күренекле шагыйрь Федор Иванович Тютчев музее урнашкан Овстуг поселогында ун мең кешелек шигъри митинг үткәрелде.

Язучылар бригадасы, атаклы Партизаннар аланында булып, сугышта һәлак булган партизаннар һәйкәл-монументына, машина йөртүчеләр һәйкәл-монументына чәчәк бәйләмнәре салдылар. Партизан аланында язучыларны партизан-ветераннар каршылап, данлы көннәрнең истәлекләре — землянкалар, сугыш барган урыннар белән таныштырдылар.

Соңыннан КПССның Брянск өлкә комитеты беренче секретаре М. К. Крахмалев язучыларны кабул итте, өлкәнең Бөек Ватан сугышыннан соң ирешкән уңышлары турында сөйләде, язучыларның сорауларына җавап бирде.

Бу зур әдәби бәйрәмгә Казаннан Гариф Ахунов катнашты.

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Татарстан язучылары союзы идарәсенең чираттагы киңәйтелгән утырышында «Казан утлары» журналының 1—6 саннарында чыккан әсәрләр турында фикер алышу үткәрелде.

Проза әсәрләре турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Ф. Ганиева ясады. Ул башлыча журналда басылып чыккан ике зур әсәргә — Э. Касыймовның «Һаваларда тургай» романына һәм Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестена тукталды.

Э. Касыймов романында әсәрнең нигезе булырдай житди вакыйга — эзлекле логик үсеш юк,— диде докладчы.— сюжеты таркау, өзек-өзек кисәкләр бер-берсенә ялганмый, ул кисәкләрдә сурәтләнгән вакыйгалар геройлар язмышында хәлиткеч роль уйнамый. Хәтта кайвакытта вакыйга үзе күренми, автор яки әсәрнең герое сүзләренә генә ышанырга мәжбүр булабыз. Әйтик, Госманның Зөфәргә, директорга, җыелыштагыларга сөйләгәннәре тасвирлауны алыштыра. Геройлар арасындагы мөнәсәбәтләр дә тиешенчә тыгыз түгел. Күп кенә эпизодлар тәмамланып та бетми. Госманның туган авылында әнисенең амәнәтен үтәү вакыйгасы моңа мисал була ала.

Шулай ук Госман житәкчелек иткән лабораториянең завод тормышындагы роле дә язучы игътибарыннан читтә калган. Менә шундый кимчелекләр романның төп герое Госман образын да зәгыйфьләндергән. Әсәрнең төп конфликты булырдай вакыйгалар өстән-өстән генә сөйләнелгәнгә Госман һәм башка геройларның характеры да йомшак булып чыккан.

Романның икенче бер герое Зөлфәгә бәйле вакыйгалар да — мотивлары булмаган мөнәсәбәтләр, максатсыз, эшсез аптырап йөрүләр генә. Зөлфәнең Зәбир дигән егет турында уйланып йөрүе, Фуаттан качуы, очрашырга туры килсә, кирегә борылуы, Асиядан гел көнләп өч нарат арасында адашып йөрүе укучының кәефен ала башлый. Аның мәхәббәт дип өзгәләнүләре стакандагы давылны хәтерләтә. Асия образы да әсәрдә куелырга тиешле проблемаларга бик үк бәйләнеп бетми. Өстәвенә, алар икесе дә татар хатын-кызларына хас булган тыйнаклык, нәфислек, ягымлылык кебек матур сыйфатларга ия түгелләр.

Гомумән алганда, «Һаваларда тургай» тәмамланган бер бөтен әсәр булып житмәгән, анда авторның үзе сурәтләгән вакыйгаларга да, геройларга да мөнәсәбәте аңлашылмый. Шуңа күрә укучы өчен дә әсәрдә нәрсә яхшы, нәрсә яман, кем хаклы, кем хаксыз икәне ачык түгел.

Байтак вакыт химиклар арасында яшәгән язучының химия өлкәсендә эшләүче кешеләрне ныклап өйрәнмәве, аларның характерын калку итеп бирә алмавы әдәби осталыгын арттыру ягыннан житәрлек эшләмәвен күрсәтә.

«Канатлар талмасын» — яшь авторның беренче зур күләмле әсәре. Әйтергә кирәк, бу повесть — 1973 елның беренче яртысында дөнья күргән уңышлы әсәр.

Автор авыл хуҗалыгы темасының бүгенге көн өчен халиткеч әһәмиятле ягын таба алган. Повестьта конфликт кискен, геройлар мөнәсәбәте тыгыз. Тормышның төрле каршылыклары белән көрәштә аларның характерлары ныгый. Геройларның үз йөзе, үз язмышы бар. Менә шуңа күрә дә аларның һәркайсы — Рәшат Галиевич та, Рамай да, Шәкүр белән Заман картлар да, Кәрам да, Һәнүз, Дамирлар да, Сәвия, Сакинә һ. б. геройлар да — истә калырлык образ булып житлеккән.

Әсәрдә бәхәс уятырлык вакыйгалар һәм мөнәсәбәтләр дә юк түгел. Мәсәлән, Рамайның хуҗалык итүдәге кайбер алымнары, Рамайның Мәрьям белән, Сәвиянең Дамир белән мөнәсәбәте. Әлбәттә, автор повестьны китап итеп чыгарганда, боларны истә тотар дип ышанырга кирәк.

Аннары докладчы Р. Батуллинның «Бер юлда», М. Галиевнең «Ана», С. Сөләймановаңың «Шаһина» хикәяләренә тукталды, алардагы уңышлы һәм кимчелекле якларны күрсәтте.

Тәнкыйтьче **Н. Хисамов** үзенең докладын журналда басылган поэзия әсәрләренә багышлады.

Беренче яртыеллыкта төрле жанрдагы шигъри әсәрләре белән журналга 25 автор катнашкан. Басылган әсәрләренең барысы да диярлек поэтик процессның тиешле югарылыкта дәвам итүен сөйли. С. Хәким КамАЗ темасын үзенчә һәм тирән итеп яктырта. Аның шигырьләренә шушы жирнең хуҗасы булган халкыбыз образы килеп керә. Шагыйрь туган жирдәге зур вакыйгаларга, бөек үзгәрешкә шушы образ аша карый. Авыл темасы да аның әсәрләрендә халык язмышы аша яктыртыла.

Халык һәм тарих, туган тел һәм шигърият мәсьәләләре Ш. Галиевнең «Уй елгасы», Зөлфәтнең «Каюм» исемле шигырьләрендә дә поэтик тирәнлек белән куела.

Г. Афзал шигырьләрендә исә ижтимагый тормышның, дөньяның хәтәр, борчулы күренешләрен тирән кичереп, образлы, үткен формада гәүдәләндерү бар. Д. Сирайның «Кеше турында жыр» исемле әсәрендә дә шигъри фикерләү шактый тирән.

Р. Хариснең «Житмеш икенче ел икмәге» исемле поэмасында кеше һәм табигать темасының үзенчәлекле гәүдәләнешен күрәбез.

Очерклар турында сөйләү өчен сүз язучы **Д. Зөбәерова**га бирелде.

Докладчы иң элек журналда ярты ел эчендә төрле темага язылган, төрле проблемалар күтәргән егермедән артык очерк басылып чыгуын уңай күренеш дип билгеләп үтте.

Нинди тәэсир калдыра соң алар?

М. Зарипов Түбән Кама каласының бүгенгесен, киләчәген сурәтләгән «Тылсым кочә» һәм КамАЗ турында «Баһадир дөньяга килә» дигән очеркларын бастырып чыгарды. Бу очеркларның икесе дә материалны яхшы өйрәнеп, кызыклы итеп, зур эрудиция белән язылган.

«Казан утлары» журналы белән «Новый мир» журналы арасында ижади элемтә урнаштырылган. 6 санда шушы элемтәнең беренче жимеше — Ф. Видрашкуның «Вахта» исемле зур очеркы бирелгән. Анда сүз КамАЗны әйдәп баручы житәкче кадрлар турында бара. Баһадир төзелешнең кыю комиссары Рәис Беляевнең унбер бала табып үстергән ана улы, авыл малае булуын да, элеграк комсомол житәкчесе булып эшләвен дә, холкы-фигыленең ниндилеген дә очерктан укып тулы беләсең. Ул тынгысыз-хәрәкәтчән, жор сүзле, вакыты белән романтик та була белә. Укучы бу очеркта КамАЗ төзелеше начальнигының беренче урынбасары Е. Батенчук һ. б. лар белән дә якыннан таныша.

Ш. Гарифуллинның «Хәмит батыр һәм аның балалары» исемле уңышлы очеркы да КамАЗда эшләүче кешеләрнең тормышын, катлаулы язмышларын сурәтли. Күренекле сәнгать эшлеклеләре Ф. Ильская, Айрат Арсланов, Сара Садыйкова, М. Хәмзин турындагы очерклар да матур тәэсир калдыра.

М. Хәмитовның «Егет булып йөрер чаклар иде» исемле бай эчтәлекле очеркында Алабуга педагогия институтының өлкән укытучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны, Дан орденнарының тулы кавалеры Рифгат Гайнуллин сурәтләнә. Очеркның язылышы салмак агымлы елганы хәтерләтә. Ярларга чайпалмый, шауламый әкрен генә ага да ага. Бу — Хәмитовның үзенә хас бер алымы.

М. Вәлиевнең «Америкага сәяхәт», В. Гудкованың «Гомер буе укытучы», М. Насыйбуллинның «Тормыш өйрәтә» очерклары да, кайбер кимчелекләре булуга карамастан, танып-белү әһәмиятенә ияләр.

Әмма шунысы кызганыч: беренче яртыеллыкта журналда бүгенге авыл хуҗалыгы проблемаларын яктырткан, колхоз һәм совхоз кешеләрен сурәтләгән очерклар бөтенләй диярлек бирелмәгән.

Филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче **Ф. Хатипов** журналдагы тәнкыйть мәкаләләре турында сөйләде.

Журналда бүгенге проза турында дискуссия ачылу, — диде докладчы, — бүгенге әдәбиятыбызда мөһим күренешләрнең берсе. Узган ел Р. Мостафин күзгатып жибәргән фикер алышуга быел И. Нуруллин, М. Вәлиев, Ф. Мусин, өлкән әдибебез Ф. Хөсни кушылып, үз тавышларын, уй-теләкләрен ишеттерделәр. Аларның чыгышларында проза үсеше турында ихлас кайгыртучанлык белән олы таләпчәнлек аралаша.

Соңгы елларда Татарстан язучылары союзы идарәсендә «Казан утлары»нда басылган әсәрләргә күзәтүләр оештыру популярлашып бара. Бу сөйләшүләр бүгенге әдәбиятның мөһим тенденцияләре турында фикер уртаклашу төсен ала. Әдәби күренешләргә карата жәмәгатьчелек игътибары туплана. 1973 елда шул сөйләшүләрдә ясалган докладлар нигезендә журналда Ш. Бикчуринның «Очеркның асылы», Ф. Урманчеевның «Бүгенге тән-

кыйть мәсьәләләре», Роберт Әхмәтҗанов-ның «Заман утлары» дигән кызыклы, шактый тирән эчтәлекле мәкаләләре басылып чыкты. Аларның берсе дә гади күзәтү генә булып калмаганнар.

Ярты ел эчендә журналда басылган мәкаләләр безнең әдәбиятта әдәби-теоретик эзләнүләр интенсив рәвештә алып барылганлыгын күрсәтәләр.

Ф. Хатипов үзенең докладында журналда басылган мәкаләләрне анализлап кына калмады, аерым авторларның кайбер фикерләре белән бәхәскә дә керде, үз тәкъдимнәрен дә белдерде.

Соңыннан утырышка катнашучылар докладларга һәм журнал редакциясе, редколлегиясе эшенә карата фикерләрен әйттеләр.

Журналның редколлегия члены **М. Әмир** докладчы Ф. Ганиеваның Э. Касыймов романына карата әйткән тәнкыйть сүзләре белән килешүен, тик докладның роман кебек үк озын, ялыктыргыч булуын, фикерләрне җыйнап бирә белмәвен әйтте. Шулай ук ул Х. Хәйруллин повестена карата, докладчы кебек үк, уңай бәя бирде. Повестьта чын тормыш бар, әдәби яктан да әйбәт эшләнгән. Әсәрдә күтәрелгән проблемалар турында махсус сөйләшергә кирәк, диде.

Аңардан соң сүз алган **Г. Бәширов** мондый утырышларга киң җәмәгатьчелекне тартырга кирәклеген әйтте, докладларда редакциянең авторлар белән эшләү мәсьәләсе дә куелырга тиеш, диде.

Казан педагогия институты доценты тәнкыйтьче **Ш. Әхмәдуллин** үзенең чыгышында редакциянең оештыру эшләренә уңай бәя бирде. Журнал редакциясенең эшен тагы да яхшырту буенча үзенең тәкъдимнәрен әйтте.

1973 елда,— диде журналның баш редакторы **Г. Ахунов**,— редакциягә егермедән артык зур күләмле әсәр керде. Шуларның унбише кабат эшкәртелү өчен авторларына кайтарылды. Җидесе басылып чыгачак. Әмма алар арасында бүгенге көнне сурәтләгән заманыбыз кешеләренә хас сыйфатларны, катлаулы мөнәсәбәтләрне гәүдәләндергән әсәрләр аз. Моның сәбәбе шул: бүгенге тормышны житди өйрәнмибез, кайчандыр күргән хәлләргә, баштан узган вакыйгаларга таянып кына иҗат итәбез.

Ә Э. Касыймовның «Һаваларда тургай» романын дөньяга чыгаруга редакция һәм редколлегия анлы рәвештә барды. Моның төп сәбәбе — республикабызның йөзен күрсәтердәй әсәрләрнең булмавы. Хезмәт кешесенә багышланган әсәрләрнең булмавы. Укучыларыбызның әдәби-эстетик зәвыклары зур, җәмәгатьчелек романга үзе бәя бирсен, дидек. Г. Ахунов киләсе елда «Әдәби тел мәсьәләләре» һәм «Язучының иҗат лабораториясеннән» дигән яңа бүлекләр ачылачагын белдерде.

Татарстан язучыларының VIII съезд трибунасы да әдәби хуҗалыгыбызны барлауда, осталыкны күтәрүдә ярдәм итәр, дип ышанабыз, диде.

Язучылар союзы идарәсе председателе З. Нури йомгаклау чыгышында докладларның һәрберсенә уңай бәя бирде, журналның эшен тагы да яхшырту буенча редакция, редколлегия, идарә һәм язучылар алдында торган бурычларны сөйләде.

## В. В. МАЯКОВСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАП

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советының киңәйтелгән утырышында бөек рус совет шагыйре Владимир Владимирович Маяковскийның тууына 80 ел тулуга карата фәнни хезмәткәр З. Рәмиев докладе тыңланды. Докладчы В. Маяковский иҗатының татар шагыйрьләренә тәэсире, трибун шагыйрь әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү проблемаларына тукталды.

## ШАМУН ФИДАИНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Оренбург шәһәренең «Россия» культура сараенда комсомол шагыйрь, Башкортстанда һәм Оренбург өлкәсендә Совет властен урнаштыруда актив катнашкан Шамун Фидаиның (Касыйм Шакирҗанов) тууына 70 ел тулу уңае белән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.


Хөсәен Ямашев исемендәге китапханә каршындагы әдәби-иҗат түгәрәге җитәкчесе Ш. Шакиров шагыйрьнең иҗаты һәм революцион эшчәнлеге турында доклад ясады. РСФСРның атказанган артисты В. Фатихов, өч сугыш ветераны, персональ пенсионер Ф. Солтанов, өлкән укытучы Г. Хәсәнова Ш. Фидаи турында истәлекләр сөйләделәр. Соңыннан культура сарае каршындагы татар үзешчән сәнгать коллективы зур концерт бирде.

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕН ЙӨРТКӘН ТЕПЛОХОДТА


Габдулла Тукай исемендәге экскурсион теплоход Уфа — Мәскәү арасында йөри. Агыйдел — Кама — Идел буйлап, Г. Тукай теплоходына утырып, ял итүчеләр һәр вакыт күп. Теплоход заманча, матур итеп бизәлгән.

Теплоход юл уңаенда, әлбәттә, Казан елга портында да тукталыш ясый. Шундый тукталышларның берсендә теплоход командасына һәм пассажирларга кунакка татар язучылары килде. Алар белән бергә Татар дәүләт музее вәкилләре дә бар иде. Музей хезмәткәрләре экипажга Г. Тукайның тормышын һәм иҗади эшчәнлеген сурәтләгән күргәзмә бүләк иттеләр. Язучылар исә татар әдәбиятының бүгенге торышы турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

Г. Тукай теплоходының Казан елга портына икенче бер тукталышында рәссам Җ. Булат бөек шагыйрьнең 165 x 130 см зурлыктагы портретын экипажга бүләк итте. Тантанада Казан шәһәре хезмәт ияләре, язучылар җәмәгатьчелеге катнашты.



Авыл урамы.



Урак есте.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

«Казан утлары» журналының 11 санында сез Әдип Маликовның «ЯШЬЛЕК УТРАВЫМ» дигән повестен укый башларсыз.

Бу санда Шәйхи Маннурның «АГЫМСУЛАРГА КАРАП» повестен дәвам итәбез, Әхсән Баяновның «ҺӘЙКӘЛ» драматик повестеның ахыры бирелә.

Поэзия бүлегендә Гамил Афзал, Гәрәй Рәхим, Илдар Әхсәнов шигырьләре бар.

Һәр сандагыча бу юлы да КамАЗ елъязмасын укырсыз. Малик Хәмитовның «КАБАТ КАЙТТЫ ЯШЬЛЕК» дигән очеркы да КамАЗ сәхифәләренә багышланган. Рәмзи Максудов үзенең очеркында бүгенге авыл кешеләренең кызыклы характерларын, эш үрнәкләрен сурәтли.

Күптән түгел редакциябезгә запастагы полковник Самсон Закладныйдан хат килде. Ул Сталинград фронтында күренекле татар язучысы Гадел Кутуй белән бергә сугышкан көннәре турында язган. Без аның солдат Кутуй турындагы истәлеген журналыбызның шушы санына урнаштырдык.

Сез бу санда культурабыз тарихына материаллар, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, яңа китапларга рецензияләр укырсыз.

Хөрмәтле укучыбыз! 1974 ел өчен «Казан утлары» журналына язылуны да исегезгә төшереп үтәбез. Сентябрь аеннан бирле илебезнең барлык почта бүлекләрендә газета-журналларга язылу бара. Сез «Казан утлары» журналын да үзегез яшәгән почта бүлегендә яздыра аласыз. Журналның индексы 73210, бәясе — бер елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210